


# Казан утлары

10.1983



# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
СОЮЗЫ ОРГАНЫ

10

1983

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## *Бу санда*

**Р. ТӨХФӘТУЛЛИН.** Тигәнәк. Повесть . . . . . 3
**К. БУЛАТОВА.** Уйландыра, шушы уй яндыра. Шигырьләр . . . . . 29
**В. ТУКТАРОВА.** Кыска шигырьләр . . . . . 31
**Ә. ГАФФАР.** Бодай бөртеге һәм тегермән ташы. Роман . . . . . 33
**М. ӘГЪЛӘМОВ.** Күзгә хикмәт. Шигырьләр . . . 74
**А. ХӘСӘНОВ.** Әбием ядкаре. Повесть . . . . . 78

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Н. ӘХМӘДИЕВ.** Яшелдән кигән каен. Шигырьләр 103
**О. КӘРИМОВА.** Күгәрчен. Шигырь . . . . . 104
**И. ӘХСӘНОВ.** Дөньяда мин. Шигырь . . . . . 104
**Ф. ГАЛИЕВА.** Горурлана белэм. Шигырь . . . 104
**И. ХӨСНЕТДИНОВ.** Яшен теле күңел. Шигырь . . 105
**К. БАТЫРОВ.** Кырларымда калам. Шигырь . . . 105
**Р. РӘКЫЙПОВ.** Тал төбендә талгын су. Шигырьләр . . . . . 106
**Г. МОРАТОВ.** Йөзү. Шигырьләр . . . . . 108

**В. ЛАРИН.** Гудок. Хикәя . . . . . 111

ӘДӘБИ МИРАС

**С. СӨЛӘЙМАНОВА.** Яңавыл хатирәләре. . . . 114

ЮБИЛЕЙЛАР

**Р. ИШМОРАТ.** Яшьлегебезне сагынып . . . . 120

БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**Х. ЯКУПОВ** . . . . . 133

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫНА

**Э. МӨЭМИНОВА.** Бер остазның ике шәкерте. Очерк . . . . . 134

БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

**А. ВЕРГАЗОВ.** Гомер сагында. Очерк . . . . . 143
**М. МӘХМҮТОВ.** Тарихи бу бергәлек . . . . . 147

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**Ф. МИҢНУЛЛИН.** Реаль хәлләргә күз салыйк . . 158

ДИСКУССИЯГӘ УКУЧЫЛАР КУШЫЛА

**С. ШӘРИПОВ.** Әсәрнең ышандыру көче кирәк! 166
**Ф. ӘХМӘТШИНА.** Кайбер теләкләр . . . . . 167

БИБЛИОГРАФИЯ

**Р. ӘХМӘТ.** Урдә имәннәр . . . . . . . . . . 169

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ...

**Н. ФӘТТАХ.** Яшь язучының бер хикәясе . . . . 173

СӘНГАТЬ...

**М. ШИҺАПОВ.** Театр — заман көзгесе . . . . 178
**Г. ВӘЛИЕВА.** Татар келәме һәм гобелены . . . 180

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

**Җ. МИҢНУЛЛИН.** Археограф Вәли Зәбиров . . 184
**З. ШӘРӘФЕТДИНОВ.** Халыкка аң-белем бирү юлында . . . . . . . . . . . . . . . 186

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

**Г. АФЗАЛ.** Син гади... Шигырьләр . . . . . . 189

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **САЛИХ МАННАПОВ, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

Адрес редакции: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза бүлеге — 53-07-61, поэзия бүлеге — 53-07-61, тәнкыйть бүлеге — 53-07-63, сәнгать бүлеге — 53-07-63, очерклар бүлеге — 53-07-61, хатлар бүлеге — 53-07-63, корректорлар — 53-07-65, техник редактор — 53-07-65, машинисткалар — 53-07-60.

Производствога бирелде 27.07.1983 ел. Басарга кул куелды 16.09.1983 ел. ПФ 07078. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65044. Заказ Я-302. Бәясе 90 тиен.

Типография издательства Татарского обкома КПСС.
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

# Рафаил Төхфәтуллин

# ТИГӘНӘК

ПОВЕСТЬ

## I



Һай, бу тигәнәкне! Кешегә җәберен салырга гына тора. Ни арада итәкне сырып та алган. Чүпли башласаң, бармак битләрен калдырмый инде бу, маникюрны да бозып бетерер. И-и, Мәҗит, синең дә чалбар балакларың чат тигәнәк. Кара аны, ипләп кенә чүпли күр. Юкса, үзеңә балагында песи балалары тырнагын кайрый мәллә, диярләр. Сүсәрә дә кала.

— Белә ул табигать, җанкисәгем. Тәмле кура җиләген җиңел генә өзеп капмасыннар әле дип, юри үстергән ул куак тирәсенә чәнечкеле тигәнәген, зәһәр кычытканын. Сакчылар итеп.

— Авызыңны күбрәк ерсаң, берәр кылчыгы күзеңә керсен тагы. Аннары белерсең тигәнәкнең нәрсә икәнен.

— Беләм мин аны. Менә син, Тәнзилә, язга чыгу белән авылга кайтыйк, яңа сауган җылы сөт сагындым, балаларга да бик кирәк, дия башлыйсың. Уйлаганың бармы: язгы сөттә шушы тигәнәкнең күпме өлеше бар?

— Язын тигәнәк булмый, акыллым, әрекмәне генә була.

— Әнә шулай язга әрекмән күбрәк булсын дип, тырыша да инде ул тигәнәк. Сиңа да ябышып китә, миңа да. Сарык койрыгына да сырыша, кәҗә сакалына да. Нәтиҗәдә язын сыерга авыз тутырып күшәрлек беренче яшел азык булып, әрекмән өлгерә. Сауганда алдына әрекмән җыеп салсаң, сыер көйсезләнүне белми. Сөт яраткач, белеп тиргә син тигәнәкне, җанкисәгем.

— Белеп тиргим, акыллым. Үзәк бәгырьләремә үткәне бар ул тигәнәкнең.

— Тиргисең, ә үзең җыйган җиләгең өстенә тизрәк әрекмән яфрагы каплadың. Бик дөрес иттең. Шиңдерми, бөтен хуш исләрен саклый җиләкнең әрекмән. Башыңа да әрекмәннән эшләпә ясап киертимме соң? Кояш та сукмас, баш сызлавыңны да юып кына алыр.

— Үзеңә ясап ки дә андый эшләпәне, әйдә, таган аса башла. Чәй кайнатып алыйк. Салырга гөлҗимешен, карлыган яфрагын җыю — минем өстә. Әйләнеп килим әле мин. Нигәдер балаларның тавышы ишетелми башлады, су коенабыз дип, чоңгылга эләкмәсеннәр тагын. Бик хәтәр җирләре бар ул Ыкның.

Уллары Равил белән Камил су читендәге юеш комнан нидер коралар; эшләре шулкадәр тыгыз боларның, хәтта бер минут теле тик тормаган Камилнең дә авызыннан ләм-мим сүз чыкмый.

Тәнзилә уеннарын бозмыйм дип аларга дәшмәде. Читкәрәк китеп, башларын су өстенә үк игән талчыбык куагы төбенә килеп утырды.

Ага елга. Тын гына, сабыр гына агып килә дә шыбыр-шыбыр итеп уйнаклап ала, ул арада тынгысыз-ярсу бөтергәләнеп куя, агым ул бөтергеләрне алга куа. Ык авыр гына көрсенгәндәй итә дә тагын тыныч кына ага башлый.

Ә су төбендә күч-күч ак болытлар йөзә, тибрәнә, актарыла.

«Узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да...»

Тәнзиләнең моң гына сузып бер җырлап җибәрәсе килеп китте. Уза шул гомерләр, аккан судай уза... Ә су төбендәге ул ак болытлар узган көннәрнең хатирәләре кебек икән. Бар да алар, хатирәләр, юк та...

«Белеп тиргә син тигәнәкне».

Әй, Мәҗит!.. Уйлап әйттеңме син моны, әллә сүз җаеннан гына телеңә килдеме?

Тигәнәк... Карамалы... Ах, ул көннәр!..

## II

Килеп төшкән көнне ук ошатты ул Карамалыны. Зур авыл иде ул, кайчандыр район үзәге булган. Әллә ничә кибете, ашханәсе, көнкүреш комбинаты, больницасы... барысы да бар. Арттарак, буын-буын итеп ак һәм карага буялган биек торба күккә сузылган. Анда, текә ярлы коры елга аръягында, кирпеч заводы. Аның заводы, Тәнзилә техник булып, кирәкле кеше булып килде анда.

Шулай да, күңеленә аеруча хуш килгәне, ихтимал, биредәге Культура сарае булды бугай. Әйе, әйе... Күңелсезләнеп, ямансулап йөрергә әнә шул ягымлы йорт ирек бирмәде дә инде аңа. Юкса, нәрсә? Аларның әби теше кебек санаулы йортлар гына калган үз авылларындагы шыгырдык идәнле клубта күптән инде ямь калмады, ә шәһәрнең мәхәббәт сарайларын, затлы театрларын, шау-шулы танцы мәйданчыкларын өч ел буе һич тә үз итә алмады Тәнзилә. Ходаем, билет алып кына кер аларга, су эчәсең килсә дә, чират торып акчаңны түлә, иптәш кызларыңның итәгенә тагылып кына йөр,— юкса, озын чәчле берәр саламторханы килеп бәйләнергә генә тора.

Биредә, ичмасам, барысы да бик гади иде. Килешле генә киенгән баянчы егет, килешле генә каш сикерткәләп, татарчасын булсын, вальс көйләрен булсын, бер-бер артлы сыздыра тора, егетләр әллә ни нәзакәтләнми генә кызларны биергә бөтереп кертәләр, ул арада барысына да кызык уеннар башланып китә: «өченчесе такъ», «чыбыксыз телефон».

Тәнзиләне дә беренче чыккан көнне үк биергә чакырып кына тордылар, «чыбыксыз телефон» аша килгән мәзәк сүзләрдән рәхәтләнеп көлде ул, такъ калып, туфли үкчәләрен һич кызганмый шык-шык йөгерде. Уен да көлке, җыр да бию, ә колак яфракларын чандыр гына Мәрзизәнең калын иреннәреннән чамасын белеп кенә агылып торган кайнар пышылдаулар кытыклап-кытыклап ала. «Кем белән биегәненне белеп бие, иркәм, хөрмәтле докторыбыз Дамир Мөхтәсимович булыр бу. Әллә авылда үзенә тиң таба алмый инде, әллә үзенең кара кашларына үзе гашыйк, берәү белән дә чуалганы сизелми хәзергә».

Гәүдәгә әллә ни озын булмаса да, зур учына Тәнзиләнең бөтен биле сыеп беткән бер егет белән биеп чыккач, Мәрзизә, тегеңә ымлап, борынын җыерып куйды:

— Бер иләс-миләс нәрсә шунда. Галстук тагып алгач та, кем дип беләсең син аны? Совхозда кара эштән башы чыкканы юк.

«Кара каш... Кара эш»,— дип кабатлады да Тәнзилә тыела алмыйча көлеп җибәрде.

— Авызыңны бик ерма, иркәм, авылда да хулиганнар җитәрлек хәзер. Сиңа да ябышып өлгермәсен ул тигәнәк.

— Нинди тигәнәк, Мәрзизә?

— Кем турында сөйләп торам соң? Тигәнәк Заһир, беләсең килсә! Алай-болай үзенә дәшә күрмә тагын кушаматы белән, сынмаган сөягеңне калдырмас. Бер җене котырса... тыярлык түгел.

«Иләс-миләс... Тигәнәк... Бер җене котырса». Ходаем, шулкадәр дә куркыныч микәнни соң ул таза-нык куллы егет? Күзләре бик акыллы-тыныч карый лабаса үзенең. Ул елмаюлары бигрәк сабыйларча инде.

«Белмәгән, сынамаган ир-ат халкыннан сак була күр, кызым, каты чикләвек була бел»,— дип, әнисе тикмәгә генә әйтмәгәндер, күрәсең. Шәһәрдә укыганда ук әйтә башлаган иде, бирегә озатканда да соңгы сүзе шул булды.

Сак булырга, каты чикләвек булырга тырышты Тәнзилә. Икенче кичне, аннан соң да куркыныч егет белән бер тапкыр да биемәде, гел хөрмәтле доктор Дамир Мөхтәсимович белән әйләнде.

Ә ничәмәдер көннәр үткәч, Мәрзизә ул кичне нигәдер клубка чыкмаган иде, баянчы «дамский вальс» игълан итүгә, Тәнзилә, аны-моны уйлап тормастан, Заһир каршына килде дә басты. Менә кызның биле тагын кытыршы-нык учта, ә үзе күзләрен аяк очларыннан күтәрә алмый, шулай да сизә: каршына килеп басуга, егет купшакланыбрак киткән иреннәрен юмарт кына җәеп җибәрде дә, әле һаман да җыеп ала алганы юк. Нәрсә уйлап шулай тулган айдай яктыруы икән аның? Яхшыгамы, әллә ямангамы?..

Музыка тынуга, гадәт буенча, Тәнзилә егетне стена буйлап тезелгән урындыклар янына озатып та куярга тиеш иде. Алай итә алмады, биючеләр чуалыбрак калган арада, ялт кына тышка ук чыгып шылды.

Җәй ахыры киче салкынча иде, тәрәзәләр яктысыннан читкәрәк китүгә, Тәнзилә дөм караңгыда калды, бөтен тәне дер-дер чымырдап куйды.

— Тәнәфескә чыгарга кайчан звонок булды соң әле? Мин ишетми дә калганмын.

Аркадан алып, тез буыннарына кадәр бу юлы кайнар чымырдау узды.

— Миңа кайтырга вакыт, Заһир. Иртүк торасым бар.

— Туңгансың син, Тәнзилә. Әйдәле, йөгереп кенә кайтыйк. Хәзер җылынасың.

Бу юлы кытыршы учка Тәнзиләнең кулы беләзек тинентен сыеп бетте, клуб эчендә, аларны озату маршыдай, яңа көй яңгырады... Киттеләр йөгереп.

Музыка хәзер ишетелер-ишетелмәс кенә колакка чалына, аның каравы, лап-лоп һәм туп-туп иткән ике пар аяк тавышы тын урамда әллә кайларга яңгырый. Юк, аяк тавышлары гына түгел, кызның леп-леп типкән йөрәк тавышы да еракларга ук ишетелми микән?

— За... Заһир... Мин җылындым инде.

— Бик әйбәт, Тәнзилә. Инде менә җилкәңә моны салыйк. Бигрәк юкадан киенеп чыккансың син.

Иң өстендәге пиджактан җылы сөт исе, тагын нindидер ягымлы ис килә иде.

— Заһир, рәхмәт сиңа. Мин кайтып җиттем диярлек инде.

— Мин әле сезне дә узып китәм. Юлдашлар без.

— Ничек? Мәрзизә сезнең өйне югары очта дигән иде.

Кап-караңгыда ап-ак тешләр җемелдәп куйды.

— Әйтер ул Мәрзизә! Кеше ни димәс, үз сукмагыңа җитмәс, ди минем әни.

«Ә минем әни әйтә: белмәгән-сынамаган егет халкыннан...» — Тәнзилә тел очына килеп җиткән сүзләрне йотып калды. Анысын йотты, ә менә...

— Син һаман да кара эштәме, Заһир?— монысының теленнән ничек ычкынганын ул үзе дә сизми калды.

— Тагын дөрес информация бирмәгән сиңа Мәрзизә. Кара эштә түгел, яшел эштә мин. — Егетнең тавышы бик җитди иде.

— Нинди яшел эш ул, Заһир?

— Күз алдыңа китер... Яшел болын, яшел аланнар. Яшел үлән эчендә яшел чикерткәләр сикерешә. Яшел эшләпәңне киеп, алмачуар атка менеп аласың да, иртә таңнан кояш баеганчы, син шунда, яшеллек кочагында. Тирә-юньдә йөзләгән сөтбикә. Алар синең һәр сүзеңне аңлый, каефең ничегрәк — анысына кадәр сизенеп торалар.

«Сөйләшә белә бу. Мин — көтүче, дип кенә әйтәсе урынга, былбыл урынына сайрый. Егетләрнең юма теленә эреп китәргә торма, дип тә әйтә иде ич әни».

— Сезгә укырга туры килмәдемени, Заһир?

— Укыйм мин.

— Кичке мәктәптәме?

— Нигә кичләтеп йөрергә? Көн үзәгендә сөтбикәләр инеш буена утлыкка туктый. Корсак тиңентен суга керәләр дә, йокымсырый-мышный күши бирәләр, бер мәшәкатьләре калмый малкайларның. Мин дә тал төбенә сузылып ятам да дәреслекләремә чумам.

— Шулай экстерн укып кына аттестат алыргамыни исәп?

— Нигә экстерн? Сессияләргә барырга совхозның бер вакытта да тоткарлаганы юк. Быел менә диплом якларга тоташ ике ай түләүле ял бирәчәкләр.

— Сез институтта укыйсызмыни-и?

— Кайчандыр Бауман укыган институт студенты мин. Сигезенчедә чакта ук аның турында «Яз кошы» дигән китап укыган идем. Институт ишеген ачып керүгә, гел шул искә төшә дә тора. Батыр да кеше булган соң Бауман.

«Тиздән дипломлы белгеч булачак, ә үзе көтүче. Әллә чыннан да иләс-миләсрәк инде».

— Менә сезнең өйгә дә килеп җиттек, Тәнзилә. Тыныч йокы, тәмле төшләр!

— Рәхмәт.

Хуҗа әбигә комачауламас өчен ул үзенә урынны өй алдында гына җәеп китә дә, салкынчада юрганың башыннан ук бөркәнеп ятуга, изрәп йокыга да китә иде. Мондый рәхәт йокыда төшләрнең аеруча матурлары керә. Әмма ул төнне тиз генә йокы алмады. Әллә кайдан гына җылы сөт исе, әчкелтем-ягымлы ис килеп йөдәтте.

Иртәгесен эшкә ничек җиңел-җиңел атлап барулары, һәр очраган берәү белән бик үз итеп елмая-елмая исәнләшеп үтүләре хәтердә. Заводта үзенең кысан бүлмәсендә утыра алмады, чи кирпечләрне киптерү лапасларын әйләнде, яндыру мичләренең утын, күңеле булганчы, көйләп йөрде. Нарядлар, тагын нindидер кәгазьләр язасы бар иде, теләртеләмәс кенә бүлмәсенә кайтты. Өстәлдәге кәгазьләргә иелүгә, дыркылдап ишек ачылды. Күтәрелеп караса, каршында Мәрзизә басып тора, үз яшеннән әллә күпмегә олыгаеп киткән, иреннәре юкарып, күкселләнеп калган иде.

— Ябышып та өлгердеме үзеңә Тигәнәк? Әйттемме мин сиңа? Әйттемме! — диде ул, үзенекенә охшамаган тыркылдаулы тавыш белән.

— Нигә ябышсын, Мәрзизә? Юл уңае булгач кына бергә кайттык.

— Юл уңае! Беләбез без нинди юл уңае икәнен. Нигә өй алдында аулакта урын җәеп куйганыңны да беләбез. Җылы кочак эзләп килдеңмени монда? Килмешәк!

— Авызың ни әйткәнен колагың ишетәме соң синең, Мәрзизә?

— Дамир белән таныштырдым, шул житмәгәнмени сиңа? Ул да килмешәк, син дә... Чукынышып бетегез. Әбезнең егетләрне аздырасы булма! Ишеттеңме? Ишеттеңме дим, шәһәр сөйрәлчеге!

Мәрзизә аның башына кусәк белән тондырып чыгып китте дисәң... кулында бер нәрсә дә юк иде шикелле.

Ә чигәләр чатный, бөтен тирә-юнь аның саен караңгылана бара иде.

Шуннан соңгы көннәрнең хатирәләре дә гел караңгылы да яктылы. Кичен бик вәземләп, сеңдереп кенә яңгыр ява башлады. Тәнзилә плащын бер салды, бер киде. Юк инде... Өркеттем моны, котын алдым, дип тантана итмәсен әле Мәрзизә. Чыктан да чыланып канат салындыручылардан түгел без алай.

Клуб янында аны әлегә танышып өлгермәгән бер кыз читкәрәк дәшеп алды.

— Эзләмә син Тигәнәкне,— диде, серле генә пышылдап. — Мәрзизәдә аулак өй бүген. Шунда ул.

— Булса соң! — Ишектән Дамир чыгып килә иде, Тәнзилә булдыра алганча яктырак елмаеп, аның каршына атлады.

Биегәндә дә гел елмаерга тырышты ул, ә үзенең үксеп-үксеп елыйсы килә иде. Түзә алмады, кеше күзенә бик чалынмаска тырышып, кайтырга чыкты. Яңгыр инде туктаса да, аяк асты бик тайгак, никадәр ашыкмасын, саграк атламый булмый иде.

— Менә моннан, чирәмнән кайтыйк, Тәнзилә.

Заһир билennән алып өлгермәсә, Тәнзилә, тайгаклап китеп, чалкан ук барып төшәсе иде.

— Уф, котымны алдың, Заһир. Ниме соң... Аулак өйдә күңелле булдымы?

— Нинди аулак өй турында сүз?

— Син махсус чакырылган аулак өй турында.

— Кызык. Махсус чакырылганмын, үзем генә берни белмим.

Тәнзиләнең Заһир кулын алып ташларга дип сузылган кулы җылыдымсу уч эчендә калды.

— Заһир, озатма син мине. Озатма моннан соң бер вакытта да! Яме? Кирәкми...

Заһир билдән кулын алды. Ул урын сап-салкын булып калды.

— Ябышма, тигәнәк күк, дисеңме?

— Ой! Юк-юк! Нигә алай дим? Алай димим. Юк.

— Димәсәң, белеп тор: миңа кайчак шулай бабам кушаматы белән Тигәнәк дип тә әйтәләр.

— Бабаңның кушаматында синең ни катнашың бар? Нигә инде...

— Белмим, ни катнашым бардыр... Ә менә әтигә бер вакытта да алай димиләр иде. Сугыш инвалиды иде әти, бик сызланып яшәде. Ямьсез сүз белән күңелен дә җәрәхәтли күрмик, дигәннәрдер инде авылдашлар. Дөнья куйганына унынчы ел хәзер.

Лыштыр-лычтыр сүзсез генә атладылар.

— Бабайга андый кушамат тагылуның тарихы кызык кына. Сугыш елларында колхоз председателе булган бабай. Җитмешкә җитеп килүче карт. Бервакыт шулай районнанмы, шәһәрдәнме килгән бер вәкил белән басуларны карарга чыкканнар. Авылдан ерак түгел кысыр калган җир буйлап үтәләр болар. Кысыр җирне алабута да билчән, әрем дә тигәнәк баса инде. Басу тулы казлар икән. «Нәрсә чәчтегез монда? Нигә аны казлардан таптатасыз? Штраф салырга кирәк каз хуҗаларына»,— дип гайрәт ора икән вәкил. «Тигәнәк басуы бу, иптәш, казлар өчен махсус үстерәбез. Үлеп тә ярата тигәнәкне казлар, моны үтеп, бодай басуына да кереп йөдәтмиләр»,— дигән бабай, күзен дә йом-

мыйча. Анысы, «махсус үстерәбез» дигәнгә ышанып тормагандыр инде вәкил, шулай да, бер җыелышта сөйләгән: «Әнә, Габбасов хәтта тигәнәкне дә ничек оста файдалана белә, казлар симертә тигәнәклектә, үрнәк алыгыз»,— ди икән. Шулай тагылган бабайга кушамат. Ә казларның тигәнәк яратуы чыннан да дөрес. Кайберәүләргә бит кешедән көләргә генә булсын. Ярар, Тәнзилә, хуш! Моннан соң озатмам. Урамның әнә теге ягыннан, сиңа күренми генә кайтырмын. Анысына рөхсәтме?

Шуннан соңгы кичләрдә ялгыз да, икесе урамның ике ягыннан да кайтырга туры килмәде. Тоташ яңгырлар башланды, тез тиңентен былчырак ерып клубка чыгу түгел, төшке ашка да кайтып йөрешле түгел иде. Таш юлдан гына ашханәгә барып килсәң ярар иде дә... анда Мәрзизә эшли, ул зәңки пешергән аш ничек тамагыңнан үтсен?

Озын кичләрне кыскартырга эше дә табылды. Киткәндә әнисе: «Үзеңә пирчәтке бәйләп киярсең, бармакларың да бишинә тотудан бизмәсен»,— дип, бер кыркым язгы йон тыккан иде. Кич буе йон яза, йон эрли хәзер Тәнзилә. «Үзеңә пирчәтке...» И әнием, белеп торасың, бер генә түгел, ике пар өр-яңа перчәткәм бар ласа. Үзеңә дигәнең, берәрсенә бүләккә диюең түгел микән? Берәрсенә... Заһирга бәйләп бирсәң, нишләр? Көнозын диярлек яңгыр коеп торса да, кетүләрнең әле кергәне юк. Кыендыр хәзер синең яшел эшең, кулларың да бик туңадыр.

Ике йомгак җеп инде әзер. Аның зур кулларына җитеп бетәр микән бу? Булгач-булгач, мулдан булсын, өч җаптан катар җебен, май эчендә йөрсен әле егетнең кулы.

Иртән эшкә киткәндә, сумкасына бер гөнҗәлә йон да тыкты. Әбәткә кайтып йөрисе булмагач, төшке вакыты барыбер бушка сафсата сатып үтә, шунда йон яза торыр.

Их, алмаган гына булсачы шул төргәкне...

Төшлектә тамак ялгап алгач, алдына газета җәеп, йон язарга утырды. Бер учлам язды, икенче учламны башлауга, күзенә чүп керде. Йоннан чәчрәде, ахры.

Башта әллә ни игътибар итмәде, күз яше белән чыгар әле дип, кульяулыгын чылата-чылата эшләвен белде. Юк, чыкмый, аның саен ачыттыра, үтереп тә кыра. Кызларга да күрсәтеп карады, күренми чүбе, эчкә киткәнче, бар, врачка йөгер, диделәр.

— Ни булды, Тәнзилә? — дип, сагаюлы-шүрләүле каршы алган иде аны Дамир Мөхтәсимович, «күзгә чүп керде лә» дигәч, авызын ерып җибәрде.

— Чүт кенә чирләп тә алмый, ичмасам, дигән җүләр уй да килә иде бу колыгызның башына. Бер караганда, бик эгоистик, антигуманистик уй, әлбәттә. Икенче караганда... егет кеше күңеленә ниләр килмәс. Окулист түгел мин түгелен, андый штат бездә буш тора хәзергә. Әмма мондый чибәр күзләрне дәвалау үзе бер бәхет...

Дамир шулай сөйләнә-сөйләнә, салкын бармаклары белән күзне авырттырып бетерде, салкын дару тамызды.

— Булды шикелле бу, Тәнзилә. Авыртырга хакы юк бу матур күзләрнең. Хәер, авыртса, суза күрмә, кил. Кая, җил тимәсен, бәйлик. Бүген дә, иртәгә дә эшкә чыгып йөрмә. Менә справка.

Ләкин күзнең авыртуы аз гына да басылмады. Хуҗа әби өйдә юк иде. Бая Дамир бәйләгән ак бинтны чишеп, көзгедән караса... үз-үзеннән куркып китте. Кысылыбрак калган уң күзе чи кызыл, кабаклар шешемсерәп, пешкәкләп беткән. Ул ачыта, әрни, чишмәдәй яшь ага. Ходаем, нәрсә инде бу? Сукыр калсаң, нихәлләр итәрсең...

Ашыга-ашыга киенә башлады. Ярамый болай. Тизрәк район больницасына барырга, машина очрамаса, җәяү йөгерергә, анда да булмаса, шәһәргә үк китәргә кирәк. Бу дөньяга якты күз белән нибары унтугыз ел гына карап калырга язмасын. Тизрәк, тизрәк!

— Мөмкин микән бу өйгә?

Тәнзилә сискәнеп китте. Ике як ишек яңагын бер итеп, бусагада Заһир басып тора, елмаямы ул, әллә бик ачулымы — яшь аралаш аерып та булмый иде.

— Тәнзилә, күзең авырта дип ишеттем, әйдә, врачка барабыз.

— Мин анда булдым инде. Пычагым да эшли алмады Дамир. Районга барырга кирәк, күз врачына. Машина табып булмас микән, Заһир?

— Бар минем машинам. Әйдә, киттек.

Капка төбендә иярле ат тора иде. Бәйдә-мазарда түгел, башын горур гына тотып, тик басып тора.

— Әйдә, Тәнзилә, уң аягың белән минем учка бас та, менеп атлан. Ияр алдына мин дә сыям әле, миңа тотынырсың. «Әһ» дигәнче илтеп җиткерә безне Алмачуар.

— Заһир, китче инде... Кеше көлдермик. Үзең генә атлан да, мин яныңнан барам. Авылны чыккач, бәлки алмаш-тилмәш атланырбыз.

— Алай да була. Только син күзләреңне йом, яше әрәмгә акмасын.

Киттеләр. Заһир аны җитәкләп алды. Артларыннан шак-шык Алмачуар атлый, җылы сулышы җилкә чокырын кытыклый. Атның муенына кыңгырау асылганмы, әллә йөгәне шөлдерләме — зың-зың килеп бара.

— Заһир, авылны чыктыкмы әле?

— Ачма, ачма күзеңне. Башта менә бу өйгә кереп чыгыйк, аннары күз күрер.

— Күрә генә күрсен инде. — Тәнзилә елмаерга тырышты.

— Күрәә, күрер. Ике дә уйлама.

Ишектән керүгә, борынга мең чәчәкле болын исе килеп бәрелде. «Өйгә дигәне... берәр печән сарае мәллә. Ходаем, үзең саклый күр!»

— Әни! Тәнзиләнең күзенә чүп кергән. Карый алмассыңмикән?

Тәнзилә яшьле күз керфекләре аша ак пәрдәле тәрәзә шәйләде. «Үз өйләренә алып кайткан ич бу иләс-миләс. Әни ди бит әнә».

— Хәзер карыйбыз аны. Кулымны гына юыйм да.

«Карыйбыз... Врач бер нишләтә алмаганны. Әллә чыгып йөгерергә инде? Район больницасы ябылганчы, тизрәк барып җитәсе иде».

Почмак яктан тәбәнәгрәк кенә буйлы бер әби чыкты. Әллә ак халат киеп алган, әллә күлмәге аклыданмы?

— Әйдә, кызым, менә монда, тәрәзә каршына утыр әле.

Әби йомшак кына итеп аның ике чигәсеннән тотып алды. Тәнзиләнең бөтен тәнен нечкә генә дерелдәү баскан иде. Әллә шүрләү, әллә туңу, әллә сызлану дерелдәве. Гаҗәп, чигәләренә әбинең җылы кулы тиюе булды, дерелдәү шунда ук бетте. Менә маңгайга, бөтенләй янәшәдә генә, әбинең җылы сулышы бәрелде, авырткан күз кабагын аз гына кытыршы, дымсу-җылы бер нәрсә сак кына айкап узды.

— Булды бу, кызым.

Тәнзилә күзләрен чет-чет ачып йомгалады. Бер бөртек тә авыртмый! Бөтен дөньясы яктырып-нурланып калган. Ак пәрдәле тәрәзә өсләрен бизәгән кипкән үлән, чәчәк көлтәчекләре өйгә җәйге нур бөрки, әбинең... юк, әби дип әйтерлек түгел әле ул, вак-вак зәңгәр бөрчекле ак күлмәкле апаның күз кырыйларындагы һәр җыерчыгы нурлы, хәтта Заһир кулындагы кап-кара юеш бияләй дә нур чәчә кебек иде.

— Апа җаным, ни рәхмәтләр генә әйтим сиңа. Мең-мең игелекләр яусын, апа бәгырем!

— Тигәнәк кылчыгы кергән күзеңә. Менә. Ярый әле вакытында килгәнсең, кан савып өлгерсә, тел дә ала алмас иде аннары.

Тел дә ала алмас иде... Бу сүзләрнең мәгънәсен ул чакта бөтенләй аңламады Тәнзилә, ташыган шатлыгына күмелеп, ул сүзләрне колагына да элмәде. Әлсә дә, белмим, шунда ук аңлар иде микән?

Күз алмасына эчкә үк кереп ябышкан хәтәр тигәнәк кылчыгын тел очына эләктереп алган, шушы ысул белән күпләрне кеп-кечкенә чүп кыяфәтендәге олы бәладән йолып алган апа икән ич ул Заһирның анисе. Күздән чүп алу гына түгел, тайган буыннарны да бик ипле урынына утырта, ул биргән шифалы үлән, чәчәк төнәтмәләре дә күп сырхаусызлауларга бик килешә, шулар белән бөтен тирә-юньгә мәшһүр Тайбә апа икән ич ул.

Боларны Тәнзилә шул көнне үк ишетеп белде белүен. Белсә дә, әллә ни шаккатмады. «Халык медицинасы» дигән төшенчә әле тиешенчә гамәлгә кермәгән, аның урынына, «им-томчы», «өшкерүче-төкерүче» дигән сүзләр өстенлек итә иде шул әле ул елларда. Аның чын мәгънәсен Тәнзилә дистә чамасы еллар үткәч, анда да гыйбрәтле бер хәлгә тап булгач кына белде, теге чактагы үз хәленә шунда гына ахыргача төшенеп җитте.

## III

Куак артында зур корылмалар торгызып уйнаган «төзүчеләр» арасында бәхәс чыкты ахры, — шаулаша башладылар. Камиле ярсып-ярсып кычкыра, «чәрелдәмә сәнә!» — ди аңа каршы Равиле. «Син үзең чәрелдисең» — ди тегесе тагы да чәрелдәбрәк.

Тәнзилә, торып, балаларга күз салды да кире утырды. Үз бәхәсләрен үзләре хәл итүдән дә хәерлесе юк. Алай дигән белән дә, чәкәләшеп китеп, суга мәтәлмәсеннәр тагын. Юк, хәлләре андыйга ук барып җитми шикелле. Әнә, бер-беренә аркалары белән борылып казынып маташтылар да, яңадан уйнарга керештеләр. Гөр-гөр сөйләшә дә башладылар.

Гомерләр диген... Тәнзилә үзе өч малай артыннан бердәнбер кыз булгангамы, абыйлары белән аз гына сүзгә килешсә дә, тизрәк анисе янына йөгерер иде. Бик ярата иде анисе канаты астына сыенырга. Артыграк та ярата иде бугай. Әни куены, әни сүзе... Бик, бик кирәк тә ул, ә кайчак... Әни сүзенә колак салып, үзеңчә хәл итү дә кирәк булгалый икән....

Ә елга ага да ага. Су төбендәге ак болытлар тибрәнә-тибрәнә дә ишелеп-ишелеп актарыла башлый.

Бер хатирә икенчесен актарып чыгара.

Сигезенчегә күрше авылга йөреп укый башлагач, мәктәпкә яңа укытучы килде. Әхтәм Харрасович. Географиядән керә иде. Әйбәт укытамы, педагоглык осталыгы ни дәрәҗәдәрәк — анысын ул чакта кайдан аерасың? Әмма шунысы һич онытырлык түгел: инде дә чибәр, инде дә ягымлы абый иде ул. Озын гына зифа буй, эре бөдрәле куе кара чәчләр. Аз гына яшькелткә тартым матур коңгырт күзләре гел көлемсерәүле. Шулай көлемсерәп кенә килеп керер иде дә, бөтен классны авызына каратыр иде. Дәрес сөйләүләре белән дип әйтеп булмастыр, алары әллә ни истә дә калмаган, кергән саен берәр мәзәк, берәр мавыктыргыч вакыйга сөйләми калмый, шунысы белән әсир итә иде классны.

Көннәрдән бер көнне, дәресләрен көтеп ала торган укытучылары мәктәпкә килмәде. Башта авырый диделәр, аннан авылдан ук юкка чыгуы беленде. Тагы да берәр көннән соң, шул матур абый турында ифрат ямьсез сүзләр ишетелә башлады. «Немецларда пленда булган икән...». «Ике җирдә ике хатыны, балалары бар икән, шуларга алимент түләүдән качып йөрүе икән». «Берсе дә дөрес түгел боларның, кызлар, нахак сүзләргә түзә алмыйча качкан ул».

Ни булса да булды, үсмер күңелләрдә чуалчык эзләр сызып калдырды да бу кеше, юкка да чыкты.
Күп җәйләр-кышлар үткәч, әле моннан берәр генә ел элек, Тәнзиләнең ике малаен ияртеп, авылга кунакка кайтып барышы иде. Автобус китәргә әле шактый вакыт бар. «Әни, әнә тегендә морожный саталар»,— диде Камиле, күзләрен очлайтып. «Кеше дә күп түгел»,— диде, бик исе китмәгәнгә сабышып Равиле. Камилнең ангинасы күзгала күрмәсен тагын, дип эчтән шүрләсә дә, Тәнзилә йөз чытмый гына вак акча чыгарды, үзе сумка, чемоданнары янында утырып калды. Балаларның күздән югалуы булды, ашыгып йөреп машина астына эләкмәсеннәр тагын болар, дигән уй тагын эчтә кыбырсый башлады. Ул арада, болай да пошаман күңелне отыры әсәрләп, үзенә таба төбәлгән сәер оер карашны тоеп алды. Бөтен тәне белән сизде моны, гамьсезсабыр булырга тырышып, як-ягына каранды, тик сәер карашның иясен шәйли алмады. Үзен шәйләп булмый, ә караш вокзал тулы халык арасыннан җанына үтәрдәй итеп бораулый бирә... Балалар да һаман күренми.
«Ник чәнчелеп китми чемоданнары, тизрәк эзләп табасы иде сабыйларны. Хәерлегә түгелдер бу».
Тәнзилә урынынннан сикереп торды, каушап-кабаланып атлаудан туфли үкчәләре кыеш-мыеш килде. Шунда аңа дәштеләр:
— Гафу итегез, сез Мәрданшина бит?
Аның каршында юантык кына гәүдәле, өлкән яшьтәге берәү басып тора: чал чигәсе купшы гына бөдрәләнеп торса да, баш түбәсе инде пеләшләнеп бетә язган, күзләре... бер күзе аңа көлемсерәп карый, ә икенче күзе бөтенләй җансыз-өнсез — аның кай тарафка төбәлгәнен дә белмәссең... Теге вакыттагы чибәр ир-егет белән уртаклыгы калмаган да диярлек үзенең, шулай да Тәнзилә аны таныды. Таныды, ә күңелнең ышанып бетәсе килми иде.
— Әхтәм Харрасович, сез түгелме соң?
— Шул үзе... Маңгаенда ике күзе, дип тә өстәр идем, дөньяга сыңар күз белән генә карап яшибез хәзер. Бераз формасына килмәсме, дип кенә асылган аның икенчесе.
— Сез һаман да мәзәк сөйләшәсез, Әхтәм Харрасович.
— И сеңелем!.. Үтеп карады бу баштан мәзәкләр!.. Кара, фамилияң бик истә, исемең генә хәтергә килми тора. Әйе, Тәнзилә шул. Үзеңне ничегрәк иркәли язмыш дигәне? Шулаймы? Бик әйбәт, бик шатмын, Тәнзилә сеңелем.
— Ә минем фараларның берсе ничек сүнүе мәсьәләсенә килгәндә,— дип дәвам итте Әхтәм Харрасович,— анысын язмыш җәзасы дияргәме, әллә аяк астыннан чыккан бәла булдымы ул, аңламассың... Тормыш сикәлтәләре бер заман Себер тайгасына кадәр илтеп ташлады бу башны. Шунда, урман кисүдә эшләп йөргәндә, күзгә чүп керде. Чүпкә игътибар чүп кадәр генә булгандыр инде, медпунктка барып килергә рөхсәт сорагач, бригадир кул гына селтәде, үзем дә ялынып маташмадым, яшь агыза-агыза эшли бирдем. Иртәгесен торсам, ачып та булмый күзне. Медпункттан больницага ук озаттылар. Йөз чакрымлы тайга юлларын үткәнче, күз йодрык кадәр булып шешеп чыкты. Койкага салдылар. Айдан артык дәвалануның нәтиҗәсен, әнә, үзең күрәсең...
«Һай, Тайбә апа җаным! Әнә нинди зур бәладан йолып калгансың икән ич син мине теге вакытта».
Авырттырып, яндырып үтте бу уй Тәнзиләнең күңеленнән. Моны Әхтәм Харрасовичка да сөйләп бирмәкче иде, тамак төбенә кинәт килеп тыгылган төерне тиз генә йотып җибәрә алмыйча торды. Ул арада, мороженый ялый-ялый, балалар да килеп җитте. Тәнзилә, уларын әллә ни гомерләр күрми торгандай, икесен берьюлы кочагына алды.

— Да-а... Тәнзилә сеңелем, бик бәхетледер син.

Тәнзилә башын күтәрде. Әхтәм Харрасовичның очрашканнан бирле, хәтта ничек бәлага таруын сөйләгәндә дә гел көлемсерәүле сыңар күзе хәзер аз гына да елмаймый... Сагышлымы, әрнүлеме, әллә эчке бер көнчелек, әллә нинди яшерен усаллык та чагыла идеме бу караштa, аңлашылмый иде.

Шулчак аларның автобусына утырта башлауларын хәбәр иттеләр. Тәнзилә, саубуллашу сүзләре мыгырданып, плащын кияргә тотынды (ә маңгайдан тир ага), кулларын җиңнәргә тыга алмый йөдәде, гаҗәпсенеп үзенә карап торган балаларга кычкырып алды һәм... абына-сөртенә атлап китүгә, каккан казыктай туктап калды. Әрнүле-сагышлы, көнче-усал караш аны үтәли бораулый иде.

— Тәнзилә сеңелем... Гафу итегез, мин дә юл кешесе идем дә... Билетка акчам житеп бетми. Бик уңайсыз да инде... Гафу итегез.

Тәнзилә башта берни аңламый торды, аннары, кабаланып, кулына беренче эләккән кәгазь акча чыгарды. Чыгаруы булды, кызгылт кәгазь калтыраулы кара учта юкка да чыкты.

Автобус кузгалып, ачык тәрәзәдән җиләс һава өрә башлагач, Тәнзилә балаларының аркаларыннан сөеп куйды. Бая тиктомалга аларга кычкыруы өчен гафу үтенүе иде бу, сабыйлар тәненә кулы тиюгә җанга да тынычлык иңгәндәй булды, ә уйлары... Чуалган-чәбәләнгән уйларының һич очына чыгарлык түгел иде.

«Бәхетледер син...» Әйе, әнә аның ике ягында ике бәхет канаты утыра. Иң олы бәхет ич инде бу. Ә күңел?.. Нигә күңелнең бер чите һаман да китек сыман? Нәрсә житми инде аңа тагын? Нәрсә житми... Заһир... Ярата иде ич ул бу егетне. «Ярата иде...» Менә хәзер шулай, ди. Ә теге чакта яшь җилбәзәк баш моны төшенеп тә җитә белмәгән.

## IV

Атнадан артык әле иләкләп-чиләкләп койган, әле пыскып кына сибәләгән яңгырлардан соң чалт аяз көннәр башланды. Урамнарда койма-рәшәткәләр буйлатып эзлек төште. Чөгермәк [1], ерганаклар аша эздән-эзгә сикергәли-сикергәли үтүләре үзе бер күңелле иде. Клубка таба бик күңелле дә бит... Ә кайтканда эз-сукмакларны чамалау түгел, ләмле чокырчыкларның үзәгеннән ук лач-лоч ерып үтәсе килә. Ник итәк-чабуларга кадәр чәчрәп бетми шунда былчырагы!

Ике көн инде Заһирның клубка чыкканы юк. Үзе күренмәсә дә, исеме телләрдә. «Тагын Ташкичүгә элдертте теге. Янгынга чаба диярсең, камчылап куа атын». «Анда да берәр кыска итәккә ябышып өлгергәндер әле, ник чапмасын». «Тигәнәкнең шул булмыйчы! Белгән инде аны...»

Мәрзизә башлап җибәрә мондый сүзләрне, Тәнзилә янына килеп, боргаланып ала: «Дамир белән араларыгыз ничек, иркәм? Әй, бәхетле дә соң син».

Өченче кичне Тәнзилә гадәтенчә клубка чыгарга җыенып беткәч, кире чишенде. Китап алып утырды, башына берни кермәде. Мендәре астыннан инде очлап куясы да бармакчасын гына бәйлисе зур бияләйне алды. Тәрәзәдән атып бәрәсе килде, алай итмәде, тиз-тиз бияләйне сүтә башлады. Сүтелгән җепнең көпшәк йомгагы элеккедән икеләтә зур иде, учка сыймыйча идәнгә төшеп китте дә караватастына тәгәрәде. Шунда таба мүкәләүгә, капка төбендә ат пошкырганы ишетелде. «Заһир килде»,— дип уйлап алды Тәнзилә, һич икеләнмичә. Карават

[1] Чөгермәк — язгы, көзге сулар озак кипми торган уйсу урын.

астыннан башын чыгарып, хужа әбигә пышылдады: «Әби жаным, мин өйдә юк, чыгып кына әйт, өйдә юк диген мине».

Колакка сак әби, ниһаять, үтенечне аңлап, кыштыр-кыштыр ишеккә таба бара башлауга, болдырда аяк тавышы ишетелде. «Бар инде җәтрәк, әйт инде!» — дип, кычкырып ук җибәрде Тәнзилә.

Ишек артында өзек-кискен сөйләшүләр сәгать буе сузылгандай булды. Тәнзиләнең тыннары кысыла, чигәләре шаулый иде. «Килсә соң... Чыгарга да, юрамалый гына качтым, дияргә...» Үзе почмакка сеңгәннән-сеңә барды.

Ишек артындагы сөйләшүләр кинәт тынып калды. Капка шапылдавы Тәнзиләнең башына китереп суккандай тоелды. Тыенкы гына ат кешнәде, тояк тавышлары бик тиз ерагайды.

«Ташкичүгә элдертте... Янгынга чаба диярсең». Карават астыннан чыгуга, кичә ишеткән сүзләр колак төбендә генә яңгырагандай булды. Өстенә берәр нәрсә элдеме-юкмы, урамга чыгып йөгерде.

Айлымы ул кич, әллә дөм караңгы идеме? Хәтердә калмаган. Шунысы гына бик истә: Ташкичү ягында, күзгә бәреп, ниндидер ут яна, бер сүнә, тагын яктыра иде.

Ул дерелди-калтырый юрганы астына кайтып ятканда, таң беленә башлаган иде бугай инде.

Иртәгесен эшкә килүгә, озын колаклар котларың алынырдай хәбәр җиткерделәр: «Кичә кич Заһир Мәрзизәне сөякләрен җыя алмастай итеп кыйнап ташлаган».

Йокысызлыктан болай да тубал күк авырайган башны тәмам миңгерәүләтте бу хәбәр. Ходаем, бер җене котырса... — дигәннәре дөрес инде алайса.

Әбәт җитүгә, айдан артык инде аяк та басмаган ашханәгә йөгерде. Мәрзизә эшкә чыкмаган иде. Мескенкәем, кузгалыр хәлләре дә юктыр инде.

Җанны кая куяр әмәлләр юк иде. Ул гына, Тәнзилә генә, гаепле ич инде моңа. Килгәч, качып калды бит, шуңа җене котыргандыр инде ул Тигәнәкнең...

Кичке эңгер иңеп килгәндә, Мәрзизәләрнең өйләренә китте. Җилҗил атлаган аяклар, таныш капка янына җитәрәк, кинәт хәлсезләнеп калды. Келәгә сузылган кулы салынып төште.

Хәлен беләсе, аңлашасы иде дә бит... Аңлар микән соң аны Мәрзизә? Авырту-сызлаулары белән аны бик күреп торасы да килмидер әле кызыйның. Ә Тәнзиләнең күрәсе киләме соң? Бик кызганыч та һәм... дөресен генә әйткәндә, очрашасы да килеп тормый.

Башын аска иеп, клуб ягына таба атлады. Авыл уртасындагы буа янында тукталып калды. Бер кичне шушында, буа төбендәге бишегендә тибрәнгән алтынсу айга карап, Заһир белән бер-беренә сыенышып-җылынышып басып торганнар иде алар. Бүген бишегенә ятмаган әле ай. Арырак ялгыз бер йолдыз тонык кына җемелди. Кичә Ташкичү юлындагы ут яктырак иде...

— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдеңме, аппагым?

«Заһир!.. Әллә кичә бияләй сүткәнне, йомгак тәгәрәгәнне тәрәзәдән күреп торган инде?»

«Йөгерергә, баш ташлап качарга тизрәк».

«Кизәнеп кенә карасын! Бугазына ябышырмын юньсезнең».

Яшен тизлегедәй бер-бер артлы әнә шундый уйлар үтте баштан. Борылып карауга, телгә бүтән сүзләр килде:

— Күрдем. Ташкичү ягына тәгәрәде йомгагың. Элдерт шунда таба тизрәк.

— Бүген инде анда элдертүнең кирәге юк, Тәнзилә. Җиңдек без...— Заһир тел күнмәстәй ят сүз өстәп әйтте. Әллә, ветеринарга укучы булмарак, латинча такылдап маташа инде, мактанчык? Үзе елмая, куп-

шаклы иреннәре колагына җиткән, эңгердә тагы да озынрак күренгән керфекләреннән шатлык-тантана бөркелә. Кызларга кул күтәрүне шулай җиңү-егетлеккә саный микәнни инде бу тиле-миле?

— Җиңгәнсең шул. Бигрәк батыр икәнсең. Суккач-суккач, өзелеп чыгардай итеп сугарга иде аны, кыз балага...

Елмаюлы иреннәр шунда ук җыелды.

— Беләсеңме, Тәнзилә... Бу салкын яңгырлар безгә бик зур бәла алып килде. Сыерларда хәтәр чир башланды... — Заһир тагын, латинча бугай, ят сүз өстәде.— Кирәкле дару үзебездә генә җитмәде. Мин Ташкичүдән, аннары Ашытбаштан дарулар алып кайттым. Ике төн буе йокы күрмәсәк күрмәдек, җиңдек ул чирне. Инде кризис үтте.

Тәнзиләнең теленә сүз килми торды.

— Кичә кич мин, шатлыгымнан шашып, сезнең капка төбенә килеп туктаганмын. Әллә Алмачуар үзе алып килгән инде шунда. Син... каядыр чыккан идең бугай. Башта Хөсникамал әбинең ни әйткәнен дә аңламый тордым. Аннары клуб ягына киттем. Менә шушы турыдарак Мәрзизә очрады. Шатлыгымны аңа да әйттем. Ә ул... Куанычымны ортаклашыр урынга, әллә ниткән ямьсез сүзләр сибә башлады. Тел әйләндереп кабатларлык та түгел... Мин Алмачуардан сикереп төшүгә, Мәрзизә чәрелдәп кычкыра-кычкыра йөгерә башлады. Әнә тегe чокырга җиткәч, мәтәлеп барып та төште. Мин аны күтәреп торгызмакчы итәм, ә ул разбой салуын белә: «Үтерә-ә... Коткарыгыз!» Шунда кемнәрдер килеп җитте... Уйлаган идем аны, әллә ниткән сүзләр таралыр да сиңа да ирешер дип... Күңелемә килгән иде.

— Нәрсәләр диде соң ул? — Тәнзилә, ниһаять, сорап куйды.

— Әйтәм ич, аның сүзләрен кабатларга тел әйләнми. Әллә ышана дип уйлыймы мине? Ни хакы бар аның сиңа былчырак атарга?

— Нинди былчырак? — Тәнзилә, өстенә чыннан да нидер чәчрәгәндәй, чиркануны дерелдәп куйды.

— Әй... Кем ышана ди аның сүзенә. Бер дә исең китмәсен.

— Шулай да, нәрсә дигән була соң?

— Корымга буя, нәҗес сөрт, алтын барыбер алтын булып кала. Шулай ди минем әни.

— Боргаланмасана! Әйт инде, нәрсә дигән була?

Заһир беразга сүздән калды.

— Беләсеңме, Тәнзилә, бер фокус-мокус күрсәтимме? — диде аннары, сүзне икенчегә бору өчен бугай, шаян гына сорады.

— Синнән көтәргә була... Фокусын да, мокусын да.

— Тсс... Игътибар! — Заһир серле генә кыяфәттә кулындагы чыбыгын салмак кына айкап алды. — Хәзер безнең алда әкият тулпары пәйда булачак. Игътибар! — Ул аскы иренен эчкәрәк батырып, ачы сызгырып җибәрде, тагын чыбыгын айкап куйды һәм... Чыннан да фокус диярсең! Сызгыруга җавап итеп, якында гына яңгыратып ат кешнәде, тояк тавышлары ишетелде, ул арада Алмачуар шык-шык егет янына килеп тә туктады.

Буа артындагы офык буйлап кичке шәфәкънең соңгы комач нурлары балкый, шул моңсу балкышта искиткеч зифа тулпар егетнең үзенә таба сузылган кулларын назлап кына үбә. Әйе, нәкъ менә үбә кебек тоелды Тәнзиләгә, чынлыкта исә Заһирның зур учыннан нидер каба иде бугай Алмачуар. Шулай да, шигъри бер манзара иде бу. Һич көтмәгәндә, күңел бөтенләй бүтән, эрнүле-ямьсез хисләр белән тулы чакта кинәт пәйда булган шигъри гүзәллек!

— Фокус түгел, могҗиза ич бу! — Тәнзилә, күз яшьләрен көчкә тыеп, ике куллап Заһирның бер як иңбашына килеп тотынды.

— Могҗиза дип... Шулай инде ул Алмачуар. Тыңлаучан... — Заһир үз иңбашындагы кулларны сак кына сыйпап куйды.

— Булса да... Теләсә кемне тыңлап тормыйдыр әле.

— Анысы дөрес. Яраткан кешесен генә тыңлый. — Заһир бик канәгать-горур елмайды. — Беләсеңме, Тәнзилә, ул сине дә бик ярата. Әйтәм ич, кичә мине сезнең капка төбенә Алмачуар алып килде. Үзем уйламаган да идем. Чыннан әгәр менә...

— Ышанды дип уйла. Яратса, әйдә, мине бер атландырып йөртсен. — Тәнзиләнең чыннан да Алмачуарга атланып әллә кайларга, бик еракларга чаптырып үтәсе килеп китте. — Теге көнне дә атланып булмады,— диде, чын-чынлап үкенгән кыяфәттә.

— Анысы аның ул көн иде, монысы менә бүген,— диде егет, кистереп кенә һәм Тәнзиләне ат өстенә меңгереп тә утыртты. Бигрәк тиз, бигрәк җиңел күтәреп, Алмачуарга утыртып та куйды аны Заһир. Атландырмады, аякларын бер якка салындырып утыртты. Ул арада үзе дә ат өстендә иде инде.

— Ой, Заһир! Мин бит уйнап кына әйткән идем. Төшим тизрәк, башым әйләнә.

— Алмачуар күп сөйләшкәнне яратмый. Син атның ялына ябышма, авырттырасың. Миңа тотын ныклабрак. — Заһир әллә чынлап, әллә юри ачулы итеп әйтте.

Алмачуар теркелдәтеп кенә кузгалып та китте.

Менә җай гына юыртып барды да малкай, кызуланганнан-кызулый биреп, кушаяклап ук чаба башлады. Менә, экияттәге тулпардай, очып кына бара башлады. Җил маңгай чәчләрен артка тарый, егет нык итеп, ышанычлы итеп билдән кочып алган. Алсу-шәмәхә офык, җемелдек тәрәзәле карасу өйләр, моңсу гына башларын иргән карасу тупыллар — барысы да аста калды бугай, күзгә чалынып-чалынып кына кала... Очыпмы — очалар гына. Өндәме, әллә төштә генә булдымы бу очыптайлар да чабу? Моны әллә ничә көннәр буе Тәнзилә үзе дә аңлап бетерә алмый йөрде. Ничек аңлыйсың? Көндезләрен, уп-уяу килеш тә, аяклары җиргә тияр-тимәс, очынып кына йөрде ич ул көннәрдә Тәнзилә. Күңел гел каядыр ашкына, аяк-куллар аз гына да ару-талуны белми, күлү-елмаюларның иге-чиге юк иде.

Әле дә хәтерендә: шулай бер иртәне эшкә килешли уйлап барды — мичләрдәге кирпечләр өлгергәндер инде, аларны тизрәк бушатасы да, яңа өлеш чи кирпечләр тезәсе булыр. Юкса, артык җилләгән чи кирпечне яндырсаң, ярты теземең яраксызга чыгачак. Тизрәк, тизрәк башкарырга кирәк моны. Кирәген бик кирәк тә... болай да бер кешене икегә бүләрдәй чакта, кемнәрдер, ни сәбәптәндер эшкә дә чыкмаган... Юк, сәбәпсезгә түгел, шактый эшче колхозга бәрәңге алышырга киткән иде.

Тәнзилә, ике дә уйлап тормастан, мич янына үзе басты. Ярдәмгә ике агай килеп житте. Тимер арбалардагы мунча ташыдай эссе бәреп торган кирпеч өемнәре тар рельс буйлап тәгәрәшә дә башладылар. Каян телгә килеп тора: «Үзләре бара болар, үзләре бара!» — дип, шаян кычкырып җибәрә, «әй, егетләрнең асыллары, ут уйный кулларыгызда, ут» — дип, агайларга каш сикертеп ала, үзенең куллары гына түгел, иңбашлары, тезләре, аркасы, үкчәләре, бөтен сеңерләре эштә, ару-талу түгел, аның саен бөтен тәнендә көч-куәт арта гына бара кебек иде. Күпме генә вакыт үткәндер, мичне бушатып та бетерделәр. «Әйтмәгәнем булсын, әллә адәми заттан түгел инде бу кызый, ана арыслан кодрәтләре бар монда»,— дип, агайларның уфылдаша-уфылдаша сөйләшеп калганнары колакка чалынды.

Әйе, бик хәтердә ул көн. Шул көнне бит инде эш сәгате бетәр алдыннан завком председателе Мәгъфүрә Сабировна аны кабинетына чакыртып алды.

## V

Үзенә шулай Мәгъфүрә Сабировна, иптәш Яфизова дип, бик хөрмәтләп дәшсәләр дә, артында — әллә бик үз итеп, әллә нигәдер өнәп бетермичәме — бары тик Мәгъфүр дип кенә йөртелгән бу апа турында заводта күп сөйләшергә яраталар иде. Эре сипкелле түгәрәк кенә йөзле, кыска чал чәченә арттан зур гына матур тарак кадап куйган, гәүдәгә әллә ни зур булмаса да, сеңер белән тамырдан гына торган ирләрнекедәй зур куллы бу ападан Тәнзилә, нигә икәнен үзе дә белмәстән, бераз шүрли иде.

Сугыш елларында башта бригадир, аннары колхоз председателе булган Мәгъфүрә Сабировна.

— Япь-яшь кыз башы белән бөтен авылны дер селкетеп кулында тотты,— дип искә алалар заводка шул авылдан килеп эшләүче апалар.

— Биленә җиткән матур толымнарын юкка әрәм итте түлке. Авылда-илдә юк иде андый толымнар,— дип өсти икенчесе.

Бригадирлыктан председательлеккә куйгач, көне буе кеше күзенә күренми Мәгъфүрә. Иртәгесен таң тишегеннән җыелыш җыйдырта. Ул елларда һәркемнең күңелендә «әллә сугыш бетте микән?» — дигән өмет яши, клуб бик тиз шыгырым тулып та өлгерә. Менә сәхнәгә Мәгъфүрә килеп чыга. Авылдашлары башта үзләренең кичәге бригадирларын танымый да торалар. Чулпылары чыңлап торган озын толымнар урынына ирләрчә кыркылган чәч, билендә киң солдат каешы, кулында, ике бармак арасында, карандаш озынлыгы итеп төрелгән махра төтенли. Чын тартучылар кебек зәңгәр боҗралар очыра-очыра залга сүзсез генә карап тора бу...

— Юк ла инде, күрше, бераз шыттырасың,— дип өсти икенче апа.— Махраны соңрак суыргалый башлады ул. Сукачы малайлар каршында эфтәритне күтәрү өчен генә. Чәчен дә алай ук кыркып бетермәгән, муен тиңентен толымнарын гына кискән иде.

— Синең, күрше, я хәтерең начар, я син ул җыелышта гүпчим дә булмагансың. Күргәнемне сөйлим мин, бүлдермә.

— Сип инде, алайса, сип.

— Шуннан... Тәмәкесен суырып бетердеме-юкмы, анысы минем дә хәтердә калмаган, кинәт кенә шап итеп өстәлгә сугып куйды бу. Ике йодрыгы белән берьюлы. Умарта күчедәй гөжләгән зал тынып калды. «Кичә сез, кул күтәреп, мине председатель итеп сайлаганда, мин үзем бу эшкә үземне сайламаган идем әле. Бүген менә сайладым. Ләкин бер шарт: мине тыңлыйсыз! Тыңласагыз, дәүләт йөкләмәләрен дә үтәрбез, үзебез дә ач булмабыз».

— Менә алай дип әйтүе дөп-дөрес. И сүзендә торды да. Алабутасын, бәрәңгесен кушмый пешергән чын тәмле ипи бөтен тирә-юньдә бер безнең авылда гына булды бугай ул елларда. Ел буена булмаса да, андый ипекәй белән сыйлана идек.

— Сыйландык шул. Җыелышта сүз куешу шулай булды бит. Без — тыңларга, ул...

— Тыңламассың Мәгъфүрне!.. Кайчак, өйдәге мәшәкатьләр белән колхоз эшенә чыгарга готкарланыбрак каласың. Берзаман урам башында нәсел айгырына җигелгән трантаска аягүрә баскан Мәгъфүр күренә. Шулай трантасына менеп бастымы, син инде аннан рәхим-шәфкать көтмә. Бакча артлап кына басуга чыгып йөгергәнеңне сизми дә каласың.

— Эшләтә дә белде, кирәк чакта ярдәмен дә кызганмады. Рәхмәттән башка ни әйтәсең. Тик менә үз тормышы гына бик ипледән булмады җанашымның.

— Анысы инде, күрше, безгә караңгы. Бәлки аның үз бәхетен шушылай табуыдыр? Ни генә әйтмә, ике малайны менә диган итеп аякка бастырды.

— Аларны бастырды да бит... Үз сабые гына дөньялыкка бик азга килде.

Сүз шушы урынга җиткәч, тыңлаучыларның колаклары тагы да үрәрәк тора, әмма кинәт җитдиләнеп калган апаларның телләре бик сүлпән әйләнә башлый.

Җәелеп үк сөйләмәсәләр дә, бер-бер артлы яуган сорауларны җавапсыз да калдырмый апалар. Болайрак икән. Сугышлар бетеп, авылга утны-суны кичкән ир-ат кайта башлагач, Мәгъфүрә председательлек дилбегәсен тапшыра да шәһәргә китеп бара. Күпмедер вакыттан соң кайтып төшә. Я хода! Тагын танырлык түгел Мәгъфүрәне. Бик үзгәреп, бу юлы шәһәрчә үзгәреп кайткан. Кыска чәчләрен бөдрәләп-алкалап килешле генә итеп ясаткан, ирениәргә иннек тә тигән бугай, чиядәй яналар. Махра суыру түгел, ирләр төтәтә башласа да, «фу» дип, читкәрәк тайпыла хәзер. «Кияүгә чыккан икән Мәгъфүрәбез, тиздән ире кайтачак та авылда туйлары булачак икән. Шәһәрдә эшләсә дә, үзебезнең як кешесе икән ире, монда ук танышкан булганнар» дип, бик белдекле хәбәрләр йөри башлый. Атналар, айлар үтә, кияү кеше һаман күзгә күренми, ә бер төнне Мәгъфүрәне әле кайчан гына үзе җигеп йөргән нәсел айгыры белән ашыгыч рәвештә район үзәгенә, роддомга илтеп куялар. Ләкин ана бәхете бик кыска була Мәгъфүрәнең. Дөньяга килеп, бер генә көн зәгыйфь-зәгыйфь аваз сала нарасый. Олы зиратта, карт өянкеләр ышыгында, җыйнак кына кабер пәйда була. Кайчан җирләгән дә үзенең йөрәк парәсен Мәгъфүрә, хәзер кая киткән,— белүче дә, күрүче дә юк. Төрлечә хәбәр-фаразлар йөри. «Кая китсен, ире янынадыр». «Андый мәнсезгә баш иеп торамы соң Мәгъфүр, Мәскәүнең үзенә үк киткән ул, шунда эшли ди хәзер». «Юк, эшләми, укырга кергән ди ул анда, бик зур кеше булып кайтачак икән».

Икенче җәйнеме, әллә берәр ел үткәчме, кайтып төшә Мәгъфүрә. «Укырга кергән» дигәннәре дә, «зур кеше булачак» дип юраулары да дөрескә чыга диярлек. Ләкин Мәскәүдә түгел, үз ягыбызда гына, Минзәлә авыл хуҗалыгы мәктәбендә ачылган махсус курста укыган, хәзер менә райондагы бөтен агрономнарга баш итеп җибәргәннәр үзен. Болары әллә ни шаккаттырмый авылдашларны. Булыр, колхоз дилбегәсен нык тотты, район күләмендә дә җитәкчелек итәргә кулыннан килер. Тик менә... Мәгъфүрә ике кулына ике малай җитәкләп кайткан, монысын ничегрәк аңларга? Берсе арыш саламыдай сары чәчле, икенчесе шомырт кара күзле, гәүдәгә исә нәкъ бер чама малайлар. Җилкәсенә болай да зур эш йөкләнгән, нигә инде мондый олы мәшәкать алды икән? Офтаналар, баш чайкыйлар авылдашлар. Башта Мәгъфүрәнең бу гамәленә бик сәерсенеп баш чайкасалар, соңрак чын соклану белән чайкыйлар башларын. Бетмәс эшләре белән бер колхоздан кайтып, икенчесенә чыгып китүенә карамастан, малайларның өс-башы һәрвакыт чиста, бөтен, тамаклары тук. Араларына кыл да сыймастай тату-дус үзләре. Шулай дус-тату булып кына, пардан киенеп, пар сумкалар асып, мәктәпкә йөри башлый малайлар, үсә төшкәч, җәйләрен еллык утын кисеп яру, печән хәзерләү, бәрәңге өю кебек эшләрне бөтенләе белән үз кулларына алалар. Кичләрен, капка төбенә чыгып, әниләрен көтеп торалар, Мәгъфүрә җигеп кайткан атны шунда ук тугарып, тау астына илтеп арканлыйлар, иртән, атны җигеп, озатып калалар.

Тормыш булгач, барысы да ал да гөл генә булып тора алмый. Көннәрдән бер көнне, әшенә, мәшәкатьләренә муеннан чумган Мәгъфүрә кинәт кенә авырып китә дә, больницага салалар үзен. Айга якын ята, малайлар аның янына ник кенә бер килеп карасыннар. Нәрсә бу? Сабыйлык ваемсызлыгымы, әллә бүтән сере-сәбәбе бармы моның? Пы-

шын-пышын сүзләр китә. «Мәгъфүр шәһәрдәге теге ир кисәге белән әле һаман да араны өзеп бетермәгән, имеш, больницага да шул сәбәпле яткан. Малайларның шуңа сыннары каткан икән», дигән сүзләр йөри. «Малайлар, Мәгъфүргә әйтмичә генә, үз эти-әниләрен эзләп, гел әллә кайларга язып яталар икән, арада бәхәс шуннан да чыккан» — дип өсти икенчеләр.

— Кеше ни сөйләмәс... Син миңа шуны әйт: безнең авылда сугыштан соң кем беренчеләрдән булып институтларга барып керде? Мәгъфүр малайлары бит!

— Керүен дә керделәр, укып та чыктылар. Мәгъфүр генә клуб чаклы өр яңа өенең тәрәзәләренә такта кадаклады.

Берсе, салам чәчлесе, үстергән әнисе кебек, агрономлыкка укый малайларның, шомырт күзлесе инженер-механик булып чыга. «Берсе булмаса берсе кайтыр, икесе дә колхозга бик кирәк белгечләр» — дип сөйләнергә ярата Мәгъфүрә, малайлар укырга киткән елны ук бик җиренә җиткереп, яңа өй торгызырга керешә. Өй өлгерә, тик малайлар анда берәр атна гына кунак булалар да, сары чәч чирәм җирләргә китеп бара, шомырт күз ул елларда бик шаулаган Братск төзелешенә юл ала.

— Пинсесе дә әйбәт кенә чыккан бугай, нигә контор эшенә барып керде икән?

— Әйтмә дә! Нигә хәленнән килгәнчә малын асрап, бакча үстереп кенә үз өендә рәхәтләнеп ятмаска? Биргә килеп, общежити тыгынлыгына барып кермәсә...

Әле бүген әбәттән килешли генә очратты аны Тәнзилә. Мәгъфүрә Сабировна почта ягыннан култык астына сургучлы посылка тартмасы кыстырып кайтып килә иде. Адымнары салмакланып калган, хәтта әбиләрчә кыштыр-кыштыр да баскалап куя. Тәнзилә сәлам биргәч, башын күтәреп исәнләште дә, гадәтенчә, эре-нык атлап китте.

Нигә кабинетына чакыртты икән? Хәтере ялгышмаса, цехта профсоюз взносларыннан бурычы юк шикелле. Ах, әйе. Цехта һәркемнең шәхси соцйөкләмәләр яздырып алырга әйткән иде бит ул. Кайберәүләр һаман да суза, җыеп тапшыра алганы юк. Шуңа утлы табага бастыра инде аны хәзер Мәгъфүрә Сабировна.

## VI

Килеп керүгә, борынга җиңелчә тәмәке исе килеп бәрелде, түр тәрәзә буенда юка гына зәңгәр төтен алкасы да тибрәнә иде. «Әллә тагын тарта башлаган инде Мәгъфүрә Сабировна? Юкса, ирләрдән берәрсе көйрәтеп чыкканмы?»

— Килдеңме, сеңелем? Әйдә, уз, утыр.

Тәнзилә Мәгъфүрә Сабировнаның күз читләрендә җылы елмаю яшеренгәнен шәйләп алды. Аның әнисе дә, берәр шелтәлерәк сүз әйтәсе булса, сиздермәскә тырышып кына көлемсерәүчән. Шул исенә төште дә, сулышлары иркенәеп китте.

— Каефләр ничек? Ияләнеп буламы авылга?

Тәнзилә: «И-и, үз авылымнан да якынрак хәзер» — дип сөйләнгән арада, Мәгъфүрә Сабировна әллә кайдан гына алып, әлеге посылка тартмасын өстәлгә китереп куйды.

— Күчтәнәчтән авыз ит, сеңелем, савабы тияр. Целинадагы малайдан.

Тәнзилә матур ялтыравык кәгазьле эре конфет алды. Мәгъфүрә Сабировна өстәл тартмасыннан алтынсу-көрән төстәге зур гына балык алып кәгазьгә төрде дә Тәнзиләгә сузды.

— Монысы Братски күчтәнәче. Бәрәңге белән ашарга бик тәмле, тыгып куй кесәңә.

— Улларың гел күчтәнәчләп кенә торалар икән үзеңне, Мәгъфүрә апа.

— Онытмыйлар, рәхмәт яугырлары. — Мәгъфүрә Сабировна, елмаеп, каршындагы өлтәл күзгесенә каранып алды. «Нигә күзгә тота ул өстәлендә? Әллә ничек... Килешми өлкән кешегә».

Мәгъфүрә Сабировна посылканы алып куярга кузгалгач, Тәнзиләнең дә бик матур чөлтәр кысалы шул көзгегә күз саласы килеп китте, үзенә таба борса... Бәй! Көзге түгел, фотокарточка икән ич бу! Берсеннән-берсе чибәр, берсеннән-берсе таза ике егет, башларын башка куеп, аңа төбәлгәннәр, кысаны кире борганда, икесе берьюлы аңа күз кыскандай тоелды.

Мәгъфүрә Сабировна урынына килеп утырды, зәңгәрсу кысалы күзлеген алып киде. Алдында кәгазь-мазар күренмәсә дә, кулына карандаш алды.

— Ничек уйлыйсың, Мәрдәншина, сезнең цех планны үтәр кебекме бу айда? Соңгы декаданы ваклый башладык бит.

— Мичкә бүген тыккан кирпечләребез әйбәт кенә чыкса, ике дә уйлыйсы юк, артыгы белән үтибез планны, Мәгъфүрә Сабировна. Минем әни әйтмешли, хәерле сәгатьтә башланган эш була күрсен.

— Хәерлегә юрыйк. Бүген үк бу эшне оештырып, бик әйбәт иттең син. Һич риясыз әйтәм, чын-чынлап сокландым үзеңә. Тик менә... Кая, күрсәт әле учларыңны.

— Нигә инде, Мәгъфүрә Сабировна?..

Эшләми эшләгәнгәдер, Тәнзиләнең учлары бармак төпләреннән кабарып-кабарып чыккан, берничә шеш сытылып, чиләнеп тора, моны аның берәүгә дә күрсәтәсе килми иде.

— Кая, суз кулыңны, суз.

Сузмыйча булмады.

— Шул шул менә! — Мәгъфүрә Сабировна карандашын шакылдатып өстәлгә атты. — Шәхси үрнәк күрсәтү ул, һич тә артыгын көчәнү дигән сүз түгел. Ир-ат халкы өчен, бәлки, ярыйдыр да. Әмма хатын-кыз өчен... Бигрәк тә кызлар өчен... Бу инде, беләсең килсә, җинаять! Аңлыйсыңмы шуны?

— Мин көчәнмәдем, Мәгъфүрә Сабировна. Бер бөртек арымадым.

— Чуртым да аңламадың алайса син мине. — Мәгъфүрә Сабировна күзлеген салып куйды. — Мин дә шулай «бер бөртек» армый идем. Эскерт башына печәнне чүмәләсе белән генә атам. Арка-җилкәдә әллә нинди тамырлар шытырдый, аның саен сәнәккә печәнне күбрәк эләктерәм. Капчыкның да иң олысын гына олауга селтәп салам. Берәр үшән ат егылса, ничек итсәм итәм, дүрт аягына бастырам. Әнә шулай шәхси үрнәк күрсәтеп җитәкләргә туры килде колхозны сугыш елларында. Ә соңыннан... Күпме ачы күз яшьләре түккәнемне үзем генә беләм дә, чылана-чылана күксеп беткән мендәрем шаһит...

— Нигә, Мәгъфүрә апа?

— Нигә! Нигә!.. Беренче балам гомерсез булгач, Казанда профессорга кердем. Турыдан-туры әйтте профессор: яшьли, кыз чагында ук, авыр күтәрү нәтиҗәсе, диде. Менә нәрсә турында сүз. Төшендеңме инде?

— Төшендем, Мәгъфүрә апа. Моннан ары...

— Вот-вот! Моннан ары онытма, Мәгъфүрә апаңның сүзләрен. — Ул кулына әлеге матур кысалы фотоны алды. — Минем бәхетсезлегем аша килгән бәхетем болар. Монысын да онытма.

— Онытмам, Мәгъфүрә апа... Ә ярыш йөкләмәләрен иртәгә үк китереп тапшырам мин аларны.

— Хәтереӊ яхшы икәнгә ышанырга була болай булгач. — Мәгъ-

фүрә Сабировна өстәл башындагы өемнән папка алып актара башлады. — Ашыгасың бугай, мин сине больше тоткарламыйм.
— Юк, юк, Мәгъфүрә апа, кая ашыгыйм, ди.
— Ашыкмасаң, әйдә киттек мина. Көчтәнәчләр белән чәй эчәрбез.
— И Мәгъфүрә апа... Уңайсыз бит.
— Син, сеңелем, бераз ялганчы да икәнсең, алайса.
— Нигә-ә, Мәгъфүрә апа?
— Үзем ашыкмыйм дисең, ә үзең Мәгъфүрә апаң яныннан тизрәк үкчә ялтырату ягын карыйсың.
— Юк, чыннан да уңайсыз. Олы кешегә мәшәкать ясап...
— Ялгыз баш олы кешегә кайчак мәшәкать ясау да бик кирәк. Киттек!
Юлда Мәгъфүрә Сабировна сорый куйды:
— Әниең янында берәрсе калдымы әле авылда?
— Кече абыем анда. Өч бала үстерәләр.
— Әйбәт. Сиңа да шундый бәхетле картлык насыйп итсен.
— Кызык син, Мәгъфүрә апа. Әле аңарчы...
— Изге теләкләр никадәр алданрак иңә башласа, шулкадәр яхшы.
Завод гомуми торагының җыйнак кына бүлмәсенә килеп кергәч, Тәнзилә шуңа игътибар итте: стеналар Мәгъфүрә Сабировна үстергән малайларның фоторәсемнәре белән тулган. Малай чактагы, үсә төшкәч, егет булып җиткәч төшкән фотолар. Хуҗабикәнең үз фотосы гына күренми.
— Икесенең берсе өйләнми, шайтаннар. Картайгач, шул инде ул, оныкларны бик сөясе килә башлый. — Мәгъфүрә Сабировна плитә янында маташкан көйгә, Тәнзиләгә күтәрелеп тә карамыйча гына әйтеп куйды.
Чәй янында әңгәмә куе барса да,ниләр сөйләшкәннәре истә калмаган. Бик акыллы сүзләр булмагандыр инде. Ә менә чәй яныннан торып, диванга килеп утыргач сөйләшкәннәр һич онытыласы юк.
— Син аларның кайсын бигрәк яратасың? — Мәгъфүрә Сабировна ничектер егетләр турында шаярулы-күңелле генә сүз чыгарды да, кинәт җитдиләнеп, сәер генә сорап куйды, ә күзләре стенадагы фотоларга текәлгән иде.
— Кемнәр турында сорыйсың, Мәгъфүрә апа?
— Хәйләкәрләнмә. Кемнәр турында икәнен бик яхшы беләсең.
— Әллә инде, Мәгъфүрә апа... Улларың турында сорыйсыңмы? Мин бит аларның берсен дә күреп белмим.
Мәгъфүрә Сабировна күңелле генә көлеп җибәрде.
— Алайса, прәмедән туп-туры сөйләшик. Дамирнымы, әллә Заһирнымы, әллә теге... шәһәрдәге егетеңнеме.
Тәнзилә, бит алмаларының бик яман кызыша башлавын тыярга тырышып, тирән сулыш алды.
— И Мәгъфүрә апа...
— Ярар, җүләр соравым өчен гафу ит. Әмма һич тә алай тикмәгә генә соравым түгел бу. Син, утыр, тыңла әле Мәгъфүрә апаңны. Ялганламасаң, бер кая да ашыкмыйм, дигән идең.
— Тыңлыйм, Мәгъфүрә апа.
— Болай бит ул, сеңелем. Бу дөньяда абруй дигән, янсә, хәзерчәләп әйтсәк, репутация дигән нәрсә бар бит. Ай-һай кирәк нәрсә ул кеше тормышында. Әйтергә кирәк, ипи-тоз кебек, җылы кием кебек кирәк. Хәтта алардан да кирәгрәк бугай әле.
— Минем әни дә шулайрак әйтә иде.
— Әниләр әйтә-ә, ә балалар, үз канатлары ныгып та җитми, әни канаты астыннан очып чыгып китә торалар. Кыскасы, шул, Тәнзилә сеңелем. Ташла син алай берьюлы әллә ничә егетнең башын әйләндереп йөрүеңне.

— Нигә әйләндерим ди-и, Мәгъфүрә апа.

— Бәлки, нарушны әйләндермисеңдер дә. Әмма әлеге репутация дигән нәрсә шундыйрак оешып килә синең турыда. Күңеленә авыр алма, әнә, әниең дә искәрткән бит бу турыда.

Өстәлдәге будильник бик каты текелди башлады, гүя чигәләргә генә бәрә.

— Онытмыйм мин әнием сүзләрен.

— Сүзләрен онытмыйсыңдыр да... Ә гамәлдә... Бик катлаулы нәрсә шул ул абруй-репутация. Син аны бөтен эшең-хезмәтең, һәр адымың, һәр сүзең белән яуларга, матур итеп сакларга тырышасың. Ә шунда ниндидер бер кабәхәт җан, әллә нинди гайбәтләр таратып, синең абруеңны астыртын гына кимерә, таплый, ямьсезли.

«Аның сүзләрен кабатларга тел әйләнми».

Хәтерне Заһирның шул сүзләре яндырып узды да Тәнзилә урынынан сикереп торганын сизми дә калды.

— Беләм мин кем минем турыда гайбәт таратканын.

Мәгъфүрә Сабировнаның үзе авыр, үзе йомшак кулы, иңбашына тиеп кенә киткән кебек булса да, кызны яңадан урынына утыртты.

— Сүз иясе артыннан кууның файдасы юк, сеңелем. Һәртөрле гайбәткә үзең аз гына да азык бирмәскә кирәк. Менә иң мөһиме кайда.

— Нинди азык?

— Әйтик, Заһир белән икәвегез бер атка менеп аласыз да, авыл урамнарын дер селкетеп, чабасыз. Ә үзең клубта Заһир белән түгел, гел Дамир белән биисең... Миңа калса, гаеп итәрдәй бер нәрсә дә күрмим мин боларда. Ә гайбәтче өчен ай-һай шәп азык инде бу. Кырыкка, меңгә күпертә ул аларны.

— Күпертсеннәр. Кирәкми миңа бер егете дә.

— Авызыңнан җил алсын андый сүзне, тиле. Чәчәк аткан гөлгә, шиңә башламас борын, бер сандугачның үз вакытында килеп кунуы бик кирәк ул. Бәлки, тегe... шәһәрдәге егетең җаныңа якындыр?

— Юк минем шәһәрдә бернинди егетем дә. Юк. Яратмыйм мин шәһәрне.

— Шулай дисеңме? Ярый, ярый. Беләсең килсә, син биредә, авылда кирәгрәк. Без суккан кирпечтән районда күпме яңа төзелешләр калкып чыга тора. Беләсеңме, хәзергесе көндә никадәр мөһим бу?

— Әһе...

— Мин үзем дә, агрономлыкта йөрергә көчем бетеп бара, инде нишләрмен, дип торганда, райкомның кулымнан килердәй мондый эшкә куюына шатланып бетә алмыйм.

— Әһе...

Беразга тагын будильник текелдәве генә ишетелеп торды.

— Шуны сорыйм дигән идем. Сезнең Мәрзизә белән араларыгыз ничек?

— Шул Мәрзизә тарата да инде минем турыда җыен гайбәтне.

— Алайса... Шуңа Заһирны котыртып, аннан кыйнаттыңмыни көндәшеңне?

— Мин кыйнаткан?! Һай, Мәгъфүрә апа, ниләр ишетәм! Берәү дә кыйнамаган аны, үзе егылган ул. Үз зәһәренә үзе абынып егылган.

— Менә бит. Гайбәткә аңа бер азык бирдеңме, күпертелгәннәргә чеп-чи ялганы да ябыша башлый. Тагын әллә ниләр әле... Мин аларга ышанмыйм, әмма ямьсез сүзне ишетү барыбер күңелсез.

— Һай, Мәгъфүрә апа, Мәгъфүрә апа...

Тәнзилә бер торып китә, яңадан килеп утыра, гүя ниндидер күзгә күренмәс җәтмәгә эләккән дә, шуннан ычкынмакчы булып чәбәләнә иде.

— Ярар, иртәгә ял көне түгел, озата чыгыйм үзеңне,— дип, Мәгъфүрә апасы да урыныннан кузгалды. — Миңа да һава булыр.

Киенеп беткәч, ул кире диванга килеп утырды.

— Мин чыгып йөрмәм, ахры. Әллә йокы басты, әллә карт сөякләр алҗып та өлгерде. Әйдә, йөрмәгән юлың түгел. Только ни... Алай ашыгып-йөгереп кайтма. Җай гына атла. Аякларың ашыкмаса, уйларың да сабырланыр. Әле сөйләшкәннәрдән иң дөрес бер фикергә килми калмассың. Сабыр акыл белән уйлан. Хәерлегә!

## VII

Салкынча көзге кич,аяз-тын, айлы-йолдызлы иде.

«Бик катлаулы нәрсә шул ук абруй-репутация» — дип, эченнән генә кабатлап куйды Тәнзилә. Бернинди уйсыз, мыскыллы бер көлемсерәү белән кабатлады. Кинәт урман полосасы ягында ачыргалы-җылак тавыш белән ябалак кычкырып җибәрде. Тәнзилә сискәнеп китте, айлы сукмак буйлап йөгерә үк башлады. Сискәнсә дә, алай шүрләмәде шүрләвен. Ишетмәгән тавыш түгел, алар авылы зиратында да җәй буе аваз сала иде ябалак. Бу юлы күңелдә әллә нинди авыртулы шом уятты бу тавыш.

Буага җитәрәк, сукмак тау кырыйлап үтә, аякларны тыя төшмичә булмады. «Аякларың ашыкмаса, уйларың да сабырланыр». Әй, Мәгъфүрә апа! Сезгә, өлкәннәргә, җиңелдер дә ул сабыр гына уй йөртүләре... Ә монда уйлар өере-өере белән ишелеп килә дә баш миендә, таяк тыккан кырмыска оясыдай, тәшвишле буталыш, чуалыш, ыгы-зыгы китә...

Буаны чыккач, аңа уңга борыласы иде. Тәнзилә, икеләнеп тә тормастан, сулга борылды. Тигез юлдан аяклар тагын юргаклый башлады. Менә хәзер үк барырга да өйләренә, Мәрзиәне чакырып чыгарырга, усал итеп, өздереп әйтергә үзенә: гайбәт сатуыңны туктатмасаң, җаныңны суырам, иманыңны өшкертәм мин синең, бел! Заһир сине түгел, мине ратканга җенең котырамыни, йолкыш! Юк инде, мә, кукиш сиңа!

Тел очына берсеннән-берсе усалрак сүзләр килә тора, йодрыклар чытырдатып йомарланган, аяклар кызуланганнан-кызулый.

— Ярамый! Ямьсез белән ямьсез булып йөрмә!

Һич көтмәгәндә аерым-ачык булып әнә шундый сүзләр яңгырады. Ләкин моны аңа берәү дә әйтмәде. Кызга үз күңеле әйтте бу сүзләрне. Ихтимал, ата-аналар, әни-әбиләр авазы булып, моңарчы күргән бар тәрбиясе, мохит йогынтысы булып яңгырагандыр ул сүзләр.

Кире борылды. Ләкин никадәр салмак атламасын, уйлар аз гына да сабырланмый, берсен-берсе куып чәбәләнә бирә, дөресрәге, уйлар да түгел, өзек тә ертык уй кисәкләре генә чуала иде башта. Ә йөрәк, әле һаман да бар көченә йөгереп баргандай, дөп-дөп тибә, сулышлар буыла иде.

Кайтып җитәргә ике-өч өй аша, түзмәде, аякларына тулы ирек бирде. Хөсникамал әбисе, гадәтенчә, күршеләргә кич утырырга кереп киткән бугай, келәгә чыбык эленгән иде. Тәнзилә чыбыкны алып та тормады, ишекне шытырдатып тартып ачты да, чишенеп-нитеп тормастан ятагына барып ауды. Башы мендәргә тиюе булды, күзләрдән яшь сытылып чыкты. Өйдә ялгызы булгач, һич тыелмыйча үкси үк башлады.

Нигә болай рәхимсез син тормыш? Бер гаепсезгә рәнҗетәсең түгелме?

Үкси-сулкылдый, инде туктыйм дисәң дә туктап булмый иде.

Шунда ян тәрәзәгә чиерттеләр.

Заhир!

Тәнзилә атылып өй алдына чыкты, эчке келәне әлә-әлә сулкылдаулы-чыелдык тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Ник килдең? Кит тизрәк!

— Бигрәк матур сайрыйсың, Тәнзилә. Әбине генә түгел, күршеләрне дә уятып бетерәсең ич. — Заhирның тавышы шаян-тыныч иде.

— Мин... теге вакытта ук әйттем. Озатма мине, йөрмә дидем. Ә син... Барысы да синең аркаңда. Ниләр генә ишетәм! Ниләр генә... Кит тизрәк!

— Тәнзилә!

— Кит диләр сиңа!

— Бер генә минутка чык әле, Тәнзилә, әйтер сүзем бар.

— Туйган мин сүзләрдән. Гарык! Хәзер үк китмәсәң... Әнә, әбинең самовары кайнап утыра, орам өстеңә кайнар су!

Авыр сулау ишек аша да Тәнзиләнең битенә генә килеп бәрелгәндәй булды.

— Нигә яратмыйсың икән син мине, Тәнзилә?

— Безнең ул турыда сөйләшкәнебез дә юк. Сөйләшәсем дә килми. Бар, кит!

Тып-тын булып калды. Бакчада яфраклар гына леперди иде.

— Заhир!

Җавап булмады.

— Заhир, нинди әйтер сүзең бар иде? Ишек аша гына әйтсәң дә була, әби өйдә юк ул.

Тагын яфраклар гына лепердәшеп җавап бирде.

— Заhир дим!..

Тәнзилә каударланып ишекне ачты. Киткән. Аяк тавышлары да ишетелмәде бит үзенең.

Йөгереп капка төбенә чыкты. Әнә чатка җитеп килә. Әллә ничек, картларча аркасын бөкерәйтеп, акрын гына атлый.

— Заhир!

Тавышы бөтен урамны яңгыратса да, егет борылып карамады.

Шуннан соңгы көннәр аз гына да хәтердә калмаган. Эштән кайткач, китап, газета укый язса кул эше тота иде бугай.

Беркөнне ишек ачып керүгә, борынга тәмле мич ризыгы исе килеп бәрелде, өй эче мамыклы-рәхәт җылы иде. Әнисе килгән! Көндез үк килгән икән инде, кызын эшеннән бүлмәс өчен хәбәрен салмаган, авылны әйләнгән, мичкә ягып, бәлеш салырга да өлгергән.

Тәнзиләнең ничәмә көн инде хаҗәтеннән гайре бер сүз сөйләшмәгән теле өзлексез тәтелди башлады. Бөтенләй сабый чаклардагыча, әнисе почмак якка чыкса да аңа иярә, өйалдына чыкса да.

Табынга утыргач та тәтелди башлаган иде, әнисе күзләре белән хуҗа әбигә ымлап куйды. «Колакка сак кеше алдында икәвең генә такылдап утырмыйлар» — дия иде ул, кызына шуны искә төшерүе иде бугай.

Әби, догасын укып, битен сыпыргач, рәхмәтләрен яудыра-яудыра почмак якка чыгып китте. Икәүләшеп тыз-быз килә-килә өстәлне җыештырып алгач та әле бераз тын гына утырдылар.

Әнисе сиздермәскә тырышып кына көрсенеп куйды.

— Абыең сүзен тыңламыйча, хаталангансың бугай син, кызым.

Әйе, техникумның соңгы курсына күчкәннән бирле әйтә башлады олы абыйсы: «Минем белән киңәшмичә, эшкә направление ала күрмә» — дия иде. Тәнзилә, күп иптәш кызлары кебек, эшкә авылга китәргә ризалыгын биреп кайткач, абыйсы алай бер дә күтәрелеп бәрелмәде тагын үзе, серле генә көлемсерәде. «Бәхетеңне кайда табасыңны

белүе кыен инде ул»,— дип куйды. Әнисе дә кызының авылга китүен бары хуплады гына. Инде менә.

— Нигә алай дисең, әни?

— И кызым, үзең бер дә сизмисеңмени соң? Башыңны ашаматайлары синең монда.

«Ишеттергәннәр... һай, ничегрәк итеп сөйләделәр икән?»

— Әни, бер кыз, көнчелегеннән, минем турыда җыен гайбәт таратып йөри монда. Ышанма син аларга, әни.

— Мин ышанмыйм да бит... һәр гайбәт төбендә ниндидер мәкер ятә диләр. Шуны бел син.

— Нишләргә соң?

— Монда киткәндә, абыең әйтеп калды. «Шәһәргә кайтам дисә, эшен дә табам, бөтен кәгазьләрен дә үзем рәтлим» — диде. Уйлап багасың мәллә?

— И әни...

Әйтер сүзләре артык күп иде Тәнзиләнең, тик ибе-җеге белән генә телгә килми торды. Абыйсының «Бәхетеңне кайда табасыңны белүе кыен инде ул»,— диюе генә күңелдә кабатланды.

Әнисе бу авыр-четерекле сөйләшүне тизрәк икенчегә борды. Күңелле генә итеп, оныклары турында, авылда булып алган мәзәгрәк хәлләр турында сөйләп китте. Сүз арасында гына әйтте:

— Онытып торам икән. Бүген кибеттә сезнең заводтан Мәгъфурә атлы бер хатын белән әллә ничек кенә танышып киттек тә сөйләшеп тордык. «Кичкә кызың белән бергәләп килеп утырыгыз» — дип тә әйткән иде ул.

— Нигә, әни, барып кайтыйк. Вакыт соң түгел бит әле. Бик әйбәт апа ул, Мәгъфурә Сабировна.

— Әйбәттер дә... Читтән улы кайткан диделәр аның бүген. Егетле өйгә кызың белән кунакка килү бер дә килешмәс ул. Аманәт сүзне җиргә салмыйм дип кенә әйтүем.

«Ни арада бөтен авыл хәбәрләрен ишетеп тә өлгергән».

— Минем дә... Бәлки Мәгъфурә Сабировна белән киңәшләшер идек, диюем иде.

— Кеше белән киңәшкәнче башта үзең ныклап уйлаганың хәерле, кызым.

Уйлады Тәнзилә. Төн буе, башкайлары берни дә уйлый алмастай дәрәҗәләргә җиткәнче уйлады.

Иртәгесен әллә уяулы-йокылы ята, әллә һаман да керфеккә керфек какмаган идеме, әнисе аңа дәште:

— Кызым, кузгалыйм инде мин. Көтүләр кереп, мал-туарны урнаштыргач, иркенләп килермен. Юкса, киленгә, эш кешесенә, йортта берүзенә бик кыенга килә.

Тәнзилә ялт сикереп торды.

— Әни, мин сине озата барам.

— Ай, кызым, эшеңә соңга калмагаең.

— Мин авылны чыкканчы гына.

Авылны да чыктылар, тукталышка да җиттеләр, автобус килүгә, Тәнзилә әнисе янына менеп тә утырды. Ананың аптыраулы, хәтта куркулы карашын кыска гына җаваплады:

— Абый барысын да үзем җайлыйм дип әйтте диден түгелме соң үзең?

## VIII

«Үзем җайлыйм» дип, җиңел генә әйтсә дә, абыйсы, моны көйләү алай ук ансаттан түгел иде, ахры, Тәнзилә шәһәрдә шактый озак кунак булды.

— Бер дә борсаланма, өлгерерсең камыт кияргә,— дия иде абыйсы, бик киң күңелле елмаеп. — Укып бетергәч тә җүнләп ял итә алмадың. Иркенләп күңел ачып алсаң, эшеңә файдасы гына тияр.

Җиңгәсе дә аз гына да тарсыну күрсәтмәде. Тәнзилә идән юарга, җәймә-пәрдәләрне уарга җыена башласа, эшен кулыннан тартып ук алгалады.

— Үзем өлгермәслек бер эш тә юк безнең өйдә. Кулларыңны ямьсезләргә ашыкма әле син. Абыең дөрес әйтә: кыз балага сәламәтлеген дә, матурлыгын да, нервыларын да саклый белү бик кирәк. Рәхәтләнеп ирек ач.

Ирек ачарга исә шактый шарты килгән иде бу өйдә. Шәһәрдән әллә ни ерак түгел бакчалары, бакча уртасында әкияттәгедәй матурлап бизәп эшләнгән дачалары бар, бакчада инде бар эшләр төгәлләнгән, авызыңнан сулар китерердәй алма өзеп ал да, көзге кояшка битеңне куеп, гамакта тибрәнә-тибрәнә, татлы хыялларга чум; өйдә төсле телевизоры, татарчасыннан, русчасыннан, чит илнекеннән иң матур көйләр язылган магнитофоны, салават күперенең бар төсләрен серле генә балкытучы затлы торшеры, аякларыңа килеп сырпаланырга гына торган иркә-йомшак соры песие... Ял итәр кешегә тагын ни кирәк?

Ә һәр шимбә яисә якшәмбенең кичендә зәвык белән җиһазланган бу ягымлы-тыныч өйгә өч-дүрт пар кунак җыела, табын телеңне йотардай тәгам-ризыклар белән тула (җиңгәсенә «атказанган кулинар» дигән хөрмәтле исем һич тә юкка гына бирелмәгән), салмак танецлар, уен-көлкесе чамасын белеп кенә яңгырап тора.

Булачак ире Мәҗит белән әнә шул мәҗлесләрнең берсендә очраштылар инде алар. Озын буйлы, гәүдәсен алгарак тартып атлый, яшькә шактый ук өлкәнрәк булса да, Тәнзилә белән сөйләшкәндә, каушабрак кала, борын тирәләрендәге вак шадралары алсу-кызыллыкка күмелә, оялчан булса да, табында урыннары гел янәшә туры килә иде аларның.

Шәһәр урамнарында килеп сарып йөрүне күңеле һич өнәмәсә дә, аяклары бер юлдан бик теләп атлый иде Тәнзиләнең. Ул — автовокзал юлы. Биредә башлыча авылдан килүче-китүче халык була, шуңадыр инде дисә... Бәй, баштарак үзе дә төшенеп җитмәгән, Заһир килмәсме, ул очрамасмы дип йөрүе ич аның бирегә.

Заһир килмәде, очрамады.

Бер көнне вокзал ыгы-зыгысында Тәнзилә әллә кайдан ук Дамирны күреп алды. Очар кош тизлеге белән килеп тә җитте, егетне кочаклап ук алды.

— Ни хәлләрең бар, Дамир? Һай, Дамир...

— Хәлләр бер көе генә. Сине бик сагынабыз.

— Качкын кызны бик сагынып тормыйсыздыр әле. Ниме... Шуны сорыйм дигән идем... Клубта уеннар буламы?

— Булуын була... Тик синнән башка җаны юк ни уеннарның, ни танцыларның.

— Шулай дигән бул. Ниме соң... Заһир да чыгамы клубка?

Дамирның һич сүнмәскә балкыган йөзе җитдиләнде.

— Заһирның аның... Мөшкелләнебрәк китте бит әле хәлләре.

— Һай, нәрсә булды?

— Әнә тегендә урын бушады. Утырып сөйләшик әле.

Килеп утыргач та Дамир тиз генә сүз башламады. Озаклап, матур каплы сигарет ачып маташты.

— Син киткән кичне бугай, Заһир клубка салган баш белән килеп керде. Бер тамчы капмый иде бит ул, эчми эчкәнгәдер, яшел елан тәмам акылын алган моның. Керде дә... урындыкларны аудара-тибә фойе уртасына килеп басты. Яшьләр, тәмам аптырашып, бер мәлгә баскан урыннарында катып калдылар. «Менә бу кыз,— ди Заһир, Мәрзиягә

күрсәтә,— минә кыйнады дип, минем турыда ялган гайбәт сатып йөри. Инде шаһит булыгыз, хәзер мин нахак сүзне чынга әвереләдерәм, сөякләрен капчыкка тутырып җибәрәм »,— ди.

— Һай, әллә чыннан да кыйнадымы?

— Мәрзизәгә чуртым да булмады ла. Чәрелди-чәрелди кызлар арасына кереп качты. Ә менә без, егетләр, Заһирны тынычландырмак булып, урап алган идек, ян-якка әйләнеп барып төшкәнебезне сизми дә калдык. Көч тә бар икән үзендә. — Дамир кашлары җыерылган көйгә елмаерга тырышты. Бу исә аның йөзенә елаган төс кертте. — Менә бу як кулбашым әле һаман да авыртып йөри.

— Шуннан, шуннан?

— Шуннан милиционер килеп җитте. Заһир шунда кызган кулдан аны да селтәп җибәрмәсенме...

— Һай, нигә инде...

— Әнә шул башсызлыгы харап итте дә инде егетне. Без инде андамонда шаулап та йөрмәс идек.

— Дамир, ниме... Карамалыга автобус кайчан була икән?

— Нигә ул?

— Барам да әйтәм милициягә... Әшәке гайбәт аркасында гына алай ярсыган ул Заһир. Чынлыкта, һич тә хулиган түгел. Барысын да сөйлим, аңлатып бирәм. Моны... моны бәлки мин генә аңлатып бирә аламдыр. Әйт инде, кайчан була автобус?

— Ай, Тәнзилә! Бигрәк беркатлы син. Милициягәме, хезмәт вазифасын үтәүче бүтән берәүгәме кул күтәрүгә бик каты ул закон. Инде суд булды. Бер елга утыртып куйдылар егетне.

— Дамир, әллә Верховный судка язып карыйкмы?

— Язарга була. Ләкин, белмим, файдасы тияр микән? Әйтәм бит, хезмәт вазифасын үтәүче кешегә кул күтәрү...

— Без бик аңлаешлы итеп язарбыз. Анда да бит кешеләр утыра. Ничек тә аңларлар.

— Ул кадәр өзгәләнмә әле син, Тәнзилә. Безнең язганны тикшереп очына чыкканчы, егетебез ялт итеп кайтып та җитәр әле. Үзен тәртипле генә тотканнарны ярты сроктан азат итәләр ди бит... Әйдә, Тәнзилә, ресторанга кереп чыгабыз.

— Рәхмәт. Мин өйдән ашап кына чыккан идем.

— Алайса, әйдә, киногa керәбез.

— Барасы җирем бар иде шул минем. Кузгалыйм. Хуш иттек, хәзергә, Дамир!

Шимбә көн иде бу. Кичен тагын кунаклар җыелды. Тәнзилә мәҗлестә гомерендә беренче мәртәбә авызына шәрап капты. Тулыр-тулмас бер рюмкадан кызып алдымы, барысыннан да уздырып көлде, шаярды, җырлады. Берәм-берәм ир-ат кунакларның барысы белән дә биеде, кеше-кара күрмәгәндә, Мәҗитнең кызгылт шадраларыннан үрелеп кенә үбеп алды.

Шуннан соңгы көннәр... Шуннан соң җир туңдырды, сөякләргә үтәрдәй салкын җилләр исә башлады. Бакчага йөрү түгел, урамга да чыгасы килми, өйдә магнитофон язмалары, хәтта матур обойлы стеналарга кадәр туйдырып бетерде, юанаеп алган соры песи дә, аякка килеп сырпаланудан бигрәк, йокы симертүен белә.

Бәлки абыйсы белән җиңгәсе шулай хәстәрен күргәндер, Тәнзиләнең эшкә урнашуын билгеләп үтү һәм аларның Мәҗит белән ярәшү туйлары бер кичне үтте.

Мәҗит эшләгән оешмага ук урнашты ул. (Абыйсы да шушы оешмага бәйле эштә.) Бу олы оешмада күп төрле белгечләр эшли, Тәнзилә үз бүлегендә сызым-кәгазьләргә күмелеп утырса, Мәҗит, терлекчелек белгече буларак, бик еш районнарга командировкаларга йөри.

Язмышына зар-тел тидерү гөнаһ булыр иде, әйбәт кенә яшиләр алар. Тик менә... Мәҗит аңарчы бер өйләнгән булган инде, моны ул туйлар узгач кына әйтте.

## IX

— Тәнзилә-әү! Су кайнап бетә инде монда, гөлҗимешеңне кайчан китерәсе-ең!

Ашыгуыннан куак энәләре бармакларын чәнчеп бетерде, эреле-вакы бер уч гөлҗимеш күтәреп, учак янына килсә, Мәҗит инде чәйгә мул итеп гөлҗимешен, карлыган яфрагын да салган, каен төбенә целлофан эскәтер җәеп, табын да әзерләгән. Балалар да килгән, ачыгулары җиткән сабыйларның, сөйләшми-нитми ипи белән колбаса бөгәләр.

— Мин... су коенып чыктым анда. Инде дә җылылыгы сүнең!

— Әйтәм җирле, чуптыр-чуптыр йөзгәнең ишетелеп торды... Әйдә, табынга утыр.

— Әбәү, Мәҗит, чалбар балагыңны һаман чистартмагансың.

— Аңа вакыт тимәде әле монда. Эш муеннан булды.

Табын яныннан кузгалгач кына Мәҗит балакларын чистартырга утырды.

— Тигәнәк дигәннән... Мин бая әйтеп бетермәдем, шушы тигәнәк аркасында, дөресрәге, тигәнәккә бәйле рәвештә, бер совхоз директоры бөтен республикада дан алды.

— Тигәнәк тә дан китерер икән.

— Китерә икән шул. Сезнең сарык асраган булдымы?

— Әти исән чакта асрый идек.

— Алайса, башыңнан кичкәндер, йонын кыркыр алдыннан, сарыкны тигәнәктән чистартып, ни изалар чигәсең. Ни тырышсаң да, бөтенләй чүпләп бетереп булмый, йонның күпмесен ташларга гына кала. Ә менә Карамалының сарыкчылык совхозы тапшырган йонда бер тигәнәк әсәре күрмәссең. Ничек ирешәләр моңа дисәң — бер киңәшмәдә директор үзе сөйләде — эрекмән тигәнәк җибәрүгә, көтүлеккә казлар кертәләр икән, бик ярата икән казлар тигәнәкне. Менә бит... Исләрең дә китәр табигатьтәге гармониягә.

— Минем дә ишеткәнем бар казларның тигәнәк яратканын. Шунда, Карамалыда ишеткән идем.

— Между прочим, анда эшләгәч, бәлки совхоз директорын да беләсеңдер әле син. Шул авылныкы ул. Заһир Габбасов.

— Беләм... Заһирны.

— Белсәң, сер итеп кенә әйтим, хөкүмәтнең зур бүләгенә тәкъдим ителгән ул егет. И достоин! Бөтен районда белмәгән кеше юк үзен.

— Синең юрауларың дөрескә чыга иде гадәттә.

— Бар андый сизгерлегем. Киләсе атнада Карамалыга командировкага барасым бар. Синнән сәлам тапшырыйммы Габбасовка? — Мәҗит, учактан кисәү алып, сигаретына ут элдерә, төтен керепме, бер күзе кысылган иде.

— Мәҗит... Мин тагын бер су коенып киләм.

Бая дөрес ялганлаган икән, су, чыннан да, гаҗәп җылы иде. Тәнзилә агымга каршы йөзеп китте, малайлар кебек чумып, су астыннан да әллә ни кадәр ара үтте.

Судан чыгуга, бизгәк тоткандай калтырый башлады, бөтен тәненә «каз ите» чыкты. Халатын төймәли-төймәли учак янына йөгерде. Учак сүнеп бара иде инде. Күмерләр соры бәрхет белән өртелгән, сыңар кисәү генә тәмәке төпчегедәй нәзек төтен пыскыта. Мәҗит «Жигули» астына кереп яткан да, мыш-мыш килеп, анда нидер боргалый.

— Мәҗит! Дөрләтче утыңны. Туңдым мин.

— Су бик жылы дигән идең бит.

— Су жылы-ы... Чыккач кына туңдыра... Җанны өшетә.

— Син, җанкисәгем, үзең генә дөрләт инде анда утны. Җылынырга әйбәтрәк була ул. Борып бетерәсем бар минем монда. Утырып калмагаек юлда.

Тәнзилә урыныннан кузгалмады. Шулай дерелдәп утырса, эченә җылы нигәдер тизрәк төшәр кебек тоелды. Кинәт колак төбендә генә кемдер кинаяле пышылдагандай булды: «Дерелдисеңме? Дерелдә, кызый, дерелдә».

— Мәҗит!

— Ну?

— Карамалыга барсаң, берәүгә дә сәлам әйтмә син анда, яме.

— Әйтергә кушканың да юк ла.

— Бер үтенечем генә бар.

— Ну?

— Хәтерләсәң, сөйләгәнем дә бар. Бер апа сукыраюдан йолып калды анда мине. Тайбә апа. Исән микән әле ул — шуны белеш.

— Ходайның рәхмәте белән исән-сау булса, нәрсә әйтергә?

— Нәрсә әйтергәме?.. Юк, берни дә әйтмә. Әгәр исән-сау булса, янына үзем барам. Берәр затлы бүләк тапшырасым, тагын мең-мең рәхмәтләремне яудырасым бар.

— Алай... Миңа сумкадан карга борынын алып бир әле. Каен төбендә.

Тәнзилә сумкадан кулына беренче эләккән тимер алып, Мәҗиткә сузды. Зур гына гайка ачкычы шунда ук машина астыннан кире очты.

— Син, нәрсә, шешле сораганга без тоттырасың миңа. Карга борынын алып бир. Плоскогубцы.

Тәнзилә иренең сүзләрен әллә ишетте, әллә юк, сүнеп баручы учак янында утыра бирде.

— Мәҗит, Тайбә апа турында белешергә онытa күрмә Карамалыда. Һай, исән-сау гына булсын иде дә, барып кайтсам иде янына.

Мәҗит машина астыннан чыкты, каен төбендәге майлы сумкада актарынгач, янадан машина астына иелгән иде, тукталып калды, килеп, учакка чыбык-чабык өстәде. Чыбыклар чи идеме, ут тиз генә дөрләп китмәде. Мәҗит, озын буен уңайсыз гына бөгеп, учакка өрә башлады.

## Клара Булатова

### Уйландыра, шушы уй яндыра

Тәгәрәпләр йөгереп үтә гомер,
Җир шарыдай юл түгәрәк түгел,
Димәк, аның чиге бер булыр...
Тәгәрәпләр йөгереп үтә гомер.
Үзеннән соң калган чиксезлеккә
Без үткәргән гомер ни бирер?

Уйландыра, шушы уй яндыра,
Ми-йөрәгең эштә чагында,
Хәрәкәтләнерлек хәл барында,
Әрәм итмә көнең, (Чикле гомерең!)
Яшәвеңнең юкка түгеллеген
Раслап яшә вакыт алдында,
Раслап калдыр Тарих алдында!

### Искәртү

Ел арты еллар Вакытта
Тезелеп үтеп бара.
Һәр киткән елның Тарихта
Үзенең эзе кала.

Ә җирдә күпме ямаулар,
Хәтердә күпме яра!..
Искесе үтми, яңалар
Өстәлеп туа бара.

Кайдадыр өйләр ишелә,
Җимергеч дулкын йөри.
Кайдадыр кеше кешегә
Корулы мылтык төби.

Шәфәкъләр кучкыл буяла,
Афәтләр ялкынымы?!
Кешелек! Кайтар дөньяга
Сәламәт акылыңны!

### Анаң көтә, хат көтә

Ап-ак, ап-ак кар төшә,
Каплап капка башларын.
Анаң көтә, хат көтә,
Солдат улы хатларын.

Зәңгәр-зәңгәр су китәр,
Юып капка асларын.
Анаң көтәр, гел көтәр,
Солдат улы хатларын.

Алсу-алсу гөл үсәр,
Бизәп капка артларын.
Анаң һаман хат көтәр,
Солдат улы хатларын.
Карап карлар ятканын,
Озатып сулар акканын,
Анаң көтә янына
Солдат улы кайтканын.
Үз янына кайтканын.
Үз ягына кайтканын.

●

Син күнеккән идең җиңәргә,
Туры килә кайчак чигәргә.
Ә шулай да елау ник кирәк?
Хак-табигать синнән көчлерәк.
Яз ясамас күздән күз яшең,
Күз яшеңне дөнья күрмәсен.

●

Дан алам дип «ах» ормады,
Яшәде аннан башка.
Сикермәде, үрелмәде
Буе җитмәс агачка.

Иген икте — үрелми дә
Җитә иде буйлары.
Дан китерде гомеренә
Җиргә биргән еллары.

## Сәвәләйдә казаяклар үсә

Сәвәләйдә казаяклар үсә,
Әби чәче тузгып утыра,
«Әби чәчен берүк җыя күрмә,
Кара кайгы килер йортыңа!..»

Кара кайма белән уратылган
Рәсем ята өстәл өстендә:
Казаяктай чиста җан шагыйрьнең
Ак чәчләре кылган төсендә.

Нурлый карчык шулай дигән иде,
Өзмәгән дә идем кылганны.
Кайгы килгән, йортым гына түгел,
Каплап бөтен якты дөньямны.

Ап-ак чәчле кылган өзелә-сибелә,
Казаяклар үкси туктаусыз...
Ярый әле чын шигърият үлми,
Нишләр иде дөнья Туфансыз?!

## Ялгыз янам

Килмә дә син,
Йөрмә дә син,
Кермә дә тормышыма,
Исемеңнән юанып яшим —
Һәм ризамын шунсына.
Килмә дә син,
Йөрмә дә син,
Күрмә дә яшьләремне,
Таң җилләре генә белсен
Син диеп яшәвемне.

Килә күрмә,
Белә күрмә,
Карый күрмә күземә,
Йөрәгемнең ялкыннары
Кабынмасын үзеңә.
Карый күрмә,
Аңлый күрмә,
Белми яшә, бул тыныч!
Ялгыз янам — яшерә алам,
Бергә янсак, куркыныч.

## Көнбагыш кояшка бага

Көнбагыш кояшка бага,
Айбагыр — айга.
Тал-тирәк суга иелә,
Мин сиңа таба.

Тау-кыя күккә үрелә,
Кошлар да шулай.
Ә минем үрелер кыйблам
Һаман син бугай.

Иелмәс башым иелде
Синең алдыңда.
Түгелмәс яшем түгелде
Синең кайгыдан.

Саргаймас йөзем саргайды
Синең сагыштан.
...Күңелем риза, зарланмыйм,
Шушы язмыштан.

## Венера Туктарова

# КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР

●

Кешеләргә карап көләм,
Аларга карап җылыйм,—
Җылаган минутларда да,
Яшәү, мин синнән туймыйм.

●

Кая киткән яшел келәм, кем күрде?
Болын өсте — ак пәрәвез,— кем үрде?
Шул ук кояш күк йөзендә. Ник түбән,
Әллә язын җирне артык күп сөйгән?..
Ишетелми кошлар җыры, ни булган?
Уятмасак та... йокыдан, көз торган.

●

...Дөньям, дисең, түгәрәк;
Нинди көчләр сине кайчан
Уттан саклый, күбәләк?

●

Ах, ул күзләр!
Күпме яну, күпме сагыну анда,
Күпме әрнү, күпме сагыш бар.
Үтәр идем күрми, аңламыйча,
Йөрәгемә...
Йөрәгемә артык танышлар.

●

Соры болытлардан ак кар ява.
Кар түгел, юк,
Күк шулай сөйгән җиренә
Туңмасын дип, тун яба.

●

Күзләреңне күргән чакта
Кирәкми иде сүзләр.
Күзләр ерак, сүзләр дә юк,
Шулмы әллә, мәхәббәтем,
Сиңа киләсе көзләр?

●

Сине мин сирәк күрәм.
Күзләрең һәркөн үбәм...

●

Йолдызларда без гел бергә,
Җирдә генә аерым,—
Гаҗәпләнмә елмаюын
Күреп ялгыз каенның.

●

Җәй арыды.
Яфракларны җиргә койды.
Җилләр...
Җилләр авыр сулап куйды.

●

Мин суларның сөйләшкәнен тыңладым,
Мин бары тик берничә сүз аңладым;
Ул сүзләргә кушылды тал, зирек тә:
— Яшәү татлы, диде алар, иректә!

●

*Сугыш үткән җирдә урман үсә.*

Халык сүзләре.

Әллә урман шаулый, әллә инде
Кемнәрнеңдер үткән гомере;
Салкын кардан арынып килгән җиргә
Нидер сөйли кебек һәр бөре.

●

Хыялларым — гомерем юлдашлары,
Сезне үземнән артык яратам.
Саргаермын кемнәрнедер сагынып,
Сезне беркайчан да саргайтмам.

Әхәт Гаффар

# БОДАЙ БӨРТЕГЕ ҺӘМ ТЕГЕРМӘН ТАШЫ

РОМАН



Су астында — чишмә, юл астында — сукмак, вакыт астында хәтер күмелеп ята. Су — җирнеке, юл — кешеләрнеке, хәтер — киләчәкнеке. Томаланган күзле чишмәләр, күктәге йолдызларын югалткан сукмаклар, яшьлегенең бар газабын гомеремнең текә тавына тәгәрәтеп мәңгерүче хәтер — минем җанымның мәңгелек йомгагы... Тик ул мәңгереп җиткерәм дигәндә генә тәгәри дә төшә, тәгәри дә төшә. Яңадан башлыйм.

Гомеремнең ташлы-туфраклы кыясыннан яшьлегемнең яшел болынына кире тәгәрәп төшәм дә су астында калган чишмә күзенә багып утырам, бармак битләрем белән беренче сукмагымның җылы, шома ташларын тузаннан чистартам.

Мин картлыгым белән яшьлегем арасында торам. Хәтерем әйләндергән тегермән ташлары арасындагы бодай бөртеге — әйе, ул — мин.

Алып көчәнүе белән хыялымның һәр атомын киерелеп күтәрәм дә аягыма басам, ләкин мин барыбер тегермән ташлары арасындагы бодай бөртеге генә. Җир тегермән ташының — берсенә, ә Кояш икенчесенә әверелә. Шулар арасыннан утлы он агымы булып кысылып чыгам да гомерем галәменә яшәгән көннәрем, эшләгән эшләрем йолдызлары булып таралам.

Мин хәтерлим.
Мин хәтерлим — димәк, яшим.
Мин хәтерлим — димәк, көрәшәм.
Мин хәтерлим — димәк, җиңәчәкмен.

## I

Үгез көтүе, кара болыт өередәй, көтмәгәндә урман читеннән килеп чыкты да күпергә бәреп керде. Һәммәсе дә аклы-каралы, бер зурлыкта, тыелгысыз, ярсу гайрәт белән тулы. Башларын игәннәр, кыска мөгезләре һаваны ерта, күз алмаларында чатнап торган яшен ташлары. Киерелеп ачылган борыннар, селәгәйле авызлар, юлны дерелдәткән тояклар, резиндай тыгыз койрыклары үз тәннәрен камчылый, караларының тимерче сандалыдай маңгайларында — ак, акларының күкрәкләрендә кара калканнар. Аяклары кыска, кәкре, мускуллары тупас, тире астына таш тыгып куйганнармыни. Сизелер-сизелмәс тирбәлгән рәшә аша мәр-

мәр дулкын булып якынаялар. Бу ташкын каршында безнең кара «Волга»быз асфальт җәйгеч каток таптап узган коңгыз хәлендә калыр кебек. Мин кайсыдыр ил музеендагы (Берлинда бугай) Аллалар белән Алыплар сугышы тасвирланган ватык мәрмәр барельефны яңадан күргәндәй булдым. Егерме-утыз адым алдарак ялтырап яткан авыл юлына төшеп туктарга өлгердек. Ул барельефтагы сурәтләр нәкъ менә шушы куәтле үгезләргә әверелеп, җиргә иңгәннәрдер кебек. Күктән сөрелгәннәр җиргә иңә, югарыдагылар түбән тәгәри, бары тик җирдәгеләрнең генә китәр урыны юк. Ә юк — мин кемдер яки нәрсәдер булып яңадан яратылырга риза...

— Сугымга куалар,— диде Исмәгыйль.— Миллион шашлык!

— Шашлык?— дидем мин, үз уем белән Исмәгыйль сүзе арасындагы ераклыкны күзалларга тырышып.

— Сугымга — кая булсын ди тагын. Сентябрь ич, квартал ахыры... Тере үгез булып керәләр, колбаса булып чыгалар. Се ля ви! КамАЗда гына түгел, анда да конвейер. Фән-техника прогрессы. Хәзер боларны да әүвәлгечә кувалда белән түгел, ә ток белән генә сугып егалар.

— Ток белән?— Исмәгыйльнең сүзе минем йөрәгемә чыннан да токлы инәләр өере шикелле килеп кадалды.

— Соң! Хәзер итчеләр врачлар белән бер — ак халаттан, резин перчаткадан. Тыныч, чиста. Ни үкереш, ни кан.

Үгез көтүе, ярларыннан ташып чыккан елгадай, урманны ерып узган юл буенча акты да акты. Тояклары астында гүләгән җир агачларны калтыратты, яфраклар коелышты, соңгы чикләвекләр дә кубып төшкәндер.

— Карале, Исмәгыйль...

— Әү, Ислам Имамович!

— Бу юл кая илтә икән?— дидем мин, ялтырап яткан авыл юлына ишарәләп.

— Урманга ич.

— Син ераккарак кара.

— Берәр авылгадыр... Анда язылган.— Исмәгыйль аермага әйләнеп карады, авыл исемен атады.

Урманда барганда, иңемә селәүсен сикердемени: бөтен тәнем шул көтелмәгән һөҗүмне кире кайтарып, ерткычны каерып атар өчен җыерылып килде кебек. Исмәгыйль күрмәде, ул кызларныкына охшаган сагышлы күзен үгезләр буенча йөртә — вокзалга килеп кергән поезд вагоннарының тәрәзәләрендә таныш йөз эзлимени.

Авыл исеме күңелемдә кире кайтмас бәхет, кабатланмас беренче сөю, онытылмас хыяллар булып, җәйге рәшәләр, язгы кар төсле балкып китте, әллә нинди — үткән гомерләрдән дә арырак ераклыктан үзенә дәшеп тора башлады. Сулаган һавам кысылып, әйләнә-тирәмне көпшәк бер нәрсә уратып алды. Шом басты, күңелемне сагыш сарды, онытылган истәлекләр уянды, һәм алар, корама юрган булып, мине баштанаяк каплап ташлады.

Җиде мең елдан соң кемгә һәм нәрсәгә әйләнермендер — билгесез, әмма хәзер мин үземнең үткәнемә үзем булып кайтып төштем! Кырык биш елдан соң нәкъ элеккеге хәлемдә. Язмышмы, нәрсә бу? Кызык. Кабергә төшеп ятасы урынга бишеккә менеп чайкалган шикелле.

Әйе, киләсе елдан Исмәгыйль атаган авылдан ерак түгел атом электр станциясе корыла башлый, мин — шул төзелешнең башлыгы...

Үгезләр узып киткән иде инде. Һавада аларның җылы исләре генә калды.

— Исмәгыйль, шунда кереп чыгыйк әле.

— Ни калган анда?— Исмәгыйль, дулкын-дулкын кара чәчле мәһабәт башын тәрәзәдән чыгарып, артка каерылып карады һәм, ачкычны борып, стартерга басты.— Кузгалабыз,— диде ул, күчергечне тоташ-

тырып. Тормоз педаленнән аягын күтәрә төшсә, хәзер без, янтаеп, асфальтка менеп китәргә тиеш идек.— Тагын йөз егерме чакрым кайтасы әле.

— Ул авылда минем яшьлегем калды, Исмәгыйль.

— Син анда тумаган ич, Ислам абый.

— Кешенең туган җире, Исмәгыйль, беренче тавышы чыккан, беренче эзе калган җир генә түгел. Аның хакында беренче яхшы сүз чыккан җир, кемдер аны беренче сөйгән җир — менә кайда ул кешенең туган җире.

Кузгалып киттек. Юл урманны кисеп сузылган югары көчәнешле электр үткәргече астыннан уза. Машина көпчәкләре астында имән чикләвекләре шартлап ярыла, артта сары яфраклар өермәсе тузгып кала.

— Авыл күченеп бетте микән инде?— дидем мин.

Исмәгыйль машинаны туктатты.

— Кыям Сөләйманович белән кайткан идек. Аталары үлгәч, җирләргә. Зиратлары да яңа инде. Авыллары күченгәнче, зират күчте.

— Вакытны сузма, алга,— дидем мин.— Зиратка.

— Зиратка?— диде ул кинәт миңа текәлеп.

Сигарет кабыздым, тирән итеп төтенне эчкә алдым да, кулым белән изәп:

— Зиратка,— дидем.

— Кайсысына?— Исмәгыйль тагын күчергечне этәрде, тик тигез генә кузгалып китә алмады, машина үкереп куйды.

— Миңа яңасына иртә әле, Исмәгыйль. Искесенә, искесенә.

— Берәр туганың күмелгән идеме әллә?

— Әйттем ич инде: яшьлегем. Минем бу авылда яшьлегем калды, Исмәгыйль.

Күзләремне ак каеннар аклыгының караш житмәс аръягына төбәп, сүзсез калдым. Берни уйламадым шикелле. Кинәт аңлатып булмас дәрәҗәдә ак каеннар арасыннан яшел яулыгын селки-селки каршыма Кәүсәриянең йөгереп чыгуын күрәсем килеп китте. Бөтен хыялымны бер ноктага, бер тойгыга, бер теләккә юнәлдерә алсам, мин чигүле ак алъяпкычлы, чулпы таккан толымлы, дүртпочмаклап яшел яулык япкан, иңенә чиләк-көянтә аскан Кәүсәрияне хәтеремдә терелтә алыр идем микән? Көпә-көндез күргән шикелле ачык итеп. Ниндидер ерак, тоеп, ишетеп, кагылып булмый торган, мәңгелеккә югалган итеп түгел, моннан бөегрәк, эчтәлеклерәк, серлерәк, сәерсендерерлек, сөйләсәң, кеше ышанмаслык итеп. Йөрәк һәм күңел... әкияткә сусаган. Каршыга йөгергән ак каеннар аклыгының аръягыннан, сары урманның йомшак туфрагыннан тавышсыз-нисез Кәүсәриянең яшел яулык болгап килеп чыгуын бөтен җаным-тәнем белән генә түгел, ә әйләнә-тирәдәге һәммә тере һәм җансыз нәрсәләр ихтыяры белән телим. Бу теләгем чынга ашмастай хыял, саташу, акылдан шашу ук түгел әле. Әнә ич, урманны килеп чыктык та ямь-яшел уҗым басуына килеп кердек. Артта — йокыга китеп, хәтта ниндидер бөҗәкләре, үләннәре, җимешләре белән үлеп яткан сары урман, ә алда — ямь-яшел сулышы белән яңа терелеккә җан өрүче җир.

Авылны күчергәннәр... Бәлки анда мин төзегән станция дә җимерелгән яисә сүтелеп утынга ягылгандыр инде, әмма ул кешеләрнең чынга ашкан өмет һәм хыялларында, хәтерләрендә, баш очымдагы югары көчәнешле көмеш чыбыклар буенча өзлексез аккан электроннарда яшидер әле. Менә ич мин дә: кире кайтып килəм — кырык биш яшькә олыгаеп. Авыр, саллы башакта кырык биш орлыкка әйләнеп юкка чыккан чәчүлек бодай бөртеге шикелле.

...Кәүсәриянең кәфендә биләүдәге бала төсле ятканы күз алдыма килде. Кара чәче толымлап үрелгән, шуңа күрә ап-ак маңгае өчпоч-

маклы итеп төрелгән адрессыз хатка охшап калган. Ул маңгайга аның әйтеп бетермәгән соңгы сүзләрен укырга теләгән сыман текәлеп торам. Тик ул сүзләрне күрергә аның йөзендәге ниндидер тере хәрәкәт комачаулый, ул шуның белән үз үлеменә ышанмаска куша иде кебек. Аның йөзен мәңгегә кәфен белән каплап куялар. Ләкин иң соңгы мәлдә кап-кара кыйгач кашлары, канатларын киң җәеп җибәргән карлыгач шикелле, төпсез ераклыктан якыная башлый һәм минә кырык биш ел буена килеп җитә алмый оча да оча, оча да оча...

## II

Кояшка ачылыр-ачылмас карашы белән текәлгән тилгәнне хәтерләтүче кара «Волга»дан чыктым да яр маңгаена килеп бастым. Күзгә табигать чуарлыгына минем чал чәчем дә үз төсен кертәдер. Йомшак һавада пәрәвез җепләре йөзә. Алар әллә кайдан — рәшәләнеп торган чиксез зәңгәрлектән килмәгәндер, ә минем тузганак шикелле башымнан күтәрелгәндер сыман. Мин ачык төстәге костюмнан, яланаяк, кара күн туфлием һәм көрән оегым киселгән нарат төбендә. Өстемдә оегым төсендәрәк күлмәк, җиңнәрем сызганулы. Пинжәгемне, элмәгемнән элэктереп, егетләрчә иңбашыма салганмын.

Тау маңгаенда — гомеремнең иң биек ноктасыннан әз генә түбәндәрәк басып торам. Каршымда — инде үткән гомергә генә сыярлык киңлек. Киләчәк, мөгаен, түбәндәге инеш тарлыгында гынадыр инде. (Хәер, бу инеш тиздән су басып, хәтсез киңәячәк бит әле!). Күпмедер вакыттан соң бу елганың тузбаш еландай йөгерек агышын, көмеш төсмерен хәтерләүчеләр җир йөзендә бер дә калмас, ә бәлки һәр карыш җир кабер кебек кирәкле, кадерле заманнар җиткәч, инеш кешеләргә яңадан әүвәлге яшь, сылу тәнен күрсәтер? Көмешсу тәнен; яшь йөрәктәй тыелгысыз сулкылдаган бихисап чишмәләрен; саф күкрәкләрдәй тыгыз ак төнбоекларын; житү кызлар тешe сыман вак һәм ак ташлар чәчелеп яткан сай чыгышларын; чәч кыштырдагандай пышылдаучы төнге талларын...

Авыл хәзер урынында юк. Әйтерсең лә аны, нигезеннән тоташлай кубарып, «шайтан туе» зилзиләсе бөтереп алып киткән. Бөтен җирне, снаряд чокырлары шикелле, элекке корылмалар утырган урыннар шадралап тора. Бары тик тегермән һәм мәчет кенә тырпаешып калган. Мәчет артында яссы ташлардан өелгән тузанлы, урыны-урыны белән җимерек, инде кибеп беткән үлән һәм бер төштә кәрлә каен үсеп утырган зират. Снаряд чокырларына охшап калган ачык каберләр...

Заманында мин дә нәрсәне сүтәсен, кайда ни корасын сорап тормадым. Кайда ул теге — морзалардан калган күләгәле юкә һәм нарат аллеялары, түгәрәк көмеш сулы парк буасы? Парк эчендә кызлар төшереп калдырган яшел каймалы кулъяулык шикелле агарып торган камышлы күл? Ул чагында хәлал көчебез белән ясаганыбыз матуррак булыр дип үз-үземне аклый идем. Кайда ул — кешеләргә мин ышандырган матурлык, гүзәллек, рәхәтлек, ләззәт? Миннән ни кала монда? Станцияме? Ул юк инде. Тегермәнме? Аны сүтәчәкләр. Безнең кара буралы буабызмы? Ул күптән агып киткән. Бары тик ак кыялар агарып тора да тау үз урынында... Әйе, мин дә җиңүче идем. Ләкин җиңүчеләрне дә җиңүчеләр була икән ләбаса. Елганың аръягындагы тигез иңкүлектә тешсез әбиләрнеке шикелле кызыл авызын ачып, зәңгәр күк чоңгылына ялгыз курган карап каткан. Галәм чиксезлегенә тавышсыз гына нидер кычкырамыни. Бульдозер белән яшел битен ертып, археологлар аның эчендәге хәзинәләрен алганнар. Инешнең яшел ярлары, сары, соры комлыклары кара тамгалар белән чуарланган: яр буендагы таллыкларны, әрәмәлекләрне кисеп якканнар. Нәкъ

без тараткан инструкция таләп иткәнчә! Чөнки бу елга, бу үзәннәр һәм бу кырлар су астында калачак. Азат Чулманны кешеләр тагын бер урыннан утлы чылбыр белән буып куйды. Яңа су станциясенең суы быел ук инде мин басып торган яр ташларына кадәр менеп житәчәк. Агачларны, һәр корылманы шул электр станциясенә барып тыгылмасын өчен кисәләр, су житмәс урынга күчерәләр. Хәзер бу кырлар, бу үзәннәрне су астында калдыру кеше куәтенең, аның мөмкинлегенең үсеше итеп кабул ителсә, берәр заманны бу инеш төбен, аның суындагы ташбашларның, төрле балыкларның уйнауларын, күлләрдәге бакаларның такылдауларын, зифа таллар арасындагы сандугачларның сайрауларын яңадан күрә һәм ишетә алу кешелек акылының тантанасы рәвешендә хупланыр.

Әнә ич, әле күптәнме соң — бары тик башымдагы чәчемнең кара чагында гына бу төбәкне киләчәкнең бер баскычына югары күтәреп, без бер турбиналы электр станциясе, ике ташлы тегермән, агач буралы буа корган, салам түбәле авыл урамнарына гомер күрелмәгән баганалар утырткан, ә аларга ике алюмин чыбык сузып куйган һәм кан шикелле кайнар, терекөмеш шикелле йөгерек ток жибәргән идек. Аларның куәте кешеләр Идел белән Каманы буарга өйрәнгәнче житкән.

Безнең яшьлек кошы булган әнә шул станцияне сүтеп бетергәннәр, ә тегермәнгә иртәгә керешәләр икән.

Каяндыр ара-тирә чаң суккандай сирәк тавыш ишетелә иде. Шул тавыш ягына таба киттем, станция торган урынга килеп чыктым. Ул урында черек такта, рубероид, ватык шифер кисәкләре, тимер-томыр калдыклары гына чәчелеп ята.

Берәү станциянең соңгы субаен кисеп ята иде. Бәлки ул Кәүсәрия белән минем төнге пышылдашуларыбызны тыңлап торган субайдыр әле? Субайны кисеп аударгач, ул терәтеп торган үткән гомер, өстемә шарламадай ябырылган истәлекләр — барысы да бергә каяндыр өстән иңемә җимерелеп төшәр һәм, буыннарым тотмыйча, әгъзам-әгъзага таралыр кебек.

Станциянең соңгы субаен электр пычкысы белән кисеп яткан кеше Каһир иде. Шундук танып алдым. Ярдан аягы астына төшкән күләгәмне шәйләп, күтәрелеп карады. Ул да таныды. Без бер-беребезне танымый булдыра алмый идек. Танымаска хакыбыз юк иде. Бүген бу төбәктә вакыт белән вакыт очраша. Ә без — киләчәк белән үткәннең бер-берсенә текәлгән сагышлы күзләре.

Таш чишмә сукмагыннан (сукмагын калын чирәм каплаган, ә чишмә үзе юк икән инде) вак-вак атлап түбән төшәм. Аяк астында кар шыгырдаганын ишетәм күк. Юк, кар түгел, ә чын күннән тегелгән туфлием шулай шыгырдый икән. Тирләгән кулыма аның — Кәүсәриянең эш белән сөялләнгән бармаклары таянган сыман. Юк, аның бармаклары түгел, кулымда — юлдан күтәреп алган бер таяк. Менә без бу урында башларыбызны ия идек тә очрашуларыбыз шаһите булган станция безне үзенең ышык һәм жылы канатлары астына ала иде.

Кәүсәрия...

Каһир белән кул бирешми генә исәнләштек.

Кипшек ярганланган ләм, чирәм, кырлык үләне, кычыткан баскан, агач черегe тузаны, пычрак кәгазь, йомычка, эре эшләнәле тутык кадаклар, тәмәке төпчекләре, май касмаклары белән капланган кызгылт жирдә егермеләп субай аркылы-торкылы аунап ята. Чокырның сыңар теше сыман тырпаеп, соңгысы гына басып калган. Хәрабәнең урта бер жирендә турбина шарламасының юан корыч юллыгы. Чиреген ләм күмгән, тәне кутырлаган шикелле: карт нарат кайрысыдай тутык катламнары белән капланган, хәл алырга яткан карт сыман, кырын яткан. Галәмәт юан калибрлы, капонирдан көпшәсе генә күренеп торган гаубицаны хәтерләтә. Кая төбәлгән? Кая атарга тора? Хәзер менә Каһир

соңгы субайны кисеп аударыр. Үткәннең хәтеремә төшеп шартлаячак соңгы снаряды итеп...

Каһир папирос чыгара. «Беломорканал». Беренче булып сүз башлавы һәрчак авыр. Ә безнең сөйләшәсе сүзебез күп. «Безнең» дим. Аныкын белмим, ә минеке байтак. Безгә сөйләшмичә һич ярамый.

Бер кавым карашып торабыз. Сынашып. Бер-беребез каршына, картлык битлеге киеп, яшьлегебез килеп басты.

Каһир миннән ун яшькә өлкәнрәк иде. Авылча йөз, авылча кием, авылча кыяфәт. Ихтимал, үзенә генә хас сурәте бардыр. Тик мин ул сурәтне аерылып торган сыйфат итеп күрер дәрәҗәдә түгел. Теләмиме? Бәлки булдыра алмыйдыр.

Мин белгән Каһирны бүтәннәрдән аерып торган сыйфат аның эчендә иде. Хәзер ул нәкъ шул сыйфатын күрсәтәчәк.

— Үзгәргәнсең,— диде ул елмаеп.

— Ә син?— дип сорадым мин.

Тагын елмаеп:

— Мин — юк.

— Каян беләсең?

— Әллә каян таныдың ич! — Ул, башын каз кебек янтайтып, чокыр кашына карап ала.

— Син дә таныдың ләбаса. Мин дә үзгәрмәгән булып чыга.

— Сине дә танымасаң...— Ул, яңакларын эчкә батырып, тирән итеп папирос суыра. Тыштан тыныч, ә эчтән киеренке. Борын тишекләреннән басым белән бәреп чыккан төтен ургымы шуны белдерә.— Үлгәч тә танырлык булды-ы...

— Син юкка үзгәрмәгәнсең,— дидем мин.

Ул маңгаен җыерып, миңа карый.

— Картаймагансың диюеңме?

— Картлык сорап килми, ул яктан без тигез... Эчке үзгәрешне әйтәм, Каһир.

— Эчке. Эчке дисең инде. Әйе, ничек булсам, шулай калдым. Бәхетем шунда. Хуҗасын алыштырган саен үзгәргән эт булмадым.

Ул кулларына алмаш-тилмәш төкерде дә төгәл хәрәкәт белән пычкысын кабызды. Миңа борылып тагын нидер әйтте, тик пычкы тавышы ишеттермәде. Җайлы гына итеп, житезлек һәм гайрәт белән ялгыз субайны кисеп бетерде. Чак читкә тайпылып өлгердем. Югыйсә... Моны ул да күрде, агарынып чыкты.

— Кит дидем ич!

Имән субай, әйләнеп, корыч юллыкка килеп төште. Һавага, чатнап, тутык ярчыклары чәчрәде. Юллык гөрселдәп куйды, бераз гүелдәгәч, тынып калды. Өске авызыннан, дары төтене сыман, җирән тузан күтәрелә башлады. Юллык-гаубица, станциянең үлеменә атап, соңгы залп бирде.

— Залп,— диде Каһир. Гүя ахыры хәерле үк булып бетмәве ихтимал саксызлыгы өчен акланырга, мине юатырга тели иде. Икебез дә бер нәрсә уйлаганбыз.

— Фронтовикмыни?— дидем мин.

— Безнең яшьтәгеләрдән кем фронтовик түгел? Ә каян...

— Белдемме? Залп диюеңнән. Күпләр өчен мондый тавыш хәзер «бух!» кына.

— Теләсәң дә онытып булмый инде.

— Кайда сугыштың?

— Үлем күбрәк җирдә. Кая җибәргәнеңне оныттыңмыни?

— Аннан ничек барып эләктең соң?

— Әйе, миңа калырга да була иде. Тик үзең сайлаган үлем кадерлерәк ул.

— Үлемнең берсе дә кадерле түгел. Син үлем сайламаган идең ич. Син язмыш сайлаган идең. Үзенә түгел. Кешеләргә. Үзенә язмыш сайладың — кешеләр язмышы белән уйнау булып чыкты.

— Менә бит, очраштык ич әле. Гомер буена янәшә йөргәнбез... Син дә, мин дә хаклы булганбыз.

— Кемнеңдер хаклы булуы хакыйкать түгел әле ул. Ә һәр хакыйкать бердәнбер һәм бәхәссез дә була алмый... Кайларда сугыштың?

— Кайда да бер үк кан.

— Алай да?

— Сталинград... Берлин... Житәме?

— Өсти аласыңмыни әле, Каһир?— Миңа нигәдер уңайсыз булып китте, сагыш басты. Бәлки болай сөйләшмәскәдер? Бәлки дошманнар булып түгел, ә дөньяның ачысын-төчесен татыган гади кешеләр булып сөйләшәсе калгандыр?

— Курск...

Аңа күтәрелеп карадым. Ул читкә текәлгән иде. Гаҗәп — без гел янәшә йөргәнбез.

— Без гел янәшә йөргәнбез,— дидем мин.

— Без аеры була ала идекмени?

Ул вокзалда, мунчада яки самолетта сөйләшеп киткән күп ветераннар шикелле үк, дулкынланып, папирос кабызды, кабыннан берсен кагып чыгарып, миңа да сүзсез генә сузган иде дә — баш тарттым. Әле генә ауган субайга утырыштык, безнең арада ниндидер магнит көче хасил булды сыман.

— Курскида кайсы тирәдәрәк йөрдең?

— Ржев.

— Мин дә шунда ич...— Ул шатлыгын һәм читтән тыш гаҗәпсенүен яшерә алмыйча, киң итеп елмайган килеш иңбашыма сугып куйды.

Мине бу очраклылык гаҗәпләндермәде. Хәер, очраклылык кына микән?

— Менә шунда без аерылганбыз инде,— диде ул.

— Сине кая җибәрделәр?

— Җибәрмәделәр... Алып киттеләр.— Ул кинәт балкыган шикелле, кинәт сүрелеп тә төште.

— Кая?

— Тәмугка. Мин хәбәрсез югалдым... «Тел» алырга киттек. Шунда үзем каптым. Тик «тел» булмадым.

— Дәшмәдеңме?

— Дәштем... Тик җан саклар өчен түгел.

— Дәштең?

— Фашистка каршы... Аннары соң, комиссия иләгеннән или башлагач, берәү мине прислужник дип чыкты.

— Каршы дәлилең бар идеме соң?

— Алдында торуым «дәлил» түгелмени?

— Гафу ит.

— Кызганма, парин!

Чыннан да. Мин аны хәзер кызганам. Ә элек ул кызганырлык түгел иде.

— Ә бу дөнья тәмугында — фронтта очрашкан булсак?— дип сорадым юри читкә борылып. Туп-туры кояшка карап. Ләкин, ялганлаган чакта дөреслеккә туры карап булмаган шикелле, кояшка озак багып тору мөмкин түгел иде.

Ул, сул күзен кыса төшеп, бармагын шартлатып куйды.

— Мин тәз ата идем.

Аны автоматлы килеш үз артымда дип күзалладым — тәнем чымырдап куйды... Юк, юк, ул арттан ата торган кешеләрдән түгел!

— Синең кулың хәзер дә нык,— дидем мин, субайларга ымлап.
Әле генә ни әйткәнен оныткандай, ул тыныч кына:
— Баз казымакчы идем, шуның өстенә,— диде.— Болар суда чыныккан, тимер шикелле — мәңгелек.
— Берәр нәрсә кор... сарай, мунча...
— Баз казыйсым бар,— дип кабатлады ул.— Закусканы кайда тотасың? Мин хәзер шәһәр кешесе шикелле таш йортта торам.
— Үзебез төзедек — кызганмыйсыңмыни?— Учым белән корыч юллыкка шапылдаткалап алдым.
— Без кызгандыкмы соң? Ни генә җимермәдек! Алар да кемгәдер кадерле булгандыр.
— Без үзебез җимергәннәрдән матурракны кордык.
— Ә болар? Әнә нинди авыл кордылар! Ә зират? Каберләр дә түгел — өч шеренга солдат!— Ул телен шартлатып куйды.— Җиргә хәзер бүтәннәр хуҗа.
— Кем ул бүтәннәр?
— Кем булса да, инде синең белән мин түгел. Бар да бүтәнчә.
— Бәлки синеңчә түгелдер?.. Бу җир беркайчан да сине хуҗасы санамагандыр.
— Кешедән ким яшәмәдем. Ә хәзер кешедән ким яшәмәс өчен үз-үзеңә дошман булган чаклар да бар. Дөнья үзгәрде, сизәмсең?
— Үзгәрмәгәнсең икән шул. Бүгенгене теге чаклар белән үлчисең.
— Теге чак дөресрәк иде.
— Ә син ул чакта да дөрес булып кала белмәдең, хәзер дә хаклы түгелсең.
— Бер генә тапкыр хаксыз булдым.... Беләсең. Тик аны юарлык кан миндә әле дә бар. Ахыр килеп, Ислам, бу җирне хаклылар гына тотмый. Беләсең ич: яхшылар да, начарлар да сугышты...— Ул урыныннан торып, миңа аркан басып калды.— Сүзең булса, өйгә кил.
Минем гафу итүемә Каһирның мохтаҗ түгеллеген шушында төшендем. Аны зуррак нәрсә гафу иткән. Һәм бу кичерү, гомуми ярлыкау өчен ул миңа түгел, ә үз канына бурычлы. Шул аңа Җир белән Кояш арасында минем кебек үк яшәргә хак бирә. Уйларымда калыккан әүвәлге Каһир белән хәзерге Каһир йөрәкләрендә бер үк кан ага — кеше каны.
Чокыр эчендә аның берүзен калдырып, югары күтәреләм.
— Кайтмыйсыңмыни әле?— дим борылмыйча гына.
— Трактор көтәм. Малайны.
— Малайны?— Борылмыйча булдыра алмыйм.— Кем ул?
— Таһир.
— Хатының кем дип сорыйм.
— Ниса.
— Теге шайтан кызымы?
— Миңа ул фәрештә булды.
— Ширәмәтов кайда?— дип сорадым мин каты ук кычкырып.
— Хәбәрсез.
«Хәбәрсез...» Ә мин аның исән икәнен беләм!
— Улларың, кызларың ничәү?
— Ике малай, бер кыз.
— Ширәмәтовның кызы кайда?
— Минеке — шул аныкы инде... Ә синекеләр?— диде ул арабыздагы киеренкелекне әллә сизмәгәндәй, әллә игътибар итмәгәндәй тыптыныч кына.
Бер мәзәк исемә төште.
— Ике киявем, бер киленем бар,— дидем. (Авыл агаеннан: «Ничә балаң бар?»— дип сораганнар. Агай: «Ике киявем, бер киленем»,— дип

жавап биргән. Рәхәтне балалары үз тормышлары белән яши башлагач кына күрүенә ишарәләве, имеш.)

Каһир, аңа ияреп мин дә, көлешеп алдык. Очрашу киеренкелегеннән арынырга теләвебез булган, күрәсең.

— Ник бер дә кайтып күренмәдең?— дип сорады ул.

— Миңа хәзер моннан бер дә китәнем юк шикелле.

— Аңлыйм. Син ерак киттең шул,— диде ул, бармагын күккә тырпайтып.

Кәүсәрия Таш чишмә суына йөргән сукмакка тагын аяк басам. Мин күзаллыйм: ул чишмәдән менеп килә, ә мин аңа каршы төшәм.

Озын чуклы йон яулык, вак чәчәкле, зәңгәр каймалы ак алъяпкыч бәйләгән; озын җиңле, җиде балитәкле яшел сатин күлмәктән; балтырлы йон оек һәм ялтырап торган резин галуштан. Галушның башы кечкенә чыктан чыланган, артына туфрак ябышкан. Көянтәсенә аккош канаты булып салынган кулын нишләтергә белми тора. Артка яшерсә, потлы чиләкләр эленгән көянтәсе төшеп китмәс өчен җайсыз бөкрәергә кирәк. Яшермәс иде — кулы бигрәкләр дә матур шул. Ул миннән шул кулы өчен ояла да. Мин аны гел шул кулыннан иркәлим. Аннары бүген гадәттәгедән дә ераккарак яшерер сәбәбе бар икән ич, күрми дә торам: тырнакларына кына ягылган икән ләбаса. Чишмәгә киләсемне белеп, шул тырнакларын да күрсәтер өчен төшкән, чукынчык. Билләһи!

— Исәнме?— дим мин хәзерге, аңа таныш түгел калын гөлдерек тавышым белән.

Әмма ул мине таный. Мөгаен, күземнәндер. Карашым нинди икән соң — боекмы, сагышлымы, шатлыклымы?

К ә ү с ә р и я. Озак йөрдең.

М и н. Син түз. Күп калмады инде, бөтенләйгә килермен.

К ә ү с ә р и я. Ашыкма әле.

М и н. Йөрәк белән вакытның никахы — гомер озынлыгы гына.

К ә ү с ә р и я. Нәрсә ул никах?

М и н. Син белергә өлгермичә калган нәрсә.

К ә ү с ә р и я. Ә син беләсеңмени?

М и н. Кан агымы туктамаска тиеш, Кәүсәрия. Мин кешегә язганның һәммәсен татыдым.

Ул, агып чыккан күз яшен учларына алып, уң кулы белән — сул, сул кулы белән уң чиләгенә сала. Әллә тамчы тамган тавыш, әллә чулпы чыңы чыга. Чиләкләре күз яше белән тулганмы соң әллә?

М и н. Мин синең өчен дә яшәдем, Кәүсәрия.

К ә ү с ә р и я. Ә мин синең өчен үлдем.

М и н. Үлүе авырдыр. Әмма яшәве дә җиңел түгел.

К ә ү с ә р и я. Минем әни бала табуы барысыннан да авыррак, дия торган иде.

М и н. Сине саклый алмаганым өчен миңа үпкәләмәдеңме, Кәүсәрия?

К ә ү с ә р и я. Ә сине ялгызыңны калдырып киткәнем өчен миңа ачуланмадыңмы соң, Ислам? Мин ашыктым...

Кәүсәриянең нәрсә әйткәннәрен генә ишетәм, ничек әйткәнен бөтенләй диярлек күрмим. Барыбер түгелмени соң? Иң мөһиме — хәзер ниндидер тылсым кичерәм. Татлы тылсым. Төш шикелле. Ә төш берни күренми торган караңгыда йокласаң да, кояш астында, чәчәкле болында ятып йокласаң да, төш инде ул. Төш — бары тик төш кенә. Бөтен дөньяга ут капса да, бөтен кеше көлеп кенә яшәсә дә, төштә бары тик төш кенә күренә. Шуңа күрә Кәүсәрия белән бу сөйләшүемнең кайда һәм кайчан баргнлыгы барыбер. Чөнки кайда һәм кайчан гына булса да, ул бары тик шушылай гына була алыр иде. Һәм ул чагында ул, төш-

тән битәр, чын бер тылсым булыр иде. Чиста, салават күперенең бөтен төсләре, кеше хисләренең бөтен кичерешләре белән тулып торган тылсым. Һәм кинәт мин, шушы тылсым үземне бөтенләе белән күмеп китүдән курыккан шикелле, туп-туры карап, тупас рәвештә:

— Мин гаепле түгел, Кәүсәрия! Ул чакны теге сәке чыннан да сасы иде ич,— дидем.

Ләкин тылсым үзенә пычрак белән селтәнүдән курыкмады.

— Бодай алтын чүлмәктә үсми ич, Ислам,— диде Кәүсәрия.

Мин. Син шундый саф идең.

Кәүсәрия. Мин ул сафлыгымны базарга алып бармадым ич, Ислам, ә сиңа бүләк итәргә дип килгән идем.

Мин. Тормыш базарында сафлыктан да арзан нәрсә булмаганны күргәнем булды минем, Кәүсәрия!

Кәүсәрия. Синең намусың мине үзенә кыйммәтсенде. Ә мин үземә караганда да кыйммәтрәк түгел идем.

Мин. Минем намусым синең үлемеңнән соң тагын да чистарыбрак калды. Әгәр дә синең үлемең чыннан да котылгысыз булса? Ул сәке миңа гомерем буена чистармас тап булып сыланып калыр иде. Ә кара намустан үлем кадерлерәк. Шуңа күрә мин беркайчан да үлемнән намусымны түләп котылмадым.

Кәүсәрия. Син кайчан үләсең?

Мин. Бер үлдем ләбаса инде... Мең тугыз йөз утызынчы елда. Әллә кыш ахыры, әллә яз башында... Ә син кайчан терeләсең?

Кәүсәрия. Хәтерең таңында мин кояш булып балкыган чагында. Мин синең янга, сынган тормышымның сынган көянтәсенә элеп, чиләкләрем тулы сагынуыңны алып килермен... Тотын минем көянтәмә, син көчкә басып торасың. Үткәннәр чокырыннан күрәсе гомер тавына менүе авыр шул ул — әнә, таягыңның хәле беткән.

— Таягымның?— дидем мин, үз-үземә пышылдап.— Аягыңның дияргә куркасыңмыни?

Җавап ишетергә теләп, тылсымлы төшемнең күгендә тургай шикелле чыңлап торган Кәүсәриямнең көянтәсенә үреләм. Тик кулым, беренче мәртәбә йөгән кидерелгән атны тынычландыргандай, әкрен генә күкрәгемнең сул ягына күтәрелә дә сак кына итеп йөрәгем турысын угалый башлый. Хәзер инде үткәннәремә үрелсә дә, киләчәгемә таба сузылса да, кулым күкрәгемнән ары уза алмый. Ә моны Кәүсәриягә ничек тә белгертмәскә кирәк. Моны миннән алданрак төшенеп, ул минем тылсымлы төшемнән киткән иде инде. Кулымны йөрәгемнән аерып, учыма карыйм. Анда йөрәгемнән саркып чыккан кан булып, Кәүсәриянең ал ташлы сыңар алкасы ята иде. Кай арада кесәмнән алганмын да кай арада йөрәгемә кысканмын.

## III

Түфлиемне җиргә сыпырып төшерәм дә киселгән нарат төбенә утырам. Бер яңа матурлык туганда, ике иске матурлык үлә. Чөнки телибезме, юкмы — яңа матурлык, ямьсез кеше ястыгына килеп эләккән гүзәл кебек, явызлар кулына да тап була. Бер матурлык — арган, хәлсезләнгән елганы алыштырачак, иске җирнең шадра йөзен каплаячак су, икенчесе — искиткеч тәртип белән корылып, урамына асфальт җәелгән яңа авыл. Алар уртасында шушы, инде кояшта кипшенеп, йөзе саргайган, вак җыерчыклар белән капланган агач төбе. Якында гына тагын бер нарат, анысын кисәргә өлгермәгәннәр әле. Ә бәлки «өлгерерләр әле» дияргәдер?

Киселгәне — Кәүсәрия, ә киселәчәге — минме?

Вакыт елгасына каршы йөзеп китәм дә, ком сәгатенең нечкә бугазы аша кысылып үткәч, яңадан хәтерем тавы түбәсендә пәйда булам. Янымда, акыллы, йөнтәс эт сыман, күземә, ә күзем аша җаныма текәлеп, минем гомер юлдашым — хыялым ята. Акылымның иң дөрес юлдан гына алып барган мәңгелек дустым минем — тозлы хыялларым...

Мине наркоматка чакырып алдылар.

Язгы имтиханнарымны биреп, Казанга — апаларга кайтып төшкән генә идем.

Кайткан кичне үк Такташның үз шигырьләрен укыганын тыңладым. Кайнар, Маяковскийча үк мәгърурлык, үз сүзенә ышаныч. Шул ук вакытта ниндидер тирән үпкәме, сагышмы кебек хис белән мөлдерәп торган зәп-зәңгәр күзләр. Икенче көнне академия театрында спектакль карадым. Зал шыгрым тулы. Кызлар күп. Озатырга да исәп бар. Туктап тор әле, дидем, ашыкма, дидем, булыр, булыр... Өченче көндә җәйне үткәрергә төшемле генә берәр эш эзләргә керештем. Җизни төнге эш табарга киңәш итте. Мин аны аңлыйм. Алар унбиш метрлы коммуналь фатирда миннән башка да дүртәү. Апа — ашханәдә, җизни — тире эшкәртү фабрикасында хисапчы, икесе дә көндезге эштә. Җизни киңәшен тотсам, мин аларны һәм ике сытык чырайлы кызларын төннәрен баскыч астындагы бәдрәфкә үзем аша атлап йөрүдән коткарачак идем. Мин идәндә ятам, астымда суккан паласка җәелгән шинель, өстемдә бумази җәймә, үзләреннән башлап мәчеләренә кадәр минем аркылы йөри. Беренче ике төнне киң итеп, иренмичә атладылар, рәхмәт яусын. Ә менә өченче төнне кулыма да, аягыма да басып бетерделәр, абынып егыла да яздылар, сытык кызларының берсе, аягына эләктереп, хәтта өстемдәге җәймәне ачып калдырырга да җай тапты. Аннары соң, тәрәзәгә яктылык төсмере иңгән бер заманны җизниләрнең агач караваты да шыгырдап алды... Кандалалар, көн яктысын сизеп, ашыга-ашыга канымны суыра башлаган чак иде, уңайсыз булды. Түзмәдем, утырган көйгә генә киендем дә, чөйдән пинжәгемне эләктереп, Кабан күле буена чыгып киттем.

Таңны колак төбендә караватт шыгырдавын алыштырган дулкыннар шавында йокымсырап көттем. Сәрби куаклары артындагы эскәмиядә кызыл күзле аклы-көрәнле бер эт белән кундык. Мин өстә, ул эскәмия астында. Уянгач, ул — үз юлы белән, мин үз юлым белән киттем. Эт, бераз ераклашкач, борылып, артымнан карап калды. Бу дөньяда хуҗасыз эт булып яшәмәс өчен мин әллә ниләр бирер идем. Хәер, үзем дә шул ялгыз эттән әллә ни ерак түгел идем ахры. Егерме беренче елда эти тифтән үлде, әни озак тормастан, ачлыктан вафат булды. Ападан олы абыйны унсигезенче елда, Казаннан чыгып качкач, ак чехлар Питрәч юлы өстендә куып житкәннәр. Бер рус агае әвене артындагы мунчага кунарга керткән булган, өсләренә ике граната тондырганнар. Моннысын соңыннан белдем. Ниндидер бер туган-тумачаны эзләп, апа белән Казанга чыгып киткәнбез. Ипи чырае күрмәгәнгә биш ай дигәндә балалар йортында әни сулышы шикелле җып-җылы ипи кыерчыгын курка-курка гына авызыма якынайтканымны хәтерлим. Аннары Казандагы «Гуж» артелендә эшләдем. Аннан рабфакка кердем. Хәзер Мәскәүдә укыйм. Энергетика институты. Безне бер профессорыбыз — атаклы Кржижановский Глеб Максимилианович «ГОЭЛРО балалары» дип атый.

Юк, мин кызыл күзле эттән мең, миллион тапкыр «хуҗалырак». Чөнки мин үз-үземә хуҗа. Нишләсәм дә — ирекле. Бернигә ярамаган чагымда дәүләт мине үз улы итте. Кесәмдә тагын бер көнлек акчам

булса да, үземне хәерче санарга хакым юк. Мине үз баласы иткән дәүләт алдындагы чиксез бурычым белән бай идем.

Сау бул, кызыл күзле эт. Тагын бер очрашу язган булса, мине танымассың инде.

Апаларда, болай, күңелсез түгел иде үзе. Аларның биш фатирга гомуми бер кухнялары бар, шунда кулларыннан тире исе килеп торган Зося белән (ул жизниләр фабригыннан) биш примус арасында көнбагыш чиртә идек. Сүз беткән араларда Зосяларның ачык ишегеннән чәчәк аткан көнбагыш табагын хәтерләтеп карап торган җиз граммофоннан әле Утесов, әле Изабелла Юрьевнаны тыңлыйбыз.

Мин укыган рабфакта арзанлы ашханә барлыгы искә төште. Шунда киттем. Иртәнге урамнан барабаннар кагып пионерлар узды. Күзем зәңгәр кафельле кибетләрнең тәрәзәләреннән кызыктырып торган колбаса бәйләмнәрендә. Аларның симез хатыннар шикелле буынтыклы-буынтыклы кисәкләрен кысып бәйләгән сүс баулары гына да әллә нинди исләр аңкыта иде, ул исләрне «Кольцо»ны уратып алган балык кибетләреннән бөтен шәһәргә таралган балык исе дә баса алмый. Авызымны ачыбрак җибәргәнмен, арттан «АМО» машинасы китереп төрттерде, сискәнеп кырыйга елышкан идем, калак сөягемә ат тәртәсе башы бәрде, мине бер кытай гына кырыйга тартып алды.

Менә безнең ашханә. Яртылаш җир астындагы, галерея сыманрак заллар. Кимерелгәннән калганга охшаган тавык муенлы кәбестә ашы, каймаклы бөтен бәрәңгеләр янына тозлы кыяр ярып салынган сарык итле «икенче», сыек чәй, чирек ипи алдым да биш ел элек утырырга күнеккән «үз» залымны эзләп, түргә киттем. Кеше әз, нигәдер кызлар бөтенләй юк. «Минем» өстәлем буш түгел иде. Безгә геометрия укыткан «миллипипед» Гайсә белән мин Мәскәүгә киткәндә наркоматта кәгазьләремә кул куйган иптәш Әбҗәлилов утырган. Баш кактым. Әллә күрделәр, әллә юк. Почмак өстәлгә утырырга исәпләп, аларга аркан борылган гына идем, «Миллипипед»:

— О-о, мәскәүләр!— дип куйды.

— Кем ул?— дип сорады Әбҗәлилов.

Йөземне генә борып, аларга тагын баш кактым.

— Тиздән без аны түгел, ул безне танымас!— диде «Миллипипед».— Баеп кайттыңмы әллә — дәшмисең?— Сүзсез генә ишарәләп, ул каршында урын күрсәтте.— «Тотса Мәскәүләр якаң» шушы буладыр инде!

— Исәнмесез,— дидем, аш-суны өстәлгә куеп һәм кул сузып. Бераз гына каушап та җибәргәнмен икән, бер телем ипием ашка төште. Игътибар итмәделәр, әмма минем чәч төпләремә хәтле кызышып куйды.— Тешләр ялкау,— дидем мин,— ипи чәйнәргә иренәләр, чылатырга туры килә.

Көлешеп алдылар.

— Таныш бул,— диде «Миллипипед» Әбҗәлиловка.— Милли Маяковскиебыз бар, милли Горькиебыз бар, милли Комиссаржевскаябыз бар, ә бу — милли Кржижановскиебыз булыр — Ислам Имамович Зәйнушин!

(Без аны менә шуның өчен «милли»ләштергән идек.)

Тагын баш кагып куйдым. Ипием өчен бигрәк тә Әбҗәлиловтан оялдым.

— Мин сезне беләм,— диде ул күзлеге өстеннән карап.— Сезнең профессор Стефанович семинарындагы бер чыгышыгызны иптәш Мөсәгыйтов ишетеп кайткан иде, шул сөйләде.

— Әйе, мине «якташым» дип берәү бик каты котлаган иде — истә,— дидем мин. «Истә» диюем бүген кулымны юмаганлыгымны искә төшерде. Җитмәсә, теге кызыл күзле эт эскәмиядән салынып төшкән сул кулымны ялап алырга өлгергән иде. Торып, керү юлындагы кул югычта юып килергә хәзер соң иде инде — әле генә алар белән исәнләшеп чыктым ич.

«Миллипипед» кинәт кызыксынучан, кырын караш ташлап алды.

— Мин сезнең өчен бик шат,— диде Әбҗәлилов.— Мөсәгыйтов бик мактаган иде.

— Кем ул?— дип сорадым мин уңайсызланып.

Алар бер-берсенә карашып алдылар.

— Өлкә комитетыннан,— диде «Миллипипед».

«Туктале,— дип уйладым мин.— Нигә әле мин аны һаман «миллипипед» та «миллипипед»? Без аны мең еллык татар әдәбияты, Тукайның Толстойга мөнәсәбәте, Толстойның Шекспир турындагы уйлары, татар декабристлары турындагы кызык сөйләшүләре, Крузенштернның дөньяны әйләнеп чыккан корабындагы татар матрослары хакындагы ялкынлы сүзләре өчен тыела алмастай олылап хөрмәт итә идек ләбаса! Тукайны безгә вак буржуаз шагыйрь, ә Фатих Әмирханны эре буржуаз язучы дип укыткан бер вакытта ул аларның тиздән мәдәниятыбызның йолдызларына әвереләчәген юрый иде ич. Гайсә Зәйналов бит әле ул! Ә «Миллипипед» дигән кушаматы өчен миңа бурычлы икәнен белә микән ул? Һәм ул кушаматны мин аңа йөзенең чалыш дүртпочмакланып торганы өчен генә такмадым бит.

(«Кем белә,— дип уйладым мин хәзер,— теге елларда бу кушамат аның язмышындагы фаҗигага билгеле бер өлеш кертмәде микән?»)

— Хәзер нишләп йөрисез соң?— диде Әбҗәлилов.

— Эш эзләп.

— Эш? Әллә уку...

— Юк, бетмәде әле,— дидем мин аны бүлеп.— Иртәрәк.

— «Эш» дигәч, чынлапмы дип торам.

— Чынлап. Эш. Киләсе кышта туңмас өчен. Пәлтәлек, бүреклек бирәр эш.

— Ә!— дип көлде Әбҗәлилов.— Шулай диләр аны! Димәк, уку бара!

— Бара.

Кузгалыштык. Саубуллаштык.

— Өйләдән соң миңа керегез әле,— диде Әбҗәлилов, сәгатенә карап алгач.— Сәгать өчкә. Берәр нәрсә уйлап табарбыз. Шәт, уйлап табарбыз.

«Шәт! Моннан чыгуга, син мине онытырсың шул инде»,— дип уйладым мин.

Әмма ялгышканмын.

Аның янына да, хезмәт биржасына да барып тормаган идем. Биш тиен бакыр чөеп җибәрдем дә, аның «күне» күрсәткәнчә, заводка кара эшкә барып урнаштым. Торып торыр җир дә бирделәр. Тагын нәрсә кирәк? Хәзер кайтып, апаны, аннан бигрәк тә җизнине шатландырам. Тулай торак ителгән бер мәчеттә уникe кешелек бүлмә. Чебен буяп бетергән лампочка. Икешәр катлы алты тимер карават. Монда ике айга түзәрлек. Аның каравы, әйтүләренә караганда, эш шактый төшемле булачак. Безнең егетләрнең кайберләре Донбасс шахталарына киткән иде. Мин дә алардан ким алмам әле. Хәер, миңа артыгы кирәкмәс тә. Бары тик бүрек белән пәлтәлек, шуңа өстәп, кышлык акча.

Хәзер инде Әбҗәлилов янына баруның хаҗәте юк. Алай да, көтеп торса, яхшы түгел дип, Кремльгә киттем. Юл өстендә ике өчпочмак белән тамак ялгап алдым. Сәгать дүртенче яртыда Әбҗәлилов бүлмәсенә барып кердем. Ул телефоннан сөйләшеп тора иде, трубкага: «Гафу итегез!»— диде дә стенадагы идәннән түшәмгәчә житкән сәгатькә караш ташлагач, миңа каршы атлады. Мин аның, мин кергәч, «Гафу итегез!» дип, телефон трубкасын куюын аңлап җиткермәдем, чөнки үземне кемдер телефоннан сөйләшүен бүлдерерлек дәрәҗәдә көтәләрдер дип уйларга мәҗбүр итә алмадым. Әмма мине гаҗәпләндерердәй нәрсә бу гына түгел икән әле.

— Бу пунктуальсезлегегез бүтән кабатланмасын,— диде ул. Ни әйтергә белмичә аптырап калуыма һичнинди игътибар итмәстән, мине тышка әйдәде.

«Булышуың бик кыска булды синең!»— дип уйладым мин килгәнемә үкенеп.— Кемгә хаҗәт соң мин? Наркомат кешеләренең синең кышкы пәлтәле һәм бүрекле булу-булмавыңда эшләре тәрәлеп каткан ди!»

Ә Әбҗәлилов, озынча залның түрендәге күн тышлы биек ишеккә ишарәләп:

— Ул сезне көтә,— диде.— Болай да соңга калдык.

Көне буена бер тапкыр да юынмаган килеш — нарком янына! Иөгереп чыгып китсәм, һичшиксез бөтен шәһәр белән эзли башларлар кебек.

— Исәнмесез,— дидем мин алга узып, арттан кереп килүче Әбҗәлиловка әллә нинди куркынычтан йолып алуын үтенгәндәй карап. Ул ишекне ябып куйды, миңа чигенергә бернинди дә юл калмаган иде инде. Колак төбемдә генә:

— Исәнме, энекәш!— дигән бер колач тавыш яңгырады. Чигенеп куйдым, әйтерсең өстемә киселгән агач ава иде.

— Исәнмесез,— дидем мин тагын, әле күрмәсәм дә, алга таба кулымны сузып.

— Әйдә, утыр,— диде минем кулымны кыскан салкынча кул.

Каршымда артка тараган чал чәчле, кара куе кашлы, борынына зәңгәрсу һәм ал кан тамырлары җәелгән, зур түгәрәк күзле һәм арыган чырайлы бер абзый басып тора иде.

— Рәхмәт,— дидем мин кымшанмыйча аягымда басып калып.

— Утыр, утыр,— диде ул, Әбҗәлиловка карап, аңа да, миңа да түрдәге өстәл алдына кара-каршы куелган ике кәнәфине күрсәтте.

— Менә шул инде ул,— диде Әбҗәлилов һәм сул якка утырды, ә мине җиңелчә генә уңдагысына этәрде.— Утырыгыз, Ислам Имамович.

— Гафу итегез, көтмәгән идем...

— Ә мин көттем,— диде нарком, аяк өсли калган килеш миңа югартыннан карап.— Эш эзлисезме?

— Таптым инде. Заводта.

— Җиңел эш эзләмисең икән.— Ул, урынына узышлый, Әбҗәлиловка карап алды.— Аннан чыгарга туры килер, Зәйнушин. Без сиңа тагын да авыррак эш табып куйдык... Пәлтә белән бүреклек булыр кебек. Безгә ярдәм итәргә телисеңме?

— Ярдәм?— Кайда утырып торганлыгымны онытып, башымны артка ташлап көлеп җибәрдем.

— Менә хәзер сөйләшергә була!— диде ул елмаеп.

— Төшенеп җитмим, иптәш нарком.

— Димәк, синеңчә, вак су станцияләре төзү үзен акламый? Синеңчә, эшче-крестьян власте үзенең вакытлы түгеллеген бөтен дөнья алдында раслады, димәк, аның кулы тигән бер генә нәрсәдә дә вакытлы дигән тамга ятмаска тиеш... Шулай дип сөйләдеңме?

Төкерегемне йотарга да куркып, башымны кагып куйдым.

— Моны хәзер дә кабатларга әзермен,— дидем мин кызган телемне корыган авыз куышлыгында көчкә әйләндереп.

— Ә Ленин алай димәде ич. Әгәр, диде ул, без бүген йөз мең трактор эшләп чыгара алсак, крестьян бөтен җаны-тәне белән коммунизм яклы булачак.

— Трактор белән инеш суы станциясе...

— Бүген егерме... хәтта унбиш мең вак электр станциясе корып, Россиядәге барлык крестьян өйләренең өчтән берендә генә булса да Ильич лампалары кабыза алсак, бөтен крестьян коммунизм өчен җаның-тәнен кызганмыйча утка керәчәк.

— Мәңгелек станцияләр корсак, без бар Россияне электрлы итәр идек. Коммунизмның киләчәге шуңа бәйле... Бу шулай булачак та,— дидем мин, теге семинарны искә төшереп һәм шуңа таянып.

— Булачак. Әлбәттә булачак.— Нарком, урыныннан торып, стенадагы без табынган ГОЭЛРО планына карап торды.— Ләкин киләчәктә.— Ул яңадан урынына килеп утырды.— Ә крестьянны коммунизмның киләчәгенә кадәр социализмның җиңәчәгенә без бүген ышандырырга тиешбез, Ислам Имамович. Ә бу синнән һәм синең шикелле меңләгән яшь специалистлардан тора. «Ислам Имамович, ди бит. Нәрсә бу — минe санга сугып олылаумы, әллә салкын мөгамәлә билгесеме?»

— Тәкъдимегезне аңладым,— дидем.— Тик мин начар лектор.

Ул көлемсерәп куйды.

— Без сиңа авыллар буенча коммунизмны пропагандалап йөрергә кушмыйбыз.— Ул, торып, Татарстан картасы каршына килеп басты, рам читендәге бер чәмәкне борып җибәрде. Картада унлап лампочка җемелдәп кабынды.— Болар — шушы елларда авылларда төзеләчәк су станцияләре.— Ул карамыйча гына картаның урта бер җиренә күрсәтте.— Менә монда бер иптәшебез эшкә керешкән иде... Биш көн элек үтерделәр.

— Үтерделәр?

— Халыкка ут һәм нур илтүчеләрнең беренчеләрен еш кына үтерәләр. Прометейдан башлап... безнең шушы иптәшебезгә кадәр. Ләкин аларны алмаштыручылар күбрәк туа. Син бәхетле кеше, Ислам Имамович — син шуларның берсе була аласың. Килештекме?— Ул иңбашы аша миңа борылып карады.

Ә мин, аның карашыннан куырылгандай, иңбашымны җыерып куйдым.

— Вакытлыча гына,— дидем мин ни әйтергә дә белмәстән.

— Вакытлыча?— Тынлык.—«Вакытлыча!»... Син үз-үзеңә каршы киләсең, энем.

— Кечкенә станция. Тик гадәттә вак эшне тавык та чүпләп бетерә алмый торган була... Укып бетерәсем дә бар бит, иптәш нарком.

— Онытма: бездә хәзер эшнең — вагы, үлемнең кечесе юк. Вак эш, вак... Пәлтәлек, бүреклек... Ризамы?— дип сорады ул кинәт кенә.

Мин дәшмәдем.

— Димәк, риза. Рәхмәт.— Ул, Әбҗәлилов тотып кергән папканы алып, миңа сузды.— Монда Рамазановның... элекке иптәшебезнең кайбер сызымнары. Өлгерә алганы кадәресе. Урында ачыклап бетереп, исәп-хисап ясар өчен сиңа күпме вакыт кирәк?

— Әйтүе кыен...

— Алай да?

— Бер айлаптыр.

— Станция быел салынып бетәргә тиеш. Югыйсә, синең кышкы пәльтәсез, бүрексез, ә авыл кешеләренең утсыз, ә безнең коры сүз белән калуыбыз бар.— Ул урынына барып утырды, өстәл тартмасыннан кара төребкә алып, аңа ашыкмый гына тәмәке тутырды, кабызып, тирән итеп суыргач:— Сиңа — ун көн,— диде.— Проект һәм смета белән көтәм. Хәер, смета синең үзең өчен генә кирәк булачак.

Әбҗәлилов урыныннан торды, китәргә вакыт икәнен аңладым.

— Хушыгыз,— дидем мин.

Нарком ишеккә кадәр озата барды.

— Ә мин хушлашмыйм, Ислам Имамович... Очрашканга кадәр,— диде ул.— Уңышлар телим, энем. Аннары... Рамазановны кем үтергәне билгесез. Әлегә билгесез. Шулай булгач...

— Аңлыйм,— дидем мин.

Нарком бүлмәсенә битем-кулым юылмаган студент булып кердем. Ә чыкканда? Әбҗәлилов язып биргән, ә нарком кул куйган таныкнамә-

дән укып, үз-үзем белән исәнләшәм: «Исәнме, су электр станциясе төзелеше начальнигы!»
«Начальнигы»! Ха-ха, кызыл күзле эт! Аңладыңмы?
Апаларга кайткач, май исе сеңгән гомуми кухняда Рамазановның биш битле мирасын карап чыктым. Сүз бары тик бер динамоны әйләндерерлек турбиналы станция төзү, шул турбинаны әйләндерерлек су җыярга плотина буу, ике ташлы тегермән салу турында иде. «Әйе, ГОЭЛРО түгел»,— дигән нәтиҗәгә килдем мин. Моның өчен генә кеше хәтле кеше үтереп була микәнни? Ә бәлки аны станция өчен үтермәгәннәрдер, ә шул станцияне төзергә килгәне өчендер?

## IV

Мин килеп төшкән авыл табигатенең матурлыгын, сурәтләргә кыенсынам. Фасылына килешле йомшак, тыйнак, саф, боек табигать. Һәркайда тынлык.
Тынлык гадәттә алдаучан.
Миңа кадәрге «Су электр станциясе төзелеше начальнигының» үлеме бу авылга килеп төшкәнче үк миндә күп фаразлар уятты. Аның чигәсенә атканнар. Көтмәгәндә һәм искәрмәстән тәрәп. Болай иң явыз дошман гына эшли ала. Гражданнар сугышын яшен шикелле аркылыга-буйга иңләп кайткан кеше үзен бүтәнчә үтертергә юл куймас иде. Уяулыгын югалткан. Сизгерлеген. Сәбәбе? Мөгаен, бер динамолы станция коруны ул да, минем шикелле, вак эш дип санаган, дошман игътибарын җәлеп итәрдәй әһәмиятле түгел дип белгән. Димәк, нарком хаклы? Кемдер Ильич чаткысы өчен крестьянның үз җанын-тәнен кызганмыйча утка керүен теләми? Кемгәдер ул чаткының кабынмас борын сүнүе кирәк.
Мин уйлыйм, уйлыйм, уйлыйм... Чөнки мин яшь әле. Минем яшисем килә. Минем яңа пальтә, яңа бүрек киеп йөрисем килә. Яңа пальтә һәм бүрек кигән килеш кызлар белән сөйләшүе җиңелрәктер дә, рәхәтрәктер дә. Билгеле инде, яңа пальтә һәм яңа бүрек бик җылыдыр ул.
Пәлтәлек, бүреклек акча эшләү алай тиз генә мөмкин түгеллеген биш көннән соң үк аңладым. Көенмәдем түгел. Ихтимал, көлкедер дә. Пальто һәм бүрек кирәк булмаса, бу эшкә керешмәс идем ич әле! Эре эш вак хыялдан да башлана икән. Олы елга инештән башланган шикелле...
Пароходтан Балык Бистәсе пристанендә төшеп калуга, райкомга кереп, мөһерле пакет тапшырдым. Моны Әбҗәлилов кушкан иде. Райкомнан бер вәкил биреп, ат белән озатып куярга булдылар. Әмма мин ялгызым җәяү генә киттем.
Авылда мине элеккеге алпавыт йортына — икенче катка урнаштырдылар. Беренче каттагы залны клуб, уку ызбасы иткәннәр. Икенче катта авыл советы. Бер бүлмәне Рамазанов өчен бушаткан булганнар, мине дә шунда керттеләр. Димәк, аны төнлә, караңгы тәрәзә каршында уйланып утырганда түгел, ә шушында, икенче катка менеп, бүлмәгә кереп үтергәннәр икән. Өстәлгә капланып яткан көенә тапканнар. Ишекнең эчке келәсе нык. Төнлә ул аны белгән кешесенә генә ачар иде. Юк, ачкан. Тагын сорау: дошманмы, яхшы белешме? Димәк, ул аның дошман икәнен белми ачкан. Ярты төн җиткәндә, үзе ишек ачып керткән үтерүче аңа яхшы таныш булгандыр. Ярты төн җиткәндә, чөнки шуңынчы җыелыш, аннары яшьләрнең уены булган. Җыелышта каралган мәсьәлә — станция төзү.
Боларны авылга килеп төшкәнче, районда ук белешеп кайттым. Ә монда — бу хакта ләм-мим. Берни белми дип санасыннар. Биредә сорашынсам, курка калган дип уйлаулары бар. Үтерүче дә сагаймасын.

Ә халык Рамазановка да, миңа да алмаш киләчәген белеп, ышанып торсын.

Шәмәхә кара таплары белән чуарланып бткән яшел бумази материяле өстәл янында утырган чулак милиционер белән исәнләштем.

— Каһир Сафин кайда?

— Председательме? Туйда ул.

— Туйда...

— Чакыртыйммы?

— Кирәкми,— дидем мин. Сез — Идрис Ярмиевме?

— Әйе,— диде ул басып.— Мин сезне көтәм, көтәм...

— Юктыр. Мин сез көткән кеше түгел.

— Казаннандыр ич?

— Казаннан. Рамазанов урынына. Мине дә үтерсәләр, сезгә эш артачак.

— Шаяртмагыз әле... Казаннан тикшерүче килүе ихтимал дигәннәр иде, сезне шул дип торам.

— Нинди туй?— дип сорадым мин бу хакта сүз беткәнгә ишарәләп.— Килен шәпме соң?

— Бөтенесе бер иш.

— Сафин «ишеләргә» генә бәйләнмәстер. Зәһ-һәр егет диделәр.

— Өйләнүче ул түгел. Укытучы Ширәмәтов.

— Сезне дәшмәдемени?

— Дәште.

— Эш күпме?

— Эш бүре түгел, урманга качмас иде.

— Алайса ник бармадыгыз?— Мин тимер сандыкка барып утырдым.

— Ул... кулак кызына өйләнә.

— Кулак кызына? Ә сез ни карыйсыз?

Ул кулын җәеп җибәрде. «Нишләтмәк кирәк?» диюеме?

— Ә Ширәмәтов комсомол. Белмәссең, үзе ул әүвәлгеләрдән.

— Нинди «әүвәлгеләр»?

— Шушы йорт хуҗасының оныгы.

— Шикләнәсезме әллә?

— Болай... шәп егет үзе. Театр оештырды. Ызбага радио ясап куйды. Кешеләргә гәҗитләр укый. Йөз егерме стакан сатып алган, өч литрлы банкы... Чәйханә ачарга җыендыңмы әллә дип көлсәк... Бактың исә шул радиога аккумулятор ясарга икән. Башлы егет! Тик тормый.

— Бәлки контрадыр?

— Бер дә сизелми алай...

— Кулак кызына өйләнүе дә сизелмиме? «Шәп егет»! Шәп булгач, туена да барырга иде. Баш кода булып!

Бераз арттырып җибәрдем бугай, ул түшәм бизәкләрен күзли башлады. Ә түшәм матур иде — яшел җирлектә бронза төсендәге затлы бизәк.

— Кулак кызы дигәч тә... ул кыз беләсезме кем? Дөньяның астын өскә әйләндереп йөргән кыз ул. Колчакка каршы.

— Кызык туй,— дидем мин.— Алпавыт оныгы — комсомол, кулак кызы — Колчакка каршы... Кияве дә шәп, кызы да... Бер Рамазанов кына юк.

— Алар бик кайгырышты.

— Кайгыларын туй белән басалармы? Авыл советы председателе белән бергә. Район милициясе башы гына җитмидер шул. Казаннан көтеп ятасыз. Ә килмәсәләр.

— Сез урнаштыгызмы әле?— дип сорады ул.

— Өлгерермен.

— Минем китәсем бар иде.

— Хушыгыз,— дидем.

Ул чыгып китте. Уңайсызланып куйдым. Катырак сөйләштем ахрысы. Куып чыгарган ише ич инде бу. «Начальник» имеш! Кем начальнигы? Инеш суыныкы. Ә су ага да ага.

Кинәт миңа тирләгән көйгә бер тәпән салкын су койган шикелле булды. «Әллә бу... әллә бу — козгыннар туемы? Корбаннары өстендә?»—дип уйладым. Кемгәдер:

— Козгыннар туй итә, ә сез кышкы чебен шикелле ике тәрәзә арасында йоклап ятасызмы?!— дип кычкырасым, бар гайрәтем белән өстәлгә китереп сугасым килде. Тик сизеп торам: беркемгә дә бәйләнерлек сәбәп юк — туй итәләр, барысы да ал да гөл. Ширәмәтов «шәп» булмый нишләсен? Начарлыгын күсәк итеп, күрәләтә болгап йөрсенмени? Чылбырсыз эт көндез өрми. Комсомол. Гаҗәп — нигә аңа бәйләнәм әле мин? Ни хакым бар? Алай дисәң, әнә — этне эткә тарткан! «Шәп» икән, нигә гади кызга өйләнмәгән?

Уйларымны бүлеп, егет җиләне кебек гайрәтле җилпеп, ишекне ачтылар.

— Менә мин! Каһир Сафин!— диде кергән кеше, кепкасын салып, пинжәгендәге тузанны каккалады.— Кунак бар икән.

— Алайса, әйдәгез, керешәбез,— дидем мин.

— Нәрсәгә?

— Кунакны сорау белән сыйламыйлар.

— Яңгыр килә,— диде ул, киң тәрәзә төбенә йонлач, зур куллары белән таянып, сары кашага астыннан югартын карап алды.— Сәбәбе бар.

— Нәрсәгә?— Бу юлы сорауны мин бирдем.

— Кунак хуҗаның ишәге — сорау тыйнаксызлык.

— Ә сәбәбе минме, әллә яңгырмы?

— Икесе дә... Димәк, Рамазанов урынына?

— Аның язмышын теләмәс идем. Бигрәк тә җәй башында кабергә керәсе килми.

— Ә мин Рамазановны костырам әле.

— Кемнән?

— Без капчыкта ятмый ул.

— Без капчыкта ятмаса да, Рамазанов каберда ята.

— Авыр туфрагы җиңел булсын.— Ул урындыкка утырды, аның авырлыгыннан урындык шыгырдап куйды. Аннары кесәсеннән ачкыч чыгарып, өстәлнең сул ягын ачты һәм кәгазь бөкеле шешә белән касә алды.— Яңгыр алдыннан, ә? Арылды, йокы килә.

— Рамазановны да шулай «йокладыгызмы»?

— Мин аларга лава оештырам әле!..

— Лава?

— Белмисеңмени? Кавалерия атакага җиңәр өчен лава белән бара. Кытыклыйм әле мин аларны—маетләр каберләреннән чыгарлык итеп.— Ул китек касәгә шешәсен туп-туры кире каплап, аракы агызды, миңа сузды.— Килүең белән. Рәхмәт сиңа.

— Мин эчә алмыйм,— дидем,— туры килгәне юк.

— Ирексезләмим,— диде ул, касәне бер тын белән эчеп бетерде дә шешәне тагын бөкеләп куйды. Торып, түрдәге ике тәрәзәне дә ачып җибәрде.— Аздылар!— диде ул каядыр йодрыгын күрсәтеп.— Бугазларыннан алмый торып, берни чыгасы юк.

— Станцияне әйтәсеңме?

— Башта колхоз оештырасы иде, аннары — станция. Менә шунда йөгән киертер идем мин кайберәүләргә. Тәртәгә генә керсеннәр. Кайгырма!— диде ул иңбашыма авыр кулын салып.— Авызлыкка риза булмасалар, явызлык ашарлар, шулай бит?

— Белмим, минем эш — станция.

— Әйдә, башта ашап килик әле... кем...

— Ислам Зәйнушин.

— Иманнарын укытырбыз әле, әйеме?— Ул башын артка ташлап көлеп җибәрде дә кыл түбәсенә төймә тагып куелган соры кепкасын киде.— Әйдә, ач кешенең ачуы яман.

Ашарга Идрис Ярмиевләргә кайтырга сөйләшкәннәр икән — шунда киттек. Салам түбәле, усак, юкә, имәннән буралган йорт. Карлыгачлар, чыпчыклар буяп бетергән тәрәзә йөзлекләре. Чоланлы өйалды. Кырып юылган идәнле һәм сәкеле тәбәнәк бүлмә. Җиз самавыр, чәчәкле-чачаклы пәрдә, кашагалар, тәрәзә төпләрендә кына гөлләре, сәкегә аяк бөкләп утырган, кара бәрхет түбәтәй кигән әтине һәм иңенә ак шәл япкан әнине күрермен, аларның чәй тәлинкәсенә өрә-өрә гәпләшеп утыруларын ишетермен дигән татлы бер хыял томаны эчендә уралып калдым. Тел очым кызышып китте. Кечкенә чагымда чатнама суык кыш көне капка келәсенә телемне тидереп алгандагы кебек. Әйе, нәкъ безнеке шикелле үк өй, тик әти белән әни генә юк. Хуҗабикәнең ачык чырай, көр күңел белән каршылавы гына таныш. Әнинекенә охшаш. Күземнән яшь бәреп чыкты. Ишегалдында комганнан юынып кына керешебез, әле сөртенмәгән идек, битне пешереп төшкән ике яшь бөртеге су тамчылары йотты.

Апа табак тулы бөтен бәрәңге, тирләп торган салкын чүлмәк белән сөтле катык, ярты бөтен арыш ипие китереп куйды. Каһир белән Идрис абый аякларын бөкләп сәкегә утырды, мин — урындыкка. Янибызга «пуф» итеп торган җиз самавыр да менеп кунаклады. Самавыр капкачы астыннан ап-ак йомыркалар килеп чыкты. Салкын сулы чүмечтә йөздергәннән соң, хуҗабикә аларны берәм-берәм алдыбызга тәгәрәтеп җибәрде. Кыстый-кыстый ашаттылар. Ян тәрәзәләр арасындагы стенадан безгә саргайган фотолар, түр стенадан Сталин портреты, чаршау артыннан ике кыз, бер малай карап торды. Табынга үсмер малайлары да утырмады: ул ишегалдында өч җапле агач сәнәк ясап маташа иде. Ясап бетергәч, озын саплы сәнәкне абзар түбәсенә кадап куячаклар: кош сөяге кебек җиңел булсынга. Тиздән печән өсте җитә. Мин боларны онытмаганмын икән әле.

Ашагач, күңел күтәрелде, өчәүләшеп инеш буена төшеп киттек. Станция урынын Рамазанов авыл уртасыннан сайлаган. Чирәм катыш каз үләне белән капланган урамны аркылы чыгып, читән тыкырыктан төштек. Читән буенда кара кучкыл яшел кычыткан, көмеш һәм кара әрем, тузганаклар, табак-табак әрекмән; кыл уртада бер генә кеше басарлык чип-чиста сукмак: читән артында инде чәчәккә бөреләнә башлаган бәрәңге, нәзек көнбагышлар, чеертергә өелгән быелгы тирес өемнәрендә кабак үсентеләре, бәрәңге арасында суган түтәлләре.

Кулларын каш өстенә куеп, безне хатыннар, карчыклар карап кала. Идрис абый, туктый-туктый, аларга нидер дәшә, ул арттарак. Могаен, мине сорашалардыр. Ә мине яшәү рәхәтлеге басты. Бөтен күңелемне изрәтүче ниндидер җыр ишетәм сыман. Тар тыкырыктан су буендагы тугайга килеп чыккач, күптән очратмаган дус-ишне күргәндәй, кулларны җәеп җибәрәсе килде. Әйләнә-тирә дөнья белән кушыласы, шунда эрисе иде. Үземне тирән йокыдан уянган итеп тойдым. Тик нидәндер читенсенәм, күкнең көньягында яшелләнә башлаган болытлар кебек, күңелемне ниндидер шом баса башлады. Минем мондалыгым чын түгелдер, боларны ниндидер бер рәсемдә яки театрда гына күрәмендер шикелле.

— Менә шушы төш,— диде Каһир, тирән ярлы инеш буена килеп туктагач.

Төбе аксыл үзле балчыклы, яшькелт сулы инеш, текә борылыш ясап, авылга таба каерылган урын. Тоба. Теге якка чыгар өчен аркылыга ике тал агачы кисеп салганнар. Агачны суга чупылдата-чупылдата, председатель аргы якка — инешкә кушылган тирән ярлы ерганакка кереп

китте. Сөзгрәк урыннан югары мендек, туфлине салып, торфлы туфракны кактым, оекларымны да салып куйдым. Җиргә яланаяк басмаганга ни гомер икән инде.

— Я, Каһир, кая, ничек салабыз?

— Эшкә килгәндә, син миңа иптәш Сафин дип кенә дәшсәң дә ярый.

— «Дип кенә»!— дип көлдем мин.

— Нигә ыржаясың? Синең шикелле кешеләр миңа «иптәш» дип эндәшсә, сиңа файда гына ич. Абруй четерекле нәмәрсә ул.

— Аңлашылды: сине тыңласалар, мине тыңлыйлар да тыңлыйлар, шулаймы?

Көлүдән чак тыелып, күн пинжәгемне салдым. Каһир аны капшап карады.

— Ошаса, ки!— дидем. Икс дә уйланып тормадым. Нарком хәтле нарком җибәргәч, яңа пәлтә белән бүректән дә артып калыр әле.— Монда фантазияне эшләтеп була!— дидем мин ярларны күздән кичереп.

Идрис абый шырпы шикелле дөрләп китте:

— Рамазанов, мәрхүм, анау төшкә буа буарга уйлаган иде,— дип башлады ул гарип кулын бөтен озынлыгына алга — тоба башланган якка сузып.— Әерганакка — стансы. Субайлар өстенә.

— Кулың нишләгән иде?— дип сорадым мин.

— Нишләсен... Ул минем ни сораганымны аңламый торды.— Ә, кулмы? Үзем.— Тешен кысып һәм шадра йөзен җыерып, ул балта чапкан хәрәкәт ясады.

— Ялгышмы?

— Уйнап,— диде Каһир.

— Балта беләнмени?

— Кашык белән,— диде тагын Каһир.

— Ярар, ташла,— диде аңа Идрис абый.— Кылыч белән.

— Үзеңме?

— Үзем кулны кисмәсәм, башкалар башны кисәсе иде — шул.

— Кем?

— Басмачылар. Фрунзега пакет илткәндә.

— Нинди пакет?

— Кызлар сәламе,— диде Каһир житди йөзенә бер тамчы да елмаю чаткысы чыгармыйча.

— Кем белгән?— диде Ярмиев.— Минем эш илтеп бирү.

— Тапшырдыңмы соң?

— Тапшырмаса, ул әллә кайчан аллаһы тәгаләгә пакет апкиткәние инде,— диде Каһир.

— Тапшырмый ярамый торган пакет иде ул... Басмачылар эзгә төште. Атны үтерделәр, елан шикелле, тау-таш арасына качтым. Табып кара — ястык мамыгына кереп качкан борча белән бер. Шунда бер таш кузгалып, кулны кысты. Тырнак астындагы кандала хәлендә калдым. Шуннан...— Идрис Ярмиев, җирәнгән сыман, йөзен чытты.— Ике чабуда... Әллә кул иде, әллә карт әтәч муены...

— Шуннан?

— Шуннан...— Ул исән кулын лобогрейка канатыдай өстән айкап, үзе борылмыйча гына артка изәп җибәрде.— Менә бу турыдан стансыга канау җырасың, анау тупыллар арасыннан...

— Ә пакет?

— Шуны сургычлаган җепне чишеп, беләкне бәйләп куйдым. Тик бит пакет ачык?! Кем укыган? Дусмы да дошманмы?.. Духтыр беләктәге җепне чишеп күрсәткәч кенә ышандылар.— Ул тагын тупылларга таба борылды.— Урта бер җиргә — шлюз.

— Ә тегермәнне?

— Телибез икән — ходай тәгаләнең култык астына. Токны тимерчыбыктан хет айга суз. Баганаң гына житсен.

— Боларны кем әйтте?

— Рамазанов. Юныс кордаш, авыр туфрагы җиңел булсын... Ә тегермәнне тау башына салабызмы?— Ул авылның урта урамы барып төртелгән тауга ишарәләде.

— Җил тегермәне түгел ич.

— Булса соң!

— Ул тауның теге ягында— Брынка, урыс авылы,— диде Каһир.— Шуларның күзен ут итәсе килә аның.

— Ник?

— Өченче ел Степан дигән байларның ике ташлы су тегермәнен тартып алдылар. Хәзер борыннарын чөйделәр. Элек күбесе безнең тегермәнгә йөри торганые.

— Үзләренеке була торыпмы?

— Степан кыйммәт каера торган иде. Аңа беренче тирең генә ярамый, җиденчесе кирәк...

— Рамазанов станциягә уңай урын тапкан.

— Уңай.

Буа буасы урыны тар. Канау казыйсы җире үзле балчыктан, су ашамый торган. Станция утыртасы чокыр тирән, турбинадан чыккан су инешкә аксын өчен өстәмә казу эшләре белән мәшәкатьләнәсе юк.

Сыңар кулын гайрәтле селтәп, Идрис абый:

— Тик монда салырга ярамый,— диде.

— Рамазанов шушында сайладымы соң?

— Шушында.

— Уңай урын лабаса.

— Ярамый.

— Үзең кодалыйсың...

— Чибәр шайтан кызына өйләнер идеңме?— диде Каһир.

— Бусы нәрсә тагын?

— Юк, өйләнер идеңме?

— Шайтанның чибәре булмый.

Кинәт ул шаркылдап көлеп җибәрде:

— Күргәнең бармыни?

Хатамны төзәтергә ашыктым:

— Шайтан гомумән юк.

— Кәләш никадәр чибәр булмасын, акыллы егет әүвәл аның килмәгән җире юкмы икәнен тикшерә. Шул менә, онытма: чибәр шайтанга өйләнмиләр.

— Станцияне шайтаннар төземәс шул, үзебезгә туры килер.

— Менә, менә, менә! Кара: монда корабыз икән, ярты авыл диңгез буенда кала, яртысы далада. Авылның йөзе өтекләнә, җаны урталай киселә.

— Сезгә электр кирәкме, әллә...

— Безгә хәзер үзебезнеке тиешле бөтен нәрсә кирәк. Мин монда гомерлеккә. Мин монда яшим.

— Бу аргумент түгел. Ун көндә исәп-хисап эшләрен төгәлләп керешергә үк кирәк.

— Ә шайтан бар монда!— диде Каһир.

— Чибәрме соң?

— Кара: буа буасы урын тар, хак. Кызлар биле шикелле. Тик бит кызлар билдән генә торса да яхшы түгел. Аларның хикмәте кинрәк җирләрендә. Буа да шулай. Монда бөтен җир тар. Хәтмәле генә яңгыр явып ташласа? Буаңны шундук ялмап йота ич, артык су тотарлык урының юк. Аннары: язгы ташуда бу ерганактан аккан су станцияне ишләтә? Итәге астына керә дә... хуш, сау бул, кодача!.. Һәр нәрсәнең үз шайтаны бар. Күрмәмешкә генә салынабыз.

— Үз тәнебездә йөрткән үлем скилетын күрмәмешкә салынган шикелле,— дип өстәде Идрис абый.

Кичә генә мин гади крестьянны бүре өере артыннан тузгып калган тузанның басылуын сабыр гына көтеп торган, кая таба барырга икәнлеге шунда күренер дип көткән, һәркайсы үзенә аерым һәм ялгыз төлкеләргә тиңләгән идем. Ак түбәле фуражка, брезент каеш белән билен буган гимнастерка, галифе һәм кирза итек кигән ябык Идрис абый да, аягына молотилка ремененнән кисеп, шуңа кирза өслек тегелгән һәм кырыйлары чачакланган сандал кигән Каһир да мин күзаллаган крестьяннарга туры килми иде. Бер-берсенә бәрсәң, чатнап ут чыгарлык чакма ташлары.

Ә авыл — минем аңымның караңгы бер почмагына сыенган карт һәм юаш бер песи. Кабер ташы шикелле авыр басынкылык, кисмәктә озак торган су сыман торгынлык, үзенә нигә кирәклеген дә белмәгән законнарга сукырларча буйсыну. Түрдәге сәкедә туып, шунда иң күбе чүпрәк курчак яки бәрәңге ат белән уйнауларын тора-бара шул ук сәкедә мәхәббәт уеннарына алыштыручы, шушында ук үзләренә ике тамчы су шикелле тиңдәш балалар табып, аларның исәнлеге өчен калтыраучы, иреннәренә соңгы тамчы су тигәнен сизми дә калып үлүче кешеләр. Аларның бер яктылыктан икенче яктылыкка, бер караңгылыктан икенче караңгылыкка күчкәнче корама юрган астында, һәм, вакытвакыт тышлыгы алыштырылып юылса да, сүрүе, бигрәк тә мамыгы бер буынның ярты гомергә җитә торган ястык-түшәктә ятулары; кайгырып елаулары янсә шатланып көлүләре; бала бишеге тирбәткәндә җырлап көйләүләренең мәет күмгәндәге елап көйләүләре белән аерылгысызлыгы... Сука белән җир сукалаганда, чабагач белән ашлык сукканда, пычак белән мал суйганда, уклау белән камыр җәйгәндә, мунчала белән идән юганда һәрвакыт һәм һәркайда маңгай бер төрле тирли, баш бер төрле уйлый — тамак тук булсын! Әмма бу бит әле җиде күкнең идән астында адашып йөрү генә.

Мин шулай дип белә идем.

Авылга бүтән кешеләр хуҗа икән — Каһир Сафин, Идрис Ярмиев кебекләр. Алар тормыштан мәгънә эзли. Алар киләчәкне күрә. Алар үзләре дөрли, тормыш учакларының да дөрләп торуын тели. Алар хәерчелектә һәм мәхрүмлектә чукрак балага җыр җырлагандай мәгънәсез үткән авыл тормышының баш очына мәңгелек лампочка элеп куячакларына ышаналар, югыйсә «Брынка кешеләренең күзен ут итәргә» бу кадәр дә атлыгып тормаслар.

Ә сүз вакытлы су электр станциясе хакында гына лабаса. Минем пальто һәм бүрек алыр өчен эшләп торуым да вакытлы. Ахыр килеп, гомер дә вакытлы. Бар да вакытлы.

Әллә минем бу авыл кешеләрен кызгануым, алар тормышын бәхетсез, караңгы, рәхәтсез итеп күрүем ялгыштыр? Бу минем күктәге бер йолдызга карап:

— Анда кешеләр бар микән?— дигән сорауга:

— Бар, ләкин алар ничек ерак яши, мескеннәр!— дип җавап бирүем ише түгелме соң? Чиксез галәмнең кайсыдер читендә (менә тагын — «читендә». Ә нигә уртасында түгел? Бәлки галәмнең читендә без үзебез торабыздыр? Әмма үзебезне кимсетмәү, үзебезне иң югары цивилизация вәкилләре итеп күрү өчен без үзебезне дөньяның кендеге дип хис итәбез, эгоистлар!)... әйе, чиксез галәмнең кайсыдыр... ноктасындагы тереклек ияләрен Җирдән ерак торганнары өчен генә мескен дип атаган шикелле, шәһәрдән читтә — уңайсызлыкта, хәерчелектә яшәгәннәре өчен генә бу авыл кешеләрен бәхетсезләр сурәтендә күзаллавым ялгыштыр. Идрис абыйлар тормышы турында караңгы төсләрдә уйлавым өчен мин үземне гаепле санамыйм, чөнки минем башка килгән фикерләр, кайры астындагы кортлар сыман, аларның башын да кимерәдер.

Аның «үз тәнебездә үлем скилетын күрмәмешкә салынган шикелле» диюе әнә шул кортлардан берсенең кайрыны тишеп, якты дөньяга каравыдыр. Алар үз язмышлары белән канәгать түгел. Юкса, станциянең кайда торачагына алар бу кадәр борчылмаслар иде. Станцияне төзү, аларга, бәлки, язмышыннан узу булып тоеладыр.

Секундның ниндидер бер өлеше арасында мин кызганудан — шикләнү, шикләнүдән — кире кагу, кире кагудан ышану юлы үттем.

Һава бөркүләнде. Тынлык бөтенләй бушап калды. Авыл, су буендагы казлар, аркандагы бозаулар, кешеләр, урман, каршыдагы тау — һәммәсе зур бер табада куырыла башлады кебек.

— Чибәр шайтан кызы дисез инде алайса. Сез хаклы,— дидем мин.— Рамазановка шулай әйтмәдегезмени?

— Аның сайлаганы астарак,— диде Каһир. Ул авыл урамы барып төртелгән тауга күрсәтте.— Шул тау итәге астында.

— Нигә башта ук шунда алып бармадыгыз соң?

— Аннары барыбер монда менәр идең.

— Алайса бу урын барыбер яхшырак.

— Монда җиңелрәк — казыйсы, күмәсе әзрәк.

— Бик шәп — тагын нәрсә кирәк?

— Безгә станция кирәк,— диде Ярмиев, фуражкасын салды да, тезенә куеп, җиңе белән эчендәге тирләгән күнен сөртеп алды.— Авыррак булыр. Тик авыр эш явыз хатын түгел, без аннан курыкмыйбыз да, җирәнмибез дә.

Алар күрсәткән урында инеш, тәкәббер сарык тәкәсе сыман, тауны китерен сөзгән дә, башы түнеп, бер урында әйләнгәләгәч, авыртуына түзә алмыйча, кинәт авылга таба сикергән шикелле. Инеш маңгае белән тау бәрелешкән җирдә кантар-кантар ак ташлар актарылып калган: гүя тәкә маңгаеннан чәчрәгән ми кисәкләре кояшта катып, ташка әйләнгән. Авыл урнашкан тау итәге буенча тигез тугай калдырып, инеш туры барган җиреннән тау артына кача. Шушы урында аның ярлары киңәеп, суы күбәеп киткән. Гүя тау итәге астында үзенең тәкәбберлеген җиңгән су кызы белән кушылган да, инде үзенең тәртипсез малай чагын сагынып утыручы уйчан ир кебек, ял итә. Ярсулар басылган, дәрт сүнгән, инде тау-ташлар сөзә-сөзә мөгез нигытасы юк. Хәзер бар көче тирән суында.

Шушы урында аның биленә буа буганнар. Шушында ук иске су тегермәне тора. Ул артын чөңкәйткән килеш, ярда кер чайкаучы юан хатынны хәтерләтә шикелле. Тегермән урнашкан чокыр, бөтен яктан карт тупылларга уратылган, күренми дә.

Авыл өйләре моннан ерак, карга ояларыдай кечерәеп күренә. Бер йортның капка төбенә кешс җыелган. Иң биек йорт. Ике катлы. Анда шау-шу, көлү, кычкыру, карлыккан гармун тавышы.

— Әһә, туй башлана,— диде Каһир.

Җирдә үзенә корбан күзләгәндәй, карашны ниндидер тылсымы белән иярте п, зәңгәр рәшә диңгезендә ялгыз тилгән әйләнеп йөри. Кояш әлсерәткән һәм торган саен җәелә барган болытлар күләгәләгән бар дөньяның кендеге кебек.

— Теге нинди йорт ул?— дип сорадым мин яр өстендә агарып торган ике катлы ак бинага ымлап.

Каһир көлеп җибәрде:

— Бая гына шуннан чыктык ич. Икенче катында син торачаксың. Морзадан ким булмассың әле.

— Нинди морза?

— Алпавыт. Татар алпавыты. Шушындый имение тоткач, патшаның артын теле белән ялаган инде ул.

— Синең тәрәзәң теге якка карый,— диде Идрис абый.
— Инешкә караган тәрәзәле бүлмәсе юкмы соң?
— Инеш теге яктан да күренә. Безнең авылның өч ягында су, бер ягында тау. Дошманнардан сакланырга уңай булган. Безнең авыл хан заманыннан гына түгел, әллә кайчаңгы.
Авыл урнашкан үр астында — елга белән ике арада башларын күккә чөеп, алтын кәүсәле наратлар үрә каткан. Аларны кыл уртага ярып, инде чәчәк атарга җыенган юкәләр сузылган — аллея ахрысы. Елга буенда ук куаклар (шомырт, чияләр бугай) чүгәләп утыра.
— Алпут паркы,— диде Идрис абый.
Аллея үргә барып төртелгән җирдән алпавыт өенә ап-ак ташлы текә баскыч менеп китә.
Күңелемнән генә станцияне иске су тегермәне урынына корып җибәргән идем инде. Елганы текә яр турысыннан борылыш артында буасың, сөзәк ярны ерып, станциягә таба канау казыйсың. Ул чагында бу тирәдә байтак җирне су басачак, шул исәптән паркны да.
— Монда яр җитәрлек тирән түгел,— дидем мин.
Каһир минем күз карашымнан алпавыт бакчасына игътибар итүемне сизенгән ахрысы.
— Под корень,— диде ул нигәдер русча.— Тырнак астына! Эзләре дә калмасын. Стоп кран... Баста!
— Матур бакча. Әрәм.
— Ә авыл ямьсезме? Ник ямьсез? Алар матурлыгы белән янәшә торганга. Безгә бүген ипи кирәк. Ни ягып пешә ул — барыбер.
— Ә минем кулны ямьсез дип беләсеңме?!— диде Идрис абый. Алар теләктәш иде.
Каһирның күзе очкынланып китте. Бу мәлдә ул минем күн пинжәкне кигәнгә, ярсулы карчыганы хәтерләтә иде. Өстәвенә ул, очып китәргә җыенгандай, пинжәкне салып, ачу белән җиргә шапылдатты.
— Безгә байлар калдыгы кирәкми. Үзебез! Теләсәк кисәбез, теләсәк турыйбыз. Сукыр тычканмы без — кем? Җитәр!
— Кызма,— дидем мин.— Бакча күмелгәч, шлюзны кая куябыз?
— Аргы як ярны уяргадыр бәлки?
— Анда зират — ярамый,— диде Идрис абый.
— Зират? Хан заманыннан калган!
— Изгеләр зираты.
— Изгеләр? Хәзер бездән дә изге кем бар? Әзме кан түктек? Без түккән кан елгасына станция корсак, кояш ягысын басар иде, кояш!
— Нинди изгеләр зираты?— дип сорадым мин.
— Кем белгән аны? Хәзер анда берни юк. Бер-ике таштан гайре. Ташландык. Авыл зираты башка төштә.
— Юк,— дидем мин,— зиратка тимибез. Яр белән парк арасына дамба сузабыз, парк урыны — станция алдындагы сусаклагыч булыр.
— Көрәк беләнме?— диде Ярмиев.
— Борын белән түгел инде,— дидем мин.
— Авыр эшне эшләве гади,— диде Каһир.— Иң авыр эш — бала табу да кабер казу диләр. Ә тегесе дә, бусы да — момент.
Ул әгузесен әйтеп, корбанга сарык чалучы кеше кебек, салкын канлылык белән ярып сөйләшә. Шул сарык янына атланып, сират күперен кичеп булганга ышанган кеше кебек. Әле сират күперен чыккач та Кораеш елан янынан үтәсе бар ләбаса!
— Бу тау белән үр арасын бусакмы? Монда хет диңгез ташып тулсын — буа эһ тә итмәскә тиеш!
Өчәү утырып, сүзсез генә тәмәке тарттык...
Иң матур күренеш морзалар өенең балконыннан ачыла икән. Бер кич кунгач, икенче көнне, әле кояш чыкмас борын, бер очтан тәмәке дә тартып керергә исәплэп, шунда чыгып бастым. Җаным тыныч түгел

иде, тәнлә эчпошыргыч төш белән саташып чыктым, шабыр тиргә батканмын. Имеш, кайнар бер сулыш бар дөньяны яндырып бетергән, ташлар эреп, ябышып каткан, зәңгәрле-аллы төзәлмәс яман шеш төсендә. Һичкем калмаган, мин үзем дә юк, тик әле кайчандыр йөрәк шикелле тибеп, сулкылдап елый-елый аңым гына яшәп ята, имеш...

Саф һава, тәмәке исе күңелемне ачып җибәрде.

Утарны корып та куйганнар соң! Күз төшкән һәр нәрсә тынгысыз уйлардан җанны чистартырга тиеш дигән аек исәп монда бөтен нәрсәдән өстен торган. Табигать бар фасыллары, һәр куагы, һәр ташы белән әфәнделәргә хезмәт итсен, һәммәсе алар файдасына, аларның күңеле хуш торсынга.

Аста, нарат ябалдашларыннан югарырак, көмеш беләзектәй бөгелеп, елга ага, тау астында бәләкәй иске су тегермәне, ак ташлы текә кыя, таш баскыч турысыннан инешкә кадәр сузылган юкә аллеясы мине үз учына салып тирбәткәндәй итте.

Ә җимерек арба калдыклары, кыйшык абзар-куралар, алты баганасы гына сураеп калган капка хәрабәсе хәзер инде монда чит, әллә кайчангы, сагышлы бер төш кенә кебек.

Нииндидер бер кодрәт белән мин бу йортка бер... унбиш-егерме еллар тирәсе элегрәк килеп эләксәм, нииндирәк күренешкә тап булыр идем икән? Тып-тыныч, һәркемне һәм һәрнәрсәне тузанлы йокы баскан булырмы икән, әллә бар нәрсә какшамас тәртиптә торып, барча кеше үзлексез бер эш белән мәшгуль булырмы?

Кайсысын күзалларга белмичә, күземне йома төшеп, йөземне җылы җилгә каршы куйдым. Шунда минем хәтеремә, җил уяткан күмер шикелле соры көлдән арынып, дүрт-биш яшемдә бабай белән атка утырып, үзебезнең алпавыт утарына килеп чыкканым кейри башлады. Бабай биш көнгә дип алып торган җилгәргечен хуҗага илтеп тапшырды бугай. Ике капчык арыш белән борчак өстәп. Кичкә өзлексез вак яңгыр керешеп, ул урыс знакумында куна калды. Мин үземне әллә нинди томанлы бер дөнья эченә килеп эләккәндәй хис иткән идем. Каяндыр нииндидер тоныкр тавышлар яңгырый, һаваны сискәндереп, этләр өргәли, әче итеп дуңгызлар чыелдап җибәрә, дәррәү төстә казлар каңгылдашып куя, наян ачыргаланып, хатын-кызлар кычкырып җибәрә, ул арада ерак бер почмактан «малайка» (бабай балалайканы шулай атый иде) чиртергә керешәләр... Безнең Актырнакны әллә ничә эт уратып ала, ә мине урыс малайлары төрле яктан тикшереп чыгалар да, берсен-берсе уздырып, уенчыклары белән мактаныша башлыйлар. Этләренең эчләре умырткаларына ябышып беткән, малайлары салам тутырылган капчыкмыни. Мин бабайның знакумыйларына кереп китәм дә сандык өстенә ятып йоклыйм.

Бабай мине иртән иртүк уята. Ут әлми-нитми генә күчтәнәчкә алып килгән бал-май белән чәй эчәбез, ә мин кечкенә йомыш белән тиз генә өй артына барып килергә ниятләп, ачык болдырга килеп чыгам да башаягымнан ишегалдындагы томанга төшеп чумам. Юеш ташларга аяк очларым белән генә баса-баса, бабай өйрәткәнчә, кеше күзе төшмәстәй почмакка сыенып, бөрмәле киндер ыштанымны сул кулымның баш бармагы белән сыдырып төшергәч кенә, бөтен ишегалдын мендәр сүрүеннән тузгыган мамык шикелле пыр китереп, әче итеп быргы кычкыртып җибәрәләр. Бар сыным белән бөрешеп киләм дә, ыштанымны да күтәрергә онытып, болдырга йөгереп менәм һәм әңгер-меңгерле тәбәнәк җылы өйгә чәчрәп керәм.

— Бабай! Пес-с иттерттермиләр!

Ул кеткелдәп куя. Аннары тыныч кына итеп, бүз төстәге көрәк сакаллы знакумыена нидер әйтә, тегесенең тирән зәңгәр күзе елмаеп кысыла. Көрән төрепкәсеннән ак юеш чынаякка көл коела. Аның күз карашы ягымлы, нииндидер хәйләкәр шуклык белән яктырып тора сыман.

Бабай үрелеп минем ыштан бөрмәмне шапылдатып куя, аннары, «Спасибо, знакум» дия-дия, минем салкын учымны үзенең кайнар һәм каты учына яшереп, болдырга җитәкләп алып чыга. Калын чиста тавыш белән:

— И мне пора,— дип, безнең арттан яшел кожан кия-кия бабайның знакумы да ияреп чыга. Аның башында кырые көмештән каеган кызыл фуражка, аягында бабайныкы шикелле үк күн читек, тик аныкы гармун күреге шикелле җыерылып тора, баскан саен шыгырдый, ә бабайныкына галуш кигезелгән.

Түземем бетеп, болдырдан «чаптыра» гына башлауга, бөтен үзәкләргә үтеп, томан эченнән, караңгыдагы учак ялкыны сыман ярсу талпынып, тагын быргы тавышы ишетелә.

— Вчерась наш Митрофаныч семь волков подвыл — матерого, двух переярков, да еще четырех молодых. Счас с охотой выезжам-с...

— Харуша-а, знакум.

Бу сүзләрне ишетсәм дә, аңламадым. Бүрегә җыенуларын гына төшендем.

Ә хәзер, моны хәтеремә төшергән бер мәлдә, миңа ул иртәнең һәр сулышы, һәр кыштырдавы, ыгы-зыгысы таныш, аңлаешлы. Беренче быргы «Бөтенеңә кузгалырга!» дигәнне белдереп яңгыраган. Икенчесе «Атларны иярләргә!» дип яңгыраган. Быргы, билгеле, хәзер белүемчә, мөгез быргы булгандыр. Безнең алпавыт ау белән якынлашканда авыл халкы башта атлы казаклар дип шикләнеп, кайсы-кая посарга ашыга, ә без, куркуның ни икәнен белмәстән, каршы йөгерә идек. Аның ау кешеләре дистә ярымга җитә, төрледән-төрле этләре ике-өч дистәгә җыела. Бабайның знакумы — минем исемдә Ягур дәдәй булып калган кеше — алпавыт авын йөртүче. Аннан кала алпавытның атка атланган көйгә озын каешлар белән эт тотып, өстертеп, котыртып торучы кызыл казаки кигән сары чәчле малайлары да күп иде.

Кояш чыгарга байтак ара бар әле.

Абзар ишекләрен тупсасына шайлы каерып ачып, эчтә араталарны дөңгердәтеп җиргә төшереп җибәрәләр дә йөгән кидерә-кидерә яңадан-яңа атлар чыгаралар, буага алып төшеп эчерәләр дә ияр салалар. Барысы да ашыга, тик кабалану юк, һәммәсе пөхтә — беренче генә кабатмыни, күзләре йомык икән, куллары эшли, яттан.

Ягур дәдәй эт йөртүчеләрне эт абзарына ашыктыра. Менә-менә канатларын җәеп җибәрердәй кошка охшап торган дәү капка алдындагы тарантаска ике егет ат җигә, өченчесе — анысы малай — аңа коры печән түши. Каяндыр «Кузгалырга!» дигән гөлдерек тавыш яңгырый, атын юырттырып, уртага моңарчы күзгә күренмәгән быргычы чәчрәп чыга да, иярендә калка төшеп, мөгез быргысын авызына китерә. Күзе йомык, киеме көмеш каймадан да чуктан, ияре яшел бәрхет белән тышланган, аты авызлыгын чәйни, ирен почмакларында сары күбек кайный.

Ул арада алпавыт үзе дә күренә. Күн фуражкадан, алмачуар атка атланган, аты да, үзе дә ярсу, яңа уенчык шикелле ялтырап тора.

Карашымны бүтәннәргә күчергәндә, барысы да башларына киялар иде, хуҗаларын баш киемнәрен салып каршылаганнар ахрысы. Алпавыт йөзен әле бер, әле икенче якка борып, әллә ниткән әмерләр бирә, сорау ала, чуклы кыска камчысы белән кизәнә.

Чәбәләнәшеп, буылып өрә-өрә ике яктан ике эт көтүе килеп чыга, һәркайсы бәйле. Бер ишесе эзгә төшеп, җанварны урыныннан кузгатучылар, бер ишесе бурзайлар, болары кай яклары беләндер әкәмәт зур борчаларны хәтерләтәләр.

Ул арада бабай да карап тормаган, бер ярым колаклы сары бия безне арбага җигеп, капка ачылганны көтеп тора. Мин шома, балавыз шикелле сары салам түшәлгән арбага мүкәләп мендем дә аягымны

солы капчыгы астына тыгып куйдым. Солылы капчыкны бабай тан белән торып, ат авызына кигереп бәйләгән булган, күрәсең, ул анын тыныннан парланып, җылынып калган.

Капка җилләнеп ачылып китә, бырғы кузгалырга кушып кычкыртуга, ишегалды күз ачып-йомган арада бушап кала.

Без кырга килеп чыкканда, алпавыт авы, чуар йомгак булып, ерак калкулыкларда тәгәри иде инде.

Кайдадыр, кемдер, нәрсәнедер тиешенчә үтәп җиткермәсә, алпавыт, кызыл хәтфәле ияренда калка төшеп, яшел саплы камчысы белән уңлысуллы селтәнә-селтәнә:

— Я же велел, скотина: сострунил — тут же брось! А ты? Замешкался, зевал, аль струсил-с? — дип җикеренгәнен ишетәм сыман.

Шул ук вакытта ау йөртүче Ягур дәдәйнең калын тавышы, эт йөртүче малайларның этләрен өстерәп, өскортып, бүре эзенә төшерүе, нидер күргән эт өеренең эрәмәлекне тоташ ыңгырашу, чинау, ырылдаугә күмүе — болар барысы да һәм урманның кыштырдап, сагаеп, куркып, сискәнеп торуына хәтле миңа күренеп, ишетелеп тора кебек.

...Бозау хәтле ана бүре белән акка куе көрән таплар төшкән чуар эт маңгайга-маңгай килеп бәрелешәләр дә яшел үләнлеккә тәгәрәп китәләр. Бүре, сикереп торып, үз юлына төшмәкче, анын өстенә кузен кан баскан кара, пумаладай йөнтәс эт белән бер колагы җирән сыек сары бурзай ябырылып каба. Бүренең шул бер мизгелгә туктап торуы җитә: кушаяклап томырылган алмачуарын үрә торгызып, анын өстенә киң күкрәкле алпавыт үзе сикереп төшә дә алгы аякларын сигездән үргән чуклы камчысы белән бәйләп ата һәм, торып, чәнти бармагы тырпайган уң кулы белән күкрәген, тез башларын каккалый, аннары алтын портсигарыннан папирос алып каба...

Анын һәм ата бүренең кан баскан күзләрен күрәм шикелле. Ә малай-шалай бүрегә тешләрен батырып, шаша-шаша ырылдаган этләрне аера. Читтә мылтык гөрселдәп куя. Томан тарала, тарала... Мин балконда, тәмәке тартам.

## V

Без төзегәннәрне җимереп, без утырткан алмагачларны кисеп, авылны яңа урынга күчереп куйганнар. Кәүсәрия чиләгенә иелеп эчкәндә иренемне көйдергән суның чишмәсе аста калган — ләм астында. Яшьлегемнең иң матур эшләрен яәҗүҗ-мәәҗүҗдәй кимерә-кимерә, тиздән монда су күтәрелә башлар. Яңа дәрья.

Яшьлегемнең кызыл чәчәкле болыннарын сагынам. Язмышымның күз яшедәй чыклы, кояш кызарудан канлы тоелган чыклы чәчәкләрен яңа су сугарыр.

Тик нишләмәк кирәк: һәр заманның үз кешеләре, һәр буынның үз буасы, үз суы, үз юлы. Иртәгә бер тормыш гөле борнасын өчен бүген ике чәчәкнең сулуы кирәк. Әгәр бодай бөртеге җиргә төшеп үлмәсә, ул бер ялгызы кала; әгәр үлсә, күп орлык китереп, яшәвен дәвам иттерер.

Мин хәтерләгәндә, уйларым чәчәк ата, фикерем орлыгы өлгерә. Миләрегез сукаланганмы, тырмаланганмы? Уңдырышлымы? Хәер, фикер орлыклары уңдырышлы туфракта түгел, бәлки аек акылда борный.

Болыт каурые урталай бүлгән кып-кызыл кояш шары дөрләп янган офыкка чумды. Җиргә караңгылык пәрәвезе уралырга кереште. Бераздан төннең беренче күбәләкләре — төнге сәяхәткә чыккан йолдызлар күренде.

Апрель аендагыча чиста күк, чиста һава. Күмере генә калган учакка күсәк белән суккалагандагыча, төнге һавага бөҗәкләрнең сызгыруы,

кыштырдавы, чырылдавы күтәрелде. Шулар арасындагы иң әче сызгыруны ишетмәс өчен, учым белән колагымны томаладым, ләкин ул тавыш башымда икән: кан басымы күтәрелгән ахрысы. Аңлаешсыз авырлык, гүя кан тамырлары буенча кан түгел, салкын терекөмеш ага. Пинжәгемне, туфлиемне кидем, исән калган наратка барып сөялдем. Исмәгыйль кунак йортыннан урын белеште, тик әле минем буш бүлмәгә кайтасым килми. Көндез күргәннәремне һәм кичерешләремне хәтерем киергесенә киереп, үткәннәрнең истә калган бизәкләрен чигәм дә чигәм, әмма әле генә себереп өелгән яфракларны кисәк искән җил яңадан таратып ташлаган шикелле, бөтәя башлаган уйларым бер уч борчак булып чәчелә дә китә.

Үземнең гомерем диңгезендә мин үземне күрәм:

Болганчык еллар арасында тончыга язып, аяк басарлык җир күзлим, ләкин киләчәк причалының миндәй тузган көймәне кабул итүе икеле инде, килеп төртелер тыныч култык юк. Кәүсәрия искә төшми менә. Ул булса...

Чү! Ширәмәт морзаның мәрмәр шикелле ак йортыннан бакчага төшә торган таш баскычка нинди күбәләк килеп кунды ул? Аның яшел канаты, җир, су, үләннәр исе аңкытып җилпенгән җил, эни кулы сыман, битемне иркәли; каршы йөгерәм, әмма аның баскычтан-баскычка куна-куна түбән төшүен, төшкән саен зурая баруын агач артыннан посып кына күзәтәм, үзем күренергә оялам. Мин анадан-тума кебек... Мин синең алда үле энкәсе ятагында елап яткан бер сабый шикелле үксез кеше, Кәүсәрия! Гаеплемен, шуңа оялам. Чөнки мине тапканда, төгәлрәге, мине тапкач, йөрәгем тибешен ишетмичә үлеп киткән анам кебек син...

Каһир, таш һәм туфрак коя-коя, ярдагы кәҗә сукмагыннан авылга менеп китте. Әледән-әле мыегын сыпыргалавыннан аның кайсы якка юл тотарга ниятләвен чамалавы кыен түгел иде — туй барган ишегалдына, ә аннан табынгадыр инде, коры чыгармаслар. Күн пинжәгемне җирдән алып, ташка куеп китте. Мине дә кыстаган иде, кая инде! Мине кайдадыр яңа пәлтә белән яңа бүрек көтеп тора... Ерақта, бик еракта. Анда хәзер бары тик станция аша гына барып җитә ала идем инде.

Җәйнең яшь хатындай яңа гына чәчәк атып җибәргән, һәр исе борынны кытыклаган, эчке бер канәгатьлек нуры белән балкып киткән, ләкин елның иң ябык, иң ач вакытында нинди туй? Әле чәчелгән ашлыкны җыеп, җан борчуын басмас, ни яшелчә, ни җиләк-җимеш өлгермәс борын авылда туй ясау — көтелмәгән бәла килү белән бер.

Өреп сүндерелгән шәм кебек, кошлар тавышы тынып калды, бары тик керәшәләр генә чыр-чу килә. Ташлар кайнар. Тынны бөркүлек кыса. Чәчәкләр ябыла башлады. Яшенле яңгыр якынайды. Тау артыннан, ат көтүе чапкандагыча ерактан ук дөбердәп, күк күкрәве килеп житте. Аңа кайдандыр мылтык тавышы кушылды. Биектә канатларын җәеп очкан тилгән, учакка ташланган каен тузы сыман, җыерылып килде, тыпырчына-тыпырчына җиргә якынаеп, күздән югалды. Туй барган капка төбендәге халык кычкырып җибәрде. Алар арасыннан кемдер тилгәнгә мылтыктан аткан икән. Күк күкрәвенә шуның гөрселдәве дә кушылган. Берданка-фәләннән аттылар ахрысы, ау мылтыгыннан андый биеклектәге кошны чүкеп төшерүе — ай-һай! Халык каядыр йөгерде, күздән югалды, мөгаен, тилгән карарга дыр. Ә мин алпавыт паркына кереп киттем. Бакча уртасындагы бака үләннәре, су мүге белән капланган кечкенә генә түгәрәк күл буена килеп чыгарга өлгермәдем, баскычтан чиләк-көянтә аскан бер кыз заты, аның артыннан ук Каһир

төшүен күреп, юка агачы артындагы зелпе куакларына постым. Кыз чәчәкле ак алъяпкычтан, дүртпочмаклап бәйләнгән яшел яулыктан, чиккән күн читектән, чулпы тәңкәләре тез чокыры турысындагы балитәкләр турысында биешә. Каһир уң канаты очыннан тилгәнне тоткан иде. Кош исән. Вакыт-вакыт тартылып куя, авызын зур ачып сулый, кызыл телен чыгарып, зәһәр ысылдый, канлы күзе яртылаш йомык. Сөйләшә-сөйләшә күл өстендә дугаланып торган күпергә килеп керделәр. Көянтәдәй бөгелгән иске күперчек. Кыз иңендә яшел көянтә, ә суда — аларның чагылышы.

Мине кызыксыну биләп алды. Яхшысынмасам да, бу самими күренешне карап бетерәсем килде.

Тау башыннан болытлар ташкыны ишелеп төште. Агач башларын тиз генә тарап киткән җил тагын тынды, күл юка боз белән капланган шикелле, аны тик суүсемнәренең очлы уклары гына чәнчеп тора. Көянтәле кыз да болытларга карап алды. Чиләкләрен чумырып, күл суы алыр дигән идем, ашыкмады.

— Явыз, җәбер,— диде ул. Тавышы калынчарак, күкрәктән килә.

— Туйдырды!— диде Каһир кошны күтәрә төшеп. Ул тагын ысылдады, киерелеп тырпайган тырнаклы аяклары белән һаваны тырнады.— Көн саен — сезнең турыда.

— Синең шикелле.

— Пөхтә чәкедемме? Күз очлы минем. Кул да каты — калтырамый.

— Балаларын ятим итеп.

— Ата бу.— Каһир салкын тәкәбберлек белән тилгәнне кызның аяк астына ташлады. Кыз читкә тайпылды, күпернең кыйшык торган култыксасы булмаса, суга ук сикерер иде мөгаен. Кош Каһирга карап ысылдады, канаты белән күпер култыксасын кыйнады. Каһир кеткелдәп торды.

— Абау!— диде кыз, аңа яулык почмагы белән авызын каплаган килеш карап.

Каһир, тилгәнне котыртып, канат очыннан һавага күтәрде. Кош, аның күзенә карап, ярсу ысылдарга кереште. Каһир аны, киң селтәнеп, култыкса аркылы күлгә томырды, тик кош, бер канатын гына җилпи-җилпи, ярга очып җитәргә көч тапты.

Каһир кызны култыксага кысты.

— Синең өчен аттым. Күпме кеше тидерә алмады. Авылда ирләр беткән диярсең. Яулык кына ябып йөриселәре бар. Мәми авызлар!

— Әле ярый аттың. Юкса белмәс идем.

— Нәрсәне?

— Миһербансыз икәнеңне, Каһир абый. Шуңа кайгырам.

— Нәрсәгә?

— Өйләнгәч, хатының белән ничек торырсың икән дип.

— Бусы инде, Кәүсәрия, синең кайгы түгел.

— Менә, үзең дә әйтәсең, Каһир абый... Йөрмә дим, йөрмә, йөрмә...

— Миһербансыз дисең инде. Мин өйләнсәм, хатынның кайгысы ул булмас.

Кыз дәшмәде, аның култыксадан кулын алуыннан файдаланып, күпердән алга атлады, тик Каһир аны чиләгеннән тотып калды.

— Бүген чык әле,— диде Каһир.

— Тилгәннәрдән куркам.

— Сезнең тирәдә күренгән һәр тилгәнне шул көтәр.

— Үзеңне дәме?

— Мин үлгәндә тырнагымда чебеш булыр.

— Тырнакларың үтәр микән, Каһир абый?

Егетнең чиләк кырыен тоткан кулы бушап китте һәм түбән салынып төште. Ул аны кая куярга белмичә, чалбар кесәсенә тыкты.

— Йөрмә!— диде кыз һәм күпердән минем якка юнәлде.
— Эх, Кәүсәрия! Үкенүдән курыкмыйсыңмыни соң?
— Абау-у-у...— дип сузды кыз аңа таба борылып.— Кыланасың дисәм... күзең, күзең әллә нинди, Каһир абый.
— Пешерәме әллә?
— Суыта.
— Боз шул син.

Кыз күкрәгендәге сыңар толымын аркасына кайтарып салды, чулпылары чылтырашты. Чыннан да боз кисәкләре чыңы ишетелгәндәй булды.

— Шул бозны эретә алган егеттән дә бәхетлерәге булыр микән?— диде кыз һәм күк күкрәвенә кушылып көлеп җибәрде. Ул сукмакка төште, аның тирән күзендә якты чаткы уйнаклап алды — яшен чаткысы. Каһир, җәһәт-җәһәт басып, күпердән чыгып китте, җирне күк күкрәве түгел, ә аның аяклары дөбердәтте шикелле.

— Ул бозыңны мин дә утка сала белермен әле!— диде ул баскычка җиткәч.

Кыз авыз эченнән көлә-көлә тегермәнгә таба сузылган сукмактан китте. Сокланып, аңа иярдем.

Аларның очрашуыннан бөркелеп торган киеренкелек, кызның утлы бездәй тапкыр сүзләре мине дә дулкынландырган иде.

Бер мәл күктә, кармакка эләккән чабактай, коры яшеннең көмеш чаткысы сәбәләнеп торды. Болыт тауларыннан, шарлама булып, күк күкрәве коелды. Бакча күлендә бака бакылдап җибәрде. Ә миннән алда йөгерә-атлый барган кыз кире борылырга уйламады да. Җирне камчылап, туктаусыз яшен яшьнәргә тотынды, күк күкрәүләре инде аяк астында дөбердәгән сыман. Мин, әле бер генә тамчы яңгыр төшмәүгә карамастан, күн пинжәгемнең якасын күтәреп куйдым. Әни искә төште. Мондый яшен килгәндә, ул догаларын укына-укына морҗа калакларын, мич юшкәләрен ябарга керешә, тәрәзәләрне бармаклары тырпайган куллары белән сыпыргалап, пәрдәләрне тарта, җиз самавырны, көзгене каплый, яланбаш утырсак, башыбызга түбәтәй кидертә, йокымсырый башласак, йокламаска куша иде. Әти, яшенгә игътибар итмәстән, үзенә нинди дә булса шөгыль таба. Әнинең дога укып пышылдауларына әтинең дөнья хәлләрен сөйләве кушыла. «Ахырзаманда,— ди әни апа белән миңа,— шушындый яшен яшьнәр, күк күкрәр, таулар мамык урынына очып йөрер, балаларның чәчләре агарыр, картлар акылдан шашар дигән»...— «Ә алла, кешеләргә булыша алмыйча, карап торыр, имеш»,— дип кушыла әти. Бу аның, гадәттәгечә, әни белән бәхәскә керүе. «Алланың кешеләр газабына карап торудан башы чыкканы бармы соң аның?» — ди ул, чабата шөшлесен көчәнә-көчәнә калып белән юкә арасында йөртеп. «Әстәгъфирулла!.. Рәхмәтеннән ташламасын дигез, алласыз!» — «Аның рәхмәтенә калсаң, синең кысыр ашыңны тартып алырга да күп сорамый ул, беләңме?»... Әти белән әни шулай мин белә белгәннән бирле бәхәстә иде.

Җил чыкты, агач башларын тузгытып, үләннәрне җир күкрәгенә кысты. Болытлар мәгарәсеннән кояшның симез бите күренеп киткәли әле. Ул, тибешкән айгырларның кайсысы җиңсә дә яраганын белдереп торган бия кебек, болытларның үзара ызгышына битараф иде.

Кыз тегермән астына төшеп китте. Мин чокыр маңгаена килеп басканда, инде менеп тә килә иде. Чиләкләрендәге су җиргә иңгән караңгылыкта эрегән кургаш сыман күе, авыр булып күренә. Бер ботагы каерылган, дуга булып, җиргә иелгән тал астыннан чыгып килгәндә, ул мине күреп алды. Ни куркырга, ни читләтеп китәргә кыймыйча, бер кавым тораташтай катып торды. Кыздан матур бер гадилек аңкып, бөркелеп тора иде. Түгәрәк йөз, алга чыгыбрак торган ияк, чак кына

почыграк борын. Моңарчы мин һичкайчан очратмаган гадилек. Менә тал, станция, чирәм, таш, сукмак, җил, яңгыр исе, яшен... менә ул — алардан аерылгысыз, табигатьнең бер кисәге, ансыз бөтенлек югалыр, һәрнәрсә таралып китәр сыман.

— Кем син? — диде ул.

— Кеше,— дидем мин.

— Пәри дип торам.

Тоташ яңгыр шавы башланды. Эңгер-меңгер куера төште. Мин аның янына йөгереп килдем, иңендәге чиләк-көянтәне җиргә куярга булыштым да аны тегермән ышыгына әйдәдем, пинжәгемне салып, иңенә яптым. Карышырга өлгерми дә калды бугай. Беренче эре тамчылар чылаткан йөзеннән һәм киеменнән җылы ис тә бәреп чыкты.

— Эремәс идем әле,— диде ул,— тоз түгел.

— Тоз түгел,— дип килештем мин, төшеп китмәсен дип, пинжәгемнең өске төймәсен төймәләдем.

— Син чынлап та пәри түгелме?— дип сорады ул кызыл иреннәннән яңгыр тамчыларын сыпырып.

— Сүгенеп бак, бәлки юкка чыгармын.

— Яхшы кешегә сүгенмиләр.

— Каян беләсең?

— Кулыңнан.

Шунда гына күрдем: мин аның кулыннан тотканмын, ә ул тартып алмаган икән.

— Бәлки йөземнәндер?

— Йөз алдаучан.

— Ә кул?

Ул әкрен генә көлеп куйды.

— Начар кешенең кулы калтырамыйдыр...

Телем әйтергә кыймаганны белдергәне өчен, мин кулыма рәхмәтле идем. Әйтү — сүз генә, кул — эш. Күз курка, кул эшли диләр ич.

— Калтырасын ла!— дидем.— Мин... мин тилгән атарга җыенмыйм.

— Тилгән? — Ул кашын җыерды.

Тилгәнне искә төшерү аңа ошамады, сүзне бүтәнгә борырга иде, тик ни әйтергә кирәген белмим әле.

— Суыңны эчим әле?— дим мин.

— Эч,— ди ул.

Башка чара калмый, эчәсем килмәсә дә (ләкин телем кызып, сөйләшә алмастайга да әйләнүе бик ихтимал бит әле, эчеп кую зыян итмәс. «На всякий случай»,— дип уйлыйм мин. Тик нинди «случай» — белмим), яңгырга чыгып басам да, аның зәңгәр чиләген күтәреп, кырыена иренемне тидерер-тидермәстән генә сап-салкын су эчә башлыйм. Вакытны сузарга теләп, кирәгеннән артыграк эчәм.

— Очраганда су эчертерсеңме?— дип сорыйм мин.

— Сорарсыңмы соң?— ди ул.

— Сорармын. Тик кем дип сорарга?— дим мин, гәрчә инде аның исемен белсәм дә.

— Кәүсәрия дип...

— Матур исем... Ни белдерткәнен беләсеңме?

— Беләм.

— Кәүсәр иясе... Ә кәүсәр — яшәртә торган сулы чишмә бит, әйеме?

— Әйе... Ә мин кемгә... су эчертермен икән соң?

— Ислам атлы егеткә!

— Ә син кем соң?

— Ислам дидем ич.

— Юк, кем, кем? — дип сорый ул басым белән. — Каян килдең?

— Рамазанов урынына. Казаннан.

— Уй!— диде ул курыккандай. Төймәсен чишеп, пинжәгемне иңбашыннан кагып төшерде, тотарга өлгермәсәм, инде сукмакны тутырып аккан күбекле болганчык суга төшәсе иде.

— Мин аның өрәге түгел.

Ул чирәмдәге юеш көянтәсенә барып ябышты, кабалана-кабалана чиләкләрен элде. Көчле яңгыр аның юка яшел ситсы күлмәген чылатып, иңбашына, аркасына, ботларына сылап куйды, ул үтә күренмәле пыяла кызга әйләнеп калды. Өрәңге яфракларындагы тамырлар кебек, эчтән һәм тыштан килгәненең элмәк, җөйләре калкып чыкты.

Көянтәсе аша кырын карап, ул чәчен, яулыгын төзәтте. Колагында — тамчы гөле чәчәгенә охшаган кызыл кашлы алкалар.

— Мин Рамазановның өрәге түгел ич, нидән курыктың? — дип кабатладым мин.

— Яманрак.

— Өрәкләр күрә торган... өянәгең бармы әллә?

— Безне бергә күрсәләр — беттем!..

— Яман сүздән куркасыңмыни? — дидем мин.

— Тарханныкылар диләр безне. Сине... берәр нишләтсәләр...

— Үтерсәләрме? Рамазанов шикелле...

— Берәр нишләтсәләр, безгә гаеп тагасылары... илаһым аллам... көн кебек ачык.

— Ник?

— Минем апамны «шайтан кызы» диләр...

— Сине түгелдер ич?

— Минем апам Рамазанов белән... йөргәние... мине дә синең белән күрсәләр...

— Һәм мине үтерсәләр, икебезне дә сездән күрәчәкләрме? — дип, кычкырып көлеп җибәрдем.

Ул чокырдан менеп китте. Сыгылып торган тал ботагыннан ул куркыткан эре яңгыр тамчылары гына коелышып калды. Ул комга сеңгән су, онытылган төш кебек юкка чыкты... Аяк эзләрен, түгелгән сөтне эчкән песи баласыдай, яңгыр суы ялап бетерде. Сүлпән генә яшен уйнаклап алды. Бөтен җир бушап калды.

Түбә ышыгында басып торам. Ышыкта... Дөнья тынды, сүрелде. Исмәгыйль кайтырга дәшә, кунакханәдә аш суына ди. Ә минем хәтерем кайнарлана гына бара.

Кәүсәрия киткәч...

...Кәүсәрия киткәч, мине нидер шунда — туй барган җиргә әйдәде. Таш баскычтан югары менеп киттем. Илле биш басма. Туй, пычрак изә-изә капка төбендә йөренгән һәм койма башларына кунаклаган бала-чагага караганда, ике катлы агач йортта бара икән. «Аңлашыла,— дип уйладым мин беркемдә дә булмаган хуҗалыкка карап.— Кулак өере. Җәй уртасында кылангач, корсаклары ачлыктан бөрешми, күрәсең».

Вакыт үткәрер өчен генә булса да, аннары соң кызыксыну да баскандыр инде, моныңише мәҗлесләрне күрмәгәнемә туганнан бирле диярлек, шуның өстенә хуҗаларны һәм башка кешеләрне белеп торган да хәерле,— малайлар көтүен ерып, мин ачык кече капкадан ишегалдына үттем.

Таш җәелгән, яңгырдан соң юып алгандай чистарып калган ишегалдын тутырып бииләр иде.

Күлмәкләре тирле аркаларына ябышкан ирләрнең артына барып бастым, игътибар итүче күренмәде. Барысы да уртадагы түгәрәккә тартыла торгач, бөтенләй эчтә — хатын-кызларның йомшак тәннәре

белән ир-атларның очлы терсәкләре арасында калдым. Колак читем белән арттагыларның «Кем соң бу?», дип пышылдашып алганнарын, кайсыныңдыр: «Шул инде, тегесенә алмашка килгән»,— дип пышылдаганнарын ишетеп алдым.

Чәчәкле кызыл күлмәк, аягына биек үкчәле туфли, иңенә чуклы ак ефәк яулык салган, чәчен тау итеп өеп куйган, озын, сылу буйлы, бер дә авылча булмаган хатын-кыз Каһирга китереп басты. Ул биемәскә итенде, аннары, гайрәт белән кулын селтәде дә, күзен йомып һәм башын чайкап, әкрен-әкрен кулларын җәя барып, түгәрәкне кысрыклап диярлек, киң адымнар белән йөреп китте, алдагылар аңа юл бирер өчен чигенәрәк төште, арттагылар күрер өчен алгарак сузылдылар.

Баскычта түгәрәк шадра йөзле, кызыл бәрхет түбәтәй кигән, сызганган җиңнәре астыннан алтынсу төкләр тырпаешкан җирәнсу сакаллы бер абзый күренде. Ул кыек якалы зәңгәр күлмәген яшькелт галифе чалбар өстенә чыгарып кигән ирнең җилкәсенә кулын салып:

— Ишкә куш килдең, Бәйнал! Әүвәлге Гиюрги кавалер, хәзер кызыл командир! Ә минем кызым — Нисам кем? Граждански сугышны чәйгә салып эчкән Ниса Тарханова! Комиссар кыз! Сугыш аңа — синең сабан туең гына!— дип салды, ә кияү булырга тиешле кеше киң маңгаен җыерып һәм кулын күкрәгенә кушырып, кара-каршы биегән кәләш белән Каһирны күзләп, әкрен генә:

— Ишкә куш дисеңме?.. Хәзер морзалар морҗа чистарта...— диде.

— Шулай, кияү! Биш пар тройкагыздан хәзер бер пар хрум итекле калдың. Тик бәхетегез булсын, Азамат атагызга рәхмәтегезне онытмагыз. Болан күк кыз бирәм бит, җәмәгать!

Ике ир, бер-берсенә минем аша иелеп сүз катышалар:

— Ана боланның ник мөгезе юк, Әзһәр, беләсеңме?

— Аның каравы ата боланныкы тармаклы — санап бетергесез.

— Мин дә шуны әйтеп торам әле: ул мөгезләрне Ширәмәтләр төпчеге кай төшенә тагып бетермәкче икән?

— Рамазановтан соң дисеңме?

— Үткән эшкә салават. Мунча яфрагы шикелле, Ширәмәткә ябышып катар димсең?

— Шулай. Бер шайтан кызын өйдә тышаулап саклаганчы, йөз борчаны болында тышаусыз тотуы җиңелрәк.

Каршы яктан:

— Кияү ник биеми?

— Аягына таш бәйләгән мәллә?

— Бәлки муенынадыр?

— Ярар, биер әле... Биер көннәре алда.

— Бүген Каһир көне алайса,— диде күршем.

Икенчесе, аның сүзен җөпләп, колагыма:

— Ә төне кемнеке — алла белсен! — дип хихылдады.

Тыгызлыктан гына эссләмәдем, мине тирләткән нәрсә — аларның яман телләре иде. Ирексездән күршеләремә җентекләбрәк карап куйдым. Кияү дә, кәләш тә аларның ут куыкларына басканмыни. Үзләре алар туенда кунак, ә телләре — пычак урынына селтәнә. Берсе — ямаулы солдат гимнастеркасыннан, ул минем аягыма басты, йон оекбаш белән чабата кигән, киндерәләре җирдә; минем һәм үзенең табан астында йомарланып ята. Боларның көнкүрешләре авыр, туй үткәрүчеләр белән кардәш-ыру, кан уртаклыклары юк, күрәсең, ян-як күршеләрдер.

Каһир мине күреп алды, тик биюен өзмәде, кәләш белән култыклашып әйләнә башлады. Аннары кәләш, биюеннән туктый алмыйча, тыпырдый-тыпырдый читкә авышты, ә Каһир, ялт туктап, миңа китереп басты, минем алдагылар аерылып китте.

— Җәмгать!— дип кычкырды ул.— Төнлә каршы очраса, куркып китмәгез, сезнең алдыгызда алтын кеше — ГОЭЛРО инженеры, авылыбызны мировой буржуйларны сукырайтачак маяк итәргә килгән электрик!.. Бармак янаса, тәртә күтәрерлек булмасын, карагыз аны!

— Яңа Рамазанов икән,— диде Азамат карт.

Каһир кепкасын салып, юеш ташка бәрде:

— Ә менә монысы булмас! Җитәр! Әле кайберәүләр тегесен космаган!— диде ул халык өстеннән караш йөртеп.— Ә косарга туры килер. Яшел үтегез чыкканчы!.. Аны,— диде ул миңа бармагы белән төртеп күрсәтеп,— Мәскәү үзе җибәргән! Ә Мәскәү белән кусәк күтәреп сөйләшмиләр, иптәшләр!..

— Күтәрергә җыенган кеше җук ич әле, иптәш Сафин. Безнең бабайлар белән әтиләр күтәргән һәрбер кусәк Себер каторгаларының шахталарында чери.

— Ленин безнең кулларга кылыч тоттырды. Аны менә күтәреп тә күрсәттек ичмаса!

— Кемнең башы үзебезнекеннән югары — долой очты!

Баскычтагы карт, кызыл бәрхет түбәтәен салып, баш очында айкады, әйтерсең лә утлы факел белән селтәнде.

— Җитәр!— дип кычкырды карт.— Ураза түгел, әйдәгез, ашаргаэчәргә. Кунакларны кылыч белән сыйламыйлар...

— Күптән вакыт,— диде минем күршем,— юкса эч тагын бушады — язгы баз шикелле.

Кешеләр эчкә уздылар. Мине ияртмәсеннәр өчен, яным белән кысылып, артка чигендем. Күрше абзыйның аягындагы чабатасы төшеп калган, ул эзләргә иелгәндә, ялгыш кулына бастым. Ул миңа, сыйрагымны чеметеп, җавап кайтарырга булган ахрысы, тик моментның файдалырагын сайлаган, күрәсең, бер хатын әче итеп кычкырып җибәрде.

— Хәдичә, Сөләйманыңны тый, тилчә кук, ботыма ябышты, затсыз!

— Ботыңны һавага элеп җөрмә, тимәсләр!

— Синең ботың кайгысы!.. Чабатама баскансың, сыер!— диде Сөләйман дигәне кешеләр аягы арасыннан.

— Чабатаңа түгел, әллә нәрсәңә дә басарлар, үшән үгез!

— Бастырган ни, бастырмый ни!..

Әрепләшү кешеләрне рәхәтләндереп җибәрде, авызларын күтәреп, тыела алмый көлделәр.

Каһир белән икәү генә калдык.

— Син ник монда?— дип сорадым.

— Никме?.. Тырнагына карап, мәчене беләләр, сыена карап — хуҗаны. Ә хуҗа андый-мондый гына түгел, белерсең әле... Аннары бу кызыл башлар сузган тәлинкәгә ничек төкерергә белермен мин.

— Бу көрәшче морале түгел.

— Мораль?— Каһир җирәнгән сыман итеп чыраен сытты да тәрәзәләреннән кыстау һәм сыйлану авазлары ишетелгән өйгә ишарәләде.— Авыл кешеләренең тамагы икмәккә туймыйча торып, бернинди мораль юк! Мин хәзергә бер генә моральне беләм — бу өй хуҗалары ишеләрне...— Аның иягендәге зәңгәрсу чокыр кызарып чыкты, яңак итләре уйнаклап алды.— Җә измәләрен изәбез, җә тәпиләп җәһәннәмгә эвакуацияләнсеннәр. Аларны шул чагында гына тыңлаучан... сарык итеп була.

— Безгә сарыклар кирәкми.

— Ә без аларга сарык түгел идекмени? Әле кайчан гына алар безнең көтүчеләребез иде... Костырырга, бөтенесен костырырга. Ашказаннарын тискәре ягына әйләндереп... Хәзер үзләренә сарык тиресе ябынырга вакыт.




*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

— Сарык тиресе ябынган бүреләрдән...— дип тотлыгыбрак тордым,— ни мәгънә?

— Көтүчеләр уяу торыр. Кичәге сарыклар — без — бүген бүре көтүе көтә — әллә начармы? Патша белән ялчы да юк, алла белән мулла да. Элек безнең баш очында аларның камчысы шартлаган, хәзер аларның борын төбендә безнең... кукиш сызгырып торыр.— Үзе дә сизмәстән, Каһир кесәсеннән револьвер алып селкеде.

— Тилгәнне шушыннан аттыңмыни?

Каһир «нинди тилгән?» дип сорамады, револьверын куен кесәсенә тыгып куйды.

— Рамазановныкы,— диде ул.

— Шуннан... атылган диделәрмени?

— Белмим. Мин әле моны белмим... Ыгы-зыгыда... өстәленнән алып тыктым. Милиционерлар күрде, Идрис абый да. Югыйсә, алып китәрләр иде дә бер җирдә күгәреп ятыр иде.

— Курыкмыйча йөртәсеңме?

— Курыкмыйча!— Аның йөзе тагын җирәнгәндәй тартылып алды.— Мин хәзер бер генә нәрсәдән куркам, туган — акылдан шашудан... Гарык күрдем. Канын да, утын да. Турадым, кистем, яндырдым — төшкә керә...— Ул озак дәшми торды. Мин аны нигәдер кызгана башладым.— Рамазанов... Бәлки ул хаклыдыр, хаклыдыр... Туйгандыр. Без ирекле. Шул исәптән үз-үзең белән исәп-хисап ясарга да ирекле... Рамазанов... Шикләнәм, туган,— мәми авыз түгелгә охшаган иде ул. Андыйлар пуляны үз каннарына үзләре буямый... Бүреләр күп. Беләсең килсә, башлана башлады гына әле... Әйдә, бу бүреләрнең дә әче балларын авыз итеп калыйк, ачуларыннан асларына җибәреп утырсыннар. Беренче һәм соңгы тапкыр утырыйк та... Аннары бугазларына да ябышырга була.

— Юк, хурланам.

— Алар безнең канны эчте — хурланганнар микән?— Ул, елмаеп, туй барган җиргә кереп китте.

Этен алдым пычакка,
Кызын алдым кочакка,—

дип көйләгәне шау-шуга кушылып эреде.

Мин ишегалды белән бакча арасына — капка һәм келәтне тоташтырып корылган биек такта койма буендагы имән бүрәнәгә барып утырдым.

Келәт ишеге төбендә кабык түбәле эт оясы. Эте юк, мәҗлес булгач, артка чыгарып бәйләгәннәр, шуннан аның әле шыңшыган, әле чинаган, әле өргән тавышы ишетелә. Тәртәләрен күтәреп, төбенә яшел печән түшәлгән һәм иске кайры тун салынган тимер күчәрле арбаны лапас астына кертеп куйганнар — анда кемдер төн куна булса кирәк. Тезмә ягында тавык кытаклый, аңа әтәч кушылып китә. Кое бурасының юеш басмасында бал кортлары безелдәшә, тәгаен, ерактан түгелләрдер, учактан чәчрәгән күмер сыман, бакча ягыннан килеп чыгалар да, шунда таба очалар. Келәт кыегы астына потлы тимер үлчәү инсәсе элгәннәр, бу өйдә чәй-шикәрдән калган нәрсәне потлап үлчәргә күнеккәнгә охшый.

Ул чак ничек булгандыр, ә хәзер миңа ул көнне Кәүсәрияне күрәсем килеп утырганмындыр кебек. Ул, теге чактагыча, табак тотып, ишегалдына чыкса, мине таныр иде микән? Юк, юк, минем бу хәлемдә аңа күренәсем килми, тиз генә торам да кунакханә ягына атлап китәргә борылам, тик мине аның тавышы туктата.

— Кая ашыгасың?— ди ул. Мин аның күкрәк тавышына абынып китәм шикелле.— Утыр әле бераз...

— Хәтернең вакыты очсыз да бит...

— И-и-и, зарланмале, бигрәк эшем кешесе булып беткәнсең, кемәем. Дөнья кендеге сиңа гына бәйләнмәгәндер, шәт. Кигәвен чаккан үгез кук, алдыгызны-артыгызны белми чапкан буласыз тагын, ходаем... Утыр әле бер, ашыкма. Менәтерә, баздан катык алып менәм, сөткә туглап бирермен, йөрәкләрең иркенәеп китәр. Утыр әле бер кинәнеп, хатын-кыз әрен тыңла. Тансыклагансыңдыр. Хатын-кыз тукран шикелле ирләр башына үз әрен тукып тормаса, миләре кортлый ич аларның, әйемәк?

— Мондый түгел идең ләбаса син, Кәүсәрия?! Картаймыш көнеңдә шушылай мырлап йөрергә калыр идең микәнни?

— Кешедән кимме әллә? Хатын-кызның әрләве ирләргә җан каймагы гына ич ул...

— Син гел «хатын-кыз» дисең. Син үзеңне «хатын» дип сөйләш.

— Кем хатыны?

— Кемнеке дип инде ул хәтле... Мин әле суксам тимер өзмәслек, типсәм ут чыгармаслык егет түгел.

— Әллә мине үзең шикелле генә картлачны авызлыклап тотмастай эби диярең бармы? Мин синең белән ничек сөйләшергә белер идем, Ислам...

— Әллә үпкәң бар инде?

— Үпкәм? Үпкә нәрсә ул? Хатын-кызның үпкәсен эретергә ир-егетнең бер үбүе җитә... Ә менә үкенече булган картны нинди кыз-кыркын юата алыр икән?

— Каршы килмәс идем, әй!

— Юатырлык чамам булса иде дә бит кана...

— Ә мин сине хәтеремә теләсә кайчан чакырып китерәм дә юанам.

— Онытмадыңмыни әле?

— Рәхәтләнеп тә бит... Аягыма тышау булып уралдың да яшьлегең җәйләвендә генә тотасың.

— Үзең ич, тиле! «Билләреңә сары каешлар булып уралаем» дип җырлый торган идең. Җырлый гына... Теге кышны гына, боз эчендә пешкән кура җиләге булып, авызыңа тамам дигәндә... әллә генә нишләдең инде менәтерә! Хәзер терсәгең якындыр да...

— Терсәк якын, син ерак.

— Якынайсам? Нәкъ шул вакыттагыча.

— Нәкъ шул чактагыча кабатланыр иде.

— Кеше баласына акыл кермәсә дә керми икән, һай! Син минем белән баласытып кына сөйләшәсең бугай, баласытып кына. Төшләреңә кергәнмендер әле, төштә акыл теләмәгәнне дә кыласың ич ул тегеләй, хикмәт... Кочкансыңдыр, мине шул сәкедә хәтсез тапкыр кочкансыңдыр әле, оятсыз. Нәкъ шул чактагыча кабатланыр дип торасың тагын, кылмыш!.. Кабатлатыр идем мин сиңа нәкъ шул чактагыча, ходаем!..

— Я, я... Сине уемда үзем белән шушылай сөйләштергәнем өчен гафу итә күр, зинһар. Гөнаһлы итә язып... Сине оныта башлаганмын ахрысы, инде менә бөтенләй бүтән рәвештә күзаллыйм.

— Ислам, Ислам! Мин шул ук. Шул ук Кәүсәриямен. Әлбәттә, безнеңчә килеп чыгарга язган булса, болай сөйләшү пычагыма да хаҗәт булмас иде инде ул. Нишләтәсең, биргәненә рәхмәт кылырга инде. Син болай да бәхетле. Миңа да яхшы. Мин мәңге яшь калдым. Юкса мин сукранып, зарланып, ах та ух килеп йөрүче, бәйләнчек, мыжык, теңкәңне корытучы, саруыңны кайнатучы, җаныңны өтүче, гайрәтеңне чигерүче, кәефеңне кыручы, җелегеңә төшүче, үзәгеңә үтүче бер карчыкка әйләнеп беткән булыр идем инде. Сиңа шундый белән сөйләшүе ничегрәк булыр иде микән, мескенкәем минем, бичарам... Син минем яңа кар шикелле ак, мичтән чыккан гына ипи ише кайнар тәнемне коча

идең. Ә хәзерге хыялыңдагы Кәүсәрия нинди? Орындың исә, кәбестә күк шыңгырдап тораммы? Кара бу коры тәнне, тез асларындагы бүлтәеп чыккан кан тамырларын, кипкән миләштәй бөрешкән авызны, пыяласыз тәрәзә сыман төпсез күзләремне... Син мине шушы хәлдә бер дә күрмәвең белән бәхетле бит.

— Әй, Кәүсәрия, әй!.. Мин соң, мин!.. Сурәтемне бер генә капшар идең дә, ап-ак чәчемне тузганак итеп таратып, карлыгач шикелле бөтен тәнеңне җиңел очырып, көлә-көлә китеп барыр идең бугай, әйеме?

— Әллә елыйсың инде, картлач?

— Карт күз елак була икән ул, нәкъ•имчәк баласы.

— И-и-и, тел бистәләре, сөйләшәбез дә сөйләшәбез, ач кешенең ачуы яман ди, әйдәле, тамак ялгыйк!

— Ни ашар идек икән соң без?

— Бөтенләтә бәрәңге пешеримме? Безнең бәрәңгенең чат ярма икәнен онытkансыңдыр инде. Юк, яңа бәрәңге пешерәм. Янына шартларга җитешеп пешкән помидор куярмын. Кайнаган сөт. Әллә салкын катык тансыкладыңмы? Аннары суң чәй эчәрбез. Бер генә чеметем мәтрүшкә дә салып. Юкә балы белән.

— А-а! Кыстый да беләсең соң, Кәүсәрия! Ярмаланып пешкән яңа бәрәңгең бармагым битен пешерә, иренемне көйдерә; помидорларыңны күреп, авыз суларым корый; катыгың каймак булып иреннәргә ягылып кала, чәең маңгаемдагы сырларны эретә. Синең белән бер генә тапкыр булса да кара-каршы утырып, юкә балы белән мәтрүшкәле чәй эчсәк, без мәңгегә оҗмах ящендә калыр идек. Ә бергә яшәсәк? Ә бергә яшәсәк! Ә бергә яшәсәк... Ул картлык дигән дию пәриен якын җибәрер идекмени соң? Безнең тәннәребез картлык каргасы куна торган борчак кыры булыр идеме әллә? Әгәр дә синең белән бер генә тапкыр булса да кара-каршы утырып, юкә балы белән мәтрүшкәле чәй эчсәк, мин ул карганы чәчемнән пумала ясап куар идем, бәдбәхетне! Яктыда килсә, мин ул картаюны (карт аю) күземне таш итеп ата-ата куар идем. Караңгыда сагаласа, йөрәгемне факел итеп, танавына тондыдыр идем. Тәнемнең тиресен салдырып, аркан ишәр идем дә дөньяның иң нык иманәнә арканлап куяр идем. Я булмаса, канымны дәрья итеп агызып, шунда тончыктырыр идем. Синең белән тормыш табынына кара-каршы утырып, тел очлары белән генә юкә балы каба-каба, бер чеметем мәтрүшкә салынган чәй эчә-эчә яшәү насыйп иткән булсамы?!. Картлык, кара мәче булып, без утырган өстәл астында безнең сөюдән калган сөякләрне кимерә-кимерә елар иде, бәдбәхет! А-а! Кыстый беләсең дә соң син, Кәүсәрия! Ярмаланып пешкән яңа бәрәңгең...

— Мин сиңа ышанам, Ислам! Синең белән тормыш табынына кара-каршы утырып, тел очлары белән генә юкә балы каба-каба, бер чеметем мәтрүшкә салынган чәй эчкән күк булды.

— Кулыңны бир әле, Кәүсәрия, үбимче бер.

— Агач тамырлары — минем кулым: сыкрап бер җир өстенә чыксалар, табарсың.

— Чәчеңне сыйпыйм әле, Кәүсәрия!

— Далаларга чык: җилдә йөгергән кылганнарны куып җитсәң, тарарсың...

— Сулышыңны тоймыйчамы?

— Җилләрне тыңла.

— Йөрәгең җылысында җылыныйм дисәм...

— Яшеннәр янына мен, Ислам.

— Кайда соң син, саубуллашыйк.

— Хәтер белән саубуллашмыйлар. Килер вакыт — ул үзе синең белән хушлашыр.

Әгәр дә шушы килеш Кәүсәрияләр ишегалдындагы бүрәнәләргә барып утырсам, һәм ул теге чактагыча каршы чыкса, мине танып иде микән? Юк, юк, минем бу хәлдә аңа күренәсем килми, тиз генә торам да кунакханә ягына атлап китәм.

Нарком янына мин бишенче көнне үк барып җиттем. Ул мине бүлмәсендә башланган утырышта катнашырга мәҗбүр итте. Сүз авырлыклар, җитешсезлекләр, бөлгенлек, очы-кырые күренмәгән буталчыклыклар, кадрлар кытлыгы хакында барды.

— Күреп торам, син әзер,— диде ул җыелыш беткәч, яссы күкрәкле секретарь хатын ясап керткән чәйне өреп эчә-эчә,— Акча, материаллар, эш кораллары сорап килдеңме?

Баш кактым. Ни өчен килгәнемне белгәнен күргән хәлдә миңа аның соңгы сүзе генә кирәк.

— Бернәрсәбез дә юк диясең киләме, кадерлем? Ничек төзибезме? Беренчедән, булмаганны төзибез, юкка күрә. Ә юкны каян алып төзиләр? Юктан.— Үзенең абсурд, ләкин бөек дәрәҗәдәге сүзләреннән ул үзе үк көлеп җибәрде.

— Юктан бар булмый,— дидем мин.— Менә, хәстәрләгән сызымнар, исәпләр.— Һәм куен кесәсеннән чыгарып, өстәлгә кәгазьләр түргәге куйдым.

Чәен эчеп бетергәч, ул, күзен йомып, учы белән битен сыпырды. Аннары нигәдер пышылдап:

— Була, Ислам Имамович, була,— диде. Бераз тын торгач, катырак итеп:— Була,— дип кабатлады.— Исбатлый алмыйм. Ләкин безнең алда — киләчәк, гади генә итеп әйткәндә,— яшәү,— дип өстәде.— Ә яшәү...

Ул сүзсез калды. Фикерен дәвам итәр дип уйладым, тик ул аңа кире кайтмады. «Яшәү юктан бар булган»,— диясе килдеме соң, әллә: «Мин әйткәнне киләчәк исбатлар»,— дип уйладымы?

Сөйләшеп утырдык. Аның «Юк» дигәне буш имезлек кенә булып калмады. Станция җиһазлары, тимер чыбык, кадак, сумала җибәрәчәкләр. «Юк» дигәне — акча, агач. Агачы авылдан биш чакрымдагы урманда үсә, ә акча кайда «пешә» икән?

— Юктан башлагыз, колхоз белән төгәлләгез,— диде нарком.— Менә шушындый «юк»ны булдырсаң... Проектын эшләгән инженер күперен дә үзе төзи. Беренче поезд узганда күпере астына төшеп, башы өстеннән уздырып җибәргәнче. Җимерелсә, иң беренче үзе һәлак була.

Үз көчемә ышанмау, бурычны үти алырыма шикләнү, билгесезлек алдында курку ул көнне кайда йөрде икән соң? Барысы да без теләгәнчә булыр кебек иде. Үзебез теләгәнчә булыр кебек. Үзебез теләгәнчә. Алай да мин:

— Беренче кат бит, иптәш нарком,— дидем.

— Дөньяга да икенче кат килмиләр. Беренче генә кат киләләр. Һәм соңгы кат.

— Ә уку?— дидем мин аның белән бәхәсләшүдән битәр, үземнән сорап.

— Тормыштан да олырак мәктәп юк, энем. Күпер кирәк. Иң мөһиме — күпер. Бүгенге белән киләчәкне тоташтырачак күпер. Без әле күпернең астында. Баш очыбызга кешелекнең иң якты өметләре төялгән поезд якынлаша, сизәсеңме? Күпер астына, егет!.. Безнең бәхет шунда. Беләсеңме крестьян ни өчен җаны-тәне белән коммунизм яклы булачак? — дип сорады ул саубуллашкан чагында. Кулын иңбашыма салып, үзе үк җавап та бирде: — Ул станцияләрне үз куллары белән төзе-

гәнгә күрә. Үзең пешергән тәмле... Үз кулы белән, аңлыйсыңмы, Ислам Имамович?

Минем аның янына баруым кирәк булды микән? Эшкә моның артык файдасы тимәде дә шикелле. Ә үзем өчен...

Икенче кат бу авылга озакка кайтырга тиешлегемне аңладым. Кая ул пальто белән бүрек! Белемемне дәвам итә алмадым. Тормыш өйрәтте.

Пароходта түземсезлек белән ярга аяк басасы мәлемне көттем. Ширәмәт морзалар бакчасына, чәчәктән-чәчәккә очынган күбәләк кебек җилпенеп, чиләк-көянтә аскан бер кыз заты төшеп килә...

## VI

Безнең хыялларыбыз матур иде. Салыначак станция Мәскәүдәге князь Йосыпов сараеннан бер дә ким-хур булмастыр сыман тоелды. Институтта безгә Каширино крестьяннарының җыйнаулашып салган электр станцияләрен алып барып күрсәткәннәр иде. Хәер, күрсәтмәсәләр дә, ул безнең күңелебездә зуррак, матуррак төстә, Ленин исеме белән бәйле булганга, кабатланмас бер биеклек рәвешендә калыр иде; бактың исә, гадәти генә, шәһәр җирендә булса, күз дә төшмәслек кечкенә бер корылма икән. Ә заманына күрә, мәшһүр ГОЭЛРОга кадәр, крестьянның зирәк акылы һәм өсте-өстенә үскән сөялләрдән күн итек табаны сыман катып беткән, ялтырап торган тырыш кулы белән юктан бар итеп корылганга күрә, ул да ихтирамга лаек төзелеш иде.

Без курткабызда МОПР (Революция көрәшчеләренә булышуның халыкара оешмасы) значогы йөртә идек, галстук такканнарны комсомол җыелышларында тикшерәбез, кызлар белән йөрибез генә — үбешмибез. Безнең хыялларыбызны ГОЭЛРОның тиздән бөтен ил буйлап кабынасы утлары үбә иде. Йөзләрчә мең кубометр бетон салу, миллиметрлы төгәллек белән корыла торган куәтле-куәтле җиһазлар — һәм үземнең тиздән шулар белән эшләргә тиешле кеше сурәтендә хис итүем минем канатым иде. Без үзебезне ил өчен гадәттән тыш кирәкле белгечләр итеп сизә башлаган идек. Глеб Максимилианович Кржижановскийның Карунин мәйданындагы СССР Госпланыннан безнең институтка килеп, ул хакта хыяллансаң да фанатиклык дип саналырлык салкын канлылык белән Ангара елгасы куәтен меңәр чакрымга тапшыру, Эйнштейнның чагыштырма теориясе, атом-төш реакциясе хакында сөйләүләреннән күңелебездә кузгалган җилкенсенүләр, түземсезләнеп, киләчәккә ашкынулар — һәм миңа нарком тапшырган бурыч... Әх, әх, әх! Хыялларымнан бик еракка чигендем түгелме соң? Кайчан гына без, бер төркем студентлар, Глеб Максимилиановичның Садовникидагы иске фатирында бер-беребез белән әле килешүсез бәхәстә, әле уен-көлкедә үткәргән онытылмас кич — һәм хәзер кайда мин, нишлим, бурычым ни, хыялым нинди? Бармак белән санарлык шәхси әйберләремнең иң кадерлесе аның шул кичтә кулын куеп бүләк иткән китап — «И. И. Скворцов-Степанов. СССРны электрлаштыру» — олы хыялларымның чәлпәрәмә килүенә шаһит бер истәлек кенәмени инде? Электр станцияләрен илнең йөрәге, ә ток йөгерә торган чыбыкларны кан тамырлары белән тиңләштерү заманнары иде. Газеталар Идел, Днепр кебек елгаларда башланачак фантастик төзелешләр хакындагы сүзләр белән тулды. Төрле проектлар, идеяләр, Чирчик гидростанциясе проблемасы тирәсендә дуслар, дошманнар бәрелешә башлады. Без үзебезне ул идеяләрнең булачак кияүләре урынына күреп, аларны яратып һәм яклап бәхәсләшә идек. Минем хыялымдагы «кәләш» тә чибәр иде — Днепрогэс, һәм кайдадыр шунда меңләгән кеше, галәмәт масштаб эчендә — мин.

Ә моның урынына язмышым күп катлы — колонналы-аркалы, бизәкчачаклар белән чуарланып беткән йорт каршындагы эт оясы кебек күренгән авыл станциясенә килеп бәйләнде. Канатлы хыял уяткан фикерем аңа сыешмаска карыша. Максат белән чынбарлык, идеал тормыш белән бүгенге көн ихтыяҗы уйларымда якага-яка килеп буразлашты.

Алай да...

Баштагы көннәрдә зур газаплар кичерә-кичерә әнә шул хыялларым үлгән кебек булды. Кайчандыр нәкъ шулай ук итеп — курка-курка гына — әни сөте белән кергән аллага ышануым үлгән иде.

Кайбер төннәрне йокыга китә алмыйча, уемда гел исәп-хисап ясыйм, лампага ут элеп, кәгазьгә таң атканчы бәләкәй станциянең төрле күренешләрен төшереп карыйм. Эш алай ук тез буыннарын калтыратырдайга охшамаган. Кара исәбем белән бөтен эш күләме ак ташлы үр итәге буенча — елгага янәшә — нибарысы җитмеш-сиксән сажин озынлыгындагы, ике-өч метр тирәнлегендәге төп канау казып, аннан тагын язгы суларны, җәйге ташкыннарны уздырып җибәрергә запас канау казудан, җиде-сигез метр биеклектәге агач бура буудан, казанлыкны киңәйтеп, тирәнәйтеп, шунда имән субайларга станция бинасы корудан һәм тегермән салудан гыйбарәт. Ә авыл урамнарына баганалар утыртып чыбык сузу — анысы, мунчадан соң салкын әйрән эчеп җибәргән шикелле, рәхәтлек, канәгатьлек кенә бирер кебек. Иң мөһиме — гадилек, эшне мөмкин кадәр җиңеләйтерлек җай табу.

Нарком яныннан кайткач, төп сызымымны, исәп-хисап кәгазен тотып, Каһир Сафин янына кердем. Ул кәгазьләремне борын тишекләреннән бөркелеп чыккан тәмәке төтене белән өретте дә:

— Шәп!— дип кенә куйды.

— Иртәгә керешик,— дидем мин.

— Иртәгә?!

— Иртәгә. Сузарга ярамый.

— Сузарга дип... Бала карында күпме йөри?

— Ә бу бит сиңа бала гына түгел,— дидем мин кәгазьләремне җыеп.— Бу, бу...

Мөгаен, кыяфәтем ата булуга ирешкән ирнеке ише генә булмагандыр. Каһир моны тойды, күрәсең.

— Иртәгә,— диде ул.— Халыкка җиткерик алайса.

— Кичкә җыелыш җый.

*Ахыры киләсе санда*

# Мөдәррис Әгъләмов

## Көзге хикмәт

Искитмәле көзнең хәрәкәте,
Иплән кенә басып килә дә
Тәрәзәгә үрелә, сүзе күптер,
Лепер-лепер һаман сөйләнә.

Искитмәле аның хәрәкәте,
Үз-үзенә шундый ышанып,
Атлап килә, җимешләрен бирә,
Яшь ана күк кала бушанып.

Күз төпләре эчкә батып кергән,
Йөзләренә төшкән сары су...
Үзеннән соң дәвам итәр тормыш
Калдырулар, әйе, авыр шул!

Искитмәле көзнең хәрәкәте,
Рәнҗүләрне белмәс, үпкәне...
Җирдә орлык — аның киләчәге,
Өстәлдәге икмәк — үткәне;

Бүгенгесе — әнә саубуллашу,
Кошлар китә — яфрак талпына.
Канатлы көз кышка кереп бара
Шул җирдәге орлык хакына.

Искитмәле соңгы хәрәкәте,
Йөзләренә коела сары су...
Үзебезне уйлап киләм әле,
Үзебезне уйлап...
Бары шул.

## Бары хәтер

Хәтер һич тә үткән генә түгел,
Ул бит әле киләчәген дә...
Юккамыни бишегендә сыман,
Орлык ята гөл чәчәгендә.

Алар бары, җиргә сикерергә,
Өлгерүне генә көтәләр —
Хәтерендә күпме гыйбрәт ята
Үз вакыты җиткәнгә кадәр.

Шулар сине максатыңа илтә,
Дөнья ваклыгыннан аралый.
Мәсләгеңнең ярыр буразнасын
Сызып куйган: «Ярый-ярамый».

Хәтер — синең печән ташыганда,
Уфалланы җигелеп тартуың,
«Яхшылыкның аның чиге юк»,—
дип
Өйрәтүе татар картының,

Хәтер — синең кара урманнарда
Адашып юл эзләп йөрүләр,
Китап аша кергән, меңәр еллык
Җимерелгән империяләр.

Һәммәсе дә хәтер.
Бары хәтер.
Бары хәтер синең дәвамың...
Каннан канга күчеп сиңа җиткән
Үҗәтлеге җиде бабаңның.

Кеше шушы хәлдән таш гасырга
Кайтып төшмәсен дип яңадан
Хәтеремнән, бары хәтеремнән
Хикмәт табып, гыйбрәт алалам.

Юккамыни бишегендә сыман
Орлык ята гөл чәчәгендә...
Хәтер һич тә үткән генә түгел,
Хәтер — синең киләчәгең дә.

## Агымсулар

«Җиңеләйде еллар» дисәк тә без
Һәр көн саен юллар ураулар.
Кешегә бер килә, килми калмый
Суга карап авыр сулаулар...

Суга баккан кеше, уй-хисләрен
Суга түккән борын-борыннан.
Каралтысын су янына салган,
Тереклеге суга корылган.

Арган йөзен, үз язмышын күргән
Гәрәбәле сулар төбендә.
Су ярсуы, сулар сабырлыгы
Кешеләрнең күркәмлегендә.

Гомерлек яр, үзенә пар тапкан,
Җырга кергән сулар буенда.
Су буенда бәреп чыккан хисләр
Йөрәк сере сыярлыгына.

Яшь кызларның иң саф мәхәббәте
Таһир булып аккан елгада.
Кызлар һаман керләр чайкаганда
Агымсуга карап моңлана.

Кызлар җыр җырлаган, ярларына
Барып кына җитсен моңнары.
Ул җырларны сулар меңәр еллар
Тыңлый инде...
Әйе, тыңлады.

Ил язмышы һаман хәрәкәттә,
Ил язмышы агым суларда...
Язмыш кадәр язмыш өйрәткәндер
Суга карап авыр суларга.

## Тагын бер кош

Көзге күкләр шундый тыныч иде,
Шундый тыныч иде бу тараф.
Киек казлар очып бара иде,
Вакыт ага иде битараф...

Пышылдасаң, җир сискәнер сыман
Тоела иде — дөнья тын иде.
Табигатьнең җиргә чалкан төшеп
Изрәп яткан минуты иде.

Зәңгәр күктә — киек каз юллары,
Басуларда — тояк эзләре,
Оча иде кибән өсләреннән
Көзнең алтын пәрәвезләре.

Агыла иде моңсу, татлы сагыш
Сары яфракларга өстәлеп...
...Кинәт кенә, мылтык тавышыннан
Ак каеннар куйды сискәнеп.

Әйтерсең лә, җирнең кайтавазы
Яңгырап кайтты чорлар аркылы.
Кеше сыман, ыңгырашып куйды
Зәңгәр күктә киек каз юлы.

Соңгы көчен җыеп талпынды кош,
Түбәнәйде... төште капланып.
...Һәрбер чорда бер үк җавап яши:
— Без аңарга диеп атмадык!

Төзәп түгел (бу ысулны беләм),
Болай гына, кызык өченгә

Җибәрелгән ядрә килеп кергән
Очып барган төркем эченә.

Иң яшенә, көчлесенә тигән,
Әле күпме очачагына!
Тагын бер кош ауды, яшь фидаи,
Тагын бер кош синең янына.

...Табигатьнең җиргә чалкан төшеп
Изрәп яткан минуты була...
Пышылдасаң, җир сискәнер сыман
Тоела безгә — дөнья тын була.

Шундый чакта яманлыкның кулы
Бәйсез икәнлеген искәреп,
Ыңгыраша киек каз юллары,
Ак каеннар куя сискәнеп.

## Җырлы көннәр

Җырлы көннәрем бу...
Ак кәгазьгә
Бер юл язалмаган хәлемдә
Сызлап-сызлап җырлар зеңләп тора
Оеп калган бәдәннәремдә.

Бер тәртипсез хәлдә язмаларым
Сибелеп яткан өстәл өстенә
Шигырьләрдә урын дәгъва итеп
Күпереп торган муллык — көз кәрә.

Җырлы көннәрем бу... Барлык хисләр
Сүзгә әйләнәчәк булса да
Күңелеңне аны алдап булмый,
Ул ихласка гына ышана.

...Ә көз әнә күзгә карап тора
Акыллы сүз көтеп, яңа сүз,
И кешеләр, сез дә көз шикелле,
Аягүрә дөрләп янасыз.

Мин үзем дә мохтаҗ җылы сүзгә,
Көз шикелле, күзгә багасыз.
Яңа сүзне әмма ишетмәссез,
Йөрәгегез булса ярасыз.

Ә ник әле шушы гүзәл көздә
Яңа сүзләр уйлап табарга?
Сүзләр шул ук, кирәк аны бары
Яраларга белеп ябарга.

Абзар өсләрендә печән тулы,
Ашлык белән тулы келәтләр.

Келәтләргә ашлык тулган көндә
Нәрсәләр бар сездә, йөрәкләр?

Җырлы көннәрем бу... Ак кәгазьгә
Бер юл язылмаган мәлемдә
Әнә шуны уйлап җырлар зеңли
Көзне сизгән бәдәннәремдә.

## Тәрәзәдән төшкән ут

*Хөрмәтле Фаил Шәфигуллин ядкаре*

Аккош күлендәге иҗат йорты...
Тәрәзәдән төшкән тыйнак утны
Йотмак булып кичке караңгы,
Сузылып чыгып агач арасыннан
Як-ягына шомлы каранды.

Ул афәтне яңа күргән төсле,
Ак кәгазьдән башын алды кеше,
Салып куйды читкә күзлеген;
Әйтте сыман: көчең җитә икән,
Ак кәгазьгә әйдә, уз, энем!

Караңгылык чикне узалмыйча,
Үз-үзеннән куркып, тын алмыйча,
Җиткән килеш тәрәз кырына,
Карап катты сәер иҗатчының
Ак кәгазьдә йөргән кулына.

Туктаганын көтте аның,
Юкка!
Әйләнде дә үзе таңгы чыкка,
Тәгәрәде үлән эченә...
Алсуланып, якты кояш чыкты, —
Ул мәдхия иде кешегә.

...Аккош күле. Сулый иҗат йорты.
Җиңәлмәде ул төн яктылыкны,
Җыр тантана итте өстәлдә.
...Башка төрле үрелә караңгылык,
Кералмагач иҗат иткәндә.

Атлап бөтен кануннарың аша
Искәрмәстән генә чыгып баса
Юл чатына, урам чатына.
Уч-нәфрәте булып яктылыкның
Кара төндә йолдыз атыла.

...Бу минутта җиңде караңгылык.
Сүндерелде... Әйе, сүнде бер ут.
Сүнде бер ут. Каләм туктады...
Йолдыз булып атылдылар күктән
Төне буе нәфрәт утлары.

**Альберт Хәсәнов**

# ӘБИЕМ ЯДКАРЕ

**ПОВЕСТЬ**



Кулларым сөялдән, аякларым чебидән арынмаган балачагым тагын шул ягы белән нык исемдә калган: кышка кердекме без, әбием белән икәүләп, булган бар эшебезне бер читкә куеп торып, чабата үрергә керешә торган идек. Юкәнең иң яшеннән, иң бөгелә, иң сыгыла торганнарыннан башта бирәр киемне, әлбәттә, үзебезгә ясап киябез. Аннары туган-тумачаларга, аннары күрше-күләннәргә. Кыскасы — бөтен һөнәрле халкына. Шөшле белән калып кыйнап уч төпләре кабарып, бармак очлары чимә-чи кан булып бетә торган иде. Чынлап әгәр, көннәр буена шулай баш күтәрми чабата үрә торгач, ел тикле озын кышның ничек узып киткәнен дә сизми кала идек.

Әбекәем-матурым әле калыптан гына алган, кәрәзле бал, тулып пешкән каен җиләге, тагын әллә нинди тәмле исләр килеп торган яңа кием чабатаны сәке читенә бәргәләп-суккалап йомшартып тора да миңа суза:

— Мәле, улым, җиңел аягым, җәннәт фәрештәләре булып кына шушы чабатаны Саесканнарга кертеп чык. Нәселләре белән тирә-юньгә дан тоткан итек тегүчеләр, читек каючылар иделәр. Ә хәзер менә тышка өстерәп чыгарга төпсез башмаклары да юк. Өйләренә керсәң, әстәгъфирулла, боларны әллә тавык басып чыгарганмы диярсең, сәке тулы бала, бичаракайларым. Аналары Тәзкирә көнозын фермадан кайтып керми. Ә Хафиз кияү соңгы хатында иртәгә утка керәбез, дип язган булган. Шуннан бирле инде менә ике атна ни хаты, ни хәбәре юк, ди. Бар, улым, бар, фәрештә булып кына кертеп чык үзләренә,— дип тизләтә.— Һич югында, алмаш-тилмәш киярләр. Сугыш басылса-а-а,— дип суза әбекәем, шушы сүзләренә тирән бер мәгънә, якты өметләр салып,— эт борчасыдай тере нәселләр алар. Тиз тернәкләнеп, шунда ук аякка басачаклар. Аталары Хафиз кияү тәвәккәлнең тәвәккәле, юкны бар, берне биш итеп йөрүче.

Безнең һөнәрлегә бомба да төшмәде, туптан да атмадылар. Әмма Бөек Ватан сугышы кырларында шартлаган бомбаларның, аткан тупларның дәһшәтле яңгыравын колагыбыз белән ишетеп, йөрәгебез белән тоеп яшибез. Әле менә шушы арада гына да күпме кешенең үлүе турында кара кәгазьләр китерделәр. Хат таратучы Васфия апай, чемкара күзле, уймак авызлы чибәркәй, авылыбызда халык сөймәс бер җанга әйләнде. Урамда ул күренсә, безнең өй каршында гына туктамаса, безнең капка келәсен генә басмаса ярар иде, дип һәркемнең

коты очып тора. Ул килмәсә, кеше әле ничектер өмет белән яши, ышанычын югалтмый. Әгәр инде кара кәгазен тотып ул килеп керсә, коеласың да төшәсең. Әнә безнең очның Әтнәләргә, Арчаларга хәтле барып сабантуйлары тотып йөргән Ярау Гаяз сугыш кырыннан ике буш җиңен селкеп кайтып керде. Хәзер авызына махрасын да әнисе Нәгыймә абыстай үзе төреп каптыра, ди.

Ә без әбекәем белән һаман чабата ясыйбыз. Калыптан төшкән һәр киемгә хуҗаларны табып кына тора ул. «Нәселләре белән оста мич чыгаручы Кубәүләргә», «бураларны картинкә итеп бураучы Адашканнарга», «укмашып беткән йонны да ефәккә тиң итеп тетүче Моңлыбашларга» өләшә генә бара. Ерак сугыш кырларында кан коеп йөргән Саескан Хафиз, Кубәү Шәйдүк, Моңлыбаш Гыймран, Адашкан Дәүләтша, Удалуй Ризван һәм башка тагын бик күп агайларның балачагасы турында кайгыртып, аларның гаиләләренә кулыннан килгәнчә ярдәм итеп торуы иде бу аның. Төпсез чоңгылларында әле хәзер дә өч айлык дуңгыз баласы кадәр җәеннәр, шарлавыкларында көмеш тәңкәле чабаклар уйнаган Камышлы елгасы буена иң беренче булып безнең җиденче бабабыз Аканай карт килеп утырган. Аканай бабай җиде ул үстереп, аларның җидесенә җиде төрле һөнәр өйрәткән. Безнең Һөнәрле менә шуннан башланып киткән. Әбием әйтә, бөтен Һөнәрле безгә кардәш тия, ди. Менә шуңа күрә бөтен авыл халкының, киленҗиңгәчәйләренең, бала-чагасының тазалыгы-саулыгы, иминлеге турында кайгыртып яшәүне үзенең бурычы итеп саный ул. Менә шуңа күрә дә инде без чабатаны бөтен авылга ясыйбыз.



Ә тора торгач, әбекәем курчакка киертердәй итеп үргән чабатасын шакмаклы ашъяулыкка төреп култык астына кыстыра да, бездән чакрым ярым гына торган рус авылы Тугашка китә. Әбиемнең анда Фекла исемле дус карчыгы бар. Әлбәттә, мин дә аңа иярәм, чөнки мин әбинең рәдифе[1], әбекәем минем рәдиф.

Безнең Һөнәрледә йорт-җир, каралты-кура корган кешеләр әвәләвәлтеннән шушы Тугаш тавы итәгеннән таш чыгарганнар. Үзебезнең келәт-амбарны салганда минем бабай да шушы Тугашка, Фекла әбидә фатирда торып таш чыгарган. Әбекәем бу рус карчыгы белән әнә шул заманнарны танышып китеп, гомерлек дус һәм сердәш булып калган. Фекла түтинең карты да, минем бабай да күптән инде вафатлар. Шушы ике ятим карчыкның гомере буена бер-берсенә йөрешеп, чәйгә дәшешеп яшәүләренә монысы бер сәбәп. Шуңа өстәп Фекла түтинең бердәнбер улы Миколай абый, минем әти белән бергә комиссия торып, сугышка да бер үк көнне чыгып киттеләр. Икесен дә Бөреле станциясенә хәтле бер арбада безнең авыл юртагы белән озата бардык.

Аның шунысы бик кызык: минем әби, матурым, бер кәлимә сүз русча сукаламый. Ә Фекла түти «татарчи белмәс»тән башка бер авыз сүз безнеңчә белми. Әмма шулай да алар бер-берсен бик оста аңлашып, бер күрешсәләр, аерыла алмыйча, рәхәтләнеп эчләрен бушаталар. Килгәнбез икән, әбиемнең сорар сүзе бер була.

— Миколаең соң әлегә исән генәме?Ниләр яза үзе?

Фекла әби чуп-чуар итеп көзге ватыклары ябыштырган кучкар башыннан моңарчы инде мең кат күкрәгенә кыскан өчпочмаклы солдат хатын кулына ала. Тагын бер мәртәбә аның һәр юлын, һәр сүзен үбеп чыга. Моңа тел белү кирәкми, болай да барысы аңлашыла. Димәк, Миколай абый исән, сирәк булса да хатлары да килеп тора.

— Фекла, ызнакум мая, балакайларыбыз исән генә була күрсеннәр инде. Ходайдан гозерләп шуны сорыйк.

[1] Рәдиф — юлдаш.

Аның изге теләкләрен Фекла түти дә бик тиз төшенеп ала. Әбием ходай тәгаләдән этине һәм дә Миколай абыйны сугыш кырларыннан исән-сау кайтаруын сорап дога кыларга керешүгә, Фекла түти дә чытырдавыклы чәй кәгазьләре белән матур итеп бизәп куйган өй почмагына килеп тезләнә. Авыз эченнән догаларын кабатлап, озак итеп чукынып тора. Аннары гына безгә сораулы караш белән төбәлә. Әбием күкрәк алдына җыеп утырган кулларын шундук як-якка җәеп җибәрә:

— Юк шул. Безнекенең соңгы атналарда хаты да, хәбәре дә юк шул әле. Мәнә шуңа бик әчебез пошып килүебез дә иде.

Фекла түти каршыбызга басып юатырга керешә. Урынсызга кайгырма, ызнакум мая, саргайтма үзеңне. Синең Фиргатең дә исән-саудыр, үзе турында хәбәр салырга тик вакыты гына юктыр.

Ул арада Фекла түтинең чәе өлгерә. Шикәр урынына мичтә киптергән чөгендер тешләп үлән чәе эчәбез. Тәмле дә була иде Фекла түтинең шушы чәе. Без манма тиргә батып чәйләп утырган арада эңгер-меңгер булып куя. Авыл арасы чакрым ярымнар гына булса да, Фекла түти безне җибәрми, куна калабыз. Җылы сәндерәгә өчәү менеп кунаклыйбыз. Таракан кыштырдаганны, чикерткә сайраганны, морҗада җил сызгырганны тыңлап озак йокламый ятабыз. Ә иртә берсе русча, икенчесе татарча белмәгән ике карчык бер-берсенә күргән төшләрен сөйләп чөкердәшәләр.

Күп тә үтми чүлмәк белән я тозлы кәбестә тотып, я куенына икеөч гәрәңкә тыгып, Фекла түти үзе безгә килеп җитә. Безнең кучкар башында өчпочмаклы хат тормаса, икесе дә тирән уйга калалар.

Бу ике ятим карчык бер-берсенең милли гореф-гадәтләрен шул хәтле ихтирам итәләр иде, бу хәлгә минем хәтта бүген дә исем китә. Фекла әби безнең өйдә һичкайчан гыйбадәт кылмады, чукынмады. Килешмәгән нәрсәгә санагандыр инде. Фекла түти түр башында, зәңгәр рам эчендә торган шамаилгә ымлый. Син дә үз ходаеңнан сора, без ятимнәрне мәрхәмәтеннән ташлый күрмәсен берүк, янәсе.

Фекла түти ишектә күренүгә, әбием дә орчык булып бөтерелә башлый. Мине тавык ояларын карап керергә йөгертә. Үзе ак батист яулыгын бөркәнеп ала. Аны артка каерып бәйләп, коштабакта апара бутый. Мич алдында таба чыжлый, өйгә кыздырган май исе тарала. Күп тә үтми, әбием өстәлгә җамыяк белән төче коймак чыгарып утырта.

Ахирәте Фекла түтине шулай төче коймак белән сыйлап озатыр иде.

Фекла түти киткәч, без тагын үз эшебезгә керешәбез. Кайнар чәйдән, тәмле коймактан соң күңеле күтәрелеп, бит алмаларына хәтле кызарып чыккан әбиемнең кулы-кулга йокмый. Кулында шөшле. Авызында мин яңа гына телеп биргән хуш исле тасма. Мәнә бу кием чабатаны бик нык итеп, авыррак булса булыр, астына өч кат юкә кертеп, әнигә үрәбез әле. Ясап өлгертә алмыйбыз, чабаталарны ашап кына тора ул. Үткән кайтуында да өч кием алып киткән иде. Әти фронтка китү белән аны районга эшкә алдылар, мәгариф бүлеге мөдире итеп куйдылар. Шундый канлы сугышлар барганда да, бер бала да сабактан читтә калмасын, укысын дип авылдан-авылга, йорттан-йортка йөреп, ул айлар буе югалып тора. Авылга мунча кереп китәргә, өс-башын чистага алмаштырырга гына кайта. Соңгы кайтуында авыл советы председателе Мөнәвәрә апай белән чана тартып өй борынча йөрделәр, фронтка җылы киемнәр җыйдылар. Күрше-күләннәрнең кайсы озын балтырлы йон оекбаш, кайсы салкын окопларда яткан бичаракайларыма шинель эченнән киярга булыр дип, кулдан гына сырган мамык күкрәкчә чыгара. Фронтка дигәндә халык инде җанын кызганмый.

һәркем йөрәген ярып бирергә әзер. Тик алсыннар гына, тик ул фашист илбасарларны юк итәргә генә булышсын.

Фронтка киткән чагында әти миңа: улым, дөнья хәлен белеп булмый, кире әйләнеп кайтмасам, төсем итеп киярсең, исән-сау кайта алсам, жан биргәнгә жүн бирер, баш киеме бетмәс, рәхәтен күреп ки, дип үзенең өр-яңа бүреген биреп калдырган иде. Соры бүре тиресеннән теккән бик жылы һәм бик матур бүрек иде ул. Бик киясем, урамга чыгып, малайларга минем менә нинди бүрегем бар, бу миңа әтием биреп калдырган бүрек дип, бик күрсәтәсем килсә дә, башыма хәтта бер тапкыр да киеп карамый мин аны озак сакладым. Чөнки бу бүректән миңа дөньяда иң якын һәм иң кадерле ис, әтием исе килеп тора иде. Башыма бер генә кисәм дә, урамга бер генә чыксам да, шушы ис бетәр, һавага очар, юкка чыгар, дип курка идем. Әмма фронтка жылы киемнәр жыючылар килгәч, аларның чанасына һәркем үзенең иң кадерле әйберсен чыгарып салганда, мин дә түзеп тора алмадым. Йөгереп кердем дә, йонлач бүрекне кочагыма алып, озаклап-озаклап иснәп, әтиемнең исен бөтен сулыш юлларыма, бөтен тәнемә сеңдереп тордым да аны белән Мөнәвәрә апайларның чанасына чыгарып салдым. Әбекәем генә аңлый хәлемне.

— Кем белә, улым, ходайның рәхмәте белән бәлкем әле әтиеңә үк эләгер,— дип, мине юатмак була.

Әбием үзенә бер сәер карчык иде инде ул. Әллә бик яшь булганга, әллә инде үтә дә беркатлы булгангамы, әбием мине нишләптер изге жаннардан саный иде. Бик еш кына, үз янына утыртып, миннән матур-матур теләкләр теләтте, синең кылган догаларың ходай күңеленә тизрәк барып житәр, ди иде.

Ә тышта тыныңны куыра торган суык. Төннәрен әйткән дә юк, хәтта көндезләрен дә безнең өй бүрәнәләре шарт та шорт килеп тора.

— И ходаем, мондый суыкларыңны беренче күрәм. Мимеч-мәлгун башына гына була күрсеннәр инде,— ди әбием. Кыш шулай бинһая озын һәм рәхимсез булса да, безнең тормышлар алай зарланырлык түгел. Әбиемнең арсландай улы фронтта, алгы сызыкта булганлыктан, дәүләт безгә ягарга утынны да кирәгенчә бирә, авыл советы безгә сәламнарны да аз сала. Түр яктагы ике тәрәзә арасында Сталин бабайның зур рәсеме бар. Ул да зәңгәр рам эчендә. Әбием шөшлесен сәке ярыгына кыстыра да, вакыт-вакыт шушы рәсем белән дә сөйләшеп ала.

— Ул мимеч-башы беткере нәрсәне жиңәргә ходай сиңа мәдәтләр бирсен, иптәш Сталин, зиһеннәреңне киң итсен,— дип дога кыла.

Әбиемнең колхоз каршында пачуты бик зур. Яше белән инде күптән чуттан чыккан булса да, әле һаман да төннәрен сыер фермасында каравыл тора. Сугыш беткәч аны хәтта «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән дә бүләкләделәр.

Әбием алдында минем пачут зур. Мин ир заты, инде кул арасына кереп барам, эшкә ярыйм. Әбием мине һәр көн кич үзе белән фермага каравылга ала. Каравылга мине дә ияртүенең сәбәбе бар. Эшкә-мазар килгәндә бик йөрәкле, бик тәвәккәл карчык булып, шул авыр елларда бөтен һөнәрле халкы турында кайгыртып яшәсә дә, кеше ышанмастай сәер яклары да бар иде аның. Төрле килде-китте төшкә, жыен юк-баргa, пәри-женгә, албасты-убырга безнең һөнәрле абыстайлары, карт-корылары арасында аннан да ныграк ышанучы булдымы икән. Ә сыер фермасы андый зәхмәтнең нәкъ оясы бит инде ул. Авылдан читтә, шыр ялангач кыр уртасында утырган фермада нигә котырышмасыннар. Әбием үзе дә нәкъ менә шул фикердә иде. Ә мин кечкенәдән ул зәхмәтләрнең берсен дә танымадым. Фермага килү белән, кая ул пәри малай-

лары, минем белән уйнарга чыксыннар әле дип, кулыма таяк алып бөтен ферманың астын өскә китереп актарынып йөрим. Аргы башта берәр нәрсә кыштырдаган саен әбием дерт итеп сискәнеп китә, каткат колхуалласын укып ала. Ә мин таягымны алам да пәри малайларын эзләргә китәм. Шулай булгач, әбиемнең мине каравылга нигә алып йөрүе бик аңлашыла.

Икенче сәбәбе дә бар. Каралты тирәсенә карак-угры, усал ниятлерәк берәрсе килеп чыкса, каравыл өе тәрәзәсеннән бер киерелеп кычкырып җибәрсәм, минем тавыш аны һәрхәлдә ныграк куркытырга тиеш. Ни дисәң дә, мин бит ир заты. Ул заманнарда безнең башкайлар бүгенгедән күп кыйбат тора иде шу-у-у-л. Каралты тирәсенә ят кеше, исерек-мазар килеп чыкканда, тегене бер әйтүдә тез чүктерә торган бер-ике бик ачы сүз дә өйрәтеп куйды әбием миңа. Каравылда торган кешегә шунсыз һич булмый икән. Теге бик тә ачыларын түгел, әлбәттә. Чүт кенә йомшагракларын, әбием колагы күтәрә алырлыкларын гына. Дөньяны күп күргән, тормышның ачысын-төчесен күп татыган карчык иде шул ул.

Ә көндезләрен безнең кәсепне беләсез инде. Әбием белән баш күтәрми чабата үрәбез. Бөтен һөнәрлегә үрә башлагач, күпме кирәк бит ул! Тышта исә хәтта җил исәргә дә батырчылык итмәгән коры суык. Әбием мичкә җылы итеп яккач, аркасын куеп җылытып тора да, бер сүзне кабатлый:

— Я ходаем, окоптагы йөрәк бәгырьләребезгә чыдамлык бир, түземлек бир. Кодрәтең киң, берүк мәрхәмәтеңнән аерма.

Шушындый ямьсез салкын көннәрнең берендә өй алдында дөмбердөмбер аяк тавышлары ишетелде. Анда караңгырак безнең. Кышын кар тутырып йөдәтмәсен дип, бөтен тишек-тошыкны көздән үк салам әвәсләкләр белән томалап куябыз. Идәннәре дә тайгак. Капшана-капшана килә торгач, берәрсе абынып егылды, ахрысы. Бөтен өй алды гөрс итеп китте. Шушы алама суыкта кем йөри инде анда, ни пычагым калган? Шулчак, калын итеп чыпта белән сырган ишегебез төбенә хәтле каерылып ачылып китте дә, үзләре белән чүмәлә хәтле суык ияртеп, ике түмгәк тәгәрәшеп килеп керделәр. Алар артыннан башына тау биеклеге итеп шәл ураган бер бөкре карчык күренде. Телгән юкәләрне, калыпларыбызны читкә куйдык. Карыйбыз — күрше-белгәннәр дә түгел болар, хәтта авылныкыларга да охшамаганнар. Карчык бездән сәдака-хәер сорарга җыенмый төсле. Баксаң, ул әле бөкре әби дә булып чыкмады. Юка чикмәне астына кыстырып бәйләгән төенчеге аны шулай бөкре күрсәткән икән. Абау, алай таякка таянып көнгә калган карчык та булып чыкмады әле ул. Зур зәңгәр күзләреннән, без чабата үрә торган юка тасмадай сап-сары чәчләреннән, мин аның бик яшь һәм бик матур апай булуын төсмерләп алдым. Ул исә шунда ишек катында ук тезләнде дә, төенчеген чишәргә азаплана башлады. Күгәрчен тәпие кебек күп-күмгәк булып күгәргән бармакларын өрепөреп җылытырга тырышса да, язылмыйлар, аны тыңламыйлар иде. Андый чакта ничек түзеп тормак кирәк тә, ничек ярдәмгә ашыкмыйсың. Кая, әллә үзем булышыйммы дип, мин дә килеп чүгәләдем, тешем белән каерып төенчеген чишеп бирдем. Бу матур апайның ике түмгәге, бу дөньяда безгә башка берни дә кирәкми, тик шушы җылы өйдән генә куа күрмәсеннәр дигән төсле, чүпрәк-чапраклар арасыннан сыңар күзләрен генә ялтыратып, тыннарын да чыгармый тора бирәләр. Боларның берсе миннән битәр, икенчесе минем чамалырак.

Мин дә булышкач, марҗа апай төенчеген, ниһаять, чиште һәм аннан ни чыгара инде бу дип көтсәк, алдыбызга сап-сары тышлы өр-яңа күн пәлтә китереп салды. Үзе гөлдер-гөлдер нидер сөйли. Пәлтәне мактый-

дыр инде. Пәлтәнең тышы сары күн, эче йомшак тире. Маржа апай аны әбигә суздьı, тотып карагыз, янәсе. Әйткән идем бит инде, әбием, бичарам, русчаны ипи-тозлык та сукаламый дип. Их, шунда соң русчаны мин белгән булсам! Маржа апай белән чәчелдереп сөйләшеп җибәргән булыр идем дә, әби алдында авторитет тагын да үсеп китәр иде. Юк, шул, белмәгәч нәрсә эшлисең. Авызымны ачып тора бирәм. Әмма маржа апайның теләген бик тиз аңлап алдык. Шушы тунны безгә сатмакчы була, мактап-мактап алырга кыстый.

Дөресен әйтим, әбекәем әлеге күн пәлтәне күрү белән ошатты. Әтинең сугыштан җиңеп кайтуына шундый бер затлы тун әзерләп куясы күптәннән килеп йөри иде аның.

— Мой мужик, мой мужик! — ди маржа апай. Бу тун урланганниткән әйбер түгел, үз иремнеке дия, янәсе. Әбекәем дә күп сатулашып тормады, кырт кисеп әйтә куйды:

— Харуш твая пәлтә, бик якши, шибкә харуш!

Харуш булмыймы соң! Маржа апайның туны күзнең явын алып тора. Шунысын белергә иде, күпмерәк каермак була икән? Әбием тунны тагын бер кат күздән кичереп, үзе янына сәкегә салды. Сизәм, тун безнеке булачак. Ә маржа апай күпме сорарга да аптырабрак тора иде, ахрысы. Шунда аның күзе ишек катында торган чиләккә төште. Ул шуңа ишарәләп күрсәтте. Бер чиләк бәрәңге! Әбидән алда мин шәйләдем, кыйбатрак сорый бу. Артыгын каермак була. Беләсең килсә, матур апакаем, бер чиләк бәрәңгегә бездә зиннәтле кашлы алкалар, балдаклар, ялт та йолт килгән алмаз ташлы беләзекләр, алтын кул сәгатьләре биреп китәләр. Алай кадерле булса, туныңны үзең ки, ә без акнан башка да яшәрбез. Мин бер әбигә, бер идән астына карап алам. Чөнки мондый алыш-биреш булганда идән астына төшеп бәрәңге тутыру минем бурыч. Әмма сизеп торам, чумарга туры киләчәк мина бүген идән астына. Әбием тунны алдыннан төшерми. Аны тагын бер мәртәбә әйләндереп-әйләндереп, күнен капшап, йоннарын сыпыргалап алды да:

— Харуш! Шибкә харуш! Мондый затлы әйберне кулдан ычкындыру гөнаһ булыр! — диде, миңа киңәш иткәндәй: — Шулай бит, улым? — дип өстәде. Ә миңа шул гына кирәк. Димәк, килештек, пәлтәне алабыз. Чиләкне эләктереп идән астына чумдым. Их, малай, канлы сугыш кырларыннан әти генә исән-сау кайта күрсен инде. Аны бер дигән күн пәлтә көтеп торачак. Шундый тунны иңнәренә салып авылыбыз урамыннан бер узу үзе ни тора!

Сугышның беренче кышы гына әле бу. Әмма шушы кыска вакыт эчендә дә үзара алыш-биреш итүче ике кеше арасында аерым, сугыш чорына хас кырыс законнар да туып өлгерде. Бер чиләк дип килешенгән икән, бер чиләк бирәсең. Артык та түгел, ким дә түгел. Бер бәрәңге ким салсаң, алучыны рәнҗетәсең. Юмартланып китеп артык салсаң, алдагы көнең турында уйла, капчык тотып үзең урамга чыгар көнгә калма. Кайчакларны мин, саранланып, чиләккә бәрәңгеләрнең гел вакларын гына тутырып менәм. Әбием моны хәзер сизеп ала.

— Бәрәңгенең сөяге юк аның. Әмма, улым, дөньяда яшисең, тормыш итәсең бар. Гадел бул. Бер ирек куйсаң, күңел нәфесләнә ул. Инсафлы бул, инсафлыкка ни җитә.— дип мине кире идән астына озата. Бу юлы инде саранланмый гына эресен-вагын бергә тутырып менәм. Менә хәзер дә гөнаһысына һич катышмый бер чиләк бәрәңге тутырып менгердем.

Җылыга кергәч тагын да күперенеп, тагын да йомшап киткән матур тун соры аюдай сәкедә, әбием алдында ята. Ә маржа апайның анда эше юк. Калтыранган куллары белән алмадай алсу бер бәрәңгене чиләктән алды. Алама, иске чүпрәкләргә төргән теге түмгәкләренә дә берәрне алып тоттырды.

— Әстәгъфирулла, тәүбә-тәүбә, безне күрә торып алдашалармы дип уйлыймы? — дип куйды әбием.— Өшегәннәрен, черекләрен тутырганнармы, дип шикләнәме инде, ходаем. Безне кемгә саный бу?

Әбием чиләктәге һәр бәрәңгене тотып-тотып, харуш, мая кәртүшкә шибкә хәруш, дип мактарга кереште. Маржа апайның бездә эше юк. Кулындагы бәрәңгесен күз ачып йомган арада ашап бетереп, икенчесенә үрелде.

Боларның хәлен без шунда гына төшендек.

— Ачның күзе киштәдә, тукның күзе биштәдә, ди. И ходаем, без нәфес колларыңны кичерә күр берүк. Бу җанашларым, бүре балаларыдай ачлар икән ләбаса! Ә мин аларны бәрәңгемне мактап газаплыйм. Күр инде, мин карт ябалакны гына күр, юлдан килгән кешегә, суыктан кергән балаларга бирәр чәшкә кайнар чәй дә бирә белмәдем,— дип, үзен орыша-орыша, тиз генә самаварын куеп җибәрде. Ә мин маржа апайлар алдына, коштабак белән үзебезгә дип мичкә тәгәрәткән бәрәңгеләрне китереп куйдым.

— Пожалыста, не беспокойтесь! Не надо, не надо! — ди маржа апай, алдына куйган тәлинкәне кире этәрә. Бушап калган төенчеген күрсәтә. Башка түләр нәрсәм юк диюен белгертмәк була.

— Ашайт, әйдә ашайт! — дип әбием кыставын белә. Көймәсе комга терәлгәндә татар сүзләрен шул рәвештә русча калыпка салып сиптерергә бик оста иде ул.

— Ашайт, знакум мая, әйдә, тартынмыйча ашайт! Твая миңа берни кирәкмәйт!

Бөтен өйне тутырып яткан юкә тасмаларны бер читкәрәк җыештырып куйдык. Маржа апай тартына-тартына гына өстәл артына теге «түмгәкләрен» дә китереп утыртты. Икесе дә кызлар икән. Ач булсалар да, тыйнаклар. Бәрәңгегә алай убыр булып ябышмадылар.

— Әй, җанашым,— дип сөйләнә әбием маржа апайга карап.— Бу нарасыйлары белән кая бара икән соң ул?

Маржа апай да тик утырмый. Энҗе кебек тезелгән ап-ак тешләрен ялтыратып нидер сөйли. Минемчә, үтереп бәрәңгене мактый. Мондый чакта тагын нәрсә турында сөйләргә мөмкин дә, тагын нәрсәне мактыйсың. Мичкә тәгәрәткән бәрәңге шундый ризык инде ул. Телеңне ачылмас жиреңнән ача. Ә без аны бигрәк тәмле итеп, яндырмый да, көйдерми дә, тик арыш саламы көленә күмеп кенә пешерә торган идек шул.

Өстен чишенеп ташлагач, без бу чибәр апайның егерме биш, күп булса егерме сигез яшьләрендәге бик матур хатын икәнен күрдек. Тавышы да ягымлы, йөзе дә мөлаем. Тик телен генә белмибез, нәрсә сөйләгәнен генә аңламыйбыз. Шундый чакта кыштыр-кыштыр килеп Фекла түти дә килеп чыкмый ичмаса.

Урам ягтагы тәрәзә алдыбыздан ниндидер шәүлә узып киткәндәй булды.

— Ахырзаман алдыннан кемне уйласаң, шул килер, дигәннәр. Чү, теге шәүлә Фекла булды түгелме соң? — дип әйтергә дә өлгермәде әбием, лыштырт итеп ишек ачылып китте, анда Фекла түти күренде. Ул буш кул белән йөрми инде. Төенчеген чишеп, өстәлгә җамаяк белән тозлы кыяр куйды, безнең барыбызга да бирәр уч киптергән урман чикләвеге өләште. Шул арада маржа апай белән гөр итеп сөйләшеп тә киттеләр. Мин көнләшеп карап торам. Эх, тел белгәч, менә ничек бит ул! Тел белү — сер белү, дип бер дә юкка гына әйтмәгәннәр шул. Аларның гөр килеп, кулларын бутап сөйләшкәннәрен, аңлашканнарын авызымны ачып тыңлап торам.

Әбиемнең самавыры шундый инде аның: куеп та өлгермисең, парын да бөрки башлый. Бар булганын чыгарып өстәл өлгерттек. Табын артында күптән болай түгәрәкләнеп утырган юк иде. Бүген исә берьюлы

алты кашык уйнатабыз. Фекла түти булдыра алганча безгә тылмачлык итә. Әлеге чибәр апай бик зур инженер хатыны икән. Бар ягыннан немец камап алган Ленинградтан боз аша чыгып, безгә кайтып килүләре боларның. Үзләрен Ташкент ягына дип озаткан булганнар. Шуннан бирле утырмаган поездлары, төшмәгән станцалары калмаган. Безнең һөнәрле дә станцадан өч кенә чакрым. Инде менә безнең авылга килеп чыкканнар.

Маржа апайның кызлары, авызларына бәрәңге капкан килеш, утырган җирләреннән йоклап та киттеләр. Әбием киштәдән ястык алды, куллары белән ишарәләп, апайга балаларын шунда салырга, аның үзенә дә бераз ятып торырга, ял итеп алырга күрсәтте.

Бу апай чыннан да бик чибәр. Зур зәңгәр күзләре бигрәк матур. Ниндидер ягымлы сүзләр әйтеп ул минем дә башымнан сыйпап алды. Ягымлы итеп сыйпаганны песи дә аңлый, аңа тел белү кирәкми. Сәкедә йоклап яткан кызларына күрсәтеп, «невеста»ә миңа «жених» ди, валлаһи. Алары тагын ни дигән сүз була торгандыр инде. Шулай да сизәм, начар сүзләр түгел болар. Их, шушы русчаны белмәү тәмам өзә үзәкне. Гомерем булсамы, ант итеп әйтәм, мин бу телне тылмачлар авызларын ачып тыңлап торырлык итеп өйрәнәчәкмен әле. Әбиемнең исен китерәсе көннәр алда әле. Һич югында киләсе җәйне үк шушы Тугашка барып дуңгыз көтүе алам. Безнең һөнәрленең күп агайлары рус телен шул Тугашка барып дуңгыз көтүе көтеп өйрәнгәннәр. Әлбәттә, берәр дуңгызың көтүдән качса, аны бүре тотып ашаса, хуҗасы килеп сине орыша башласа, рус телен бик тиз төшенә башлыйсың инде аны.

Ә маржа апай бик шаян булып чыкты. Чөйдә эленеп торган бер кием чабатаны алып килде дә, шыгырт-шагырт атлап, көзге алдына килеп басты. Кулларын биленә куеп, биегәндәй итеп тыпырдап алды. Үзе көлә.

— И-и, ходаем, нинди ачык апай икән бу, валлаһи! — ди әбием дә аны ошатып.— Бу сугыш дигән нәрсәне үләт кырсын! Боларның да өйләре, торган почмаклары булгандыр инде. Шушы сугыш дигәнең ходайның фирештәләргә тиң бәндәләрен туган җирләреннән, сөйгән ярларыннан аерып, нәүмиз-ятим итеп, газап-михнәтләр чиктереп, кайларга китереп ташламый. Чын йөрәгем белән әйткән каргышларымны, ходаем, изге сәгатьләреңдә кабул ит. Сугыш дигән нәрсәне үләт кырсын!

Бераздан апай үзе дә балалары янына сәкегә ятты. Тегеләре тынычсызланып кашыналар. Маржа апай шуңа бик уңайсызлана, балаларының кулларын тота, аларның кашынуларын безгә күрсәтмәскә тырыша. Ә безнең әбидән ни дә булса яшерермен димә инде. Аннары ул тегеләй дә болай читләтеп, төрле уйдырмалар белән сөйләшүче дә түгел. Әбием һәр нәрсәне үз исеме белән атап, турыдан бәрдерүче карчык. Кашынып яткан кызларга күрсәтеп:

— Бу җанашларым чат беттер инде,— диде, без шунда ук мунча ягарга керештек.

Әллә ни арада гына суын ташып, әллә ни арада гына мичен тергезеп җибәрдек. Әллә ни арада гына шалтырап имән күмере төште, мунчабыз инде өлгереп тә килә. Әбиемнең башында әллә нинди каршылыклы уйлар йөзә. Кисәк-кисәк кенә авыз эченнән быдыр-быдыр сөйләнеп ала, шыңшып-шыңшып кына җыр көйләп куя. Үз-үзе белән байтак вакыт шулай сүз көрәштергәннән соң тәвәккәл генә бер фикергә килгәндәй:

— Ие шул! Ничек ул минем башыма моңарчы килмәгән! — дип куйды. Мунча тирәсендә кайнашкан җиреннән кисәктән генә туктап, өйгә кереп китте, апайны уятты.

— Гүләйт, дучке, әнә сусит гүләйт! Саесканнар, Адашканнар гүләйт,— дип аны урамга куа башлады. Янәсе, караңгы төшкәләгәнче пәлтәңне тотып авыл борынча йөреп кер. Кирәк нәрсәңә алыштыр. Әбием үзе миңа карап:

— Әтиең исән-сау кайтса, улым, яланөс йөрмәс әле. Аңа моннан да затлы туннар табып куярбыз, шулай бит,— дип сөйләнде. Күрәм, шундый тунны кулдан ычкындыру әбиемә кыен. Ләкин ул аны нишләптер алмаска булды.

Маржа апай урамнан бик озак йөреп, тәмам туңып, дер калтырап кайтып керде. Әмма аның тунына берәү дә кызыкмаган. Аны алучы булмаган. Бер сынык ипинең баш бәясе торган чаклары иде бу. Кая инде ул кеше өстендәге тунга кызыгу. Үз өстендәге соңгы күлмәген бер телем икмәккә биреп китәргә әзер торучылар да күп иде. Сугыш менә шул инде ул. Сугыш... Сугыш... Аны бүтән күрергә язмасын. Сугыш берәүгә дә ташлама ясамый.

Әбием маржа апайны да, аның балаларын да каен себеркесе белән чабып үзе мунча кертте. Мунчадан соң бездә тәртип бер — мәтрүшкәле сөтле чәй эчәбез. Маржа апайның исеме Элеонора икән. Русча өйрәнергә дәртем зур, мин бу исемне тиз отып алдым. Әбием дә аптырап калмады.

— Эч әле, Нурия килен, тагын берне генә булса да эч. Мунчада чәп-чәп итеп чыкканнан соң сөтле чәй эчү үзе бер гомер,— дип, аны кыставын гына белә. Элеонора аның өчен Нурия булып китте. Тегеләр дә кыстатмыйлар. Чәйне шупырдаталар гына. Тынгысыз, һәркемгә йөрәген ярып бирердәй юмарт әбиемнең башына тагын бер кайгы өстәлде:

— Ул Ташкент дигәннәре дә җәһәннәм астында бит әле. Анда ничек барып житәрләр? Ярар, мең газаплар белән барып та житсеннәр, ди. Анда аларны кем көтеп тора? Бу бер чиләк бәрәңге аларга күпмегә генә житәр? Артыгын шул мин дә бирә алмыйм, амбарда ашлыгым ишелеп ятмый,— дип, Элеонора апай һәм аның балалары өчен бик борчылып, тирән кайгыга төшеп утыра. Башына бер-бер уй-хисап төшсә, әбием аның очына чыкмый калучылардан түгел инде. Калын мамык шәлен Элеонора апайга бирде, үз башына минем бүрекне басып киде. Икәүләп колхоз идарәсенә чыгып киттеләр.

Председателебез Зөлхәбирә апайга үзе белән ияртеп килгән матур апаның хәлен кыска гына сөйләп тә бирде.

— Зөлхәбирә кызым, синең каршыңа алып чыккан әлеге чибәр маржам бик зур кызылармеецның җәмәгате икән. Шулай булгач, кызылармеец семьяларына тиешле өлештән аңа он, бәрәңге, тоз, кәнбагыш мае бирдерт. Озатыр кешегез булмаса, үзебез дә озатып куярбыз,— әбием борылып миңа карап алды.— Җиңел чана җиктереп ат бирегез.

Зөлхәбирә апай үзебезнең авылда туып-үскән, моңа хәтле чит җирләргә чыгып йөрү түгел, күрше авылга кунакка барырга да өлгермәгән юаш кына бер кыз. Русчага килгәндә, ул да безнең кебек. Әле дә ярады, идарәгә, шинель итәкләрен җилфердәтеп, ике кулын да өздереп күптән түгел генә фронттан кайткан Җиһангир абый килеп керде. Башта идарәдәге кызлар, барысы бергәләп, чыр-чу килеп, ничек кирәк алай аңа бастырык юанлыгы тәмәке әзерләп каптырдылар. Имезлеген каптыргач кына елаудан туктаган бала төсле, Җиһангир абый шуннан соң гына буылып-буылып йөткерүеннән туктады. Әле анда да:

— Их сез, кызлар, кызлар! Тәмәке дә төрә белмисез бит! Барлыюклы әчмүшкәмне дә түгеп-чәчеп бетердегез. Мин сезгә менә минем

әнкәй төргән тәмәкемне күрсәтер идем,— дип, башта кызларны орышып алды, аннары гына тылмачлык итәргә кереште.

Элеонора апайның атап кына барыр җире дә юк икән. Камалыштан котылгач, аларны Ташкентка дип озаткан булганнар. Балаларыңны интернатка урнаштырабыз, үзеңә эш бирербез, дигәннәр. Әмма юлда аларның поездын ике-өч тапкыр бомбага тотканнар. Эвакуация комиссиясе биргән документларын, һәр станциядә кайнар аш, җылы ипи ала торган талоннарына хәтле югалтып бетергәннәр. Аларны озата килүче сыңар күзле гвардия старшинасы башкаларны коткарып йөреп, соңгы бомбежка вакытында үзе һәлак булган. Болар үзләре дә чак кына исән калганнар.

— И-и, алай булгач, бу бичараларны ни дип тагын да михнәтләр чиктереп йөртергә. Бары бергә, югы уртак булыр, үзебездә генә калсыннар. Ташкентта да туган әнкәсе өзелеп көтеп тормый икән ләбаса. Тотсын да язсын гаризасын, алып куйыйк колхозга,— дип, әбием мәсьәләне җиңел һәм тиз хәл итү ягында иде. Аның һәрчак шулай инде, законнары үзе белән. Тормышны мөмкин булганча катлауландырмау, аның вак-төяк сикәлтәләрен шома гына узып китү ягында булды ул. Ә безнең Зөлхәбирә апай, ур мга чыкса, кулына чукмар башлы таяк тотмый бер адым атламый, ата каздан, нәни көчектән, мөгезсез тәкәдән курка, коты алына председателебезнең. Әмма бу юлы ул да уйга калды. Чигәсен кашымый хәле юк. Уйламый-нитми генә кеше язмышын хәл итәргә аның хакы юк. Аның ни дип әйтергә дә аптырап утыруын күреп, әбием эшне тагын да тизләтте.

— Торуын үзебездә генә торырлар, анысы өчен баш ватмасагыз да була. Куышыбыз җылы, күңелебез киң, ничек тә сыярбыз,— дип куйды.

Байтак кына чигәсен кашып утырганнан соң Зөлхәбирә апа да телгә килде:

— Колхозга алуын анысы алырбыз, ләкин берәр төрле эш беләме, һөнәр-кәсебе бармы икән соң аның?

Әбием Җиһангир абыйның каршына ук килеп:

— Соң, улым Җиһангир, шуны сорап кара әле, фельдшер-мазар түгелме? Ходай кушып, ат духтыры булып чыкмасмы? Югыйсә, мәйтәм, кинәнер идек бер,— дип төпченде.

Күе тәмәке төтене арасыннан Җиһангир абый үзе күренми дә, карлыккан тавышы гына ишетелә.

— Ирем врач иде, ди Профессор. Фронт госпитальләренең берсендә баш врач, ди. Ә үзе скрипкада сыздыра икән. Шуңа укыган. Пианинода, рояльдә уйныйм, ди.

— Менә монысы начар,— дип, Зөлхәбирә апайдан алда әби әйтә куйды. Дөньяда үз карашы, үз фикере белән яшәде инде ул. Инде син хатын-кыз затыннан булып тугансың икән, я табиблык ит, я мөгаллимәлек. Матур итеп тегә бел, суга бел, чигә бел. Һич югында аның үзе кебек чабаталар үрә бел. Ә музыка, скрипка кебек әйберләрне танымады, аларны тамак туйдырмый торган килде-китте юануларга гына саный иде. Аны гаепләп сөйләвем түгел бу. Шундый кырыс заманалар иде бит. Алай да әбием югалып калмады.

— Ярар, анысы өчен дә баш ватмагыз, үзем эш табармын мин аңа. Бөтен авылга әнә күпме аяк киеме кирәк. Һич булмаса, чабата ясарга өйрәтермен,— дип, бу каршылыкны да җиңел генә хәл итте.

Шулай итеп Элеонора апайны беркая да җибәрмәскә, һөнәрледә калдырырга күндереп кайттылар алар. Әбиемнән бигрәк моңа Элеонора апа үзе сөенеп бетә алмады. Сөенмәссең! Шушы суыкларда кемнең калтырап салкын вагоннарда йөрисе килсен. Ташкентта ул бәлкем җылыдыр да, җимешләр пешеп, карбызлар өлгерә торгандыр. Әм-

ма анда хәтле әле күпме барасы бар. Элеонора апа бездә калуына балаларын кочаклап-кочаклап шатланды.

Әллә ни арада гына, беребезнең телен беребез төшенә башлап, бик тату, бик дус яшәп киттек без. Элеонора җиңги бик уңган, бер җиңен сызганса, ярты өеңне кузгата торган апай булып чыкты ул. Ак балчык изеп шул кечне үк мичне акшарлап алды. Тәрәзә кашагаларын юып элде.

— Күрче, ходаем, күрче генә, йорт эшенә кулы тәмам сусаган булган икән, балакаемның,— дип, әбием аны мактап бетерә алмый. Элеонора җиңгинең канатны бик килештереп тотып мич агартканын, оста борып кер сыкканын карап-карап утыра да, бер сүзне кабатлый:

— Әле дә, ходаем, шуңа башым җитте, үзебездә калырга күндерә алдык. Илдә чыпчык үлми үлүен, әмма шулай да бу суыкларда нинди газап-михнәтләр күреп, иза чиккән булырлар иде.

Элеонора апайга чыннан да эш тетми. Нигә тотынса, шуны ялт иттерә. Ә кайбер көннәрне безгә ял бирә, олы кызы Лораны иртә дә әбием белән минем урынга фермага каравылга китә.

Елның тәмам иза чиктергән чоры — җәй башы иде: уңышның яңасы әле өлгермәгән, ә иске запасларның коргаксыган чагы. Әбием ни хәтле генә кысып тотса да — ишебез күп — яз башына безнең идән аслары да бушады, җилпуч төпләре дә такырайды. Бәрәңге сабагын пешереп тә, алабута орлыгын уып киптереп тә ашап карадык. Ил өстендә кара сугыш сөреме төтәгәндә, шәхси кайгы-хәсрәтеңне исәпкә дә алмыйсың. Аш талымлап тору гомумән юк, өстәлгә ни куйсалар, шуңа мең рәхмәт. Әле менә әбием, имеш, берәр күкәй дә сытып җибәрсәң, ат кузгалагы шулпасыннан тәмле шулпа бу дөньяда юк икән, дип ишетеп кайткан. Имеш, бу шулпаның шифасы баш әйләнгәннән, тешләр какшаганнан, эч йомшаганнан да бер дә галәмәт икән. Әбием бит уендагы күңелендә, күңелендәге юлында карчык иде. Кулыма ап-ак итеп юган, бәләк белән йомшарткан капчык тоттырды.

— Бар әле, улым, йөгереп кенә җыеп кайт әле шул атаминлы яфракларны. Без дә пешереп карыйк, ни чыгар икән,— дип, мине болынга йөгертте. Ә болын безнең артта гына. Аскы урамны кисеп, басмадан гына чыгасы. Андагы ат кузгалагын кеше генә түгел, атлар да ашап бетерә алырлык түгел. Урман булып утыралар. Болынның иң матур җирен сайлап, кузгалакларның иң яшелләрен, иң яшьләрен, күбәләк-чебен кунмаганнарын, кырмыска тешләмәгәннәрен генә сайлап җыярга керештем.

Көннәрдән бер көнне чиләклап орган яңгырга эләгеп уракта шактый иртә кайттык. Манма су булган киемнәрне киптерергә мунча ягып җибәрдек. Ишегалдыбызга әйләндерә торган кайрак көйләп куйган идек. Мунча өлгергәнче, без әбием белән бөтен күрше-тирә хатыннарының уракларын тешәргә керештек. Нурия җиңги колхоз амбарына сәхәргә тиешле онны алырга чыгып китте. «Сәхәр» дип әйтүнең үзенә аерым тарихы бар. Анысы да әбием галәмәтләре инде. Ул турыда алдарак әле.

Күп тә үтмәде, Элеонора апай амбар алдыннан бик күңелсезләнеп кайтып керде. Төенчеге буш, он да алмаган. Ләм-мим генә өйгә кереп китте. Ян сәкегә ятты да, стенага карап, сулкылдап-сулкылдап еларга кереште.

— Әле генә кояш булып балкып чыгып киткән идең ләбаса! Я ходаем, ни булды? Нәрсә булды? — дип, әбием аның янында орчык булып бөтерелә. Ләкин Элеонора җиңги дәшми, сәкедән башын да күтәр-

ми славын гына белә. Без ни дияргә дә, ни кыларга да аптырашып торган арада күршебез Хәлимә апа кереп житте. Сәкедә елаган Элеонора җиңгигә күрсәтеп, әбиемнең колагына нидер пышылдады. Әбиемнең кинәт йөзе житдиләнде, күзеннән усал чаткылар чәчрәде. Шунда ук чөйдән камзулын алып киде, кызу-кызу итеп чабатасын бәйләде. Аның артыннан мин дә урамга йөгердем.

Басудан яңгыр куып тарату сәбәпле, халык бүген бар да өйдә. Амбар алдында да халык байтак. Бары да әлеге «сәхәр» оныңа чыкканнар...

Сугышның бер көне дә зур сынау. Ә бу аның өченче елы инде. Өч ел гомер өч кием чабата үрү, я туздыру гына түгел. Амбарлардагы, келәтләрдәге сугыш алды запаслары никадәр сак, никадәр кысып тотсаң да күптән беткән. Йорт саен булмаса да, шешенүчеләр дә күренгәли, урамда барган җирләреннән башлары әйләнеп китеп егылучы малайлар да бар. Җитмәсә, алда урак өсте. Халыкны ничек тә аякта тотарга, ныгытырга кирәк. Зөлхәбирә апа колхозның аксак карт үгезен суйдырды. Элекке җыеннардан калган зур казанны су буена астырып, авыл халкына көненә бер кайнар ит шулпасы пешертә. Ул казан тирәсендә, әлбәттә, без — малай-шалай — күбрәк чуалабыз. Һәркемнең җамаягы үзе белән. Башта без инештә су коенып чыгабыз. Аннары тал күләгәсенә ятып, аш пешкәнне көтәбез. Карт үгез ите казанда озак кайный, озак пешә. Әмма алай да күңелле. Көтәбез, түзәбез. Аптыраш, шушы ачлыкка барыннан да бигрәк без, малай халкы ныграк бирешәбез. Чөнки сугыш дип тормыйбыз, йөгерәбез, чабабыз, үсәбез, буйга тартылабыз. Малай кеше булгач, бер-берең белән бил алышасы, көчеңне сынап карыйсы да килә. Ә хәл юк. Тал күләгәсеннән чыгып өйгә кайтырга да көчең җитмәс төсле. Ә Зөлхәбирә апаиның шушы ит шулпасы сихри көчкә ия. Берәр җамаяк, кайчакларда икәү дә эләгә, шушы шулпаны шупырып куйганнан соң, моңарчы гәүдәсен көчкә күтәреп, юк җилгә селкенеп йөргән малайларның йөзенә дә матур кызыллык йөгереп китә. Көч сынашырга, бер-берең белән бил алышырга дәрт, теләк туып куя. Туып кына калмый, алыша да башлыйбыз. Бездән читтәрәк утырган әбиләр, әниләр моны күреп:

— Яңага барып тоташырга күп калмады, аңа тоташсак, хәзер тернәкләнерсез, балакайлар,— дип, алдагы көннәргә зур өметләр баглап, гөр килеп алалар.

Быелгы ураза нәкъ урак өстенә туры килде. Әбиемне беләсез, бик үз сүзле карчык бит, болай да ач, тегеләй дә ач, дип, ел тикле озын җәй көннәрендә ураза тота башлады. Аңа ирләре фронтта булган апайлар, җиңәчәйләр, сугыш кырларындагы егетләренә сагыну хатлары язып торган кызлар да ияргәләделәр. Авылның карт коммунисты Мукум абзый, әбиемне идарәгә чакыртып, син контра, син саботажник дип, өстәл сугып кычкырып та, тәмле тел белән юмалап та, аңа ураза тотмаска, хатыннарны үзенә ияртмәскә үгетләде. Мукум абзый андый сүзләрне күп белә. Ул Һөнәрленең беренче коммунисты. Буденный армиясендә эскадрон башлыгы булып акларга каршы сугышкан. Безнең Һөнәрледә колхозны ул оештырган. Шул елларны аны авыл кулаклары чүт кенә үтерми калдырганнар. Качкан төшләреннән атып, үпкәсен тишкәннәр. Менә шул дәверләрдән бирле үлми дә, саулыкка да туймый яшәп азаплана. Җылы сөт кенә эчеп, җылы мич башында гына утырса, бәлкем терелеп, тернәкләнеп тә китәр иде. Юк шул. Кешесе ул түгел. Бер аягы белән инде күптән кабер читенә баскан, ә башында һаман колхоз кайгысы. Ә безнең әбине өстәл сугып кына җиңәрсең, бар.

— Син, Мукум кияү, миңа алай янама да, куркытма да. Мин инде андый яшьтән узган. Янарга хутың да юк. Үземә тиешле утыз су-

тыемны урамны? Урам. Шуның өстенә йөз көлтәмне бәйлимме? Бәйлим. Ә башкаларда минем эшем юк,— дип кенә бара.

Алай гына да түгел. Әбиемнең чыдамлыгына, түземлегенә бар халыкның исе китә. Үзебезнекен бетерүгә без башкаларга, көнлек нормасын тутыра алмаучыларга булышабыз. Эш дигәндә, чабыш атыдай, үзен кызгана белмәдә инде ул. Әбидән бигрәк бар халыкның Элеонора жиңгигә исе китә иде. Урак урының серенә төшенә алмыйча икеөч көн генә чиләнде ул. Ә хәзер менә ул бәйләгән көлтәләрне жир өстендә типкәләп йөртсәң дә таралася юк.

Зөлхәбирә апа иртән сәхәр ашаучыларга бирәр тәлинкә борчак оны өләшә, бирәр калжа итне өйләренә бирдертә башлады. Шунсыз мөмкин түгел. Элеонора жиңги менә шул онга чыккан жиреннән күңелсезләнеп кайтып, сулкылдап еларга тотынды бит.

Нәвалбикә әбинең бер дә эшсезгә, бер сәбәпсезгә йөрмәсен авылда беләләр бит инде. Амбар алдында груһ булып торган халык, балачага як-якка тайпылып юл бирделәр.

Гыйшык Гатасының килделе-киттеле сүзләре амбар тышына ук ишетелеп тора. Әмма әбине күргәч, ул нигәдер шүрләп калды. Кулындагы онлы тәлинкәсе шуып идәнгә төште, ярылды. Әбием исә, кем әйтмешли, исәнме юк, саумы юк, Гатаны майлы бөдрә чәчләреннән эләктереп алды да, тышка сөйрәде.

— Кая өстерисең, хәзер үк жибәр! — дип, Гата, карышмак, әби кулыннан ычкынмак була. Безнең әби кулыннан ычкынырсың, бар.

— Жибәрми торсын әле, ди. Әйдә мунчага! Аркамны юарсың. Мунча өлгерттем.

— Нишләп мин синең белән мунчага барыйм. Тиле карчык, жибәр хәзер үк.

— Ә-ә-ә! Шулаймы бәдбәхет, бәдсурәт, бәдбуй! — әбием Гатаны амбар алдына алып чыкты да, шалт берне тегенең яңагына. Күзеннән утлар күренгәндер. Амбар алдындагы халыкның ник берсе арабызга катышсын да, ул гарип кешене нигә рәнжетәсез дип, ник берсе әйтсен. Киресенчә, халыкның барысы безнең яклы. Нәвалбикә абыстай, биргән юлы ныграк бир, безнең өчен дә булыр дип, хуплап торалар әле.

Гата төскә-биткә чибәр генә, уттай янып торган чем-кара күзле, бөдрә чәчле булса да, тумыштан чалыш аяклы, чулак куллы иде. Шунлыктан аны армиягә дә алмадылар. Авылның кулына корал тотардай барлык ир заты фронтта булганлыктан, хәзер ул үзен көтүдәге тәкә кебек хис итә. Кайда аулак өй булса, шунда Гата беренче егет. Кемнең капка төбендә кызлар жыелса, алар арасында, күзләрен майландырып, әз генә кызмача Гата утырыр. Гата фәләннең килене белән кунган икән, фәләннең кызы Гыйшык Гатасыннан буйга узган икән, дигән сүзләр ишетелеп кенә тора. Аксаклыгын, чулаклыгын онытып торып, «Гыйшык Гатасы» дигән кушаматны тактылар. Гатаның бу узынулары, бу бозыклыклары турында авылыбызның фронттагы егетләре дә хатлар аша белеп, ишетеп торалардыр, мөгаен. Үзебезнең күрше егете Малик абый бер хатында: Гата белеп торсын, әгәр исәнсау кайта алсам, кычыткан арасына салып, кулым туйганчы солдат каешы белән ярачакмын, дип язды. Әмма фронт кыры бездән кош очып житмәстәй ерак. Анда бер барып эләккәч, тиз генә әйләнеп кайтулар юк. Аннан кемнең кайтасы, кемнең газиз башкайлары югалып каласы әлегә суга сәнәк белән язылган. Шуңа авыл егетләренең окоплардан янап, кисәтеп язган хатларына Гатаның бик исе китә. Аның кулында колхоз амбары. Утлы күмердәй янып торган күзләренең, бөдрә чәчләренең сихере житмәгәндә чия иренле кызларны кәрәзле баллар белән сыйлап алдалый.

Әбием шушы Гатаның бирә генә кирәген. Ник берәү арага катышсын да, ник берәү яклау сүзе әйтсен.

— Нуриям белән мунча керәсең килдемени, карачкы, җир-бит. Үзең генә түгел, шәүләң дә, күләгәң дә җирәнгеч,— дип тетә генә тетмәсен.— Авыл кызларын рисвай итеп, мыскыллап йөрүеңне ишеткәләдем. Анысына катышмадым. Аларның һәркайсының тамырлары нык, терәүләре таза. Сугыш кырыннан сөйгән егете кайтмаса, агасы кайтыр. Алары кайтмаса, авылдагы ир туганнары аякка басырлар. Синнән сорау алыр кешеләре табылыр. Син, хәшәрәт нәрсә, ни дип минем ятимемне рәнҗеттең, ни йөзең белән аңа шундый пычрак сүз әйтә алдың?

Майлы күз Гатаның азгын нәфесе безнең Элеонора җиңгигә дә төшеп йөргән икән. Он өләшкән чагында:

— Әгәр икәү парлап мунча керсәк, тәлинкәләп кенә бирмәм, онга коендырам инде сезне,— дигән.

Элеонора җиңги тиешле онны да алмый, шуңа бик гарьләнеп елап кайткан икән.

Әбием Гатаны орышты, орышты, уңны-сулны яңагына бергәләдебергәләде дә, амбар алдында ташлап калдырды. Гата бездән соң да амбар алдында бик озак елаган.

— Бу хурлыкка бер көн түзәр хәлем юк. Кайтам да асылынам, я суга ташланам. Гарип, инвалид кешене шулай мыскыллаганы өчен шул җен карчыгын закон каршында җавап бирдермәсәмме?! Исемем Гата булмасын! — дип нык янап, амбарын да бикләми, өенә кайтып киткән Гата.

Асылынмады да, суга да ташланмады. Безне судка бирергә дә батырчылыгы җитмәде. Югыйсә, өйгә кайткач, бераз ачуы басылгач, чәчennән йолыксам да, яңакларга кирәк булмаган икән хәшәрәтне, судка бирсә нишләрбез дип, әбием куркып утырган иде.

Өч көннән соң үзебезгә тиешле онны алырга амбарга мин чыктым. Гатаның яңагына әбием бигрәк нык, җан ачуы белән ялтыраткан икән. Дуңгыз нәрсәнең күз төбе күсәк белән тарткандай күгәреп чыккан. Болай кул уйнату беркем өчен дә яраган эш түгел. Әбием дә соңыннан нык үкенде. Әмма аның «тәрбиясе» Гатага уңай тәэсир итте. Шул көннән авылның чибәр киленнәре белән мунча керергә дәрте кайтты, гайрәте чикте бугай. Һәрхәлдә бу турыда сөйләгәннәрен бүтән ишетмәдек.

Фронтларда сугышлар кыза барган саен безнең чабаталарга да сораучылар артып кына тора. Хәзер аны бездән кем генә килеп сорамый. Чабата туздыручыларга Элеонора җиңги дә өстәлде. Ул әллә ни арада гына колхоз активына әйләнеп китте, көндезен дә, кичләрен дә идарәдән кайтып керми. Чабаталарны дүртәүләп ясарга керештек. Без ясыйбыз, Лора белән Дора киндерә ишәләр. Сары башлы, чыпчык борынлы бу ике кыз, икесе дә җырга бик оста булып чыктылар. Русча җырларны да күп беләләр, татарчасын да әйттерәләр генә. Әллә нинди шаян, авызыңны ерып тыңлый торган җырларны аларга күршебез Хәлимә апай керәп өйрәтә. Ул үзенә бер кызык апай. Безнең зур стена көзгесе каршына килеп баса да:

— Нәвалбикә абыстай, күрче бу кыйгач кашларымны, күрче бу калын толымнарымны, күрче бу нечкә билемне? Я, әйт, бармы минем бер килмәгән җирем? — дип, уенын-чынын бергә кушып үзен-үзе мактарга, үз-үзенә сокланырга керешә.— Бу Гитлер, башы беткере җан, нужәли бар егетләребезне кырып бетерер икән, нужәли миңа насыйп берәр кара мыеклысы исән калмас икән, ходаем. Миңа бит буш җиңен җилтерәтеп кайтса да, култык таягына таянып кайтса да ярый. Минем ал тотырып бала табасым, биш кыз, биш малай үстерәсем килә. Шушы зифалыгым, шушы гүзәллегем белән мин нужәли әкрен сызып ялгыз картаермын икән? Шушы озын толымнарымны кытыршы

кулларына алып назлаучы, нечкә билләремнән кочып алып иркәләүче нужәли булмас икән? Алай булгач, бу дөньяга мин нигә генә туганмын соң? Иркәләүче, назлаучысы булмагач, бу матурлыгым миңа нигә хаҗәт?

Әбием, эшен читкә куеп, Хәлимә апайның сүзләрен аптырап тыңлап тора. Ни дип юатырга да сүз тапмый. Хәлимә апа миңа таба борыла да, яныма килеп, тәрәлеп үк утыра.

— Ичмасам, Илдар энем, син дә тизрәк егет булмыйсың,— ди.— Их, яраткан, кочагымнан чыгармый сөйгән булыр идем үзеңне.

Мин оялам, кып-кызыл булам. Сүз дә юк, Хәлимә апай чибәрләрнең чибәре. Аңа бөтен авыл соклана. Әмма ялгыша ул, аңламый ул минем йөрәкне. Хәлимә апайның сеңелесе үзеннән дә матур. Минем күз мөнә шул Филсинәдә инде. Урамда аны күрсәм, телдән язам, алар өз турыннан узганда һәрчак абынып егылам. Их, мәнә шулай бер сәкедә Филсинә белән янәшә утырсаң иде. Әбием исә әле Хәлимә апай чыгып киткәч тә:

— Бигрәк матур булып тулып өлгергән чагы шул, балакаемның. Ә кыз бала түтәлдәге кыяр белән бер, вакытында өзмәсәң, саргая башлый. Үзе дә саргая башлармын дип курка. Кияүгә чыгасы, ана буласы, итәк тотырып балалар үстерәсе килә җанашымның,— дип, үз-үзенә сөйләнеп утырды. Аннары үз сүзенә үзе үк каршы төшеп:

— Саргаймас әле, саргаймас. Әүвәлгеләрнең: бал бозылмас, кыз картаймас, дигән сүзләре бар. Киләсе язларга сугышлар да басылып куйса, бер дигән батырлар кайтырлар. Капка төпләреннән яучылар өзелмәс. Сизми дә калыр, бер дигән егеткә үзем үк димләрмен әле,— дип куйды.

Шундый кичләрнең берендә безгә, гыж-гыж килеп, Мукум абзый килеп керде. Әбиемнең авылда бераз шүрләгән кешесе дә, нык ихтирам иткән кешесе дә шушы Мукум абзый инде. Әмма аның кисәктән генә килеп керүе безне бераз шикләндерә калды. Нигә дисәң, кешесе шундый, бер дә юкка йөрүчеләрдән түгел. Бу юлы ни дип йөрүе икән? Әллә теге вакытта әбиемнең ураза тотканын кабат исенә төшергәнме? Әллә Гата жалу биргәнме?

— Кара төнләтеп ни йомышлар белән йөрүең әле бу, Мукум кияү?— дип каршылады аны әбием.

Мукум агай тиз генә җавап бирергә ашыкмады. Сәке кырына утырып башта хәл җыйды. Без аннан күзебезне алмыйбыз. Агай бигрәк каты гыжлый башлаган.

— Бу юкәләреңне бер читкәрәк куеп тор да, мондарак күчеп утыр, Нәвалбикә җиңги. Кычкырып сөйләргә хәлем юк, әмма синең яныңа зур киңәш белән кердем,— диде ул, бераз хәл алгач. Мин дә әбием янынарак күчеп утырдым, бертуктаусыз чырык-чырык килешкән Лора белән Дорага тынычланырга кушып бармак янадым.

— Мин шулай сизенәм, сугышның очына әле ерак. Кай кичләрне уйланып ятам. Ул фашист илбасарларны тар-мар итү өчен тагын ничек ярдәм итеп була соң дип сорыйм,— дип, Мукум абзый сүзен дәвам итте. Әмма без аның тел төбен һаман да аңлап җиткерә алмыйбыз. Әбием миңа карап куйды, мин аңа сораулы караш белән төбәлдем.

— Халык белән сөйләшеп карасак, ике-өч танклык кына акча нужәли җыя алмабыз икән. Сизәм, дошманны кыйнарга барыннан да бигрәк танклар күп кирәк. Бу сугышта шунсыз берни чыгарып булмый. Безнең Һөнәрле бирсә өч танк, күрше Тугаш бирсә икене — үзебезнең район буенча гына да күпме җыйналачак,— дип дәвам итте Мукум агай.— Бу безнең фронтка, җиңү көнен якынайтуга зур ярдәмебез, лаеклы өлешебез булыр иде. Мәнә шул хакта иртәгә җәмәгать җыены ясарга исәбем бар. Халык ни дияр, кушылырлармы икән, Нәвалбикә?

— Нигә кушылмасын! Сорап торасын, Мукум кияү,— дип, күтәреп алды аны әбием.— Хөсне-ниятне, изге теләкне аны барыбыз да тиз төшенәбез.

— Жый жыеныңны, Мукум кияү, бер дә икеләнми жый,— дип кү этләде әбием сүзен.— Ил язмышы хәл ителгән чакта икеләнеп торалармы соң? Кирәк булгач акчасын да, башка нәрсәләрен дә табарбыз.

«Акчасын табарбыз» дигәч тә төшенеп алдым. Без әбием белән инде кайчаннан бирле акча җыябыз. Әни дә хезмәт хакын кайтарып тора, этидән дә килә. Әмма без аларның бер тиенен дә тотмыйбыз. Сыер аласыбыз, чәй янына сөтле, катык-сөзмәле буласыбыз килә. Авыл җирендәге тормышның бөтен яме дә, ишегалдың тутырып мал асрауда бит. Сыер-сарык асраган кешенең ишегалды ук ямьле, хуш исле була, күңеленне тартып тора. Менә киләсе көзләргә үзебез дә берәр сыер, я булмаса башмак тана, һич югында алып үстерергә корчаңгы бозау булса да юнәтә алмабызмы дип йөрибез. Сугышның да бер чиге булыр. Без дә баш күтәрми чабата ясаудан арынырбыз. Йорт-җир, каралты-кураны рәтләп, ишегалды тутырып мал асрап яшәр көннәр турында хыялланабыз.

Сизәм, әбием сыер алырга дип җыйган шул акчаны исендә тотып әйткәндер инде.

Мукум абзый кесәсендәге тастымалны кып-кызыл кан белән тутырып озаклап йөткерде дә, ничек тын гына килсә, шулай уй-хәсрәтләренә чумып, китеп тә барды.

— Ни ял итми, ни тәрбия тотмый. Тәмам бетәшә, бичара. Бу килеш озак гыжлый алмас, соңгы җәйләрен җәйләп йөрүедер мескенең,— дип, озатып калды аны әби.

Ул заманнарда радио-фәлән юк. Дәфтәр бите хәтле генә газета кисәген дә Васфия апа әллә нигә бер китерә. Фронттагы хәлләрне, дөнья яңалыкларын әлегә шушы «гыж-гыж Мукум» абзый үткәрә торган җәмәгать җыелышларыннан ишетеп кайтабыз. Берсеннән икенчесен көтеп алабыз. Ә бу юлы колхоз идарәсе алдындагы чирәмлеккә халык аеруча күп җыйналган. Мукум агай идарә баскычына гына утырып, башта политик хәл турында сөйләп алды. Шушы Мукум агайның белмәгән нәрсәсе булдымы икән, бигрәк башлы кеше иде ул.

— Черчиль-мәлгунь, Рузвельты да инде әйтер идем, икенче фронтны һаман да ачмыйлар,— дип сөйләп китте ул. Икенче фронт дигән нәрсәне ачсалар, Гитлерны ике яклап пешекли башласалар, аның хәле бик тә мөшкел буласы икән лә кана. Сугыш та тизрәк бетәр, кан коелу да туктар иде. Монысын кәҗә дә аңлый. Ә менә Черчиль белән Рузвельт аңларга теләмиләр. Икенче фронтны ачуны һаман тартып-сузып киләләр икән.

— Безнең халыкның каны коелганнан, илдә ятимнәр артканнан аларга ни соң? — дип куйды Мукум абзый.— Алар моңа сөенә генә.

Шул икенче фронт дигәннәренең капкасын әби белән барып, төбенә хәтле каерып ачардай булып, йотылып тыңлыйбыз без аны. Монда чыгар алдыннан әбием куенына сыер алырга дип җыйган акчаны тыкты.

— Димәк, үз көчебезгә таянырга кала, җәмәгать. Бил-бауларыбызны тагын да кыса төшеп, тагын бер көчәник. Туган армиябезгә үзебезнең һөнәрле исеменнән, ятим калган балалар, аналар исеменнән берәр танк алып бүләк итәрлек акча җыярга дигән тәкъдим кертәм. Берәүне дә көчләмибез, һәркемнең кулыннан, мөмкинлегеннән килгәнчә...

Шунда чирәм өстенә, үз каршына ук Мукум абзый каешланып беткән фуражкасын салып куйды. Башта куен, аннары ян кесәләрен актарды. Әллә бөтенләй акчасы юк, әллә алырга онытткан. Булмавы да мөмкин. Өй эче тулы бала-чагасы. Хатыны авыру, үзе чирле. Акча дигән нәрсә аларга каян килсен, килгәне кесәсендә ничек торсын?

Мукум абзый түш кесәсен капшады. Аннан куен сәгатен тартып чыгарды. Каптырган җиреннән чылбырын ычкындырып сәгатенә озаклап карап торды.

— Малая Каховка янында акларның бер отрядын чорнап алып юк иткән өчен командарм Семен Михайлович Буденный моны миңа үз кулы белән биргән иде,— диде. Колагына куеп, аның йөрешен тыңлап торды. Сәгатьнең көмеш капкачын шап иттереп япты да, фуражкасына салды.

Күзем әбием күзе белән очрашты. Ул баш кагып куйды. Кат-кат яулыкка төргән янчыкны куеныннан алып миңа бирде. Яз булмаса, җәйгә, җәй булмаса, көзгә сыер алырбыз, дип тиенен тиенгә өстәп җыйган акчабызны Мукум агайның фуражкасына китереп салдым. Күбен күп түгел инде ул. Әмма илебезгә басып кергән, тыныч тормышыбызны бозган, күпме аналарны тол калдырган, күпме балаларны ятим иткән фашист илбасарларның өсләренә атарга бер снаряд ясарга гына җитсен. Без шуңа да бик шат, шуңа да, түбәбез күккә ашып, сөенәбез.

Мукум абзыйның фуражкасы тиз арада акча белән тулды. Ул гына җитмәде, каяндыр тубал табып китерделәр. Фронт дигәндә, дошманны җиңүгә дигәндә, халык, җанын сорасалар, җанын да бирергә әзер. Апайларның, җиңәчәйләрнең кайсы колагындагы алкасын, кайсы кулындагы ядкарь беләзеген китереп салалар. Сыер алырга дип җыйган акчабыз гына әбиемә әзрәк тоелды, ахры. Батист яулыгы астыннан еллар дәвамында ап-ак булып агарган, юкарган чәч толымнарын тартып чыгарды. Куллары калтырана, иреннәре дер-дер килә. Үзе кебек тынгысыз, бер минут та чыңламый тора алмаган көмеш чулпыларын чишәргә тотынды. Алар белән саубуллашу аңа җиңел түгел. Әбием чулпыларын кулында әйләндергәләп, аларның матур, колакка ятышлы чыңын тыңлап, карап торды. Бу минутларда аның күз алдыннан бөтен тормыш юлы узгандыр. Аңа шушы чулпыларны бүләк иткән бабамны исенә төшергәндер. Әмма чулпылар белән саубуллашыр көн дә килде. Тормыш, вөҗданы шуны таләп итә. Әбием зың-зың иткән көмеш чулпыларын тубалга китереп салды.

Бу минутларда бар халыкның күңелендә бер генә уй, бер генә теләк. Әбием исә аны сүз белән әйтеп бирде:

— Бу изге эшкә җаным да җәл түгел, ходам. Тик кан коюю гына туктарсын. Тиз көннәрдә безгә җиңү шатлыкларын күрү насыйп булсын. Күз алмаларыбыз, йөрәк бәгырьләребез исән-сау йөреп, җиңүчеләр булып кайтсыннар. Бу теләкләребез, җан гозеребез изге сәгатьләрдә кабул булсын. Амин, амин!

Шуннан күп тә узмады, безнең һөнәрлегә алтын хәрефләр белән язылган хат килеп төште. Моны Михаил Иванович Калинин язган. Үз исеменнән, иптәш Сталин исеменнән зур рәхмәтен белдерткән. Бу хатны идарә җыенында укыган чакны боларның барын да безгә Элеонора җиңги русчалап та, татарчалап та төшенерлек итеп аңлатты. Шунысы гына үкенечле булды, бу шатлыкларны Мукум абзый гына күрә алмады. Төнлә, идарә утырышыннан кайтышлый, ул авыл күпере өстенә егылып җан биргән. Суынган гәүдәсен иртән генә табып алдылар.

Авылыбызга бомбалар төшмәсә дә, баш очыбызда дошман снарядлары ярылмаса да, канлы сугышның дәһшәтле авазлары өстебездә

әледән-әле яңгырап кына тора. Тәмам туйдырган кышның, капылт кына җылынып китеп, назлы яз белән көрешергә ашыккан көннәре иде бу. Лора белән Дораның кулларында бәйләү энәләре. Әбием, ясый башлаган чабатасын читкә куеп, аларга солдат перчаткасе бәйләргә өйрәтә. Элеонора апайның да, әбиемнең дә кәефләре яхшы, күңелләре күтәренке. Шулай булмыйни, әлегә өстебез бөтен, тамагыбыз тук, кем әйтмешли, тагын нәрсә җитмәгән. Әнә тышта яз килә. Саба җилләре исәргә тора. Фронттан да көн саен берсеннән-берсе матур хәбәрләр ишетәбез. Безнең гаскәрләр әле теге, әле бу шәһәрне азат итәләр, дошманны кыйнап алга баралар. Шундый көннәрнең берендә урамыбыз башында Васфия апа күренде.

— Бар әле, улым, Васфия апаңны чәй эчәргә чакыр. Тәмле чәй белән сыйлап җибәрсәк, икенче килгәндә безгә бирәр өчпочмаклы сәлам хаты калдырып китмәсме,— дип, әби мине почта ташучы апаны каршы алырга йөгертте.

Васфия апа урам буйлап килде-килде дә чынлап та безнең капка төбенә туктады. Авызын да ачтырмадым, әбием кушканча, өйгә дәшеп керттем. Әмма аның кулында без көткән өчпочмаклы солдат хаты түгел, дегеттән кара булып күренгән, симез печатьле зәңгәр кәгазь. Аны күрү белән әбием коелды да төште. Ул да, Элеонора апа да баскан җирләрендә каттылар да калдылар. Беренче булып әбием телгә килде.

— Алмыйм-алмыйм бу кәгазеңне, сузма да, йөрмә дә, үтерсәң дә аласым юк,— дип, кулларын алъяпкычы астына яшерде.— Мин бит сине хат китерер, дип чәйгә дәштергән идем...

Әбием ике кулын кая куярга белми, батист яулыгының очын бөтерә. Аннары үзен кулга алып:

— Бар-бар, күземә күренмә, кыяфәтсез нәрсә, хәзер үк чыгып кит, күземнән югал, бу тирәдә бүтән эзең булмасын,— дип, пыр туздырып, Васфия апаны урамга куа башлады. Бик аңлыйм мин аны. Болар барысы да аның каушап калуыннан, башына күсәк белән суккандай, миңгерәп төшүеннән генә әйтелгән сүзләр булгандыр инде. Васфия апа бу кәгазьне бигрәк көтмәгәндә китерде шул. Анда әтиемнең Кавказ өчен барган канлы сугышларда хәбәрсез югалуы, ут эченә беренчеләрдән барып керүе, шуннан чыкмавы турында язылган иде.

Бүгенгедәй хәтеремдә, бүгенгедәй, менә хәзергенәдәй күз алдымда, әбиемнең бер кулында ясый башлаган чабатасы, икенчесендә шөшлесе. Иреннәрен тешләгән, дәшми. Тик күз яшьләре генә идәнгә тып та тып тамалар.

Хәбәрсез югалу — ул бит әле үлде, җирләдек дигән сүз түгел. Бәлкем әле исәндер, госпитальгә эләккәндер, контузия алгандыр, табылыр, үзе турында хәбәр салыр, дип яшәргә өмет бар. Әмма шушы хәбәрдән соң әбием бөтенләй кәеген, сүзсезләнеп калды. Уйга чумып утыра-утыра да, бары бер җырны җырлый:

Ай-һайлүк дигән тавышка,
Оча кошлар камышка.
Агач булсам, янар идем,
Эчем тулы сагышка.

Бәхетсезлек йогышлы чир белән бер икән ул. Адресыңны бер белеп алса, килә дә тора икән. Күп тә үтмәде, Васфия апа тагын безнең урамда күренде.

— И, ходаем, шушы мәхәббәтсез нәрсә тагын кемнең кайнар яшьләрен коярга йөри инде безнең очта? — дип, бу юлы да аны тәрәзә аша беренче булып әбием күреп алды.

— Тагын безгә керә күрмәсен,— дип, мине урамга, капка бастырыгын салып керергә йөгертте.

Кем капкасы алдына туктар икән инде бу дип, котыбыз очып көтеп торабыз. Васфия апа бу юлы да безнең капка алдында туктады, кыяр-кыймас кына капка келәсен басты. Бастырыкны кире алырга, капканы ачарга туры килде. Инде капка төбенә хәтле килгән кәгазьдән алай гына котылып буламы соң? Бу юлы кәгазь Элеонора апайга адресланган иде.

Элеонора апай бу зәңгәр кәгазьнең үзендә берәр өметле, йөрәккә җылы бирердәй сүз тапмакчы булыпмы, аны тегеләй әйләндерде, болай тотып карады. Күзенә бер якынайтты, бер ерагайтты. Аннары бөтенебезне куркуга салып, ямьсез тавыш белән кинәттән генә улап елап җибәрде. Матур апай тәмам шашынып, битләрен умырып, чәчләрен йолкып, кояшка, айга карап өч көн, өч төн улады. Ашамады, эчмәде, юату сүзләрен ишетмәде. Әбием баштарак:

— Еласын, еласын, бичарам, без, хатын-кыз заты, әчебезне елап бушатабыз. Бер елап арыгач, җиңелрәк булып китә ул,— дип йөргән иде дә, әмма Элеонора җиңгинең елавы атна буена киткәч, «Константин мой, Константин», дип ыңгырашуы басылмагач, нык хафага төште. Лора белән Дораны аналары үз яныннан беркая җибәрми. Елыйелый дивана каламы, акылдан шашамы дип, котыбыз очып торды.

Васфия апа хатларның хәвефлеләрен генә түгел, вакыт-вакыт шатлыклыларын да китерә. Беркөнне идарәдән Элеонора җиңги шундый хат алып кайткан. Моны фронтка без бүләк иткән танкларның берсендә сугышкан танкист язган. Ул хәзер яраланып Сарапулда госпитальдә ята икән. Кама суын әчеп әле миңа монда байтак ятырга туры килер, дигән. Латыш егете, исеме сәер генә — Пескунас атлы икән. Авыл хәлләрен сорашкан. Егет кешенең башындагы кайгы-хәсрәте билгеле инде, берәр кыз белән хат алышырга мөмкинме, дигән. Сезнең авыл кызлары борын чөерүчеләр түгелме, рәсемемне салсам, җавап язарлармы икән, дигән.

Мукум абзый үлгәннән бирле аның бурыч-вазифасы әбием өстенә йөкләнде. Хәзер бар эшне ул башлап йөри, авылның олысы, кечесе аңа киңәшкә килә. Әле менә бу юлы да, хатны кулына тотып, әби Зөлхәбирә апа янына чыгып китте.

— Ул гуспитәлдә яралылар латыш егетеннән башка да житәрлектер. Бу егетне без үзебезгә алып кайтыйк. Безнең танкыда сугышкач, шунда яра алгач, безнең егетебез була инде ул. Алып кайтыйк та, үзебездә дәвалыйк. Даруы-ние булмаса, житешмәсә, әнә, яңа гына сауган жылы сөт эчертербез. Аннан да шифалы дару юк инде ул.

— Нәвалбикә абыстай, күңелләребез белән икебез дә бер үк сукмактан атлыйбыз икән ләбаса. Аны мин дә шулай уйлап тора идем. Алып кайтсак, бик яхшы булыр иде ул,— дип, әбиемнең сүзен шунда ук куәтләп, күтәреп алды. Аягында йөрерлек хәле булса, танкист егетне авылга алып кайтып дәваларга булдылар. Госпитальнең баш врачы исеменә тиешле кәгазен дә яздылар.

Аны алып кайтырга Җиһангир абый белән мине җибәрергә хәл иттеләр. Мине җибәрми тагын кемне җибәрсеннәр. Авылыбызның каш өстендәге күзе кебек егете булып киләбез, бит. Җитмәсә, күңелдә мәхәббәт дигән нәрсә дә үзен сиздерә башлады, үзебезнең күрше кызы Хәлимә апайның сеңелесе Филсинәне ошатып йөрим. Әле кайчан гына аның белән гамьсез килеш ташаяк уйнап йөргән идек. Ә менә хәзер шуны күрсәм, коелам да төшәм, телсез калам. Ахырда түзмәдем, күңелемдә тулып ташкан тәүге хисләремне ак кәгазь битенә төшереп, Филсинәгә хат яздым. Мәхәббәт дигән нәрсә харап икән ул. Бөтен кыюлыгыңны, бөтен егетлегеңне юкка чыгара да куя. Көненә ничәмә күрешеп, безгә әле теге, әле бу йомыш белән кереп-чыгып йөргән күршең белән хат аша, хат ташучы Васфия апа аша сөйләшер көннәргә калдым. Минем хатны алдыңмы дип кенә сорыйсы югыйсә. Батырлы-

гым житми. Урамда Васфия апа күренгәнне, җавап хаты килгәнне өзелеп көтәм. Минем хатны Васфия апа тапшырган булырга тиеш. Күргән саен икебезгә генә аңлаешлы итеп күз кысып ала. Тапшырган булырга тиеш, тик әлегә җавап хаты гына күренми.

Чүмәлә төпләрендә кунып, Камага хәтле кырык чакрым җир чыктык.

— Барасы җиребез байтак. Пешереп чыксам, бозылыр. Моны бик ачыккан чакта гына суеп ашарсыз,— дип әнни кәрзингә утыртып, әби ем безгә тере әтәч бирде. Әтәч итен күптәннән татып караган юк. Бу кикрикбайны мин беренче кичне үк «кыт» итү ягында.

— Тип-тере җанның нигә канын коярга? Сиңа тими, миңа ябышмый, әйдә, кәрзиндә утыра бирсен,— дип, Җиһангир абый каршы төште. Баштарак ярады. Чүмәлә төбенә барып башыбызны төртү белән изрәп йокыга китәбез. Иртән дә соң гына уянган булыр идек. Әмма әтәч безгә алай кояш күтәрелгәнче йоклап ятарга ирек бирми. Аның беренче тавышы белән үк аякка басабыз, юлны дәвам итәбез.

Әмма соңгы кичтә, инде Кама күренә башлагач, әтәчебез кәрзин эченнән чыгып качты бит, каһәр. Бераз аяклары язылсын, хәл җыйсын дип, киндерәне мин чишкән идем. Ике кулы да булмагач, Җиһангир абый аны, куып җитсә дә, тота алмый. Өлгерлеккә мин бик өлгер, әмма әтәч миннән дә өлгер. Канатларын җилпеп, чүмәлә башына мендe дә китте. Аннан аны тотарсың, бар. Шул вакытта әтәчне суйдырмаганга Җиһангир абыйга үпкәләгәнемне белсәгез икән. Авызыннан сулар китерә торган юан ботлы, күркәдәй эре әтәч иде ул.

Сугыш вакыты булса да, юлдан кеше өзелми. Халык белән шыгрым тулы пароходта Кама буйлап өскә таба тәүлек ярым мендек. Җиһангир абый белән юл йөрүе үзе бер рәхәт икән. Холкы да әйбәт, шаян сүзләр сөйләргә дә оста. Тик шул ягы мәшәкатьле, атлаган саен авызына тәмәке төреп каптырасы бар. Аны авызыннан өзми, имезлек урынына суыра. Ә мин тәмәкенең төтенен түгел, исен дә сөймим. Әмма төрми дә хәлең юк. Авызыннан имезлеге чыкса, Җиһангир абый ашамый да, эчми дә, сөйләшми дә.

Без утырган пароход авыр көпчәкләре белән суга-суга, әкрен генә өскә үрмәли. Чистайны узгач микән, пароходка кулыннан кечкенә генә кыз җитәкләгән бер сукыр утырды. Өстендә Җиһангир абыйның кы шикелле иске шинель, башында кояшта янып уңган пилотка. Сукыр солдатның култык астында тальянкасы да бар. Аларга безнең яннан урын бирделәр. Бу сукыр абый үзеннән бигрәк җайлап кызны утыртты. Үзе дә утырганнан соң, кулына гармунын алды. Әйләнә-тирәсендәге халыкны күрмәсә дә, аларга күптәнге танышларына дәшкәндәй итеп:

— Нәрсә, якташлар, бер сыздырып җибәрсәм ачуланмассыз ич? — дип сорап куйды. Гармун уйнаганга, күңелләрне юатканга ачуланалармы соң инде! Бигрәк тә пароходта!

— Сорап торасың тагын! Кем ачулансын! Тарт, әйдә, тарт. Сыздыр әле үзебезнең як көйләрен,— диештеләр.

Сукыр солдат гармунын сузып җибәрде, ирләрчә калын, ачы сагыш тулы тавыш белән күзләрдән яшь чыгара торган моңлы җыр башлады.

Идел бит ул, тирән бит ул, тирән бит ул, киң бит ул.
Караңгы төн, томанлы көн — без аерылган көн бит ул.

Бу җырны минем моңа кадәр дә күп ишеткәнем бар иде. Җырга әбием дә оста. Күршебез Хәлимә апа да чын артистка — көйләрне үзе чыгара. Әмма шушы көйне бу кадәр дә җиренә җиткереп, шулай моңлы итеп башкаручыны гомердә күрмәдем. Бигрәч тә бирә икән ходай

кеше дигәнеңә моңны. Ул җыр башлауга моңарчы гөж килеп торган трюм тып-тын калды. Хәтта имчәк балалары да, аналарының күкрәкләреннән аерылып, чак кына башларын күтәрә төшеп, гармунчыга төбәлделәр. Ә солдат әйттерә генә. Аңа хатыннар кушылдылар.

Тау астында салкын чишмә
Агып төшә улакка.
Агып барып күрер идем,
Идел акмый ул якка.

Тәмле әйбер күп булмый, күп булса, кадере югала дигәндәй, солдат кырт кына уйнаудан туктады.

— Җәмәгать, майт якасын, әллә берәрне төреп тә бирәсезме? — дип, иреннәрен ялап алды. Әйтерсең, кәнфит суырырга әзерләнде. Җиһангир абый миңа ымлады. Башкалар янчыкларын чыгаргаланчы, мин җәлт кенә «капка бастырыгы» төреп солдатның авызына каптырдым. Солдат канәгать калып, кеткелдәп алды. Җиһангир абый аның янынарак күчеп утырды.

— Кайсы фронтларда булырга туры килде, тылда күптәнме соң, брат? — дип сорады. Сукыр абзый башта «Тукта, сораучысы кем соң әле?» дигән төсле кулы белән Җиһангир абыйны капшады. Аның башта бер буш җиңен, аннары икенчесен тотып карады. Сыпырып-сыпырып алды.

— Майт якасын! Әллә икесен дәме?

— Икесен дә, сволочь! Йөз илле ике миллиметровканы корып ятканда прямуй попадание белән. Үз күз алдымда кисте дә төшерде.

- Сукыр солдат күзләрен капшап алды:

— Мин... атакага барганда. Хәтерләмим дә, әллә минага баскан-мын, майт якасын, әллә анда снаряд ярылган... Аңыма госпитальдә генә килдем. Бөтен җир таза-сау, тик менә күзләр генә...

— Мине бигрәк хур итте, сволочь,— диде Җиһангир абый. Сукыр солдатның сүзен урта бер җирдә бүлеп, авыр итеп көрсенеп алды.— Чалбар төймәсен чишеп төймәләргә дә кеше кулына калдырды. Тормыш итү, көн күрү безгә җиңел булмас инде.

Юлдашыбыз күзенә бәйләгән чүпрәкләрен төзәткәләп алды. Йокымсырап барган кызын капшады. Моңлы җырлар җырласа да, үзе болай бик шат күңелле абзый күренә. Мин төреп биргән «бастырыкны» да ошатты. Үзенең дөм сукырлыгына да ничектер юмор белән, «майт якасын» дип кенә карый төсле. Ә Җиһангир абыйның бераз төшенкелек белән әйткән сүзләренә каршы:

— Анадан бала артмый. Бу гариплекне начар юлда, азгынлыкта йөреп алмадык. Борчылма, якташ, туган ил ташламас әле,— диде. Мин төреп биргән «бастырыкны» тирән итеп тагын бер суырды да, калган өлешен сүндереп, пилоткасы ярыгына кыстырды. Тагын бер тапкыр йоклаган кызын капшады.

— Янында шундый юеш борыннарың булганда, сукыр булсаң да, дөнья ямьле ул. Хәтта үз хәлең турында онытып та җибәрәсең,— дип, шапылдатып кызын сөйде.— Уянып та карамый.

Сукыр солдат бик ачык кеше булып чыкты. Безнең нинди сәфәр тотуыбызны, кем янына баруыбызны белеп алгач, юлдашыбыз тагын да ачыла төште. Адресларын бирде, кайтканда кунакка керергә чакырды. Үзе район җиренә пенсия кәгазьләрен тутырырга барган булган. Авыллары нәкъ безнең юл өстендә генә икән.

— Сугышка алынганчы Гайрәтле Сафа идем, майт якасын. Хәзер Сукыр Сафага әйләндем. Шулай дип сорасагыз, күрсәтерләр. Авылыбыз пристаньнан чакрым ярым гына. Үзем умарталыкта каравылчы.

Сафа абзый авызын зур ерып көлеп җибәрде.

— Бер уйласаң, чын кәмит инде, майт якасын. Миннән нинди каравылчы булсын. Бөтен умарталыкны күтәреп китсәләр дә, мин нишлим, кая барам, кемне күрәм. Авылдашларны әйтәм, бала-чагасы ишле, ә умарта тирәсендә акмаса да тамар, ач булмаслар әле, дип куйдылар инде,— дип бөтен тормышын, хәл-әхвәлен, алты бала атасы булуын сөйләп бетерде. Кайтышлый умарталыгына кереп чәй эчеп чыгарга чакырды.

Сафа абзыйлар төшеп калганнан соң, без дә озак бармадык. Сарапул дигәннәре кечерәк кенә шәһәр булып чыкты. Госпитальне дә бик тиз эзләп таптык. Танкист яткан бүлмәгә күтәрелдек. Көндезге чәен дә эчертми аны үзебез белән җилтерәтмәк идек. Әмма ул уебыздан кире кайтырга мәҗбүр булдык. Танкистыбыз бер аяксыз булып чыкты. Үзебез белән ияртергә дә, ияртмәскә дә белмибез. Аны алырга дигән ният белән килүебезне алай да әйттек. Моны ишетүгә, танкистның авызы ерылды. Үзе юньләп култык таягы белән дә йөри алмый, шулай да безгә иярәсе килә.

— Күңелен бер җилкендергәч, инде ияртмәсәң дә кызганыч. Ияртсәк, сыңар аяк белән күпме генә бара алыр,— дип пышылдый миңа Җиһангир абый. Киңәш итеп соравы инде. Ә бу танкист абый миңа беренче күрүдә үк ошады, ничектер үз тоелды. Ул бит фронтта безнең авыл халкы бүләк иткән танкта сугышкан.

— Авылыбыз җәһәннәм астында түгел бит әле. Кырык чакрым араны ничек тә, мүкәләп булса да узарбыз. Бәлкем әле МТС машинасы очрап куяр. Килгән килгән, Перкунас абыйны калдырмыйк инде,— дидем. Аны ияртми мөмкин дә түгел. Ул без чакырганны, кыстаганны көтеп тормаган. Аркасына капчыгын асып, кулына шинелен тотып, безнең янга төшеп басты. Пристаньга безне госпиталь алашасында озатып куйдылар. Кичке пароход белән без аска төшеп тә киттек.

Аска төшүебезне сөйләмим, түзәрлек булды. Кайнар чәйне бер үзем капсам, икенче Җиһангир абыйга каптырам. Чәебез дә, шикәребез дә бар. Боларны Перкунас абыйга юл азыгы итеп бирделәр. Безнең бер туктамый татарча сиптергәнне елмаеп тыңлап, тын гына утыра бирә.

Галәмәтләр пароходтан төшкәч башланды. Үч иткән төсле ни ат, ни машина очрамады. МТСка керосин ташый торган машина бездән алда гына кайтып киткән булып чыкты. Яр кырыенда утырудан файда юк. Әкрен генә атлый торырга булдык. Моны әйтүе генә җиңел. Култык таяклары белән бүлмә эчендә дә юньләп йөри алмаган Перкунас абый, юлга чыккач, абына да сөртенә, сөртенә дә егыла.

Урманлыкка җиткәч, корган юка агачы кисеп, Перкунас абыйга агач аяк ясап карадык. Аның белән дә озак бара алмады. Әллә ничә кат марляны үтеп, аягыннан кан саркый башлады. Миңа, тормышның ачысын-төчесен әле татый гына башлаган бер яшүсмергә, болар барысы да гыйбрәтле күренешләр иде. Кеше дигәнеңдә бар икән түземлек, бар икән чыдамлык, дим эчемнән генә. Перкунас абый сер генә бирми. Нинди сызланулар, нинди тән газаплары кичерүе аның йөзенә чыккан. Култык таякларын кысып тоткан, хәтта аркасындагы капчыгын да миңа бирергә теләми. Үзебезнең Җиһангир абый да, юлда танышкан Сукыр Сафа абзый да, әле менә Перкунас абый да, күрәм, үҗәт холыклы, үз сүзле кешеләр. Үлсәләр дә, сер бирмәячәкләр. Мондый уллары булган халыкны дошман мәңге җиңә алмаячак.

Алдагы бер рус авылына кереп, Перкунас абыйның аягын сүтеп бәйләдек, «уф алла» арбасы сорап алдык. Аның ай-ваена, сыңар аягын тәрәп карышуына да карамыйча, арбага утыртып тартып киттек.

Кичен теге чүмәлә төбенә туктасак, менә әкәмәт, берни булмагандай, әтәчебез шунда йөри. Әйтерсең, безне зарыгып көткән. Килеп туктавыбызга ук кыткылдап яныбызга чыгып басты.

— Сагынырга да өлгерденме? Качып йөрсәң менә шулай була ул. Ярый әле, үзеңне төлке тотып ашамаган,— ди аңа Җиһангир абый. Ә минем шатлыгым эчемә сыймый. Солдат кәтилүгеп тотып, инеш буена йөгерергә торам. Исәбем абыйларны әтәч шулпасы белән сыйлау. Бүген ул миннән кача алмас, нибуч. Һәм мин аны хәйлә корып тәпиеннән эләктердем дә. Әмма хәзер болар икәүләшеп әтәчне «кых» итүгә каршы төштеләр. Аңламассың аларны. Бар белгән сүзләре кирәкмәгәнгә кан коймыйк. Болар өчен әтәч сую да кан коюга әйләнгән. Әйтәм ич, һич аңламыйм мин аларны. Күпме җирләр гиздереп, кызыл кикрикне кире әбиемә кайтарып тапшырырга туры килде.

Безнең һөнәрледә эшсез, кәсепсез кешене тапмассың. Бу турыда башта ук әйткән идем шикелле. Без арба белән тартып кайткан Перкунас абыйга да Зөлхәбирә апа кулай эш тапты. Сугыш башланганнан бирле буш торган урын иде бу. Вакансия. Бер сукыр аты, кучеры, сынык арбасы, кибеп кыршаулары таркалган ике-өч мичкәсе булган янгын сараена начальник итеп куйды ул аны. Ә Перкунас абый шуннан муеныннан ашып канәгать. Колхоз кәнюшниендәге атларга камытлар, дилбегәләр ишеп, шуннан көннәр буе кайтмый ята.

Аннары тагын кашык белән җамаяк ясарга бик оста булып чыкты ул. Ә савыт-саба сугыш елларында иң интектергән, иң житешмәгән нәрсәләр булып истә калдылар. Кибетләргә кайтмый. Күрше авыл марилары базарга агач кашыклар ясап китерәләр. Әмма гел ач, гел ашыйсы килеп торганлыктандыр, ахры, ул кашыкларны гел авыз тирәсендә генә уйнатабыз. Һич югында эч пошканда кимерә башлыйсың. Шунлыктан алар күпкә чыдамыйлар.

Анысы аның әле бер хәл. Монда гаҗәпкә калырлык әллә ни юк. Тагы үзебезнең күрше Хәлимә апаның хәйләкәрлеге исемне китерде. Башта миңа:

— Һи, энем Илдар, тишек борыным! Бу дөньяда минем су анасыдай сылу, караңгы төндә күк йөзенә ялгызы калыккан айдай япа-ялгыз Хәлимә апам бар, дип исеңә дә кереп чыкмый. Шул гуспитәл хәтле җиргә баргач, мәйтәм, энем-йонлы колагым, ранный егетләрнең әзрәк чибәррәген, кызлар күзе төшәрдәен алып кайтасы иде. Ә бу Перкунас абыең абау да шыксыз, абау да сөйкемсез бит. Чәче — безнең мич пумаласы, борыны сука калагы. Тешләре тырма тешләре, күзләре — ужым ашап эче күпкән сыерныкы. Тотып яратырлык бер генә җире дә юк,— дип, Перкунас абыйны яманлаган, аннан көлгән булып кыланды. Аннары көзге алдына басып, уенын-чынын бергә кушып: — Кара инде син минем сызылып киткән кашларымны! Суланып пешкән алмадай бит алмаларымны! Җыеп кулыңа алсаң, зиһенеңне чуалтырдай, хәтереңне югалтырдай, күрче, бу чәч толымнарымны! Балдак киертердәй чәч толымнарымны! Бу сугыш афәтенең дә бетәсе булмады. Нечкә билемә кул салырдай, мине назлап сөярдәй егетләр нүжәли кайтмаслар икән? Нәвалбикә абыстай, бәгърем, сизәсеңме, картаям бит, картаям. Гөл урынына шиңәм, каравыл! Ходаем, теләсәң ни эшлә, бер кияү тап миңа! — дип, гадәти озын монологын сөйләп, барыбызны көлдереп, уфтанып ала. Ул шулай безнең башны гына катырган икән. Беркөн каравылга төшешли күрәм, инеш аркылы басма өстендә бик тәмләп кочакланышып торалар. Кем белән диегез әле? Тырма тешле, калак борынлы, сөйкемсез Перкунас абый белән. Их, Хәлимә апай, хәйләкәр җан! Колак төпләренә килеп бер ачы итеп сызгыртып җибәрмәкче идем дә, ярар инде, мәйтәм, юансыннар. Андый хәлләрне генә аңламыйммы соң! Үзем дә егет кеше ләбаса. Аның сеңелесе Филсинәгә үземнең йөрәк серләремне тагын бер төшендерергә теләп, бер җыр чыгарырга йөрим әле. Чыгарсам, «Галиябану»дан ким булмый инде ул. Менә, менә ул җырның көе тел очымда гына йөри.

Сүзләрен генә табасы бар. Теге чакта минем хатка җавап бирмәде, аңсыз кызый. Ә мәнә җырымны җавапсыз калдыра алмас, нибуч.

Ә Хәлимә апай, алдакчы баш, Перкунас абый белән сугыш беткәнче үк туй итеп, өйләнешеп тә куйдылар. Туп тавышлары басылгач, еллар тынычлангач, өч балаларын алып, Перкунас абыйның туган якларына китеп югалып та тордылар. Әллә һава килешмәде үзләренә, әллә башка сәбәптәнме, алар тагын Һөнәрлегә әйләнеп кайттылар. Перкунас — авыл халкы өчен күптән Әнәс абыйга әйләнде. Ул әле бүген дә колхозның яңгын сүндерү сараенда башлык. Аягым сынар дип тормый, янгын-мазар чыга калса, түбә башларына аяклылардан җиңел менеп китә.

Шул калудан Элеонора җиңгиләр бездә сугыш беткәнче торды. Тамагы ач, өсте ертык килеш берәү дә музыка тыңлап, җырлап йөрмәс дип тормады Элеонора апай. Бездә калуларына күп тә үтмәде, каяндыр мандолина, думбра табып кайтып, безне музыка грамотасына өйрәтә башлады. Кичләрен хәзер клуб гөр килеп тора. Саф мәхәббәт, батырлык, туган ил, җиңү турында әллә нинди матур җырлар җырлыйбыз. Моңа кадәр аларның дөньяда барлыгын да белми идек. Хәзер үзебез җырлыйбыз. Арадан иң ошаганнары «Огонек», «Синенький платочек» булды. Менә шул көннәрдән башлап безнең Һөнәрле яшьләре тагын бер һөнәргә өйрәнеп алдылар. Ничә егетебез, ничә кызыбыз музыка училищесы, консерватория тәмамладылар. Һәр йортта гармун, скрипка, мандолина, гитара. Елның елында безнең Һөнәрле яшьләре район, өлкә күләмендә үзешчән сәнгать смотрларында беренче урыннарны яулап торалар.

Сугыш беткәч, Элеонора җиңгиләр кире Ленинградка кайтып киттеләр. Әмма үзләрен оныттырмадылар. Чәй-лимон, тәмле конфетларны әбигә салып кына торалар. Кунакка да бик чакырып язалар. Бер барып, торган җирләрен күреп, үзләрен кочып кайтырга безнең дә исәп юк түгел, җыенып йөри идек. Ләкин башкачарак килеп чыкты.

Татлы хыялларым тормышка ашып, авыл хуҗалыгы институтының беренче курсында укый башлаган көзем иде бу. Сентябрьнең үзе җылы, үзе җилсез, үзе чалт аяз бер көне. Ике-өч көнгә генә әбиемә бәрәңге алышырга кайттым. Мин кайтуга, кайсы көрәген күтәреп, кайсы кәрзин өстерәп, булышырга Хәлимә апайның балалары кереп житте. Әби дә безнең янда, бәрәңге чүпләшә. Бакчабызның аргы башына куе булып керән үскән.

— Банкага тутырып, беразын сиңа да биреп җибәрермен. Ипи өстенә генә салып, аш алдыннан берәр генә кашык капсаң, күңелне күтәрә, кәефне яхшыртып җибәрә, шифасы да зур. Ә менә боларыннан кышын кайтышыңа тәмле итеп кәбестә тозлап куярмын,— дип, күп итеп керән тамыры җыйды әби.— Улым, кышын дигәннән, синең белән шуны киңәшергә йөрим әле. Нурия җиңгиләрең бу хатларында да бик чакырып язганнар. Бер җаен табып кышын әллә барып та кайтабызмы? Быел, ходайга шөкер, каз бәбкәләрем дә ишле чыкты, һәркайсына бүләк итеп мендәр алып барырбыз. Нурия җиңгәңнең үзен дә, кызларын да бик сагындым.

— Кышка әле ерак, минем басып кына укыйсым, имтиханнар тапшырасым бар. Аннары күз күрер,— дидем мин.

Әбием минс сагынган. Аның сөйләшәсе, эчен бушатасы килә. Ә мин каерып-каерып җир казыйм. Бераздан ул, безне җир өстендә калдырып, чәй куярга кереп китте. Тозга ярып бәрәңге пешергән. Өстәлгә Элеонора җиңгиләрдән килгән күчтәнәчләрне дә куйган. Ә чәйдән соң ничектер сәер генә итеп:

— Әллә нәрсә булды әле миңа. Кисәктән генә башым чатнап-чатнап китә, күз алларым караңгылана,— диде.

— Салкын баз өстенә кереп-чыгып йөрдең бит, шунда салкын бәргәндер. Бераз ятып тор, чыкма.

— Чүт кенә ятып торыйм алайса,— дип, әби киштәдән ястык алды.— Улым, син дә чыкма, ял ит. Анда күп җир калмады инде, бүген булмаса, иртәгә дә бетереп ташларсыз.

Мин кулыма китап алып, тәрәзә янына утырдым. Күрәм, әбиемнең хәле яхшы түгел. Шуны раслагандай, ул авыр ыңгырашып куйды.

— Әллә балаларның берсен йөгертимме, фельдшер кызны дәшеп килсеннәрме?

— Әҗәлең җиткән булса, улым, ул гына ярдәм итә алмас, әлегә борчымый торыйк.

— Нинди әҗәл житсен ди әле. Кышын Ленинградка барасыбыз бар. Өйләнгәнеңне күрәсем, бишектә балаларыңны тирбәтәсем килә дип йөри идең бит әле. Юк, юк, мин укып бетерми, башлы-күзле булмый торып, әҗәлне аны капкабыз төбенә дә китермибез.

Минем бу сүзләремне ишетте микән ул. Аларга җавап итеп берни дә әйтмәде.

> На позицию девушка провожала бойца.
> Темной ночью простилися на ступеньках крыльца.

Берәү өчен шушы җыр берни дә тормый торгандыр. Ә мин аны бүген дә тыныч кына тыңлый алмыйм. Аның беренче сүзләрен ишетү белән күз алдыма почмакларын ап-ак бәс сарган авылыбыз клубы килеп баса. Элеонора апайның кулында мандолинасы. Ул уртага чыгып баскан. Әллә йөрәкләребезнең кайнарлыгыннан, әллә нык әсәрләнүдән залның салкын, ягылмаган булуын сизмибез дә. Киресенчә, эссе әле безгә. Һәркайсыбызның бит уртасы кызарып пешкән алма кебек яна. Залда утыручыларның күбесе бу җырның сүзләрен аңлап, мәгънәсенә төшенеп тә җитми торганнардыр бәлкем. Әмма күбесенең күзендә яшь ялтырый. Концертка әбием дә чыккан. Алгы рәттә үк утыра. Яулык очы белән ул да әледән-әле яшен сөртеп ала.

Әйе, шул еллар исемә төшсә, минем колагымда әле хәзер дә шушы җыр яңгырый. Концертларда гына түгел, без аны урамнарда да җырлап йөри идек.

> На позицию девушка провожала бойца.
> Темной ночью простилися на ступеньках крыльца.

Шушы җыр аша ничектер үзеннән-үзе әбиемнең көләч йөзе, өй тирәге генә түгел, ил тирәге булган матур образы күз алдыма килеп баса. Васыятьләре исемә килеп төшә. Аның матур истәлегенә тугры булып яшисем килә.

# Нур Әхмәдиев

## Яшелдән кигән каен

Әй, бәгырем, каенкаем,
Киенгәнсең яшелгә.
Беләм, син гашыйк булгансың,
Әйт, оялма, яшермә!

Бәлки, өметсез гыйшыктыр,
Бәлки, ул да янадыр.
Мәхәббәт, кайчан килсә дә,
Барыбер өр-яңадыр.

Әйт, яшермә, кемнән, кемнән
Барып сөенче алыйм?
Сандугач күк, арагызда
Сердәшче булып калыйм.

Сөюнең беләм януын,
Ләззәтле әрнүләрен.
Күктәге йолдыз — очкыны
Шул гашыйк бәгырьләрнең.

Әй, таң җиле, тимә әле,
Тимә әле каенга!
Җыр язган чаклары бугай
Аның җаныкаена.

Араларында гомерлек
Сердәшче булып калыйм.
Әйт, каенкай, кайсысыннан
Барып сөенче алыйм?

## Әкиятләр туар булса

*Зөлфәткә*

Җилләр сүндергәнме өмет утын,
Гөмбә үскән мәллә хыялга?
Йоклаганга, бәлки, барыбердер,
Моны сизү авыр уяуга.

Ышанычны урлаучылар йөри,
Атом, нейтрон тотып кулларга.
Ничек әле җөрьәт итә алар,
Ничек җөрьәт итә без барда?!

Ишетелә елау: юк, гадәти
Елау гына түгел бу юлы.
Родариның гүя язылмаган
Әкиятләре сыман, моң елый.

Ишетәсезме сез шушы моңны?
Ишетегез, хәссас күңелләр!
Барысы да әле әкиятне
Саклый алыр хәлдә түгелләр.

Күпләр дошман җирдә
вәхшилеккә,
Яхшыга да кемдер дошман ич!
Әкият яшәр, тик яшәсен җирдә
Әкиятләргә булган ышаныч!

Без ышанып яшик туасыга,
Вакытында килер үлемгә.
Яңа әкиятләр туар булса,
Орбитасын саклар җирем дә.

## Ольга Кәримова

### Күгәрчен

Бигрәк сәер очты бу күгәрчен...
Һаваларда борылып-сыгылып,
Ашкынды ул һаман биеклеккә,
Агачларга бәрелеп-сугылып.

Бер чаялык белән талпынды ул—
Канатлары белән тырмашып,
Күренмәгән дошманыннан, гүя,
Биеклеккә качып — юл ачып.

Сукыр иде кошчык. Күз
урынында
Ике чокыр — ике тап кына.
Ә йөрәге, бөтен көчен җыеп
Һаман әле күккә талпына.

Очкан кошлар нәләт укыдылар
Кансызлыгы өчен берәүгә.
Ә күгәрчен?
Бөтерелгән кәгазь кисәгедәй
Җансыз мәтәлде ул түбәнгә.

Җылы болытлардан ләйсән
койды,
Чишмә акты таудан юл ярып,
Мә, ал мине, дигән алма кебек,
Кояш чыкты кабат кызарып.

Ә күгәрчен инде селкенмәде,
Ике якта — ике ак канат.
Әйтерсең, ул шулай җир-анадан
Ярдәм сорый иде соң кабат...

РОБЕРТ РӘКЫЙПОВ *тәрҗемәсе.*

## Илдар Әхсәнов

●

Дөньяда мин эштә таптым дуслар,
Рәхмәт ул туганлык илчесенә.
Металл кырдым, магистральләр салдым,
Мендем буровойлар сөңгесенә.

Таянычым арта гына барды
Күтәрелгән саен биегрәк:
Бер куәтләү сүзе Илнең миңа
Йөз кыенны җиңәремә терәк.

## Фәһимә Галиева

### Горурлана беләм

Алкышлаулар. Син җиңүче бүген,
Дан мәйданы тоткан баһадир.
Синнән — җиңү, миннән — горурлану...
Җиңүчегә хөрмәт, бәһа зур.

Син җиңүче бүген. Чигенмәдең,
Авырлыкны тезләндердең ич.

Җиңүләрдән башың әйләнмәсен,
Яңа дәрман сиңа, яңа көч!

Язгы ташкын чагы йөрәгеңнең,
Дан мәйданы — синең колачың.
Гүзәл биеклекләр яулый торган
Җиңү җегәрлекле син, лачын.

Елмаюым — эчтән балкуым ул.
Кайгы кытыкласа, көләм мин.
Синнән — җиңү, миннән горурлану:
«Син!» — дип, горурлана беләм мин.

## Илдар Хөснетдинов

### Яшен тели күңел

Карап торам кышкы тәрәзәгә,
Тырнак белән кырам бәсләрен.
Ни өчендер, белмим, шушы кичтә
Телим күктә яшен яшьнәвен.

Бу кыш белән нинди килешү ди!
Юк, мин җәйдән әле туймадым.
Бар табигать җәйнең төсен җуйды,
Ә мин менә төсен җуймадым.

Йөрешендә хәйран тизләгән шул,
Эх, табигать әллә нишләгән.
Кыш, сулышын ак бөркәнчек итеп,
Кар егете белән кичләгән...

Карап торам кышкы тәрәзәгә,
Җил арбада җилә Декабрь.
Сау яшеллек килә күз алдыма,
Яшен тели күңел нигәдер...

## Котдус Батыров

### Кырларымда калам

Җәяү генә кайтып киләм,
Авылымның тын чагы;
Үр менүгә — яшел чәлтәр,—
Мең яшәр урман ягы...
Ераклардан каршы ала
Хуш исе белән болын,
Сискәндереп кешнәп куя
Инеш буенда колын.
Юл читендә куе арыш
Чуклы серкәсен коя;
Таңны тоеп бытбылдыклар
Түзми пырхылдап куя.
Сагындырган басу юлы,
Котү чыккан иртәләр...
Күңелемдә нечкә кыллар
Тынгы белми, чиртәләр.
...И, туган як, рәхәтлегең! —
Күңелемдә һәр көнең...
Йөрәгемдә шыта синең
Тук башаклар бөртегең.

## Роберт Рәкыйпов

### Тал төбендә талгын су

*Жыр*

Тал төбендә талгын су,
Яшьлек чагым калган су,
Аерылмаска вәгъдә биреп,
Көмеш йөзек салган су,
Талган су...

Тал төбендә салкын су,
Яшьлегемдәй алкын су,
Аерылышкан вакытларда
Йөрәкләргә якын су,
Салкын су...

Тал төбендә инеш-су,
Вак-вак ташлы көмеш су,
Яшьлегемне саклап калган,
Мәңгегә сөенеч су,
Бу — көмеш су,
инеш-су!

●

Бер карасам,
Шинель кигән ерактагы төпчегенең
Сагышыннан
Чәчләренә бәсләр төшкән әнкәм сыман...
Бер карасам,
Иңбашына шәл ябынган каен кебек,
Якты нурын сибеп тора тирә-юньгә,
Мин шат диеп, карый көлеп...
Бер карасам,
Йомшак ап-ак бураннарын киенгән дә
«Туган тел»не жырлый кебек, бишегемә
Иелгән дә — килен мәллә?!
Бер карасам,
Күрәм аның ат урынына жигелгәнен.
Ләкин һич тә мин күрмәдем кайгылардан
Жебегәнен, жиңелгәнен.
Бер карасам,
Керфегемә өрә йомшак тургай жилен.
Кем дип кенә, ни дип кенә уйласам да
Туган жирем — туар жырым!..

### Россиягә оча аккошлар

Бер ай инде безнең күргәнебез —
Диңгез белән зәңгәр күк кенә.
Туган илдән килгән соңгы хатлар
Күкрәк кесәсендә йөртелә.

Акчарлак та очмый бу тирәдә,
Ярлар бигрәк ерак корабтан.
Киек казлар үтә баш өстеннән,
Язлар алып ерак-еректан.

Барыбызның күзе күктә иде,
Иярдек без казлар артыннан.
— Россиягә кайта бу аккошлар,
Россиягә! — диде лейтенант.

— Енисейга!— диде шунда кемдер,
— Свиягага!
— Обька!
— Севанга!
— Печорага!
— Агыйделгә кайта!
— Онегага!
— Нева!
— Кубаньга!

— Днепрга! — диде старшина,
Мичманкасын күккә чөйде дә.
Һәр диңгезче кайтарасы килде
Аккошларны туган җиренә.

Ә минемчә, шушы киек казлар
Кайтыр төсле иде Иделгә.
Аккош булып киек казлар белән
Әй, кайтасы килә иде лә...

Онытылды ару-талулар да,
Арткан төсле булды җегәрлек.
Россиягә очкан аккошларга
Гүя хатлар биреп җибәрдек...

## Өйгә кайтам

Самотлордан, Төмәннәрдән искән җилләр
Чупай, Урсай ташын сыйпап өйрәнделәр.
Себерләрдә үскән кебек, өй каршымда
Үсә моңсу кәкре-бөкре өрәңгеләр.

Туган илгә сагынуларың көчле булса,
Мәхәббәтең, ихтирамың тирән, диләр.
Җырлап җибәр: яшьлегеңне сөйлим, диеп,
«Әллүки»гә чайкалалар өрәңгеләр.

Өйгә кайтам — иң-иң гүзәл шатлыкларга,
Чикерткәле тыныч урам — Әлмәтемә.
Бу төбәктә каргалар да, чыпчыклар да
Әнкәм телен, татар телен әйбәт белә.—
Мине танып исәнләшә, хәл сораша
Чыпчыкларым — шаян кошлар, чырык кошлар.
...Рәхим ит, дип баш чайкыйлар юл буенда
Ак сиртмәле кара алтын суырткычлар.

Урманнарым тулы гөмбә, җиләк белән,
Каен төбе — кояш тулы, төймә-төймә.
...Хәлләр шәптән, күңелләрем әйбәт, менә
Өйгә кайтам, Әлмәтемә,
Әлмәтемә!

## Газинур Моратов

### Йөзү

Ышанмасак та үзебез
Юк-бар имеш-мимешкә,
Алтын балык тотабыз дип,
Чумган идек инешкә...

— Йөзә беләсеңме? — диеп,
Сорап тормады заман...
Бүген менә колач салып,
Иделгә кереп барам.

Ярдан ерагайган саен,
Хәвефлерәк, шомлырак.
Чигенү юк! Хәзер инде
Кайсы ярга да ерак.

Йөзәм! Йөзәм! Юк, кирәкми
Нәтиҗәсе, азагы.
Күктән гүя котлау ява,—
Акчарлаклар авазы.

Чыр-чу, гауга артта калды.
Колагымда — су шавы.
Йөзәм! Йөзәм! Тынмасын тик
Дулкыннар алкышлавы.

### Кинокадр

...Генералның йөнтәс кулы
Күтәрелде өскә.
Барабаннар чинап куйды
Тантаналы төстә.

...Укылды хөкем карары:
— Кызганмаска үзен!
Безнең мәрхәмәтне күрсен —
Капламагыз күзен!

...Кымшанып куйды туфрак-җир.
Диварлар түкте яшь.
Күзләрен йомды алсу таң.
Яшеренде Кояш.

...Кулына әфлисун тотып,
Бәдрә чәчле сабый,
Эшафотка менеп китте,
Баскыч саный-саный.

●

Урам буйлап барган чакта очратсаң
Юл аркылы чыгып килгән кырмысканы,
Таптый күрмә (мин дә — нәни) —
Таптый күрмә,
Үз-үзеңне саклагандай сакла аны.

Урман буйлап атлаганда очратсаң
Оясыннан егылып төшкән кош баласын,
Күрмәмешкә салышма син (мин дә — кошчык),—
Кире кайтар әнкәсенә күз карасын.

Диңгезләрне кичкән чакта ишетелсә
Дельфиннарның үзәк өзгеч СОС авазы,
Ишетмәскә җай эзләмә (мин дә — дельфин) —
Үзеңә үк кире кайтыр игелекнең
Кайтавазы.

Еллар аша барган чакта очратсаң
Югалтулар чәрдәкләгән язмышларны,
Читләп узма (мин дә — яра), —
Табиб бул син,
Сыгып чыгар җаннан кайгы-сагышларны.

## Урманда

*Иду на вы.*
Князь Святослав

Өркү нигә, гөлкәйләрем,
чалгы тотып килмәдем.
Кошкайларым,
оягызны
туздырырга килмәдем.
Каеннарым, селерке я
дүркә [1] эзләп килмәдем.

Сөйләшик бер, серләшик бер,
җаннарыбыз бер laca...
Аңлашырбыз гүзәллек һәм
язмышлар теле аша.

## Үзгәрешләр көтәм

Кошлар калган туктап бер ноктада,
Син калгансың туктап кыл уртада...
Мәңге шулай булыр дисең мәллә,
Мәңге шулай барыр димсең эшләр, —
Үзгәрешләр көтәм, үзгәрешләр...

Язмышыннан берәү йөзен чыткан,
Гаиләдә низаг-ызгыш чыккан,
Илләр чыраена илләр суккан...
Мәңге шулай барыр димсең эшләр,—
Үзгәрешләр көтәм, үзгәрешләр.

Гадәтилек сарган уйларыңны,
Юлларыңны сарган, елларыңны...
Мәңге шулай барыр димсең эшләр,—
Үзгәрешләр көтәм, үзгәрешләр.

## Яралы көз

Сагыш исе җанны сара,
Бәгырьне әчеттерә.
Озаткан торналарым да
Шом булып төшкә керә.

Кемнең кулы җитте икән,
Табигать, әйт, тизерәк,—
Каршы алган торналарым
Озаткannan — кимерәк.

[1] Дүркә — мунча селеркесе.

●

Безнең дә бит еллар учагында
Бераз инде гомер көйрәде...
Бишегемне тибрәткәндә әнкәй
Кайсы көйне икән көйләде?

Кайсы көйне икән көйләде ул?
Хәтереңдә булса, әйт, йөрәк, —
Үксез җаннар азмы җир-бишектә!
Юатырга кирәк!
Җыр кирәк!

●

Бүразнага тамган тамчы тирнең
Бәһасе ни димсең, күпме тора? —
Болытларга багып уйга калган
Башаклардан сора.

Бәгыреңнән тамган тамчы канның
Бәһасе ни димсең, күпме тора? —
Ил-Ватанның кләймәсе суккан
Җырларыңнан, иманыңнан сора.

Ир күзеннән тамган тамчы яшьнең
Бәһасе ни димсең, күпме тора? —
Бәхет толпарыңны урлап качкан
Сөйгәнеңнән сора.

... Гомер бәһасе ни «азат» илдә? —
...Бер пистолет
утыз доллар тора...

●

Соңгы юлга җыенганда,
һәркемнең күңел дәрьясы
изге уйлар —
васыятьләр белән тула.
Хәтта гомер буе
гөнаһ кылган бәндә күзләрендә
кешелекле бер уй була.
Күп вакытта
иң хак сүзләр
нәкъ шул чакта әйтелә дә!
...Ә исәннәр
һәрбер сүзне җөпләп тора.
Алтын тапкан малкуардай,
һәрбер сүзне
хәтеренә салып тора...

## Курчак театрында

...Ә биредә
курчаклар да нәкъ кешеләр инде:
берәүләре — явыз, икейөзле,
берәүләре — кешелекле, изге.

Баксаң,
үзләре җансыз бер җисем,
сабыйларның юанычы бары.

...Ләкин курчаклар булып та
кешеләр уйный шул,
кешеләр уйлый...

## Владимир Ларин

# ГУДОК

**хикәя**



Куптән түгел бездә шундый хәл булды бит әле. Заводның гудогы бозылды. Баш инженер Филипп Филиппович мине үзенә чакыртып алды да:

— Ишеттеңме бүген гудокны,— ди.

— Ишеттем,— мин әйтәм.

— Ничек соң?

— Тавышы үзгәргән димме, нигәдер тоныграк кычкырта. Тузгандыр ул. Кочегарканың төзелүенә дә биш былтыр бит инде.

— Син, Иванов, менеп төш әле шунда, нәрсә булды икән. Эштән чыкса, алыштыр. Складта бар бугай.

Мин үзем инструментальныйда эшлим. Безгә мондый эшләрне еш тапшыралар. Катлаулы йозак ватылдымы анда, пружинаны чыныктырырга кирәкме — безгә, инструментальныйга китерәләр. Элек андый четерекле эшләрне Вася абзыйга төртәләр иде. Ул инде коеп куяр. Юк ул хәзер, пенсиягә китеп барды. Елга буенда балык каптыра. Гудок ишене генә без дә рәтли алабыз анысы... Шулай итеп мин кочегарка түбәсенә менеп киттем, гудокны сүтеп алдым. Чыннан да беткән икән. Күп эшләгән инде, җитәр. Кулда бераз әйләндергәләгәч, чыгарып ташларга булдым. Яңасының тавышы да ярыйсы гына болай, калын итеп, бас белән җиппәрә. Ә искесеннән менә соңгы араны кычкырырга өйрәнүче яшь этәч тавышлары чыга иде.

— Ярый бу, ярый, — диде Филипп Филиппович. — Ярыйсы гына тавышлы.

Кәефләр күтәрелеп китте. Эш эшләнгән, кабул ителгән. Ни кирәк тагын. Вася абзый безгә: «Егетләр, инструментальщик борчаны да дагалый белергә тиеш»,— дип әйтә иде. Әлбәттә, бу инде булган хәлләр. Моның белән Тула осталары гына шөгыльләнгән. Ә менә инструментальщикның оста слесарь да булырга тиешлеген Вася абзый тукый килде. Һәм бу дөрес тә. Гудок кычкыра. Эшкә чакыра. Ә тавышы «синең эш!» дип искә төшереп тора кебек.

Беркөнне цехта Вася абзый күренде.

— Гудокны кем ремонтлады? — дип сорый бу.

— Нәрсә булган, әллә начармы? — дим. — Яңаны куйдык. Инженерга да ошаган, мактап та алды хәтта.

— Мактадымы, юкмы — минем анда эшем юк. Син шуны әйт: искесен кая куйдың?

— Ничек инде кая? — дим мин. — Сезгә барыбер түгелмени? Хәзер истә дә юк инде кайда икәне. Утильгә озаткannардыр үзен. Бакыры гына да ярты пот бит.

— Ничек инде утильгә,— дип кычкырып ук җибәрде ул. — Мин аның өчен, кирәк булса, ике самавыр бирергә әзер. Нишләвегез бу, ә?

— Гудоклар бездә житәрлек бит,— дим мин. — Теләсәң кайсын сайлап ал. Бусы ошамаса, башкасын куярбыз.

Вася абзыйның йөзеннән хәтта кан качты.

— Эзләп карыйсы иде бит,— диде кемдер.— Бәлки табылыр әле.

— Утильне кичә генә платформа белән озаттык. Табып кара хәзер.

Вася абзыйның маңгаена тир бәреп чыкты, чал мыегы тырпайды.

— Берни аңламыйсыз сез, егетләр. Заводның традицияләренә дә исегез китми.

— Кем әйтте сезгә завод традицияләрен сакламыйбыз дип. Заводны без дә яратабыз аны. Әйләнә-тирәли бакчаны да үзебез утырттык.

Карт кулын селтәде дә инженер янына китеп барды. Аңа тагын берничә карт иярде. Филипп Филиппович кабинетына килеп керделәр. Инженер утырырга кушты. Делегациянең ни өчен килүе белән кызыксынды. Тегеләр, үз чиратында, зарларын сөйлиләр, иске гудок кайда, дип төпченәләр. Инженер, әлбәттә, берни белми. Эше болай да муеннан. Шунда мине дәшеп алды. Бер дә ошамады бу миңа, йөриләр инде баш катырып, мәйтәм. Исләре киткән шул бакыр кисәгенә. Алтын югалтканнармыни! Кирәк бит, шулвакыт келт итеп гудокны кочегаркада калдыруымискә төште. Барып карасам — ята караңгы почмакта аунап, ватык кирпечләр арасында. Тартып чыгардым да китеп тә бардым иңгә салып.

— Менә ул,— дим.

— Исән икән әле! — дип сөенде Вася абзый. — Мин инде эретергә алып киткәннәрдер дип торам.

Картлар гудокны урап алдылар, җиңнәре белән тузанын сөрттеләр. Аннан тезелешеп утырдылар да тәмәке пыскытырга керештеләр. Китте ялганып әңгәмә.

— Маркелыч, хәтереңдәме малай чакта забастовкада катнашулар? — ди Вася абзый.

— Билгеле хәтердә,— ди тегесе.

— Эх, гүләп тә карады инде гудок ул чакта! Халыкны митингка җыйды. Ә труба очында кызыл флаг җилферди. Заводка жандармнар якынлаша.

— Әйе, тавышы бөтен тирә-якны күмеп китте. Җандармнар винтовкадан ата башладылар. Пуля тишекләрен соңыннан этиең ямады.

— Гражданскийда да, шәһәргә аклар якынлашкач, бик каты гүләде гудок. Көрәшкә чакырды, кулга корал алырга.

— Субботникларга да аның тавышына җыела идек. Юлдан төшкән паровозларны күтәрдек,— диде Маркелыч.

— Ә Ленинны күмүләр... Гудокның кайгылы тавышы әле дә истә.

— Әйе, андый нәрсә онытылмый.

Картлар мәсьәләне шулай китереп чыгардылар ки, җыелган халык бертавыштан гудокны кире куюны таләп итә башлады. Ул бит сыналган иске дус белән бер, янәсе.

— Бәлки аны ремонтлап бирергәдер? — дип сорады Вася абзый инженердан. — Яраклык әле ул.

— Рәхим итегез,— ди инженер. — Алай итсәк, дөресрәк тә булыр. Күпме вакыйгаларның шаһиты булган ул.

Вася абзый белән Маркелыч көнозын иске гудок белән маташтылар. Чистарттылар, бакырчылар янына алып барып, тузган җирләрен ямадылар. Аннан, кочегарка түбәсенә алып менеп, урнаштырып та төштеләр. Төш вакыты җиткәч, гудок берзаман яңача көйләп җибәрмәсенме! Үен коралымыни. Аһәңле тавышына кочегарка тирәсенә халык җыела башлады, ә картларга бу — сөенеч өстенә сөенеч, ерык авызларын җыеп ала алмыйлар.

— Күрдеңме инде эшнең нәрсәдә икәнен? — ди Вася абзый.

— Күрдем, заводның гудогын йөрәгең белән дә тыңлый белергә кирәк икән, — дим.
— Менә шул шул, — ди карт.
Шулай ел ярым чамасы хезмәт итте гудок. Вася абзый белән балык каптырганда да тавышы колакка килеп кергәли иде. Аннан безгә яңа директор килде.
— Әле дә сакланамы шушы әйбер сездә? — дип гаҗәпләнде ул. — Алар күптән бетте бит инде. Фән дә тотарга кушмый — тавышы зарарлы, ди. Аннан, ни әйтсәң дә, искелек калдыгы бит. Сүтеп алырга кирәк.
Шулай да, үз белдеге белән алып ташлаттырмады ул аны. Җыелыш җыйды. Сөйли: хәзер инде, иптәшләр, халык бездә аңлы, эшкә килергә чыбыркылап торасы юк, ди. Барыбыз да вакытында киләбез, вакыт җиткәч китәбез, ди. Шулай булгач, гудокның кирәге дә калмады, ди.
Аннан чыгышлар башланды. Бәхәс купты. Берәүләр «калсын!» ди, икенчеләре — «алырга!» дип кычкыра. Бер ишеләре «гудок ул мәҗбүри хезмәт өчен генә кирәк» дисә, кайберәүләр «ничек инде алай?» дип каршы төшә.
Җыелышка Вася абзый да килгән иде. Тәмам алгысынды бит карт — берничә тапкыр сүз дә алып карады. Кычкыра, дәлилләр китерә, кулларын бутый. Гудок тавышын без гомер буе тыңлаган, туганда да шул тавыш астында туган, ди. Кемдер аның тавышыннан бәлки мендәр белән каплана торгандыр, ә миңа ул гимн белән бер. Без үлгәч теләсәгез нишләтерсез, ә хәзергә — ни-ни, гудокка тимәскә!
Әлбәттә, арттырыбрак җибәрде карт. Аңлатып та карыйлар үзенә, тормыш алга бара бит, һаман бер урында таптанып булмый, диләр. Түзмәде, бу юлы трибунага ук менеп китте.
— Эшләр алайга киткән икән, әйдәгез, болай итик: утильгә озатканчы, без аны лутчы, берәр нәрсә язып куеп, мәңгеләштерик.
— Нәрсә языйк соң? — дип кычкыралар залдан.
— Мәсәлән, болай: «Капиталга каршы барган көрәштә эшчеләрнең коралы булды», дип.
Халык дәррәү кул чаба башлады.
— Дөрес,— диләр. — Шулай итик! Акыллы сүз әйтте!
Каршы төшүчеләр дә табылды. Кирәкми, җансыз әйбергә мемориаль такта куяргамы, диләр. Нәтиҗәдә гудокны моннан соң кычкырттырмаска булдылар. Алырга кирәк дигән фикергә килделәр. Вася абзый җыелыштан бик моңаеп чыкты. Ә соңрак барыбер аның тәкъдименә әйләнеп кайттылар: телсез булса да, торсын шунда котельный түбәсендә язулы килеш. Бәлки киләчәктә әле заводның музеен да ачып җибәрерләр. Ул чакта пыяла астында аңа да урын табылыр. Директор да моның белән килеште.
Шулай итеп гудок кабат инструментальныйга әйләнеп кайтты. Бакыр стаканын да без шомарттык. Уттай балкып китте. Азот кислотасы белән кырыена язу да яздык. Башта Вася абзый тәкъдим иткән сүзләрне — «капиталга каршы барган көрәштә эшчеләрнең коралы булды», дип язмакчы идек тә, кире уйладык. Булган хәлне теркәү белән генә чикләндек: «1905 елда гудок завод эшчеләренә стачка башлануны хәбәр итте», дип язып куйдык.
Шуннан бирле аның тавыш биргәне юк. Үзе төзек, бар җире тәртиптә, рычагны тартсаң, гүләп җибәрәчәк.
Хәзер бездә заводка килгән һәр кешегә аның турында сөйлиләр. Бу — традициягә әйләнеп китте.

*Русчадан* **СОЛТАН ШӘМСИ** *тәрҗемәсе*

*Күренекле татар совет шагыйрәсе Саҗидә Сөләйманова егерме еллык иҗат гомерендә бай әдәби мирас калдырып китте. Моны раслау өчен шагыйрәнең «Сабыр канатлары» исемле зур җыентыгына («Шигырь китапханәсе» сериясеннән) тупланган, халык яратып кабул иткән, вакыт сынавын үткән шигырь һәм поэмалары да җитәр иде. Авторның үлем белән көрәш арасында иҗат иткән «Гөлбадран» исемле повестен, «Мәхәббәт сынавы» җыентыгына кергән үзенчәлекле хикәяләрен, сәяхәт язмаларын, балалар өчен язган шигырьләрен, газета-журнал битләрендә чәчелеп яткан күп санлы очеркларын, әдәби мәкаләләрен һәм театр рецензияләрен исәпкә алсак, язучының әдәби эшчәнлегенә торып-торып сокланырлык.*

*Саҗидә Сөләйманова эшләп иҗат итте. Ул гомеренең егерме елга якынын укытучылык хезмәтенә — балалар һәм нефтьче кадрлар тәрбияләүгә багышлады. Аннары — партиянең Әлмәт шәһәр комитеты лекторы, район һәм шәһәр радиотапшырулар редакторы. Халыкара хәл турында заманында аның эчтәлекле лекцияләрен тыңламаган нефтьчеләр, төзүчеләр, колхоз һәм совхоз хезмәтчәннәре Әлмәт районында сирәк калгандыр.*

*«Азат хатын» журналы редколлегиясе члены һәм Әлмәт әдәбият берләшмәсе җитәкчесе буларак, С. Сөләйманова яшь авторларны табу һәм тәрбияләүгә вакытын, көчен кызганмады. Республикабызның төрле якларыннан көн саен килеп торган хатлар, хатка ияреп килгән шигырьләр бервакытта да җавапсыз калмады. Ул аларда хат иясенең йөрәк тибешен тоеп, кулына каләм алып, төннәр буе шулар белән бәхәсләшеп чыга. Аның каләмдәш дусларына, укучыларына язган киңәш-табышка, бәхәскә бай мондый хатларын бергә җыеп (ә бу бик кирәк!) бастырганда, үзе бер китап булыр иде.*

*Халык файдасына үз-үзен аямау, ахыргача янып яшәү — каян килгән бу сыйфатлар язучыга? Бу ургылып аккан ташуның чишмәсе кайчан башлана?*

*Мондый сорауга укучы Саҗидә Сөләймановаының архивында калган «Яңавыл хатирәләре»ннән өлешчә булса да җавап табар дип уйлыйбыз*[1].

## Саҗидә Сөләйманова

# ЯҢАВЫЛ ХАТИРӘЛӘРЕ

Мин Бүә буенда үстем. Сабый чагым — Бүә суында коенып, ташлыгында кызынып, әрәмәсендә бөрлегән ашап йөрү булып күз алдыма килә.

Яңавылның[2] үзендә яшәвемне аз хәтерлим. Тимер юлдан ерак түгел кечкенә агач өй истә. Гөл чүлмәге белән янәшә тәрәзә төбенә утырып, әнкәйләрнең эштән кайтуларын көтүемне хәтерлим. Әткәй белән әнкәй ул вакытта тимер юлда эшләгәннәр. Колхозлашу елларында әткәй, Сөләйманов Гаделша, егермебишменчеләр рәтеннән «Восток» артеле оештыручыларның берсе булган. Яңавыл янындагы Йобанай дигән авылдан берничә гаилә берләшеп, Урадыдан ерак түгел урында җир алганнар, коммуна төзегәннәр. Әйе, башта ул коммуна булып оешкан, «коммуна» сүзе колакка нык кереп калган. Тора-бара Урады игенчеләре белән берләшеп, артель «Юлбаш» колхозына әверелә. Ә «Восток» — колхозның җимеш бакчасы булып кала. Бәләкәй чакта мин ул бакчага барганымны, алма-җиләк ашаганымны хәтерлим. Әткәй-ән-

[1] Кереш сүз авторы һәм шагыйрә архивыннан басылмаган әсәрләрне журналга әзерләүче — шагыйрь Әдип Маликов. Редакция.

[2] Башкортстан АССРдагы район исеме.

кәйләрнең клубта спектакль куюларын, үземнең сәхнәгә менеп, шигырь сөйләвем бүгенгедәй күз алдымда. Бик кечкенә булганмындыр, мине алгы рәттән сәхнәгә күтәреп кенә бастырдылар да, сөйләп бетергәч, янә күтәреп алдылар.

Урадыдан без Сарашты авылына күченеп киттек, аннары Аксәеттә яшәдек. Бу авыллар ул чакта Яңавыл районына керәләр иде. Әткәй колхоз председателе, аннары авыл советы председателе булып эшләде. Тәтешле районы төзелгәч, Райзо мөдире, бераздан район башкарма комитеты председателе булып күтәрелде. Бөек Ватан сугышында катнашты, персональ пенсионер булып, 1958 елда дөнья куйды. Күңелемдә әткәй халыкка хезмәт итүнең тере үрнәге булып яши. Ул үзе кирәк чакта трактор йөртә, кул белән урак ура, колхозчылар белән ярышып печән чаба иде. Ничектер, матур итеп, сокланырлык итеп эшли белә иде ул.

Урадыга мин җәй саен кайтып йөрдем. Анда әнкәйнең әнисе, сеңелләре яшәде. Ураokы елгасы, Бүә буйлары мәңгелек ямь булып күңелдә калган. Олы кешене күмәрлек тирән урыннарда да Бүә төбендәге чуер ташлар асылташлар сыман ялтырап-җемелдәп күренеп яталар, ул елга шундый тонык, шундый тиз агымлы иде — безнең балачак сафлыгына һәм яшьлек омтылышына тиң иде.

Сугыш башланган җәйдә дә Урадыга кайттым. Нәнәйнең төпчек улы Миңнулла Ерак Көнчыгышта хәрби хезмәттә иде, Көнбатышка фронтка узып барышлый телеграммасы килде. Нәнәй ашыгып кына май язып алды да станциягә җыенды, аңа мин дә иярдем. Тәүлек буе төнлә дә йокламый көттек, эшелоннар уза торды, бәләкәй абыйны күралмадык. Нәнәй кучтәнәчләрен сугышка китеп баручы бүтән солдатларга өләшеп бетерде. Ай буе станца юлын таптады нәнәй. Көнбатышка китеп барышлый язган хаттан башка егерме яшьлек Гыйльмуллин Миңнулладан бүтән хәбәр килмәде. Ул хатта «...фашистларны тар-мар итми кайтмабыз» дигән юллар бар иде. Гомумән, хат күтәренке рух белән, җиңүгә нык ышанып язылган иде.

1942 елның җәендә Урадыда өч ай буе колхозда эшләдем. Мин 8 нче классны тәмамлаган идем, җәйге каникулда мәктәп балаларын колхозга эшкә җибәрделәр. 15—16 яшьлек кызлар бер төркем булып эшли идек. Бригадирыбыз Гафифә апа — исеме шулай хәтердә калган — ул безне, ничектер, сөеп-яратып эшләтә, без дә аны бик ихтирам итә идек. Өстән әйтеп оештырылмаган ярыш белән, җыр белән эшләдек. Һәр эшнең үз юлдашлары-ярдәмчеләре була икән. Утауда уенкөлке, мәзәк сөйләү, печән җыюда җыр, уракта — ярыш. Эшкә кояш чыкканчы китәбез, бигрәк тә урак өстендә шулай. Кояш чыгуын кырда каршылыйбыз. Кояш төшлеккә җиткәндә җиңел урдырып киткән арышны көлтәләп, һәр кайсыбыз өч йөз көлтә бәйлибез. Бу — көнлек норма дигән сүз. Аннары сослан ышыгында сөт-катык ашыйбыз, кояш кыздырганда, ял итеп алабыз. Кояш баш өстендә торганда, көлтә бәйләве бик авыр: көлтә бавы шартлап сына, камыл без кебек булып ката, кулны чәнчеп, канга туздыра. Кояш сүрелгәндәй иткәч, янә караңгы төшкәнче 100—150 шәр көлтә бәйлибез, бусы инде нормадан тыш. Кояш баткач, уйсурак җиргә төшеп, җитлегеп бетмәгән арыш урып, яки солы йолкып алабыз да һәрберебез дүрт йөз илле көлтәлек бау әзерләп, сослан астына күләгәгә куябыз. Иртәгә баулар әзер, эш кызурак булачак! Кайтышлый Ураоы елгасы буенда оек-чабаталарыбызны салып, аякларны юабыз, яшел чирәмнән җәяү атлыйбыз. Ачык тәрәзәләрдән урамга яшь бәрәңгеле аш исе, кыздырылган май исе таралган... Нәнәй мине яратып кына битәрләп тә ала: «Нигә шулай караңгыга каласыз, сезне кем мәҗбүрли?» Шунысы әйбәт тә: безне беркем мәҗбүр итми, үзебез эшнең ниндидер кызыгын, ямен табып эшлибез. Ә бәлки, ир-ат сугышка киткәч, эш безнең җилкәдә калды

дип, җаваплылык тоеп эшләгәнбездер. Бу хакта безгә, 14—16 яшьлек кыз балаларга беркем берни сөйләми, әмма бөтенебез моны аңлый. Эвакуацияләнеп килгән гаиләләр, фронттан килгән өчпочмаклы хатлар, үлем хәбәрләреннән хәлнең үтә киеренке булуын күреп, сизеп тора идек. Бергә эшләгән кызлардан Рәшидә, Ләбибә, Уйзат (ул бик моңлы җырлый иде), Зәбидәләр бар. Егет-җиләннән Асаф, Рәшит, Мидхәт. Унынчыны тәмамлагач мин тагын җәй буе Урадыда эшләдем. Бу егетләр сугышталар иде инде. Асаф белән Рәшит кире әйләнеп кайтмадылар. Мин аларның исемнәрен генә беләм, чөнки мәктәптә бергә укымадык, ә авылда фамилия белән дәшү юк. Бригадир Гафифә турында: яшь кенә сөйкемле хатын... Ул безне атнага ике генә күрә — эш биргәндә һәм эш кабул иткәндә. Кешенең өстендә торып эшләтү юк иде. Бәлки шуңа да без ямьле итеп эшләгәнбездер. Хәер, мин унынчыны тәмамлап килгәндә, халык шактый басынкыланган, моңайган (1944 елның җәе иде бу), Гафифә апа да кырысланган иде. Эштән кайтышлый колхоз амбарына кереп, йөзәр грамм пешкән икмәк алып кайта идек. Сеңелем Мәдәния белән эшләп алган шул икмәкне бөтен гаиләгә бүлә идек. Безнең әткәй ул вакытта сугышта иде, нәкъ шул чакларда әнкәйнең сәламәтлеге югалган иде.

Нәнәй вафат булганнан соң, мин Урадыга кыска вакытка гына ике мәртәбә кайтып әйләндем. Беренчесендә әнкәйнең сеңелләре Газизә һәм Газимә апаларым авылда, нәнәйнең өе дә исән иде. Икенчесендә инде ул өйнең урыны да калмаган, алма үләнле өйара аркылы таш юл салынган. Өйнең хуҗасы булып калган Газизә апага Яңавылда казна йортыннан квартир биргәннәр. Газимә апа кызы янына шәһәргә күченеп киткән. Урадыда калган иң якын дусларым — Уралы елгасы белән Буә буйлары — алар да үзгәргән: элекке сафлык, житезлек юк, олыгайганнар, җитдиләнгәннәр, комланганнар димме... Яшь-җилкенчәкнең күңелен әллә кайларга алгысытып, уйнаклап акма әле дигәннәрме — Буәне буып, эшкә җиккәннәр.

Урадыга бәйле истәлекләр «Җир-су» поэмасында бераз чагылган. Ләкин аларны нинди дә булса әсәрдә язып бетерү мөмкин түгел. Буә суының безнең ише вак балаларны иркәләп-шаяртып, еракларга агып китүе, күгелҗем кара бөрлегәннәрнең безнең белән качышлы уйнаулары, кичү аркылы чыгып, Яңавылга алып баручы яшел сукмак... «Сез каласызмыни, без китәбез!» дип, гел каядыр ашыгучы яшел вагоннар!.. Һәрвакыт күңелдә алар.

*19 сентябрь, 1977 ел. Әлмәт.*

* * *

Үземнең мөстәкыйль биографиям кайчан башланды икән? Әткәй тәэсире, аның халык арасындагы абруе һәрвакыт янәшә булгандыр, каршылыкларны җиңелрәк үтәргә ярдәм иткәндер. Авырлыклар күрдем дип әйтә алмыйм. Булганнары вакытлы шикелле, үтә торган шикелле тоелды.

1944 елда унынчыны тәмамладым, авыл мәктәбендә ике ел укытучы булып эшләдем. 1946—50 елларда Уфа пединститутында тарих факультетында укыдым. Сүз арасында әйтим, «марксизм-ленинизм нигезләре»н Уфа университетының хәзерге ректоры Чанбарисов укытты. Сайлаган фәне, ышанычы, логика көче белән бөтен барлыгыңны яулап ала торган кеше. Студентларча яшерен генә мин аңа гашыйк идем, ирләр фәне саналган марксизм-ленинизмны отличнога укый идем. (Безнең курста күпчелек фронттан кайткан яшь офицерлар, алар белән ярышу — ай-һай!)

Институтны тәмамлагач, Әбъялил районында башкорт мәктәбендә бер ел укыттым. 1951 елда Әдипкә кияүгә чыгып, Татарстанга килдем. Минзәләдә Вахитов исемендәге татар мәктәбендә дүрт ел укыттым, анда укытучыларның комсомол оешмасы секретаре булып эшләдем. 1953 елда партиягә кандидат булып кердем, 1954 елдан — партия члены.

1955 елдан — Әлмәттә. Кечкенә нефть техникумында тарих укытучысы, партиянең шәһәр комитетында лектор, Әлмәт радиосының редакторы. 1963 елда беренче китабым чыкты, шул елдан Язучылар союзы члены. Еш кына «ничек яза башладыгыз?» дигән сорау бирәләр. Менә бу юлы съездга баргач та берәү шул сорауны бирде: «Язучыларның хатыннары яза башлый: Рәйсә Ишмуратова, Гөлшәһидә, менә сез. Ничек була ул алай?» Мин ничегрәк җавап бирергә, дөрес тә булсын, шаяру да булсын, дип уйлап өлгермәдем, әлеге мәҗлестә булган Миргазыян Юныс минем урынга җавап бирде: «Гаилә тормышы шундый нәрсә ул, монда шигырь язу гына түгел, әллә нәрсә эшли башларсың». Әчынлап әйткәндә, әдәби атмосфераның тәэсире булмый калмады. Мәктәптә укыганда ук мин стена газетасының редакторы була торган идем, 6—7 классларда әдәби журналның редакторы булдым хәтта. Дәфтәр-дәфтәр шигырьләремне укытучылар алып укып йөрттеләр дә әллә кая куйдылар.

«Профессионал» булып китүемә август аенда бер ел тула. Аңа чаклы олылар өчен дүрт, балалар өчен дүрт шигырь китабым чыккан иде. Русча китап чыгарам дип, Казанга, Мәскәүгә йөри башлагач, эшне калдырырга туры килде. Шушы эшләми торган арада әлек язган әйберләрдән тагын өч җыентык әзерләдем — икесе яңа, берсе «Кызыл каурыйлар» дип аталган сайланма. Яңаны язуга караганда язганны дөньяга чыгару эшләре күбрәк нервыны һәм вакытны ала икән дигән фикергә килдем. Үз-үземә дә таләпчәнлек арта, кешеләрнең дә миңа таләпчәнлеге арта бугай — елдан-ел кыенлаша бара. Әлекке шикелле күргән бер нәрсәгә сокланып, гаҗәпләнеп шигырь чыгарып булмый. Шигырь бер үк вакытта фикергә дә, хискә дә бай булсын. Икесенең берсе җитмәсә, мине инде ул канәгатьләндерми төсле... Нинди дер сәер гадәтем бар: дөнья шаулаткан авторны мин шундук укырга ябышмыйм. Шау-шулар тынгач кына иркенләп укыйм, бу чакта инде миңа бер кем дә үз фикерен такмый төсле, хөкемне үзем чыгарам. Хемингуэй белән шулай булды, Межелайтис белән. Һәр икесе алдында баш иям. Димәк, минем критерийлар җәмәгатьчелекнеке белән тәңгәл килә. Межелайтис минем өчен әле дә яңа. Соңгы елларда үзем өчен тагын бер яңа шагыйрь, димәк, яңа дөнья ачтым: Марина Цветаева. Китабы кулга төшкәнгә чаклы минем аның хакында бер нәрсә дә укыганым юк иде. Бары ике юлын гына ишеттем:

Милый не вечен, но вечен мир.
Не понапрасну служим.

Шуннан эзләп табып укыдым. Фикер һәм хисне укмаштырган яшен ташы. А. Вознесенскийлар яңа сыман тоелган иде, алар Цветаеваны гына кабатлаганнар икән.

Бездә (татарда) хатын-кыз шагыйрьләрне аерым исемлеккә теркәү кагыйдәләшкән. Чын шагыйрьләр рәтендә торырдайлары булмаганнамы? Әллә алар хатын-кызга гына тулысынча аңлаешлымы? Ләкин бит хатын-кыз бөтен укучыларның яртысын тәшкил итә. Ә менә Маринаны мин форма һәм фикер бердәмлегенең көче ягыннан хәзерге күп ир шагыйрьләрдән өстен куям.

Яраткан шагыйреңә ирексездән иярү була торгандыр. Сибгат Хәкимгә дә, Хәсән Туфанга да ияреп алдым бугай. Аз гына. Гомумән, мин иярү ягында түгел.

*23 июль, 1974 ел. Әлмәт.*

## Сиңа дошман кирәк булса

*Шагыйрь дустыма*

Дошманың бик усалмыни, дустым,
Дошманыңа атап башладың
Әсәреңне... Әйткән сүзләрең дә
Хәтерләтә вулкан ташларын.

Дошманнарсыз, әйе, кызык түгел,
Гел бер төрле яшәп туясың.
Кайчак — җилне кылыч белән кискән
Дон-Кихотка охшап куясың.

Дон-Кихотның инде, ир намусын
Яклап, туң дөньяга янавы...
Дошманнарны дуслар арасыннан
Эзләү дә бит түгел яңалык.

Дуска тибеп калу кыен түгел,
Дус бит сындыралмый сыйракны.
Якыныңны чит-ят итеп күрү —
Күрә белмәгәннән еракны.

Кешеләрдән качып уйнаганда,
Баянда да байтак фальшь китә.
Баш китәрдәй эшләр булмаганда,
Вак-төяген дуслар фаш итә.

Сиңа дошман кирәк булса, дустым,
Агу чәчмә сулар һаваңа.
Ерак дошманнарга буй җитмәсә,
Бар бит алар безнең арада:

Дан-опиум, ялагайлык, яла...
Чистартмасак эчтән вөҗданны,
Җир йөзендә безгә җиңел булмас
Җиңеп чыгу тышкы дошманны.

## Юлларыңда юлдаш булыйм

*Җыр*

Атландык икәү чаптар атларга,
Язгы елгалар шаулап акканда.

Куллар бирештек, сүзсез килештек
Тормыш юлыннан бергә атларга.

Тормыш юлын бергә үтәргә,
Аерылышкан чакта күтәргә.

Җилдән, давылдан, дустым, арала,
Кеше сүзенә, дустым, карама.
Күңел киң булса, уйлар бер булса,
Җил дә үтәлмәс безнең арага.

Кеше сүзләренә карама,
Җил дә үтмәс безнең арага.

Булыйм юлдашың, юллар ярганда,
Булыйм сердәшең, уйга талганда.
Дуслык чыныга авыр юлларда,
Дуслар сынала ялгыз калганда.

Кайгың булса, ялгыз күтәрмә,
Шатлыгыңны ялгыз үткәрмә.

●

Биюченең йөрәгендә
Җигүле атлар бардыр...
Калдырма җиде ятларга
Яратып сөйгән ярны.

Сыздыра, әй, гармуннары,
Йөрәкләргә ут каба.
Егет ничек түзеп торсын,
Кызлар чыккач уртага.

Гөл сабагы — буй-сыннары,
Айдай нурлы йөзләре.
Уйландыра, моңландыра —
Җырлый Әлмәт кызлары.

................

*Шушы көннәрдә әдәбиятыбызның ике күренекле шәхесе — ике зур язучысы: Гадел Кутуйга һәм Риза Ишморатка 80 яшь тула. Бу уңай белән без Риза Ишморатның Гадел Кутуй турындагы истәлекләрен басабыз. Истәлекләр ике язучының тормыш һәм иҗат юлын күзаллау өчен генә түгел, ә 20—30 еллар тормышын, иҗади атмосферасын хәтердә яңартуы, аңа яңа детальләр өстәве белән дә кызыклы.*

## Риза Ишморат

# ЯШЬЛЕГЕБЕЗНЕ САГЫНЫП



*Риза Ишморат.*

### Беренче танышу

1923 елның август ахырлары. Ниһаять, мин атаклы шагыйребез Тукайның: «И Казан, нурлы Казан»,— дип мактаган шәһәре — Казан каласында. Тукай бүген дөньяда юк. Ләкин аның мине балалык көннәремнән үк сихерләгән шигырьләре исән, күп кенә дусишләре — Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал исән, атаклы әдип Галимҗан Ибраһимов, революция белән бергә туган яшь шагыйрь Һади Такташ яши Казанда. Башка әдипләр, шагыйрьләр, артистлар, кыскасы, әдәбият, сәнгать дөньясы ашкындырып алып килде мине монда.

Казанда мине Җир төзү техникумының тулай торагына урнаштыру белән бергә җир эшләре комиссариатының хәзерге Ленин урамында урнашкан ашханәсенә беркеттеләр. Икенче көнне үк Казан урамнары, мәһабәт йортлары, аеруча университет бинаралы белән таныша-таныша барып, күтәренке рух белән ашханәгә килеп кердем. Керсәм, ике егет өстәл янында тордылар да, көлешә-көлешә сөйләшеп, ишеккә таба киләләр. Берсе озын гына буйлы, кара чәчле, йөзе, күзләре, ап-ак тешләре, үзләреннән-үзләре көлеп ниндидер бер яктылык бөркеп торалар. Икенчесе, тәбәнәк буйлы, юка сөякле, шулай да гаҗәеп чибәр, сөйкемле, нәзакәтле егет... Чү! Монысы бит Уфада минем белән бергә укыган, комсомолга кергән егет. Уфаның барлык тамашачыларын таң калдырып, декламацияләр сөйләп йөргән Габдулла Вил-

данов, кызлардан бигрәк әдәбиятка гашыйк егет. Шигырьләр, әдәби парчалар яза, сәхнәгә гашыйк, бөтен дөньяга гашыйк. Аны күрү белән мин бик шатланып:

— Габдулла, син дә Казанда димәк, хәзер?

— Син Казанда булгач, нигә миңа да Казанда булмаска ди.— Без көтелмәгән бу очрашудан шатланып, якын дусларча каты итеп кул кысыштык. Ул миңа үзенең юлдаш дустын тәкъдим итеп:

— Таныш бул, бу иптәш бүгенге әдәбиятыбызны әйдәп баручыларның берсе — шагыйрь Кутуй була. Укыганың бардыр?

— Кутуй?! Юк, кызганычка каршы, укыганым юк — дим, Кутуйга кул биреп.

— Зарар юк, укыр әле, укыр,— ди Кутуй, ялкын күзләрен текәп һәм кулымны каты гына кысып. Шул арада Габдулла шаяра-көлә мине дә Кутуйга тәкъдим итеп:

— Шагыйрь һәм артист Риза Ишморат,— ди.

— Шаяртма! — дим бераз уңайсызланып.

— Бүген әле чынлап ук шагыйрь дә, артист та булып өлгереп җитмәгәнсең икән, бер дә борчылма, Казан ул, җаным, өлгертәчәк сине. Шагыйрь итеп тә, артист итеп тә, теләгең булып, бик тырышсаң әгәр, нинди булса да берәр өлкәдә мөгезле шайтан итеп тә.

— Мөгезле шайтан?!

— Курыкма, дус кеше,— ди Кутуй,— Казан кадәр Казанга килгәнсең икән инде, нинди булса да бер өлкәдә мөгез чыгармыйча булмый.



*Гадел Кутуй. 1925 ел.*

— Безнең җитәкче абзыйлар театрдан да бигрәк безгә бүген җир кайгысы әһәмиятлерәк дип, мине җир төзү техникумына җибәрделәр,— дип, ашханәгә күзләремне төшереп алдым.— Алар да дөрес куя мәсьәләне. Җир, икмәк — иң кирәге. Аштан, икмәктән башка дөньясы да дөнья түгел.

— Исеңә алып куй, Риза дус,— ди миңа Габдулла,— бу сүзләрне сиңа, ни җитте кеше генә түгел, татарның мәшһүр футурист шагыйре Кутуй үзе әйтә.

— Футурист?!— мин күзләремне мөмкин кадәр тулырак ача төшеп, Кутуйга тагын бер кат карап куям.— Футурист?.. Анысы кемнәр була инде? Футурист... Футурист... Үземнең кайдадыр укыган сүзләрне хәтерләргә тырышам.

— Кемнәр дип, Мәскәүдә — Маяковский, Асеев, Казанда — Кутуй, Сирин һәм мин...

Барыбыз да бер-беребезгә карашып көлеп җибәрдек.

— Әдәбиятта алга, киләчәккә карап эш итүчеләр. Шигырьдә, театрда, гомумән, сәнгатьтә иске алымнарны җимереп, яңаны эзләүчеләр. Бүгенге йөгерек көннәрнең эчтәлеген, заман таләп иткән проблемаларны халыкка үткенрәк, үтемлерәк итеп иреештерүдә яраклы форма табу...

— Реализмны читкә бәреп ташлапмы?

— Әйе, иске реализмны,— диде Кутуй.

— Реализмның яңа формасын табу,— дип өстәп куйды Габдулла.

— Әйе, әйе, яңа формасы... Яңа дөньяның, яңа эчтәлегенә хасрак яңа реализм,— ди-ди сөйләп китте Кутуй. Ашкынып, ялкынланып, үзләренең футуристлар группасына тартып, иптәшлеккә, хезрхаһлыкка мине дә кушарга теләгәндәй. Шундый уй башыма килергә дә өлгермәде, Кутуй сөйләүдән тукталып, миңа карап елмаеп куйды да:

— Бәлки әле бара тора син үзең дә безгә теләктәш булырсың!
— Сезгә?.. Кемнәргә, футуристларгамы?
— Ничек дип әйтим... Футуристларга дисәм, куркырсың, мин үзем дә ул сүзне өнәмим, Габдулла да шулай ук, бу сүз-терминның халыкка аңлашылмаганы өчен генә түгел, без эзләгән юлны дөрес үк итеп ачмаганы өчен һәм, бигрәк тә...— Кутуй миңа футуризм турында, ул елларда киң җәелеп киткән төрле әдәби агымнар турында гаҗәеп бер кайнарлык, ашкыну белән озын итеп сөйләргә теләгән иде ахры, ләкин Габдулла аңа ирек бирмәде:

— Кутуй җаным, син танышыр-танышмас үк Ризага лекция укырга тотындың. Ярый ла синең белән минем тамак тук, аның бәлки эчендә бүреләр улый торгандыр, ашасын ул, туйдырсын тамагын, сөйләшер өчен безгә алда да көннәр бар. Син дә, мин дә Казанда төпләнгән. Бер килгәч инде ул да монда калачак, без әле аны үз ягыбызга аударырга өлгерербез.

Миңа Кутуйның сүзләрен тыңлау, аның белән танышу никадәр кызыклы һәм күңелле булса да, ашханә ябылганчы ашап-эчеп алу бик мөһим иде. Шуңа күрә Габдулла дустымның тәкъдимен бик хупладым. Алдагы көннәрдә шушы ашханәдә үк күрешергә сүз куешып, җылы гына аерылыштык. Дөресен әйтим, якын дустым Габдулла Вилданов һәм Гадел Кутуй белән очрашу көтелмәгән зур бәхет булды. Аеруча Кутуй үзенең җитез, өлгер, гаҗәеп мөлаем характеры, киләчәккә һәм яңалыкка ашкынулы омтылышы белән миндә онытылмас якты тәэсир калдырды. Алар китәр китмәс үк ашарга утырдым. Ләкин өстәл янында аш ашаудан бигрәк дустым Вил Уразай һәм яңа танышым Кутуй турында уйладым. Нинди ялкынлы егетләр! Алар белән аралашып, дуслашып яшәсәк, бергә-бергә яңа дөньяга бару күңелле һәм нәтиҗәле булачак. Ул көннәрне без — яшьләр, башлыча комсомоллар, бөтен эшебезне иң элек дөнья — коммунизм төзүгә юнәлтә, шул турыда уйлый, һәркайчан, һәр җирдә бик кайнар һәм горурланып сөйләшә идек. Димәк, Казан миңа күңелле дөнья вәгъдә итә. Яңа, якын дуслар, Кутуй, Уразай кебек бөтен уйларын яңага тебәгән энтузиастлар. Әгәр тормыш юлында алдагы көннәрдә дә шундый кешеләр очраса, барыр юлларым бәхетле булачак. Шулай уйлана-уйлана ашымны ашап ашханәдән чыгып китүемне дә хәтерләмим.

Алдан ук шуны әйтәсем килә:

Барыр юлларым бик сикәлтәле булды. Дусларым, туган-тумачаларым, гомумән, илебез халыклары белән беррәттән авыр, бик авыр юллар үтәргә туры килде. Яшьлек чорымның иң матур, күңелле минутларын, кайгылы-хәсрәтле минутларымны уртаклашкан, кирәк чакта соңгы тиеннәрне бүлешкән дусларым аз булмады. Шулай да ялкын йөрәкле, хәрәкәтчән, яңаны эзләүче, көләч Кутуй аерылып тора.

Маяковскийның Кутуй тәрҗемә иткән «Сул маршы» ошый иде безгә. Без, театр техникумы укучылары, 30—35 кеше аны бергәләп кычкырып укый идек. Без аны техникумыбыздагы ачык сәхнәдә дә, Татар дәүләт театрында да, университетның актлар залында да укыйбыз, хәтта урамда да.

«Сул марш» безнең өчен кумәк декламация гына түгел, алга — якты, яңа дөньяга бердәм атлап барганда яңгыраган чакыру тавышыбыз да. Ул дәрт бирә безгә, яшәү көче. Безгә генә түгел, тыңлаучыларга да. Ул үзебезгә ошамаган әсәрләргә, спектакльләргә карата протестыбыз да иде.

Бервакыт Татар дәүләт театрында (ул чакта әле Академия театры дигән исем бирелмәгән иде) «Пәри кызы» дигән спектакльне карагач, без — ун-унбиш егет (кызларыбыз да бар иде ахры) «Сул марш»ны театрның тамаша залыннан — балконнан торып укыдык. Кумәкләп, мөмкин кадәр кычкырыйбрак. Тамашачылар аптырабрак безгә карап торгач, арадан берәү: бу егетләр котырганнар ахры — дип әйтеп тә куйгандай булды. Әйтсә бит, безнең аңа исебез китмәде. Безнең протестыбыз — протест. «Пәри кызы»— экият. Ә заман яңа эчтәлек таләп итә, яңа форма...

Бүген менә күп еллар узып, гомеремнең соңгы дистәләренә баскан чорда үземнең якын дусларымны, бигрәк тә яшьлек чорымдагы әдәбият-сәнгать әйләнәсендәге дусларымны барлап карыйм. Алар: Әхмәт Фәйзи, Габдулла Уразай, Кутуй, Туфан, Такташ, Минский, Әхмәт Исхак, Муса Җәлил, Әсгать Мәҗит, Хәким Сәлимҗанов, Са-

лих Сәйдәш, Таҗи Гыйззәт, Ширияздан Сарымсаков, Кәрим Тинчурин, Җәүдәт Фәйзи, Габдрахман Әпсәләмов, Газиз Иделле, Фатих Кәрим, фронтташ дусларым Гали Хуҗи, Госман Бакиров, Мөхәммәт Садри, Мостай Кәрим, Гыйлемдар Рамазанов һәм... аларны әле тагын да өстәргә мөмкин. Ләкин шулар арасында нинди генә очракта да минем өемә килеп, яки мин аларның өйләренә барып соңгы телемнәребезне бүлешкән, иҗат шатлыкларыбызны, уй һәм хисләребезне, алдагы планнарыбызны да уртаклашучылары дүрт-биш кенә кеше. Аларның берсе Кутуй, Гадел Кутуй. Ул гаделлеккә нигезләнгән яңа, матур тормышны, киләчәктә туар яңа кешене — үзебезне, улларыбыз, оныкларыбызны күз алдына китерә генә түгел, аны булдыру өчен бөтен чараларны күрә, эзләнә, яңадан-яңа чаралар табу өчен тырыша. Кайчакта абынып сөртенеп тә куя, ләкин йөрәге саф, алган якты идеалына, Ленин күрсәткән изге юлга, һәрвакыт турылыклы. Көчле рухлы чын кеше, әдәбият-сәнгать, гомумән идеология фронтының иң актив эшлекләреннән берсе. Ул һәрвакыт актив хәрәкәттә — иҗат итә, оештыра, укый, эзләнә, тикшерә, төрле катлам кешеләр белән аралаша, сәнгатьнең бер төре дә аның игътибарыннан читтә калмый. Бер карасаң, ул театрда спектакль карый, концерт тыңлый, үзенең фикерен әйтә, туры әйтә, я газетага язып чыга. Я әдәби кичәдә үзенең шигырьләрен укый, дусларының иҗатын тыңлый. Әдәбият



*Утырганнар — сулдан уңга: Риза Ишморат, Гадел Кутуй, Хәсән Туфан. Басканнар — Әсгать Фәхри, Әсгать Мәҗит.*



Риза иптәш Ишморат! Биредәгеләр татарның Октябрь сораган сәнәгъ нәфисәсен торгызу өмәсенә — иртәгәләргә сул белән батыр атлап баручылар. Биредәгеләр бер-берсенә шигырь белән, сәхнә белән шефлар. Минем йөрәк шулай бергә барыш маршына бәрә. Болар мәнә шул көннәрнең истәлеге сиңа.

Х. Туфан. 4/IX-25.

турында диспут, фикер алышу, бәхәсләр булса, ул анда иң актив катнашучы, күп чак аларны оештыруда үзе чаралар күрә.

Кутуй, Такташ, Кави Нәҗми, Туфан, Толымбай, Әхмәт Исхак, Г. Ризван, Фәтхи Бурнаш, Илгизәр, Сирин, Гомәр Гали, Закир Гали, М. Парсин, Галимҗан Нигъмәти, Ф. Мөсәгыйть, Фаик Таһиров, Әсгать Мәҗит, Шәрәф Мөхмүт һ. б. һ. б.— бу чордагы әдәбият-сәнгатьтәге хәрәкәтнең уртасында торып иң актив катнашучылар болар... Береннән-бере усалрак сугыш чукмарлары. Берәүләр иске алымнарны яклап реализм ди, берәүләре имажинизм я футуризмны, конструктизмны, кайберәүләр символизм, я романтизмны алга сөрәләр. Ду-у килеп сөйләшү, бәхәс, кычкырыш, шау-шу һич тукталып тормый. Дөреслек өчен шуны әйтергә кирәк: бәхәс алып баручыларның барысы да диярлек бер идеал өчен — яңа тормыш, социализм, коммунизм өчен, Совет дәүләтен яклау, аны ныгыту өчен дип көрәшәләр. Асылда бөтенесенең дә реализмнан артык ераклашасы килми. Һәркайсы диярлек үз юлларына якынрак реализмны, аның яңарак бер чагылышын эзли. Яңа реализм, диалектик реализм, конструктив реализм, социалистик реализм, коммунистик реализм һ. б.

Билгеле инде, мин үзем дә әдәбият һәм театр өлкәсендә эшләргә әзерләнүче кеше һәм кайбер драма әсәрләре язган кеше буларак бу шау-шулы бәхәсләрнең уртасында — Кутуй, Габдулла Уразай, Әсгать Мәҗитләр белән бер сафта булдым.

...Без үзебезне футуристлар дип түгел, Мәскәүдә Маяковский җитәкчелегендә төзелгән Левый фронт — Леф оешмасы үрнәгендә Сул фронт — Сулф, Сулфчылар дип йөртә идек.

Театр техникумында безне әдәбият дәресләреннән укытучы, барыбызның да хөрмәт иткән укытучыбыз атаклы әдип Фатих Әмирханны төрле урыннарда үткәрелә торган әдәби бәхәсләр вакытында бер җирдә дә очратмадым. Хәер, ул аяклары зәгыйфь булганга, үзенә махсус ясалган коляскада гына йөрегәнгә, андый урыннарга бармый иде. Ләкин шулай да барлык әдәби агымнар, бәхәсләр белән танышып бара. Татар әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге бәхәсләр белән генә түгел, рус һәм башка милләтләрдәгеләре белән дә танышып бара иде. Дәрес вакытында әдәбияттагы яңа агымнар турында сөйли һәм үзенең реалистлар позициясендә торган язучы икәнен әйтә, футуристлар белән имажинистларны нык тәнкыйтьли, бу агымнарның безнең тормышыбызга чит икәнен һәм шуңа күрә дә аларның вакытлы булганын, иртәме, соңмы аны яклаучыларның реализм позициясенә басачакларын әйтә. Кайвакыт дәресләрен, без марксист әдипләр реализмны яклыйбыз, дип башлый иде. Укучыларның сорауларына тулы җавап бирә, аның үзе белән бәхәсләшеп үз фикеребезне әйтүебезне бик ярата, безне ышандыру өчен бик тәфсилләп, төрле дәлилләр китереп сөйли, кайчак үткен — сатирик алымнар да куллана. Мәсәлән, футурист һәм имажинистлар турында сөйләп, ул «Кутуй иптәш белән Нәҗми иптәшләрнең әсәрләре, шулай ук үзләре дә миңа, Казанда революциягә кадәр яшәгән Мөхәммәтҗан атлы килде-китте кешене хәтерләтәләр», ди. Мөхәммәтҗан үзенең муенына буш калай банкалар, төрле шалтыравыклар тагып, урам буйлап, мәзәкләр, такмаклар сөйлисөйли, кешеләрне көлдереп йөри торган иде. Трамвайга утырса, кешеләр утыра торган яктан түгел, киресенчә, алар төшә торган яктан утыра торган иде. Үзләренең баскыч-баскыч итеп, нормаль акыллы кешеләр ачык аңламый торган шигырьләре белән футурист Кутуй иптәш белән имажинист Нәҗми иптәшләр, минемчә, әнә шул Мөхәммәтҗанга охшыйлар, ә менә безнең реалист язучылардан Кечкенә Җәлил имзасы белән яза башлап, хәзер инде Муса Җәлил дип кул куя башлаган шагыйребез бар. Яшь әле ул. Казанга килгәненә дә нибары бер-ике генә ел. Ә язганнары менә дигән шигырь. Реалистик алым белән язылган, Тукайча. Шигырьләренең теле дә матур, әйтергә теләгән фикере дә ачык, рәхәтләнеп, тәм табып укыйсың. Аның киләчәге дә өметле.

Мин классташым Нәҗиб Касыймов белән икәүләп Фатих абзый фикерләренә каршы килеп, безнең белән дусларча аралашып йөри торган Кутуй шигырьләрен яклап карасак та, фикерләребезне дәлилләбрәк, тирән мәгънәлерәк сүзләр табып укытучы абзабызны ышандыра алмадык.

Мин ашкын йөрәкле, бу көннәрдә инде якын дустым булып киткән Кутуйны бик ярата, хөрмәт итә идем. Шулай ук миңа үзенең тирән эчтәлекле хикәяләре, «Яшьләр» кебек пьесасы, аеруча «Фәтхулла хәзрәт» кебек оригинал повесте белән күңе-

лемне яулаган укытучыбыз Фатих Әмирхан да бик якын һәм хөрмәтле кеше иде. Аның дәресләрен мин түземсезлек белән көтеп алам. Аны һәрвакыт диярлек каршылап, тарантастан күтәреп алып, классыбызга кадәр китереп кафедра артындагы урындыкка утырта идем. Шул күтәреп килгән өч-дүрт минут эчендә, аның үзе белән генә, кызык-кызык әңгәмәләребез дә булгалап ала иде. Ул безгә атаклы татар әдипләре, шагыйрьләре турында сөйли. Алар белән үзе якын аралашып яшәгәнгә, аларны һәр яктан яхшы белгәнгә бик кызыклы итеп тасвирлап сөйли, без йотылып тыңлый идек. Бер көнне ул безгә Тукай һәм Сәгыйть Рәми дигән темага инша яздырды. Без әлбәттә бик тырышып яздык иншаны. Минем бер дәфтәрне тутырып ук язган иншама: «Мәүзугны бик дөрес аңлап язылган» дигән һәм симез генә итеп бик яхшы билгесе куйган, Фатих Әмирхан, дип имза салган. Аның шундый билгесеннән минем башым күккә тиде билгеле. Ачык сиздем: футуристларны яклап маташкан бу егеттән адәм рәтле кеше чыкмас, мөгаен, дип уйлаган укытучыбызның да миңа карата фикере яхшы ук үзгәрде. Бер көнне үзен күтәреп барган арада миңа сорау бирә:

— Ризә туган, сез бу котырганнар арасына (Кутуйны гына түгел, техникумда ул чорны хөкем сөргән Сул фронт җитәкчеләре Ярослав Гамза, Борис Симолин, Константин Чеботаревларны да күздә тотып) ничек килеп эләктегез?— ди.

Нәрсә дип җавап бирергә дә белми аптырап барган арада тагын бер сорау биреп «кайларда укыдыгыз?»— ди. Мин аңа Сараш авылында Шәриф һәм Сәгыйть Сүнчәләйләрдән, аннан соң Уфада Госмания мәдрәсәсендә укыганымны әйткәч:

— Шулайдыр шул, шулайдыр,— дип куйды, миңа ягымлы гына караш ташлап. Бераз тын баргач:

— Хәер, сез бу футуристлар йогынтысыннан тиз котылырсыз,— дип уйлыйм...

— Фатих ага, без футуристлар түгел, без Сулфчылар...

— Барыбер. Сулфчылар да реализмнан яхшы ук ерак торалар. Кутуй да, ул идеал итеп санаган Маяковский да, башкалар да, хәер, аек акыл белән карап яшәгән барлык язучылар һәм театр әһелләре кайчан да булса бер реализм юлына басачаклар,— диде Фатих ага үз фикеренең хак икәнлегенә нык ышанып.

Миңа гына әйтми, класста дәрес вакытында да сөйли иде ул бу сүзләрен. Революциягә кадәр күп еллар элек ул Тукай, Г. Камал, Галимҗан Ибраһимовлар кебек прогрессив караштагы торып, революциягә хәерхаһ булган әдип үз фикере өчен актив көрәш алып бара иде.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге агымнарга карата Фатих ага Әмирхан карашында, билгеле зур дөреслек бар иде. Мәгълүм булганча, утызынчы еллар башында Сулфчылар да, имажинист һәм символистлар да, РАПП, ТАПП һәм шуның кебек төрки исемнәрдә яшәгән башка әдәби оешмалар да партиябезнең Үзәк Комитеты карары нигезендә бер исем — Совет язучылар союзы — дигән исем белән йөртелә башлады. Иҗат методында да бер метод — социалистик реализм методы нигез итеп алынды. Дөрес бу Фатих ага әйткән иске реализм түгел, яңа тип реализм, социалистик реализм иде. Шулай да реализм иде. Без партиянең бу карарын зур канәгатьләнү белән, шатланып кабул иттек. Бу чорда актив иҗат итә башлаган кешеләрнең берсе Гадел Кутуй булды. Ул социалистик реализм нигезендә «Солтанның бер көне» әсәрен һәм атаклы «Тапшырылмаган хатлар» повестен язды. Иҗатында иң күренекле урыннарның берсен алган «Тапшырылмаган хатлар» аңа зур дан китерде, әдәбиятыбызның классиклары белән бер сафка бастырды.

## Казанда Маяковский

1928 ел. Җәй. Урамнарда бер генә сүздән торган афиша —«Маяковский». Хәрефләренең һәркайсы ярты метр чамасы. Урамның икенче ягыннан ук күзгә ташлана. Димәк, Казанга зур кунак килә. Маяковский — олы шагыйрь. Шигырьләре — яшен уты, бомба. Ә дусларга — чакыру авазы. Яктыга, яңа дөньяга.

— Кутуй белә микән? Әллә өенә барыргамы?..

Һи-и, үзем дә инде. Кутуй булып Кутуй булсын да Маяковскийның киләсен белмәсен имеш. Уйлана, уйлана укып, афишадан күземне алырга өлгермәдем, янымда

Кутуй басып тора, миңа караган да елмая.— Я, ничегрәк каршы алабыз шагыйрь дустыбызны?— ди.

— Ничегрәк дип, дус икән, димәк дусларча. Чәйгә чакырабыз. Ничек диләр әле бездә? Такта чәем, якты чыраеммы?

— Шул гынамы?

— Чәй белән якты чырайдан зуррак нинди хөрмәтебез бар?.. Хәер син Маяковскийның иске танышы. Үткән ел килүдә «Сул марш» шигырен татар телендә укып үзеннән рәхмәт алган кеше.

— Онытмандыр да инде ул аны.

— Онытамы соң! «Казан» дигән шигырендә дә сиңа өч-дүрт юлын багышлаган ич.

Уйный-көлә барган сүзебез җитди төс алды һәм без Маяковскийны ничек каршы алу турында төрле планнар кордык.

Ниһаять, без түземсезлек белән көтеп алган ул сәгатьләр дә килеп җитте. Кич. Татар дәүләт академия театры. Маяковский шигырьләрен үз авызыннан ишетергә теләүчеләр белән зал шыгрым тулы. Тамашачылар арасында Маяковский шигырьләрен бик нык яратучылар да, аның шигырьләре шигырь түгел, алар революцион лозунгларга охшый диючеләр дә аз түгел. Без, аның иҗатын тулысынча хуплап, шигырьләрен яратучы яшь язучылар, аеруча дулкынланабыз. Маяковскийны хөрмәтләп көчле кул чабулар белән каршы алырга җыенабыз. Үзебез генә түгел, күп кенә яшьләрне, студентларны да аны алкышлап каршы алырга өндибез. Кутуй бу эштә аеруча активлык күрсәтә. Зал гөр килә. Кайберәүләр Маяковский сәхнәгә чыгу белән үк сызгырырга җыена. Шигырь укыгач та «Долой!» дип кычкырмакчы, сызгырмакчы булалар. Янәсе аның иҗатына протест белдерәләр. Ә без андыйларга каршы көчле алкышларыбыз белән отпор бирергә һәм: «Браво! Бис, Маяковскому!»— дип, йөзләгән кеше бердәм кумәк тавышыбыз белән ул бугаз ертучыларның тавышларын күмәргә әзер торабыз. Без сакта. Менә пәрдә ачылды. Зур, зур адымнар белән атлап сәхнәгә мәһабәт гәүдәле Маяковский чыкты. Зал атаклы шагыйрьне алкышлар белән күмде. Ул залны үткен күзләре белән сөзеп: «Кемнәр анда атлый уң белән? Яле, Сул белән!— дигәндәй, карап чыкты да тамашачыларга баш иде. Кемдер берәү «Долой!» дип кычкыра башлаган иде, икенче берәү шап итеп аның авызын томалады. Залда тик ыг-г дигән гырылдау гына ишетелеп калды. Юк, берәү дә сызгырырга батырчылык итмәде.

Менә Маяковский шигырьләрен укый.— «Фининспектор белән сөйләшү», «Совет паспорты», «Сул марш», Сергей Есенинга багышланган шигырь һ. б. Шундый итеп укый, укый түгел, көр тавыш белән шундый оста итеп сөйли, тыңлаучыларның йөрәген тетрәтә. Бу минутларда залда утыручылар, барысы бер кешедәй булып, бөтен уй һәм хисләре белән бары тик Маяковскийның тылсымлы иҗаты белән генә яши. Уку тәмамлангач, кемнеңдер әче итеп сызгыруы да көчле гөрелте, алкышлар, «Браво! Урра!» — дигән тавышлар эчендә югалып калды.

Владимир Маяковский!..

Юк, заманыбызның талантлы шагыйре генә түгел, гаҗәеп көчле, музыкаль тавышка ия булган һәм һәр җөмләсе, һәр сүзенең мәгънәсен бөтен тирәнлеге, нечкәлеге белән тыңлаучыларга ирештерә ала торган оста артист та икән. Минем үз гомеремдә Казанда, Ленинградта, Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә Маяковский шигырьләрен зур осталык белән укыган бик күп атаклы артистларны тыңлаганым булды. Ләкин аларның берсе дә миндә Маяковский үзе укыган кадәр көчле тәэсир калдыра алмады.

Маяковский үткәргән кичәнең иң кызыклысы сораулар һәм җаваплар өлеше булды. Ә Кутуй белән минем өчен һәм татар Сулфчыларының Кутуй кебек үк куәтле локомотивы булган шагыйрь Хәсән Туфан өчен дә иң күңеллесе Маяковскийның безгә чәй мәҗлесенә кунакка килүе булды. Чакырдык Маяковскийны, үзебезгә, Сулфчылар янына. Татар театр техникумының уку-укыту эшләре мөдире Б. Н. Смолин булмәсенә. Көтәбез. Көтүчеләр, бүлмә хуҗасыннан тыш художник-педагог К. К. Чеботарев, педагог И. Г. Ингвар, аның хатыны артистка Н. Володина, яшь язучы Г. Минский һәм тагын бер ике кеше. Килерме Маяковский, юкмы? Аны үзләренә чакы-

ручылар без генә түгел бит. Югары уку йортлары, төрле оешмалар, редакцияләр барысы да үзләренә тарта. Ә без монда кечкенә бер төркем. Хәер, без бит Сулфычылар. Маяковскийның үзе шикелле үк әдәбиятта, театрда гомумән сәнгатьтә революцион эчтәлек, социалистик эчтәлек өчен көрәшүче һәм шул эчтәлеккә лаек яңа форма эзләүчеләр. Димәк, теләктәшләре, соратниклары аның. Килергә тиеш һәм ул килде дә.

Маяковскийның олы, мәһабәт буй-сынына димме, әллә шатлыгыбыз бик зургамы булмабез кинәт тулып ук киткәндәй булды. Маяковский ишектән керә-керә үк үзенең көр тавышы белән «Исәнмесез, дуслар!» дип барыбыз белән дә кул биреп исәнләшеп чыкты. Аның белән бергә килгән Кутуй безне таныштыра барды. Әңгәмә бик кызык, җанлы һәм күңелле булды. Симолин белән Кутуй Маяковскийны Казандагы әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге яңалыклар белән таныштырдылар. Маяковский үз нәүбәтендә безне Мәскәүнең әдәби яңалыклары һәм үзенең яңа иҗат планнары белән таныштырды. «Кандала» исемле яңа сатирик пьеса тәмамлаганын һәм аны Э. Мейерхольд театры, Мейерхольдның үзе сәхнәгә куячагын әйтте. В. Каменский, Н. Асеевларның яңа иҗатлары турында сөйләде. Яшьләрдән Семен Кирсанов дигән шагыйрьнең нык кына күтәрелеп килүен, әйбәт кенә яңа шигырьләр иҗат итүен сөйләде. Безнең янда ул үзен искиткеч гади, күптән үк таныш булган якын дуслары арасында утырган кебек тотты. Без олы кунагыбызны куе итеп ясалган чәй, шакмаклы шикәр һәм ак күмәч белән сыйладык. Маяковский белән бергә үткәрелгән әдәбият һәм сәнгать турындагы бу әңгәмә мәҗлесе минем тормыш юлындагы иң күңелле хатирәләрнең берсе булып калды.

Минем генәме? Түгел билгеле. Кутуй өчен, Туфан һәм Минский өчен дә, шулай ук Симолин һәм Ингвар өчен дә бу шулай иде. Һәм без асылда бу истәлекле очрашу өчен, иң башлап Маяковскийның татар дөньясындагы беренче шәкерте Гадел Кутуйга бурычлы идек.

...1930 ел. 14 апрель.

Татар Дәүләт Академия театрының тамаша залы. Бу көннәрдә мин Татарстанда сәнгать эшләре буенча эш алып баручы җаваплы кеше буларак, спектакль карыйм. Бик бирелеп, кызыксынып. Кемдер әкрен генә килеп, нидер әйтергә теләп ахры, җилкәмә кагылды. Борылып карасам, башын иебрәк Кутуй басып тора. Шомлы гына пышылдап әйтә бу миңа.

— Чыгыйк әле,— ди.

Нәрсәгәдер бик нык борчылган ахры. Спектакль барган минутларда да залга кереп мине алып чыгарга теләвенә аптырабрак урынымнан кузгалам. Тамашачыларны артык борчымас өчен, әкрен генә басып, тиз-тиз генә ян ишеккә килеп, залдан чыгабыз. Чыгабыз һәм, Кутуй калтыранган тавыш белән миңа коточкыч хәбәр әйтә.

— Маяковский фаҗигале төстә һәлак булган,— ди.

Мин хәбәрне ишетеп тетрәнеп китәм.

Юк! Бу хәбәргә ышанасы килми. Ышанасы килми. Шундый оптимист, тормышка гашыйк кеше, бөтен көчен Совет дәүләтен ныгытуга, коммунизм төзү эшенә багышланган шагыйрь, бөек идеал өчен көрәшүче, көчле рухлы кеше...

— Сәбәбе нәрсә икән?— дим Кутуйның күзләренә карап.

— Әйтә алмыйм, бәлки иртәгә радиодан тулырак әйтерләр,— ди Кутуй.

— Ул бит, моннан ел ярым элек кенә нәкъ менә шушы ук театр сәхнәсеннән Сергей Есенинга багышланган шигырь сөйләде.

Надо вырвать радость
        у грядущих дней.
В этой жизни
        помереть не трудно
Сделать жизнь
        Значительно трудней.

— Шул шул инде. Әле күптән түгел генә «Бөтен тавыш белән!» («Во весь голос») дигән поэмасын язып, укучыларны көрәшкә чакырды.

...Как живой
с живыми говоря,
Я к вам приду
В коммунистическое далеко,—

диде.

Ә бүген ул юк... Маяковский булып Маяковский...— Кутуй минем күзләремә карады:

— Ничек аңларга бу хәлне?

— Әйе, аңлавы кыен,— дидем мин авыр сулап...

Мең, мең еллар буе тораташ булып басып торган гранитларның кайчан да булса бер җимерелеп төшүләрен күз алдына китерергә мөмкин, ләкин корыч ихтыярлы титан шагыйрь Маяковскийның дөньядан китүен күз алдына китерү мөмкин түгел иде.

Бик кызганыч һәм шомлы иде Маяковскийның шулай фаҗигале рәвештә дөньядан китүе. Әмма бу минутта исә каршымда тәмам аптырап, үзен-үзе югалтып басып торган Кутуй тагын да кызганычрак булып тоелды миңа...

## Ватан сугышы елларында

Гитлер Германиясе башлаган дәһшәтле сугыш бөек Совет дәүләтенең һәм барлык совет халыкларының көчен сынау көннәре булды. Барлык совет язучылары һәм билгеле инде татар совет язучылары да зур сынау үтте бу көннәрдә.

Горурланып шуны әйтәсем килә: Ватаныбыз авыр көннәр кичергәндә, язучыларыбызның барысы да — фронттамы, тылдамы, дошман концлагерендамы — үзләренең барлык егәрләрен, талантларын дошманга каршы көрәшкә бирделәр. Сугыш кырында яки палач балтасы астында һәлак булдылар, ләкин каушап калып дошманга бирелмәделәр.

Сугышның беренче көннәре, беренче атналары. Кутуй белән мин, икебез дә берүк яшьтәге кешеләр, сугыш башланган көннәрдә үк военкомат билгеләгән урынга барып, үзебезнең хәрби хезмәткә яраклы сәламәт кешеләр икәнлегебезне күрсәтеп, тикшерү үтеп кайттык. Икебез дә фронтка җибәрүләре турында хәбәр килүен көтәбез. Көтәбез һәм дошманга ачу, нәфрәт уты юнәлдерелгән әсәрләребезне язабыз. Без генәме шулай? Түгел, билгеле. Барлык язучыларыбызның да илбасар фашистларга карата ачу һәм нәфрәт, халкыбызны аяусыз, изге көрәшкә чакырып язылган ялкынлы шигырьләре, парчалары, хикәя һәм пьесалары туа... Кутуй совет очучысы Мостафаның сугышта тиңсез батырлыгын тасвирлаган «Яшен» исемле хикәя язды. Мин өч күренештән торган «Дошман лагеренда» дигән пьеса яздым. Муса Җәлилнең «Дошманга каршы» һәм «Тупчы анты» шигырьләре туа. Шәйхи Маннурның «Туган ил өчен», Нур Баянның «Көрәшкә!», Әхмәт Фәйзинең «Бүре походы», Әхмәт Исхакның «Озату җыры», Таҗи Гыйззәтнең «Ил агасы» исемле пьесасы, Әхмәт Юнысның «Канлы күл» шигыре һәм башка күп кенә язучыларыбызның әсәрләре туа. Алар барысы да социалистик Ватаныбызны саклап калу өчен халкыбызны изге көрәшкә чакыралар. Сугышның беренче атналарында ук без — Кутуй белән икәүләп — сәхнәдән күрсәтү һәм декламация итеп сөйләү өчен, «Җиңү бездә!» дигән зур гына күләмдә әдәби җыентык төзеп Татарстан китап нәшриятына тапшырабыз. Сигез кечкенә пьеса, унҗиде шигырь, сигез хикәя, Г. Бәширнең «Сиваш» романыннан «Фрунзе» һәм «Броневик» кебек өзекләрдән торган бу җыентык 1941 елны Гази Кашшаф редакциясендә басылып чыкты.

1942 елны мин дә «Ватан кызлары» исемле пьеса язып, һәм берәр пәрдәлек пьесалардан торган җыентык төзеп, «Үлем фашизмга!» исеме белән бастырып чыгардым.

...Кутуй да, мин дә тиздән фронтка китәчәкбез. Фронт, сугыш куркытмый безне. Ләкин өйдә калачак гаиләбез, береннән-бере яшьрәк балаларыбыз борчый. Көз килә, аның артыннан кыш, салкын кыш башланачак. Өйне җылыту, мичкә ягу өчен бөтенләй утыныбыз юк. Кутуйның да, минем дә җылына белми торган убыр мичләребез

утын кетә. Бездә гениемени шундый авырлык. Түгел. Бөтен Казан шундый хәлдә. Шулар өстенә азык-төлек, гаиләбез өчен зарур булган башка кирәк-яраклар.

Язучылар союзы һәм Композиторлар союзы идарәләренең үтенеп сораулары буенча житәкче органнар безгә шәһәрдән 10—15 километр ераклыктагы нарат-чыршы урманыннан күпмедер күләмдә участок бирделәр. Үзебез кисү һәм кайтару шарты белән, әлбәттә. Шулай булса да, моңа бик сөендек. Әле фронтка китеп өлгермәгән язучылар, сугышка киткәннәренең гаилә әгъзалары, һәркайсы өч кешедән торган бригада оештырып, үзебез балта, пычкы, башка кирәкле әйберләр әзерләп, көн саен урманга утын кисәргә йөрибез. Безнең бригадада өч кеше. Кутуй, мин һәм ул вакыттагы Язучылар союзы председателе вазифасын башкаручы иптәш Тәхфәт Имаметдинов. Көн саен иртүк, кояш чыгар-чыкмас ук Бауман урамында, Язучылар союзы идарәсенә җыелып, йөк машинасы көтәбез һәм, ул килү белән, тәлләшеп урманга китәбез. Машина көткәндә барган сүзләребез — өебездәге авыр хәлләр, яки утын кисү, соңыннан аны ничек кайтартулар турында түгел, күбрәк дошманның рәхимсезлеге, ерткычлыгы турында...

Мең төрле сораулар борчый безнең йөрәкне. Борчый гына түгел, тетрәндерә. Житмәсә ул арада минем бертуган энем — техник лейтенант Нәҗиб Ишморатовның һәлак булуы турында хәбәр килде. Икенче энем — рядовой солдат фронтның алдынгы сызыгына сугыш кораллары ташучы Һади Ишморатов, поезд барганда бер вагоннарына фашистлар самолеты ташлаган бомба төшеп шартлый. Күп кенә кеше һәлак була. Ул, җиңелчәрәк контузия алып, Казанга кайта. Берничә көн торгач, яңадан фронтка китә. Аннан инде кире әйләнеп кайта алмый, кайдадыр сугыш кырларында ятып кала. Йөрәгемне өзгәли минем бу хәбәрләр.

Фронт хәлләре авырая бара. Шәһәрләр артыннан шәһәрләребез китеп тора — яна, җимерелә. Фашистлар Мәскәүне алу нияте белән алга омтылалар. Кайчан туктатыр безнең гаскәрләр ул ерткычларны? Йөрәк әрни... Үзебез урманга барып, утын әзерләүне дәвам иттерәбез. һәм ашкынулы бер дулкынлану белән үзебезне фронтка җибәрү турында повестка көтәбез. һәр көн иртән, мине күрү белән, Кутуй:

— Чакыру кәгазе килмәдеме әле?— дип сорый.

— Юк,— дим мин.— Ә сиңа?— Ул да шундый ук җавап бирә.

Беркөнне иртәрәк килдем. Йөрәгә өзгәләнгән Кутуй да иртәләгән. Тик Тәхфәт кенә килеп өлгермәгән. Хәер, безне урманга алып барырга дигән машина килергә дә байтак вакыт бар. Сүзебез һаман шул. Фронт хәлләре.

Гитлерчыларның һөҗүме турында көндәгеннән куәнечсезрәк хәбәрләр.

— Синең белән мин бармый торып, мөгаен, дошманның һөҗүме тукталмас, без барсак, һичшиксез, туктатачакбыз!— дип куйды Кутуй көлемсерәп.

— Бик дөрес,— дидем мин, Кутуй сүзен җөпләп, шулай ук бераз шаяру тоны белән.

Юк, бу безнең ахмакларча үз көчебезгә ышану түгел иде, бу безнең күңелебездә дошманга нәфрәт белән кайнаган теләгебез иде. Теләгебез генә түгел, дошманның инде хәле, көче нык кимүенә һәм минә, минә... бүгенме, иртәгәме аның һөҗүме тукталачагына һәм, һичшиксез, туган илебез җирләреннән куылып җибәреләчәгенә ныклы ышануыбыз иде. Кутуй, мин һәм башкалар фронтта сугышучы туганнарыбызга ярдәмгә барсак, дошманны ничек тә туктата алырбыз кебек иде. Бу көннәрдә үлем куркытмый иде безне. Гаҗәеп бер хәл, дошман һаман алга ыргыла, фашистларга зәһәрле нәфрәт бездә. Ләкин курку, каушау юк. Дошманны җиңүебезгә ышану гына яшь безнең күңелдә. Бу ышану партиябезнең зирәк акылына, полководецларыбызның тирән акыл белән эш итүләренә, Суворов, Кутузовлар кебек дөрес стратегия, дөрес тактика алып баруларына нигезләнгән. Барлык кешеләребез үз хезмәтен элеккегә карый икеләтә, өчләтә тырышыбрак башкара. Көлү, шаяру, җыр, бию дә элеккечә үк ышанычлы юлдашыбыз безнең.

Шулар турында җанлы әңгәмә барганда, Кутуй, кинәт сөйләүдән туктап, миңа бераз карап торгач, сәер генә елмаеп куйды.

— Синең башыңа ниндидер бер уй килеп китте ахры, Кутуй?

— Әйе,— диде Кутуй,— гаҗәеп тә бер уй килеп чагылып узды,— һәм ул әйтергәме аны юкмы дигәндәй уйланып торды да, әкрен генә:

— Без инде, билгеле, сугышка бармый калмаячакбыз, барачакбыз һәм кулы-

быздан килгән кадәр намус белән сугышачакбыз. Үзебезне аямыйча. Үзенә дә, сиңа да нык ышанам. Ләкин әле минем башыма килеп узган уй ул түгел.— Кутуй тагын туктапып калды.

— Әйтеп бетер.

— Икебезнең беребез кире әйләнеп кайталмыйча, сугыш кырларында ятып калыр кебек.

— Я, я? Әйт әле, кайсыбыз икән ул?

— Син кайтмассың кебек тоелып китте миңа.

— Бик мөмкин,— дидем мин салкын гына.— Сугыш кемне алып китәрен бик сайлап тормый.

Кутуй әйтеп бетергәнемне дә көтеп тормыйча, шул сүзләренә гафу үтенгәндәй, мине кочаклап алып, аркамнан сөеп куйды һәм көр генә тавыш белән:

— Юк, юк! Синең белән без үлемгә биреше торган кешеләр түгел. Икебез дә исән-сау кайтачакбыз. Бу дөньяда әле без эшлисе эшләр күп, бик күп,— диде.

Сүзләребез тәгәлләнеп өлгерер өлгермәс, Тәхфәт килеп җитте һәм без, башка иптәшләр белән бергәләп гөрләшә, гөрләшә урманга юл тоттык.

...Хуш исләр аңкып торган саф һавада урман кисүләре бер бәйрәм генә ул. Пычкың үткен булсын да балтаң тәртиптә булсын. Безнең исә балта, пычкы яклары, кайберебез күрше-күләннән генә алып торган булса да, начар түгел. Эшебез җиңел бара. Төз һәм биек чыршыларны чажылдатып кисәбез дә, ботакларыннан арындырып икешәр метр озынлыгы итеп өеп куябыз. Кибә торсыннар. Без аларны әз-мәз кибү белән үк, машина булса — машина белән, ат-арба табылса — арба белән, соңгаракка калсак, чана белән булса да өебезгә ташып куячакбыз. Шулай күпмедер көннәр урманга килеп, тирләребезне агыза-агыза тырышып эшли торгач, һәрберебезгә дүртәр метр, өчебезгә унике метр утын әзерләдек. Юан-юан чыршы бүрәнәләре, берничә каен да бар иде ахры.

Утын әзерләнде. Гаиләбезгә утын, бигрәк тә нәни балаларыбызга җылы булачак дип сөенүебезнең чиге-чамасы булмады. Тик шунысы бәла — утыныбызны өебез ихатасына китерү өчен чара табулар. Ай!.. авыр булды — ни машина, ни арба, ни чана, ни ат, ни кешеләр. Ут йотып, ары бәрелеп, бире сугылып йөри торгач, октябрь узды, ноябрь җитте. Гадәттәгедән күп иртәрәк зәһәрле кыш башланды. Утыз, кырык градустан артык салкынлык. Җитмәсә фашист мәлгуньнәр инде Мәскәү янында... Мине Военкоматка чакырдылар. Бауман районы Военкоматы. Өлкән батальон комиссары Вихлянцев кабинеты, анда военкомнан башка тагын ике кеше утыра. Икесе дә икешәр шпаллылар. Комиссар озак сөйләшеп тормыйча кулындагы документларга күз төшереп алды да:

— Иптәш Ишморатов, сез коммунист, хәлебезнең кискенлеген яхшы аңлыйсыздыр... Дошман Москвага бәреп керергә җыена. Москва безнең өчен бит... Хәзер, аның ни дәрәҗәдә кыйммәт икәнен сезгә аңлатып торасы юк. Кыскасы шул, без сезне фронтка җибәрергә уйлыйбыз.— Ул кулындагы документларны тагын бер кат карап чыкты да, бераз елмая төшеп:

— Сез бит батальон белән командалык итә алачак кеше,— дип куйды.

— Юк, иптәш комиссар, бу минем кулымнан килми. Батальон командиры була алырлык көчем юк, хәрби белемем дә юк,— дим.— Ә менә политрук, агитатор була алам. Агитация, пропаганда минем эш. Сугышчыларны, әйдәгез, иптәшләр алга!— дип дошманга каршы атакага алып бара алам,— дим. Вихлянцев янында утыручы иптәшләр берәнә-бере карашып, елмаеп ук куйдылар. Мактанчык дип уйладылар күрәсең.

Вихлянцев миңа чыгып бераз көтеп торырга кушты. Чыктым. Уйланам. Секундлар эчендә мең төрле уй башымнан чагылып узды. Мәскәү язмышы. Ватан һәм халкыбыз язмышы... Салкын өй... балалар. Урманда өелеп торган утыннар... Иртәгә үк китеп барсам, кем алып кайта аларны?.. Кутуй ни хәлдә икән? Әгәр Кутуй фронтка китеп өлгермәгән булса ул булышыр иде дә бит. Тик ничек булыша алсын икән ул? Утын турындагы уйларыма уралып туган-тумачаларым чагыла. Нәҗип һәлак булды. Һади да шулай, мөгаен. Әле берничә көн элек кенә Минзәлә райкомында эшләүче бер туган абыем Зыя да (ул 1919 елдан партия члены) фронтка китеп барды. Киткәндә берничә минутка гына минем янга кереп чыкты. Нәҗип белән Һади турындагы

хәбәрне ишеткәч, берничә секунд сүзсез утырды, тәмәкә тартырга дип кесәсеннән янчыгын чыгарды. Балаларга күзен төшереп алды да янчыгын кире куйды. Чәй әзерләмәкче булдым. Көтмәде. Аягүрә басты да, эчендәге бөтен ачуын җыеп:

— Фашист этләр безнең ил ачуыннан барыбер котыла алмаслар!— диде дә минем белән һәм балалар белән хушлашып, кызу-кызу атлап чыгып китте. Фанатикларча партиябез идеалларына бирелгән гадел, турылыклы коммунист кайларда икән ул бүген? Бәлки ул да инде... Беренә-бере бәйләнешсез куркыныч уйлар башымда өерелделәр. Колагымда Кутуйның сүзләре: «Без барсак, дошман һөҗүмен туктатыр идек шикелле», һәм тагын: «Син сугыштан кире әйләнеп кайта алмассың кебек».

Кабинеттан ике шпаллы хәрбиләрнең берсе чыгып, минем алдыма килеп туктады. Бик ягымлы тавыш белән тыныч кына татарча итеп:

— Сез, иптәш Ишморатов, юкка гына батыраеп сөйләшәсез. Сез хәрби кеше түгел. Мәскәү янына барып җиту белән рядовой солдат булып сугышка керүегез һәм шул көнне үк сафтан чыгуыгыз бик мөмкин. Мин сезне беләм. Сез язучы һәм режиссер. Гади режиссер гына түгел, Татар Дәүләт Академия театрында күп еллар баш режиссер булган кеше. Сез әле культурабызга, Ватаныбызга күп файда китерәчәк кеше. Фронтка барырга, сугышта катнашырга өлгерерсез. Күп һәм файдалы эшләр дә эшли алырсыз. Мин Бауман районы партия комитетының хәрби бүлек мөдире буларак, сезне фронтка җибәрүдән бераз вакытка сабыр итеп торырга тәкъдим иттем.

Шул сүзләрне ишеткәч, мин, бу йомшак күңелле хәрби кеше кем булды соң әле?— дип аның йөзенә күземне төшердем. Юк, таныш түгел. Гаҗәп, ул мине таный, ә мин аны танымыйм. Исем-фамилиясен сорашып өлгермәдем, ишекне ачып, минем фамилияне әйттеләр. Кердем. Миннән бераз калышыбрак әлеге иптәш тә керде. Өлкән батальон комиссары Вихлянцев миңа туры карап:

— Иптәш Ишморатов, без сезне бу юлга калдырып торырга булдык. Кирәк булгач, чакырырбыз. Хәзергә сез иркле. Кайтып китәргә мөмкин! — диде.

Ишектән чыкканда миңа мәгълүм булмаган әлеге хәрби иптәшнең йөзенә тагын бер кат күз ташлап алдым. Кем булды соң ул? Юк, таныш түгел кебек иде ул миңа.

...Сүз уңаеннан шунысын да әйтим: сугыш бетеп байтак заманнар узгач бу иптәш белән мин якыннан таныштым. Ул бу вакытта инде үзе дә сугышта булып, анда күп батырлыклар күрсәтеп күкрәген күп орден һәм медальләр белән бизәгән полковник Зыя Шаһиәхмәтов иде.

Ә урмандагы утын? Йөгерә-йөгерә йөри торгач, сөйләп кенә аңлатып бетерә алмаслык авырлыклар күреп, кырык градуслык салкында Гужтранспортта эшләүче яхшы күңелле кешеләр ярдәмендә алып кайттым мин утынны.

Ә бер көн иртән уянып ашап, эчеп өлгермәдем, Кутуй килеп керде. Аны мин шатланып һәм нигәдер шулай иртәләвенә бераз гаҗәпләнебрәк каршыладым.

— Әйдә уз, утыр.

— Юк, утырып тормыйм,— диде Кутуй, минем бик зур мичемә һәм биеклеге дүрт метр ярым булган бүлмәмә күз төшереп алды...— Мин әле сиңа бик зур йомыш белән килдем.

— Йомыш?

— Әйе. Дөресрәге үтенеч... Син утыныңны алып кайткансың дип ишеттем.

— Әйе, мең бәла белән.

— Мин әле һаман транспорт таба алмый азапланам,— ди-ди сөйләп, ул миннән бер-ике ягарлык кына булса да утын биреп торуымны үтенде.

Без утын сараена чыктык. Ул мин алып кайткан утыннарны күреп, башын селкиселки, бераз уйланып торды.

— Синең утыннарың да котәләр сине,— дидем мин.

— Беләм,— диде ул әрнүле тавыш белән.

— Син дә Гужтранспортка барып кара.

— Барам, барам, тик бүген әле хәлебез хәл. Мичебез ягылмаган. Балалар белән барыбыз бергә җыелып кичкенә бүлмәдә гомер итәбез. Керосинка җылысында.

— Ал менә шул бүрәнәләрнең берсен. Үзеңә ошаганын сайлап,— дим аңа утын әрчемәсе күрсәтеп.

Ул сүземә ышанып җитмәгәндәй күзләрен тутырып миңа карады.

— Ал, ал...

Ул ике метрлы бүрәнәләрнең берсен, мөмкин кадәр юанрагын сайлап алды. Сайлавын сайлады, ләкин ничек алып кайтырга? Бауман урамыннан ул яшәгән Комлев урамына кадәр? Яхшы ук чи, бозлы бүрәнәне без көч-хәл белән күтәреп ишек алдына алып чыктык та тәгәрәтә, тәгәрәтә капка төбенә алып бардык.

— Кечкенә чанагыз юкмы? — диде Кутуй.

— Юк шул, булганы да...

— Берәр бау, аркан сымаграк нәрсәгез дә юкмы?

Эзләп-эзләп ни бары бер метр чамасы бау кисәгеннән башка бер ни дә таба алмадык.

— Булды! — диде Кутуй бер карарга килеп,— башка бернәрсә дә кирәкми!

Ул тиз генә билендәге чалбар каешын чишеп алды да шуның белән бүрәнәне бәйләде һәм аңа әлеге бауны ялгады. Ялгады һәм бүрәнәне боз булып туңган җирдән шудыра-шудыра Бауман урамы буйлап өстерәп алып китте. Салкынлык кырык градуслар чамасы. Урамда кар юк диярлек. Суык, бик суык... Шулай да Кутуй күңелендә җылылык. Минем дә нәкъ шулай, Кутуйга ярдәмләшеп бүрәнә өстерәшәм. Икәүләп булгач, җиңелрәк. Күп урыннарны йөгерә-атлый үтәбез. Ике кварталлар җир узгач, Кутуй әйтә миңа:

— Бар, Риза дус, син кайт. Мин моны үзем дә алып кайтып җиткерәм,— ди.— Моңысы өчен зур рәхмәт сиңа,— ди.

Ул авыр бүрәнәне бозлы ташлар өстеннән шудыра-шудыра өстерәп Бауман урамы буенча юнәлә. Мин аның көч-хәл белән баруын бераз карап торам да, утын сарае ачык калганы исемә төшеп, тиз-тиз атлап кайтып китәм.

...Инде бу көннәргә күп еллар үтте. Сугыш тәмамлануына да кырык елга якын. Миллионнарча кешебез сугышта һәлак булды. Күпләр яраланып, гарипләнеп, ә кайберәүләр бөтенләй диярлек исән-сау килеш туган илләренә кайттылар. Кайтучылар арасында мин үзем дә, Берлин өчен барган урам сугышларында каты яраланган булсам да, үз аягым белән туган-үскән илемә кайттым. Үземнең яраткан эшемне дәвам иттерәм. Ә менә сугыш кырларында зур батырлыклар күрсәтеп Берлинга якынлашып килгән көннәрдә һәлакәткә очраган Кутуй дустым кайта алмады. Аның турында уйлаганда һәрчак аның белән бергә шаулап узган яшьлек көннәрем исемә төшә. Ә кайчакны Кутуйның зәһәрле салкын көннәрдә Бауман урамы буйлап әлеге бүрәнәне өстерәп баруы күз алдыма килеп баса.

## Кутуй фронтта

1941 елның ахырларында Кутуй фронтка китә. Йөрәгендә фашист илбасарларга чиксез ачу-нәфрәт саклаган кыю солдат Гадел Кутуй дошманны туган илебездән куып җибәрү өчен җанын, тәнен аямыйча сугыша... Менә ул фронтның иң кайнар, иң җаваплы урынында — Сталинградны саклау өчен барган сугышларда. Гвардия берләшмәсе командиры полковник Михайлов Кутуйга характеристика биреп болай дип яза:

«Минем» берләшмәгә килгәндә Кутуев гади рядовой солдат иде, натурасы белән тыйнак иде. Үзенең югары белеме белән, язучы булуы белән бер кайда да, бер кайчан да һаваланмады. Фронтның кырыс чынбарлыгы таләп иткән һәр тапшырылган эшне, һәр боерыкны намус белән үтәде. Иптәш Кутуев сугышта һәрвакыт батыр һәм кыю иде. Үзенең түземлелеге, шат күңеллелеге белән башкаларга үрнәк булды. Ул һәр сугышчан йөкләмәне нәкъ үз вакытында үти иде.

Иптәш Кутуев Сталинград сугышларында катнашып, шунда КПСС сафына керде. Ул тәрбияче-оештыручы буларак, үзен искиткеч сәләтле итеп күрсәтте. Һәм дивизион парторгы итеп сайланды. Иптәш Кутуев фронтта үзен иҗат кешесе буларак та танытты. Ул частьның тарихын язды, әдәби монтажлар төзеде, Кызыл Армия матбугатында, сугышчыларның үзешчән сәнгать эшләрендә актив катнашты».

Гадел Кутуй сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. Сталинград оборонасының героик көннәрен чагылдырып «Без сталинградчылар» исемле тирән эчтәлекле нәсерен яза.

...Ниһаять, Кутуй Белоруссия фронтында. «Кызыл Армия» исеме белән чыгарыла торган Белоруссия фронты газетының татар телендәге басмасында хәрби корреспондент. Аның кулында хәзер дошманга каршы юнәлтелгән автомат яки пистолет кына түгел, фронтташ дуслары Гариф Галиев, Зыя Ярмәкиләрдәге шикелле үк, каләм. Сугышчыларны дошман өстенә алга әйдәп баручы ялкынлы сүзләр. Газета битләрендә аның фронтның алгы сызыгына барып ут эченнән алып кайткан хәбәрләре, «Тетрә, Берлин!» кебек утлы нәсерләре басылып чыга.

Ләкин фронтның бик авыр һәм мәкерле шартлары аны аяктан ега. Бөтен йөрәге, уй-хисләре белән дошманны җиңүгә омтылган, шуның өчен барлык көчен биргән Кутуй дустыбыз җиңү көннәрен, аның тантанасын күрә алмый. Бу көннәрдә ул бер аңына килеп, бер аңын югалтып госпиталь шартларында үткәрә. Ниһаять, 1945 елның 16 июнендә вафат була. Моннан да фаҗигалерәк үлемне күз алдына китерү дә кыен!

Язмамны тәмамлап шуны әйтәсе килә: Кутуй үзенең бөтен талантын, яшьлек дәртен биреп, яңа, якты дөньябыз өчен көрәшкән, социалистик Ватаныбыз, бөек халкыбыз өчен ялкынлы гомерен биргән кеше, чын кеше иде!

# *Бер сорауга — бер җавап*

**Сорау:**

*Республика рәссамнары соңгы елларда үткәргән күргәзмәләрдән кайсысы сездә аеруча көчле тәэсир калдырды һәм ни өчен?*

**ХАРИС ЯКУПОВ, СССРның халык художнигы:**

*Минем күңелдә иң зур тәэсир калдырганы — Мәскәүдә үткәрелгән, Татарстанның 60 еллыгына багышланган күргәзмә булды. Бу күргәзмә республикабызның культура тормышында, татар халкының рәсем сәнгате тарихында гаять мөһим вакыйга иде.*

*Урамда суык. Крымская Набережная кар белән капланган. Йөзләрчә тамашачылар ашыга-ашыга зур сарайга — СССР Художниклар союзының күргәзмә залына таба агылалар.*

*Беренче тәэсир — залларда кояш чыккандай яктылык, җылылык. Матур буяулар белән эшләнгән картиналар, күренешләр, кеше сыйфатларын төшергән рәсемнәр. Графика әсәрләре — китап өчен ясалган иллюстрацияләр, сатира рәсемнәре, плакатлар. Скульптуралар. Декоратив әсәрләр. Театр сәхнәсе өчен башкарылган эскизлар... Кыскача гына әйткәндә, монда, әкият патшалыгына кергән шикелле, рәсемнәр дөньясына керәсең. Чөнки күргәзмәдә Татарстан рәссамнары тарафыннан 1920 елдан 1980 елга чаклы ясалган, ягъни 60 ел эчендә иҗат ителгән 1000 әсәр куелган.*

*Монда әсәрләрнең дә иң яхшылары гына сайлап алынган. Алар арасында Казанның карт художниклары, беренче татар рәссамнарының укытучылары Н. Фешин, П. Беньков әсәрләре куелган. Янәшәдә — республикабызның хәзерге заман рәссамнарының күбесен укыткан В. Тимофеев, П. Сперанский, Н. Сокольский эшләре. Беренче милли рәссамнарның әсәрләре. Алар арасында Г. Арсланов, Ш. Мөхәммәтҗанов, Ф. Таһиров һәм Б. Альменовның китап өчен ясалган график эшләре, С. Ахун һәм Б. Урманченың скульптуралары һ. б.*

*Күргәзмә залларында йөргәндә, мин 1957 елда Мәскәүдә уздырылган Татарстан сәнгате һәм әдәбияты көннәрен дә искә төшердем. Ул көннәрдән соң 23 елдан артык вакыт узган икән. Тарих өчен бу дәвер артык күп түгел билгеле, ләкин үсеш зур булгач, горурланасың. Шул елдан соң гына да безнең рәсем сәнгатебез ничек алга атлаган, нинди яңа уңышларга ирешкән!*




Энҗе Мөэминова

# БЕР ОСТАЗНЫҢ ИКЕ ШӘКЕРТЕ

ОЧЕРК

## Олы язмыш хуҗасы

Авыл хуҗалыгы эшчәннәре көне уңае белән, Әлмәт нефтьчеләрнең культура һәм техника сараенда үткәрелгән тантаналы җыелышта президиум өстәле янында янәшә утырганнар иде алар. Уртада — Һади ага Рахманов. Самат Әхтәмов белән Зөфәр Шәйдуллин — аның ике ягында. Һади ага Рахманов — кунак, ә Самат Сираевич белән Зөфәр Газизович тантананың хуҗалары. Һади ага узган еллардан истәлекләр сөйләячәк. Ә шәкертләре бүгенге җиңү шатлыклары белән уртаклашачаклар.

Районның иң алдынгы игенчеләре, терлекчеләре Һади ага Рахмановны зур игътибар белән тыңлыйлар.

«...Бөек Ватан сугышы башлануның икенче көнендә үк, запастагы офицер буларак, фронтка киттем. Озак та үтмәде каты яраланып, госпитальгә кердем. Сугыш мине беренче группа инвалид ясады.

1943 елның февраленнән башлап, яраларым төзәлеп тә җитмәгән килеш, мин колхоз белән җитәкчелек итәргә алындым. Инвалидлык буенча билгеләнгән пенсиямнән баш тартып, аны шушы көнгәчә дәүләт фондына калдыра килдем. Ул чорда, булдыра алган кадәр, бар көчемне халыкны фронт өчен икмәк һәм башка төр продуктлар хәзерләүгә туплау эшенә бирдем.

«Зәй» колхозы 1947 елны республикабызда иң беренче миллионер колхоз булды. Колхозчылар көче белән, авыл елгасында ГЭС төзедек. Авыл өйләрендә электр утлары кабынды. Радиоузел, колхоз хуҗалыгында электромоторлар эшли башлады.

1954 һәм 1964 елларда безгә экономик яктан бик нык артта калган колхозлар кушылды, «Зәй» колхозы ун вак хуҗалыкны үз кочагына алды. Шунысы хәтердә калган, соңгы кушылган колхозның госбанкта, счетны япмау максаты белән генә калдырылган, 73 тиен акчасы бар иде.

Тәмам таркалу хәленә килеп җиткән бу хуҗалыкларның дәүләткә һәм башка хуҗалыкларга булган бурычларын түләп бетергәннән соң, колхозның үз көче белән кирәкле объектларны төзү эшенә керештек.

Мисал өчен әйтсәк, сигезенче бишьеллыкта шундый максат белән 2 млн. 550 мең сум акча тотылды. Колхозның акчалата доходы 6 млн. 797 мең 500 сумга җитте. Бик күп авыл хуҗалыгы техникасы сатып алынды. Колхозыбыз республиканың үрнәк-тәҗрибә хуҗалыгына әйләнде...»

Трибунадан үзе турында берничә җөмлә генә әйткән бу хөрмәтле кеше миндә, нәкъ менә шушы көнне, аның белән якыннан танышу теләген уятты.

Мин архивтан өч документ һәм ике фоторәсемне аерып алдым. Документларның берсе — автобиография.

«Мин Рахманов Һади Махмурахман улы, 1910 елны Әлмәт районының Нәдер авылында ярлы крестьян гаиләсендә туганмын. Әтием 1921 елны үлде. Шул елдан башлап мин, башта үз хуҗалыгыбызда, ә аннан соң авыл кулакларына ялланып крестьян эше белән шөгыльләндем» — дигән юллар белән башланып киткән, һәрбер җөмләсе үзе бер тарих булган бу олы тормыш елъязмасы менә мондый җөмләләр белән тәмамлана:

«...Мин 1939 елдан КПСС члены. 27 ел КПСС райкомының Пленум члены, 15 ел бюро члены булдым. 10 мәртәбә өлкә конференциясендә делегат булып катнаштым. СССР Верховный Советының бишенче чакырылыш депутаты. Колхозчыларның өченче Бөтенсоюз съездына делегат булып катнаштым. Миңа 10 мәртәбә Мәскәүдә Бөтенсоюз Халык Хуҗалыгы Казанышлары күргәзмәсендә катнашу хокукы бирелде.

1971 елны Ленин ордены белән, 1950 һәм 1966 елларда Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары белән һәм төрле елларда хөкүмәтебезнең медальләре белән бүләкләндем».

Икенче документта Һади ага Рахмановка хөкүмәтебез тарафыннан бирелгән бүләкләрнең исемлеге теркәлгән. Аларның саны ике дистә ярымнан да артып китә.

Өченчесе — фактлар белән дәлилләнгән тарих — Һади аганың үз кулы белән язылган «Истәлекләр».

«...Мин 1928 елда авылыбызда комсомол оешмасы секретаре ярдәмчесе булып эшләдем. Комсомол — авылда зур көч булып, партия-совет күрсәтмәләрен үтәп торды.

Партиябез тарафыннан бирелгән директиваларны крестьяннарга аңлату, авыл халкын колхозга берләштерү буенча җыелышлар үткәрү, берәмләп чакырып сөйләшү, көндез һәм төннәрен аерым йортларда йөреп аңгәмәләр үткәрүнең чиге булмады.

Мин үзем, колхозга биргән үз атымны җигеп, колхоз басуында беренче бураznаны сыздым. 1930 ел уңышын чәчеп, урып җыйганда колхозда 35 баш эш аты, 10 сабан, бер ашлык сугу машинасы, 6 пар тимер тырма бар иде.

...Колхозга каршы яшертен корткычлык эшләп ятучы кулаклар безгә тынгылык бирмәделәр. Мәсәлән, коммунистлар, комсомоллар файдаланмасыннар, изге дин урыныбызны таптамасыннар дип, авыл халкы көче белән салынган мәчет бинасын һәм зур мәктәпне төнлә ут төртеп яндырдылар. Авыл активистларына каршы ерткычлыклар эшләделәр, һөҗүмнәр оештырдылар. Мин үзем дә үлемнән очраклы рәвештә генә котылып калдым. Авыл Советы бинасында, авыл Советы секретаре хезмәтен башкарып утырганда, кулына сапсыз чалгы тотып кергән берәү: «Коммунист-комсомоллар, сез бетәргә тиеш, муеныңны чабып өзәм!» — дип, берничә мәртәбә миңа кизәнде. Бәхетемә каршы, көтмәгәндә кеше килеп кереп, мин котылып калдым...»

Минем кулымда ике фоторәсем. Аның берсе — Һади абыйның 1930 елны, партия билеты өчен төшкән рәсеменең зурайтылганы. Ә икенчесе — «Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераннары стенды» өчен төшерелгән рәсем.

Беренче рәсемнән, бөдрә чәчләрен күпертеп үргә тараган, йөзеннән һәм күз карашыннан яшьлек дәрте бөркелеп торган чибәр егет карый. Икенчесеннән — гомер юлдашы, укытучы Наҗия апа белән бергә берсеннән-берсе әйбәт дүрт бала тәрбияләп үстергән әти кеше, оныклары өчен иң матур яшәү үрнәге булган ягымлы бабай карап тора.

Авылдашлары аның белән һәрчак горурланалар. Чөнки Һади ага Рахманов — чын-чыннан халык ихтирамын казанган кеше, ил агасы.

Шагыйрь Гали Хуҗиевның аңа багышлап язган «Тәрәзәләр таңга карый» исемле поэмасында менә мондый юллар бар:

Урман буенда егылган солдат,
Һөҗүмгә барган чагында ярсып;
Яралы аның ике аягы:
Берсендә — пуля,
Берсендә — ярчык...

...Инде ул минә Әлмәт ягында
Туган туфракта уела әзе.
Шушы туфрактан мәңге аерылмас
Пәһлеван итеп сизә ул үзен...

Һади аганы бүген дә пәһлеван диясе килә. Яшьләр йөрәгенә ул салган көч-кодрәт, яшәү ялкыны, бар талантыңны балкытып яши белү кагыйдәләре бүгенге тормышыбызда чынбарлыкка әйләнде. Чөнки аның кылган эшләре, бөтен гомере үзе ЧЫНЛЫК!

## Агачны җимешеннән таныйлар

Авылның нәкъ уртасында кирпечтән салынган ике катлы бина тора. «Ярыш» колхозы идарәсе урнашкан бу мәһабәт йортның икенче каттагы үзәк урамга караган бүлмәләрнең берсе — колхоз председателе өчен. Заманча итеп, тыйнак һәм матур җиһазландырылган.

Председатель гадәтенчә, иртә таң белән үз бүлмәсендә өстәл артына утырып түгел, кешеләрне ишек алдында сәламләп каршы ала. Ә аннан соң, кичке караңгылык төшкәнче эш урынында алар белән бергә була.

...Менә бүген дә шау-шулы эш көне тәмамланды. Караңгы төште. Асфальт юлдан, нур көлтәләре бөркеп машиналар чаба.

Әнә, председательнең эш бүлмәсендә дә ут кабынды. «Самат Сираевичның иртәгәге эш көне башланды» — дип уйлап куйдым мин. Кичке уннарсыз кайтып китә алмый әле ул. Иртәнге сәгать дүртләр-бишләрдә инде ул, һәрвакыттагыча, аяк өстендә.

Каяндыр җигүле ат килеп чыкты. Арба тәгәрмәче һәм ат тоягы тавышлары кичке караңгылыкта машиналар шавына кереп югалды. Һәм шушы дагалы ат тоягы тавышы, үзе белән ияртеп, минем уйларымны үткәннәргә алып кереп китте.

Мин шушы колхозның, үзем эчендә кайнап үткән дүрт дистә еллык тарихын яшен тизлеге белән күз алдымнан кичерә башладым. Алар колхоз идарәсенең тәмәке төтене, пыскып янган лампа төтене белән тулы, тынчу кысан бүлмәсендә барган сөйләшүләр булып гәүдәләнделәр, кайтавазлар булып яңгырадылар.

1941 ел. Игеннәр кар астында калды. Кар астындагы пакостан көлтә бәйләгәндә туңып күшеккән бармакларымның әрнүләрен тоям...

1944 ел. Атлар күтәрәмдә. Чәчүлек орлык юк. Бөгелмә элеваторыннан (утыз сигез чакрым) бәләкәй арбалар белән чәчүлек орлык ташырга кирәк. Сабанга чыкканчы хуҗалыктагы савым сыерларны да җигәргә өйрәтергә туры киләчәк. Чыбыркы белән суккан саен тартәгә шартлатып тибә, яки тизрәк җиргә ятуны чамалый торган, ул вакыттагы сабыйларның бердән-бер туендыручысы сөтлебикәләрне күз алдыма китерәм.

1945 ел. Басуларны чүп үләне басты. Мәктәп балаларын, бераз хәле булган әбиләрне тартасы иде бу эшкә. Капчык-торбышалар да тузып эштән чыккан. Баса йолкуны оештырырга кирәк.

Җигүле ат дугасыннан да биегрәк булып үскән үләнне тарта-тарта бармаклары суелып беткән укучы балаларым искә төшә...

1947 ел. Фермаларда терлекләр саны бик аз. Хуҗалыклардан, икмәк белән алмашып, яшь бозаулар җыйнарга кушалар.

Баласыдай кадерле яшь бозавын колхоз фермасына илтеп тапшыручы киң күңелле, шәфкатьле аналарны уйлыйм. Күзгә яшьләр килә...

1968 ел. Халыкка туйганчы ипи ашатуга ирештек. Партиябез, хөкүмәтебез безнең алга хәзер халыкны терлекчелек продукцияләре муллыгы белән тәэмин итү бурычын куя.

Менә шушы елны, менә шушы зур проблеманы хәл итү өчен колхоз белән җитәкчелек эшенә җигелде партия солдаты Самат Әхтәмов.

* * *

Иртә таңнан һәр ике авылның яшьләре, урта буын кешеләре «Вахта»ларга төялеп Әлмәт, Мактама, Карабаш, Бөгелмә, Лениногорск якларына эшкә китеп бара. Авылда кайгыртучан хуҗаларын көтеп, күпсанлы техника, меңләгән терлекләр һәм... санаулы гына кешеләр кала. Шул кешеләр белән көненә мең төрле мәшәкате килеп чыккан зур хуҗалык эшләрен башкарырга кирәк.

Урта мәктәпне тәмамлаучы яшьләрнең, мәктәпләрдә авыл хуҗалыгы һөнәрләренә өйрәтелеп, таныклыклар алып чыгуларына карамастан, колхозда калмауларын да өстәсәк, нефть ягы районнарындагы колхозларның хәле аңлашылыр. Кеше җитми. Эшли башлавының беренче көннәрендә үк менә шушы проблеманы хәл итәргә кирәклекне тойды Самат.

Яңа чаралар эзләргә кирәк. Эзләргә һәм табарга! Гомерләре буена игенчелеккә тугры калган кешеләр тәрбиясендә үскән яшьләргә таянырга, аларга тәпле белем алу өчен ярдәм итәргә. Җирнең, игеннең, хезмәтнең абруен иң югарыга күтәрергә!

...Махсус урта һәм югары белемле унҗиде яшь белгеч эшли хәзер колхозда. Шунысы куанычлы: аларның күпчелеге — эти-әниләре колхозда эшләп гомер иткән кешеләрнең балалары. Ипинең төмен һәм бәясен белеп үскән авыл яшьләре.

Әхмәтов үзе дә этисенең данлы хезмәт юлын дәвам иткән кеше. Аның этисе Сираҗетдин ага сугышка кадәр «Зәй» колхозында бригадир булып, сугыштан яраланып кайткач, Нәдер авылында авыл Советы председателе булып эшләгән. Сугышның авыр яралары аның гомерен иртә өзгәннәр. Әгәр ул бүген исән булса, республикабызның унынчы чакырылыш Верховный Советы депутаты булган улының күкрәгендә «Хезмәт Кызыл Байрагы» орденын күреп чиксез шатланыр иде...

Авыл башында, ак кирпечтән матур итеп салынган алты яңа йорт урнашкан. Яшеллеккә чумып утырган бу йортларда колхозның яшь белгечләре яши.

Ишек алдында күперен торган ямь-яшел үлән. Бакча коймаларын үрмә гөлләр япмасы каплаган. Түтәлләрдә — чәчәкләр. Бакчаларында — җиләк-җимеш агачлары, бәрәңге һәм барлык төр яшелчәләр үсә. Матур итеп агачтан бурап салынган мунча белән янәшә, кирпеч гараж, сарайлар. Яшел чирәмдә — тавыклар төркеме. Койма буенда яшь бозау күшәп ята. Муллык!

Газы, суы булган өч бүлмәле квартирада гарнитурлар, палас, келәм, хрустальләр — барсы да бар! Яши бир рәхәтләнеп!

«Мине иң яхшы бер белгечегез белән таныштырыгыз әле» — дигәч, «Алар барысы бик әйбәт эшлиләр»,— дигән иде Самат Сираевич.

Начар эшләргә хакы юк ич аларның! Эшләү һәм яшәү өчен бөтен шартлар, бөтен уңайлыклар тудырылган. Алай гына да түгел әле, аларның күбесе махсус машина яки мотоцикл белән дә тәэмин ителгән. Җиң сызганып эшлә генә! Һәм эшлиләр дә алар.

«Иртә таңнан һәр ике авылның эшкә иң сәләтле яшьләре, урта буын кешеләре «Вахта»ларга төялеп Әлмәт, Мактама, Карабаш, Бөгелмә, Лениногорск — тагын әллә кайларга эшкә китеп бетә» — дигән идек алдарак. Бу проблеманы хәл итүнең дә бер чарасы табылды.

Ленин комсомолы исемен йөртүче, Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Миңлебай газ эшкәртү заводы колхозга шефлык ярдәме күрсәтә башлады. Заводның элекке директоры Фәйзулла Гайнуллин һәм партком секретаре — элекке үзебезнең укучыбыз, Тәйсуган авылы егете — Ирек Ихсанов, безнең колхозның «даими член нары»на әйләнделәр. Бу башлангычны заводның хәзерге җитәкчеләре дә бик матур дәвам итәләр.

— Остазыгыз кем сезнең? — дип сораган идем мин бер көн Саматтан.

— Һади абый! — дип җавап бирде ул минем бу соравыма.

Аның бу җавабы миндә Һади абыйның үзе белән очрашу теләген уятты. Самат бит Һади абый җитәкчелек иткән колхозда озак еллар партком секретаре булып эшләде. Менә шул елларда «Зәй» колхозы республикада гына түгел, ил күләмендә билгеле колхозга әйләнде.

Без Һади абый белән очраштык.

— Һади абый, шәкертегез турындагы язмамның тәмамланган кадәресен укып күрсәтәсем килә. Тыңларсызмы икән?

— Бик рәхәтләнеп...

Укып бетергәч, мин, һөкем көтеп, беразга тынып калдым.

— Барысы да дөрес, тик менә, Саматның сельпода эшләгән чорын да язарга кирәктер дип уйлыйм мин үземчә — дип, салмак башлады Һади абый.— Аны бит колхозга горком аша мин кайтарттым. Ул бераз миңа үпкәләп тә йөрде әле моның өчен. Коммунистлар белән җитәкчелек итү өчен мин менә нәкъ Самат кебек көчле кеше булуын тели идем. Сельподан да бер дә җибәрәселәре килмәде аны. Районда иң алдынгы сельпо председателе иде бит. Кооперация эшчеләренең Бөтенсоюз съездына катнашкан кешә.

Ә менә аны сезнең колхозга алганда бер дә миннән рөхсәт сорап тормадылар. Юкса мин аны үземә алмаш булыр дип ышанып хәзерли идем...

— Ышанычыгызны артыгы белән аклаган бит шәкертегез!

— Анысы шулай да. Ул чакта минем үземә читенгәрәк туры килде шул. Хәзер инде мин аның өчен шатланып бетә алмыйм. Кулыма район газетасын алу белән, иң элек, «Ярыш» колхозын эзли башлыйм. Киләчәге дә шулай матур булсын дип кенә телим.

— Зөфәр Газизовичны да колхозыгызга сез чакырып кайтаргансыз түгелме соң әле, Һади абый? — дип сорадым мин җай чыгудан файдаланып.

— Әйе. Аның белән беренче очрашу кызык булды. Зөфәрнең әнисе безнең авылныкы бит. Ире сугышта үлгәч, монда күчеп килде. Сеңлесе янына. Ул чорда безнең колхоз киндер игә иде. Киндер көлтәсен эшкәртергә колхозчыларга бүлеп бирә идек.

Чалбар балакларын сызганып, апасы батырган киндер көлтәләрен күлдән чыгарып маташа иде ул. Үзе — югары белемле ветврач. Гаҗәпләндем дә, сокландым да. «Менә бу чын авыл кешесе икән болай булгач! Моны үзебезгә кайтартсак начар булмас иде» — дигән уй үтте. «Безгә эшкә кайтмыйсыңмы, егет? — дим.— Врач штаты бездә юк-югын, зоотехник булырсың. Врачлыкны да алып барырсың». Бик үк каршы түгел икәнен белгәч, чарасына керештем. Ялгышмадым. Ишеткәнсездер инде, аңа «РСФСРның атказанган зоотехнигы» дигән исем бирелде бит!..— диде Һади ага аның өчен чын күңелдән шатланганын белдереп.

Каршыбызга озын буйлы, күпереп торган кара бөдрә чәчле чибәр егет килеп басты.

— Олы улыбыз Илдар. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлады. Хәзер «Победа» колхозында эшли,— дип таныштырды Самат Сираевич мине аның белән.

— Ә кечесе кая хәзер?

— Солдат хезмәтендә. Казанның ветеринария институтын тәмамлагач китте...

Атасы һөнәрен сайлаган кешенең бәхетле булуын гасырлар исбат иткән. Мин үзем якыннан белгән һәм яраткан авылдашларым турында язганда, шуңа шатланам: аларның һәр берсенең диярлек бер яки ике баласы ата-анасы һөнәрен сайлый. Күңелле күренеш! Өлкәннәр эстафетасын ышанычлы алмаш көтә.

«Иртә таңнан кара төнгәчә эштә бит ул» — диде Самат Сираевичның гомер юлдашы Рәхилә ханым.

Уйлап карасаң, колхоз председателе өчен һәрчак — «урак өсте». Кыр эшләре бетүгә, ремонт көтеп тора. Ансы тәмамлануга, язгы чәчү башлана. Анысының очы җәйге, көзге эшләргә тоташа. Терлекчелектә — ел буе көрәш. Төзелеше дә тукталып тормый. Шуларны планлы рәвештә хәрәкәткә китерүче төп фигура —

колхоз председателе. Безнең «Ярыш» колхозы өчен Самат Сираевич Әхтәмов ул. Аңа карата мәнә нинди фикердә безнең кешеләр. «Эшлекле, таләпчән, хуҗалык җанлы, принципиаль», «Эленке-салынкы йөргәнне яратмый», «Белгечләргә ышана», «Шуңа күрә аның кул астындагы белгечләр башка җиргә китмиләр. Киресенчә, ниндидер сәбәп белән киткәннәре дә кире әйләнеп кайталар», «Хуҗалыкның бөтен тармакларындагы хәлне, даими рәвештә, үзе карап, тикшереп, белеп тора», «Дилбегәне үз кулында тота белә...»

Әйтелгәннәрнең дәреслеген кемнән дә булса раслатып торасы юк. Авыл бит бу! Монда беркемнән дә, бернәрсәне дә яшерә алмыйсың.

Самат Сираевич менә нинди күркәм сыйфатларны остазыннан үзенә күчереп ала алган.

— Минем өчен иң зур шатлык үзем белән янәшә яшәүче кешеләрдән рәхмәт сүзләре ишетү. Иң олы хәсрәтем дә шул — халык ышанычын вакытында үти алмау,— ди Самат Сираевич.

Әйе. Самат Сираевич халыкка тугры хезмәт итә. Мин аны үз көндәлек тормышымда тоеп та бик яхшы беләм. Бер генә мисал. Әлмәт нефть ятмаларыннан табылган газ, бик тиз арада, Көнбатыш Европа илләренә кадәр барып җитте. Ә без үзебез — шул хәзинәнең хуҗалары — бу рәхәткә җитмешенче елларның башында гына ирештек.

Кемнәрнеңдер җавапсызлыгы аркасында төзелеш өчен билгеләнгән барлык акча тотылып беткән, ул эш сүнеп калган иде инде. Җир астында ун еллап яткан газ үткәргеч торбалары яраксызга чыккан, меңнәрчә сум акча исраф ителгән иде. «Кем башлаган шул бетерсен. Кем гаепле — шул җавап бирсен»,— дип тормады Самат Сираевич, эшне өр-яңадан күтәрде һәм башкарып та чыкты. Инде Тәйсуган авылында шул мәсьәләне хәл итәсе бар.

Нефть районнарында яшәүче кешеләр өчен икенче проблема — чиста су мәсьәләсе. Председатель хәзер шуны булдырырга йөри.

Зәй елгасы үзәнендәге тау иңенә кирпечтән салынган зур-зур корылмалар кичкенә генә бер матур шәһәрчекне хәтерләтәләр. Болар — колхозның киләчәктәге төп перспектив үсеш юнәлешен билгели торган терлекчелек комплексы корылмалары. Ул өч чиратка бүленеп төзелә. Аның беренче чираты файдалануга тапшырылды инде. Хәзергә монда 2000 баштан артыграк терлек бар.

Колхозыбыз райондагы савым көтүләрен тулыландыру өчен нәселле таналар үстереп бирәчәк. Якын киләчәктә районда сөт ризыкларының муллык чыганагы булачак безнең колхоз. Колхозның бөтен эше шул олы максатны күздә тотып планлаштырыла. Ул максатка ирешкәнче бик күп таңнарны төн белән тоташтырырга кирәк булачак әле Самат Сираевичка.

— Максатка ирешү — җиңү ул, киенлыкка каршы осталыкны куеп кына яулап була аны,— диген иде Самат Сираевич.

Ирешү ысулларын да белгәч, максатына ирешер, дип ышанасы килә.

## Ул бүген дә мәсьәләләр чишә

Улы яки кызы, олыгайса да, әни кеше өчен ул әле һаман сабый булып калган сыман, укытучы кешегә дә, үзенең элекке укучылары, инде нинди генә зур дәрәҗәле кешеләр булуга карамастан, барыбер, парта артында утыручы укучы сыман тоела. Алар үзләре дә сине олылап каршылыйлар.

Зөфәр мине аягүрә басып каршы алды, исемемне әйтеп кул биреп күреште. Һәм шул вакытта аның йөзе, оялчан малайларныкыдай, бераз алсуланып та кит-

те. Дулкынланмаслык та түгел: дистә еллардан соң мин аның янына, математикадан контроль эш өчен булган дәфтәренә билге кую өчен түгел, ә үткән гомер һәм хезмәт юлына тормыш тарафыннан куелган билгеләрне күрү өчен махсус рәвештә килдем.

Мин аңа куелган андый билгеләрне беренче мәртәбә Әлмәт шәһәренең Ленин мәйданындагы Мактау тактасында, икенче һәм өченче мәртәбә «Почет билгесе» ордены, «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены белән бүләкләнүчеләр арасында күргән идем инде.

Бүген ул — республикабызда гына түгел, бөтен илгә билгеле булып баручы, районның хуҗалыкара терлек симертү берләшмәсе директоры.

...Минем «математика буенча истәлек дәфтәре» дип йөртелә торган дәфтәрем бар иде. Әйбер төрү өчен эшләнгән сары кәгазьдән, зур форматлы итеп тегелгән ул дәфтәрне миңа сугыш барган чорда, кәгазьгә иң кытлык вакытта, үземнең бер укучым бүләк иткән иде. Аңа кайдандыр посылка белән җибәргән булганнар.

Шул кадерле дәфтәрнең тышлыгына мин «Математиканың катлаулы мәсьәләләрен җиңел чишә ала торган кеше, тормышның үтә четерекле мәсьәләләрен дә җиңел хәл итә алачагына ышанам» — дип язып куйган идем. Бүгенге көндә, минем шул дәфтәрем тышлыгына язган фикеремнең дөреслеген раслаган укучыларым аз түгел. Алар ил күләм, дөнья күләм мәсьәләләрне чишәләр.

Менә шундыйларның берсе — Зөфәр Газизович Шәйдуллин.

Кәләй — шәһәрдән ун-унике чакрымнар ераклыктагы крәшен татарлары авылы. Берләшмәнең — аны районда әле һаман элеккечә «Кичү» совхозы дип йөртәләр — үзәге шунда урнашкан. Халкы — эш сөючәнлегеннән бигрәк, бәйрәмнәр яратуы белән танылган халык. Нинди генә бәйрәмнәр юк аларда! Хәтта, «Әтәч бәйрәме» дип йөртелгәненә кадәр бар. Шулар янына халкыбызның традицион бәйрәмнәрен, модага әйләнеп киткән «туган көн»нәрне, туйлар, юбилейлар һәм атнага ике ял көнен дә өстәсәк, хәл үзеннән-үзе аңлашыла торгандыр.

Кешенең бәйрәмнәрдән соңгы кәефе билгеле инде. Менә шуның өчен биредә эшләүче җитәкче кешегә икеләтә авыр.

— Күрегезче! Өч ел вакыт эчендә Кәләй ничек үзгәргән! — дип, соклануымны белдермичә булдыра алмадым мин шофер егеткә.

— Хәзер без аны үзебез дә «Кәләйград» дип йөртәбез! — диде ул, ике яклап тезелгән кирпеч йортларга ишарәләп.— Бусы — «Яшьләр урамы»! Совхозның яшь терлекчеләре яши. Болары — быткомбинат, балалар бакчасы, культура сарае, кибет. Сез аның эчен күргәнегез бармы соң әле? Бөтенләй көзгедән генә тора ул. Белоруссия осталары үрнәгендә эшләделәр аны. Колшәрип ягында да шундый ук. Ә менә терлек симертү комплексын күрсәгез, исегез китәр.

...Иртәнге сәгать дүртләр-бишләр тирәсендә идарә ишек төбе автовокзалны хәтерләтә. Төрле-төрле маркалы дистәләгән машиналар үзләре тирәсендәге кешеләр төркемен төяп, төрлесен-төрле якка алып китеп бетерә.

— Болар барысы да үз кешеләрегезме соң, Зөфәр Газизович,— дип сорыйм мин.

— Совхозда эшләүчеләрнең җитмеш проценты — үзебезнекеләр.

— Әйбәт! Шәһәр борын төбендә генә, ничек тотып тора аласыз?

— Яшьләрне солдатка зурлап озатабыз, шартлар тудырып, каршы алабыз. Теләсәләр укырга җибәрәбез аларны. Акчалата ярдәм дә бирәбез. Өйләнешүче яшьләргә комсомол туйлары үткәрәбез. Аларның кулларына, бүләкләр белән бергә, квартира ачкычы тапшырабыз. «Яшьләр урамы»нда бөтен уңайлыклары булган, икешәр семьяга исәпләп төзелгән, икешәр-өчәр бүлмәле егерме биш яңа йортыбыз бар инде. Ел саен шундый ун йорт салабыз. Үзе төзергә теләүчеләргә материаллар, ссуда бирәбез.

— Хәзерге яшьләрне ул гына да канәгатьләндерми бит...

— Рухи ихтыяҗларны әйтәсез инде сез. Анысын да истә тотабыз. Район күләмендәге бөтен төр спорт ярышларында да без, биш ел рәттән инде, җиңүчеләр булып киләбез. Сабан туйларындагы ат ярышларында һәр елны беренче биш урынны без яулап алабыз. Кышкы спорт ярышларында да беренчелек бездә була. Спорт буенча методистыбыз бар безнең.

Культура йорты каршында көрәш, гер күтәрү, бокс секцияләре эшли. Үзешчән сәнгать ярышларында да без җиңәбез. Культура бүлеге дә бүләкли аларны. Совхоздан да өстибез.

— Безнең хуҗалык 1978 елдан бирле дәүләткә табыш китерә. Менә шул табышның социаль-культура бүлегенә каралган өлеше ярап куя! Шуларга байраклар белән бергә бирелгән бүләк фонды да өстәлә әле...

Минем уйларым тагын Зөфәрнең мәктәп елларына әйләнеп кайтты.

Шигырьләр яза иде ул. Һәм шуларны зур тәнәфесләрдә, клуб сәхнәләрендә үзе укый иде. Шигърият һәм эшәкелек янәшә яши алмый. Җырлы күңел — нурлы күңел ул!

Шул турыда сүз чыгу белән:

— Ул әле хәзер дә, берәр җиргә озаккарак китсә, хатларын шигырь юллары белән яза. Яшьлек елларыбызда мине дә бәйрәмнәрдә гел шигырьләр белән тәбрикли иде,— дип, сүзгә кушылды, гадәттәгечә тыйнак һәм сабыр гына итеп, гомер юлдашы Сәвия.

Бүлмәләрнең берсендә бөтен бер стенаны диярлек алып торган китап шкафыннан Сәвия бер бәйләм хатлар алып килде.

Арасыннан берсен укый башладык. Ике бит кәгазьне шыплап тутырган бу хат шигырь юллары белән язылган һәм ул: «Сөекле улым Зөлфир!» — дип башланган иде.

— Улыгыз кайда соң әле үзе?

— Мәскәүдә, командировкада...

Хатлар актарганыбызны күреп:

— Әтинең миңа язган хатлары да бар! — диде кулына бәйләм эше тотып утыручы Зөлфирә. Ул — институт тәмамлап эшли башлаган олы кызлары.

— Лилиягә язылганнары да — гел шигырь,— дип өстәде әниләре Казанда институтта укучы кызын искә төшереп.

Күкрәккә сыеша алмаганлыктан, тышка бәреп чыгып, кәгазьгә шигырь булып тезелгән хисләр! Бәхетле кеше Зөфәр Газизович, бик бәхетле кеше! Улы, килене, кызлары аның тирәсендә «әти, әти» — дип, бөтерелеп йөриләр. Ә икенче класста укучы төпчек уллары Марсель аның тезеннән дә төшми. Җылы, йомшак, ягымлы мөгамәлә бөтен өй эчен нурландырып тора. Бу күренеш Зөфәр Газизовичны минем күз алдымда икеләтә үстереп җибәрде һәм аны буй җитмәс биеклеккә күтәрде. Чын-чыннан бәхетле ул бүген. Озак еллар буена көрәшеп, хезмәт һәм тырышлык белән яулап алынган бәхет бу.

Әтиләре Газиз ага 1942 елны Сталинград өчен барган героик көрәштә батырларча үлеп кала. Бу вакытта Зөфәргә нибары ун яшь була. Әниләре дүрт сабые белән утыз яшендә тол кала. Институтны тәмамлап эшли башлау белән үк Зөфәр белән Сәвия аны үз тәрбияләренә алалар. Сәвиянең әнисе белән сеңлесе дә сыя алар янына.

Институт тәмамлаганнан соң МТСлар каршында өч ел өлкән ветврач булып эшли Зөфәр. Аннан соң аны, ул вакыттагы СССР Верховный Советы депутаты, Һади ага Разманов үз районыбызга, үзе председательлек иткән «Зәй» колхозына чакырып ала.

Һади ага кул астында ул унөч ел өлкән зоотехник, өч ел баш ветврач булып эшли. Шушы елларда терлекчелек өлкәсендәге уңышлары өчен Зөфәр Газизович Бөтенсоюз Халык Хуҗалыгы Казанышлары Күргәзмәсенең көмеш һәм бронза медальләре белән, орденнар белән бүләкләнә. Һәр сыердан сөт савып алу күләмен 1800 литрдан 3145 литрга чаклы күтәрүгә ирешәләр алар.

— Бу еллар минем өчен хезмәтемнең нәтиҗәсен күрү шатлыгын кичергән иң истәлекле елларым булды. Һади ага кул астында тормыш мәктәбен үттем мин,— дип сөйли Зөфәр Газизович үзенең «Зәй» колхозында эшләгән чоры турында.

Инде менә 1976 елдан бирле «Кичү» совхозында. Шушы арада эшләнгән эшләр дә шактый.

Бүгенге көндә совхозда 9500 баш терлек һәм 8000 гектар чәчү мәйданы хисаплана. Терлекләрнең 6000 башы бөтен уңайлыклары булган, бөтен эше механикалаштырылган комплекста тәрбияләнә. Тәүлеккә 850 граммга кадәр үсеш алуга ирешәләр терлек караучылар. Быел хуҗалыкта 35000 центнер ит җитештерелергә тиеш.

Моннан тыш башкарылачак эшләре турында директор:

— Үзебезнең шефлыктагы дүрт оешмага 18500 бройлер чебиләр бирдек. Аларны җитәрлек күләм комбикорм белән тәэмин иттек,— дип аңлата.— Нәтиҗәдә 350 центнер кош ите алынды. Алар шул оешмаларның үз эшчеләренә дәүләт бәясе белән сатып бирелде.

Райпога 60 гектар җир, каралтылар биргән идек, алар анда каз, үрдәк, мөгезле эре терлек симертеләр. 600 центнерга якын ит хәзерләделәр.

Шәхси хуҗалыкларда кош-корт, терлек асрау өчен дә шартлар тудырырга тырышабыз. Совхозда эшли торган терлек асраучы һәр кешегә печән, 3 центнердан 5 центнергача салам бирәбез. Мөмкинлектән чыгып, комбикорм сатабыз. Авыл интеллигенциясен дә игътибарсыз калдырмаска тырышабыз. Хуҗалыктагы малларның саны елдан-ел арта.

Безнең төп максат — продукциянең үзкыйммәтен киметү, сыйфатын яхшырту, күбрәк табыш алып, халыкның көнкүреш дәрәҗәсен күтәрү. «Кадрлар барысын да хәл итә» дигән канатлы сүз һаман да үз көчендә кала бит әле. Безнең хәзер махсус урта һәм югары белемле, яхшы хәзерлекле 35 яшь белгечебез бар. 40 эшчебезне Мәскәү янындагы Воровский исемен йөртүче совхоз каршында оештырылган кыска сроклы курсларда оператор эшен башкару өчен укытып кайтарттык. 12 кешебез институтта һәм техникумнарда читтән торып укый. Урта мәктәптә укучы яшьләребез, унынчы классны тәмамлау белән үк, үзебезгә эшкә киләбез дип торалар. Җәйге каникул вакытларында булышалар.

Терлекчелектә эшнең уңышлы булуы, турыдан-туры кырчылыктагы эшнең уңышлы баруына килеп тоташа. Бу яктан да йөзгә кызыллык килерлек түгел икән. Зөфәр Газизович:

— Моңа кадәр мине күбрәк зооветеринария яңалыклары кызыксындыра иде. Хәзер инде менә агрономия белән мавыгам,— дип сөйли.— Махсус әдәбият алдырам. Союзның сортлы орлыкчылык станцияләре белән элемтә тотам. 1979 елны Башкортстанның «Чишмә» селекция станциясе корылыкка чыдамлы арыш алып кайтып, 900 гектар мәйданга чәчкән идек. Коточкыч корылык булды, шуңа да карамастан, гектардан уртача 31 центнер җыеп алдык. Кайбер участокларда 50 центнергача булды.

Омскидан солының яңа сортын алып кайтып чәчтек. Уртача 35 центнер уңыш бирде. Авыл хуҗалыгы эшчәннәренең бәйрәм көнендә күргәзмә залына куелган гранулаланган яшел кукуруз онын хәтерләдегез микән? Республикада беренче булып без ясадык ул уңышлы тәҗрибәне. Терлекләр өчен бик файдалы...

Әнә шулай, әле һаман яңадан-яңа мәсьәләләр чишә, Габдрахман урта мәктәбендә математика мәсьәләләрен отличного чишәргә өйрәнгән Зөфәр Шәйдуллин. Эш өстәленә ачып куелган көндәлек дәфтәренә генә игътибар итик без аның. Иртәгә үк хәл ителергә тиешле мең дә бер шөгыль язылган анда.

Остаз һәм шәкертләр бүген тагын очраштылар.

«Ярыш» колхозы һәм «Кичү» совхозына, 1982 елгы хуҗалык елындагы уңышлары өчен байраклар тапшырылды ул тантанада.

Кайчандыр Самат Сираевич һәм Зөфәр Газизовичлар, бер үк кошның ике канаты сыман, Һади абыйны һәм ул җитәкли торган колхозны биеккә күтәрергә ярдәм иткән булсалар, хәзер инде үзләре шул нигездән старт алып, зәңгәр киңлектә остазларыннан югарырак очалар.

Азат Вергазов

# ГОМЕР САГЫНДА

ОЧЕРК

Көз иде. Түгәрәк күлне һәр яктан әйләндереп алган усак-каеннарның яфраклары саргаешып җиргә коела. Төньяктан искән җилдән су өсте шадраланып килә, гүя җан өшеткеч салкыннан күл дә туңып-калтырана кебек.

Күлнең аргы текә ярында ике кеше күренде. Алар, сукмактан килеп, камышлы су читенә төштеләр. Озын буйлысының кулында озын саплы соскыч сыман нәрсә дә бар. Ул, шуны суга чумырып, күл төбеннән нидер эзләп маташты. Бераздан алар икәүләп кара-кучкыл ләм чыгардылар. Соскыч башына ябышып чыккан балчыкны бармакларында җентекләп изеп карадылар. Үзара сөйләшкәләп, бу эшне тагын кабатладылар. Чыккан балчыкны тагын изгәләделәр, бәхәсләшеп тә алдылар. Кыска буйлысы, кулын селтәп, кире китмәкче булды. Тик, иптәшенең аякларын чишенә башлавын күреп, тукталып калды.

— Тилердеңме әллә? Бозлы суга кереп...

Озын буйлысы:

— Ул арада гына берни булмас! — диде дә ярым чишенгән көе салкын суга кереп тә китте. Билдән суда торган хәлдә кызу хәрәкәт белән соскычны күл төбенә батырды. Һәм, табышын кулына тотып, текә яр читенә ашыкты.

Бу — шул үзе, алар эзләгән шифалы ләмгә ия балчык иде. Билгеле, аның шифа үзлеге махсус анализ-тикшерүләрдән соң гына тулысынча ачыкланды. Әмма моңа беренче тапкыр игътибар итү бик кирәк иде. Бу ачышны исә югарыда телгә алынган озын буйлы кеше — Казанда яңа ачылган санаторий-профилакторийның баш врачы Ибраһим Гашигуллович Гашигуллин ясады.

Курортлар идарәсенең физиотерапия фәнни-тикшеренү институты үткәргән кызыклы мәгълүматка күптән юлыкты ул: белгечләр 1957 елны ук Казан янындагы Зәңгәр күлдәге ләмле балчыкның дәвалау үзлегенә ия булу мөмкинлеген чамалаганнар икән.

Алтын балык тоткандай булды Ибраһим Гашигуллович. Ләкин бу «алтын балык»ны профилакторийга ташуы бик кыен булып чыкты. Ләм алына торган урында яр бик текә, аңа берничди транспорт белән дә якын килерлек түгел. Бульдозерлар яллап, яр буен тигезләтү врачка мең төрле яңа мәшәкатьләр тудырды. Әмма ул үз сүзеннән кире кайтмады, эзләгәнен тапты, профилакторийда дәвалауның бик үтемле яңа чарасын куллануга иреште.

Шуннан соң гына бу ләм бүтән дәвалау йортларын: ГИДУВны, Васильево санаторием да кызыксындыра башлады.

* * *

Иртә. Дөньяны томан каплаган. Ибраһим Гашигуллович шушы аксыл тыгызлык аша еракка төбәлеп карый, гүя нәрсәнедер күрергә тырыша. Тик берни дә ачылып китми. Күңел үз эчендә кайный башлый, хәтердә үткәндәгеләр яңара...

...Казан медицина институтын тәмамлаганнан соң Ибраһим ун ел буе Апас район больницасында баш врач булып эшләде. Аның тырышлыгы аркасында үзәк больницаның яңа кирпеч бинасы салынды, аңа өстәп, 35 урынлы инфекцион больница да булдырылды. Райондагы фельдшер-акушерлык пунктлары артты. Кыскасы, районда медицина хезмәте күрсәтү шактый яхшырды.

1966 елның августында Ибраһим Гашигуллович «Казантатхимстрой» оешмасы карамагындагы санаторий-профилакторийның баш врачы итеп алынды.

Дәвалау, профилактика йорты әле яңа төзелеп килә иде. Ул бик матур урында — анысына тел-теш тидерерлек түгел, тик бина гадәти торак йорт проекты буенча салынып ята. Ибраһим Гашигуллович кирпеч, измәләр арасында әрле-бирле йөри, аның зәңгәр күзләре уйчан, эчендәге уйларын тәкърарлап, иреннәре генә селкенә: «Монда — физиотерапия кабинеты, врач бүлмәсе булса, теге якта — торак өлеше, аргы башта — ашханә-кухня. Су процедуралары өчен урын кайда? Бу бүлмәләр дәвалау кабинетлары өчен дә ярап бетми. Кухня да җайлы урында түгел. Димәк, бинаны үзгәртеп салырга кирәк!»

Мондый сүзне әйтергә генә ансат. Күпме өстәмә материал булдырырга, аларны китертергә, эшкә кертергә... Моның өчен көнозын чабарга, төрле оешмаларга мөрәҗәгать итәргә, бик күп кешеләр белән уртак тел табарга кирәк. Уйлый торгач, төрле процедуралар, душ-ванналар өчен дә урыннар ясалды: йортның подвалыннан файдаланырга булдылар. Җылыткыч ванналар, шифалы балчыкны изеп кайнарлату өчен махсус җайланмалар эшләнде.

Төзелеш барганда ук, баш врач дәвалау йортының кадрларын: врачларны, шәфкать туташларын, пешекчеләрне, җыештыручыларны туплый торды.

Врач Людмила Михайловна Королева, завхоз Бәдыйгъ Галиевич Вәлиев, медсестра Наилә Миңлевәлиевна Хатипова, пешекче Анастасия Степановна Никифорова санаторий-профилакторий ачылуның беренче көннәреннән үк шунда эшли башладылар.

Яңа дәвалау йортында иң файдалы процедуралар җайга салынды: ылыслы, күкертле, «энҗеле», диңгез суы ванналары, электр ярдәмендәге дәвалар, массаж, физик күнегүләр, диетик туклану — барысы да кеше гомерен озайтуга хезмәт итә.

Ниһаять, дәвалanучылардан беренче рәхмәтләр ишетелә башлады.

Эшен намус белән башкаручыларны да ике төрлегә бүләргә мөмкин: беренчеләре барлык мөмкинлекләрдән оста файдаланып алны-артны белми, бик тырышып эшлиләр, икенчеләре исә булганга гына канәгать түгел. Аларның карашы еракларак төбәлгән, эшнең бүгенге колачы гына аларны канәгатьләндерми, киләчәктән күбрәкне көтәләр алар.

Ибраһим Гашигуллович та, гомере буе, ирешелгәннәрдән генә канәгатьләнә алмыйча иҗат итә. Аның күңел түрендә һәрдаим тынгысызлык яши. Шул тынгысызлык Ибраһим Гашигулловичны илебезнең ил алдынгы санаторий-профилакторийларында йөртә, иң кыю белгечләр белән киңәшкә чакыра һәм яңа ачышларга этәрә. Мәскәү, Одесса, Ярославль санаторий-профилакторийларындагы төрле процедуралар кабул итүнең алдынгы ысуллары, ясалма юл белән күкертле су ванналары булдыру, кислород күбеге, энә белән дәвалау кебек эффектлы чаралар үзләштерелде.

*
* *

...Ул гадәттәгечә салмак адымнар белән профилакторийга килеп кергәндә, монда инде эш башланган: вестибюльләр, коридорлар ялт иткән, пешекчеләр, тирә-юньгә тәмле ис таратып, иртәнге ашны әзерләп йөриләр.

— Хәерле иртә. Тәртипме?

— Әйе. Беренче диета өчен ит тә хәзер пешеп чыга.

— Ниләр җитешми?..

Хезмәттәшләренең үтенечләре баш врачның блокнотына язылып куела.

ак халатлы осын буе әле анда, әле монда чагылып кала. Бар нәрсә дә тәртиптәме, нәрсә җитешми,ниләр булдырырга кирәк? Баш врач бүлмәсендә үткәреләторган иртәнге киңәшмәләр вакытында бу җитешсезлекләрне бетерү чаралары билгеләнә. Көн дә чыгып торган кимчелекләрдән котылу, нигездә — Ибраһим Гашигулловичның үз өстендә. Катлаулы мәсьәләләрне чишүдә ул еш кына «Казанхимстрой» тресты җитәкчеләренә мөрәҗәгать итә.

Процедуралар кабул итү вакыты җиткәч, баш врачның төп игътибары тулаем аларга күчә.

Ап-ак ятакларда кайнар парафинга төренгән авырулар ята.

— Рәхмәт, буыннарның сызлавы басыла бара, доктор,— дип кала аңа олы яшьтәге мыеклы абзый.

— Тагын да кайнаррак итеп булмыймы бу парафинны? — ди бер егет.— Маңгаеңнан атылып тир чыкмагач азы...

Баш врач нинди температурада дәвалануның шифасы зуррак булуын аңлатып үтә. Егет ризалашканын белдереп елмаеп куя.

Ибраһим Гашигуллович соңыннан медсестра Гөләндәм Минһаҗевага күрсәтмә бирә:

— Менә нәрсә, сеңелем, бүген кич белән сездә дәваланучыларның барысын да үз бүлмәңә җый. Мин алар белән бу процедура хакында әңгәмә үткәрермен. Чөнки дәвалау чарасының шифалы булуына авыруның ышануы бик мөһим.

Баш врач су процедуралары бүлегенә кергәндә, медсестра Мәдинә Сәфиуллина җырлый-җырлый ванналарга су агыза иде. Кызның моңлы, йомшак тавышы, сәер яңгырап, бар бүлмәләрдә ишетелеп тора. Ылыслы ваннада ятучы бердәү:

— Безнең Мәдинә сулар белән генә түгел, җырлары белән дә дәвалый безне,— дип куйды.

— Дөрес сүз бу,— ди баш врач.— Мәдинә килгәнче, без бу бүлмәләрдә репродуктор аша музыка уйната идек. Хәзер репродукторның кирәге калмады.

Ибраһим Гашигуллович шаяргандай әйтсә дә, бу сүзләрендә хаклык та бар икән. Балчык белән дәвалау бүлмәсендә репродукторлардан талгын гына көй агыла. Кайнар ләмгә төренеп яткан кешеләргә шифасы да тия сыман. Баш врач янына кечерәк кенә гәүдәле, җитез хәрәкәтле Гөлфәридә Сабирова килеп җитте.

— Бар да тәртиптә, иптәш баш врач,— диде ул кара тутлы йөзендә нур уйнатып.— Бүген берниндн дә зарыбыз юк.

— Сезнең дә юкмы? — дип сорады Ибраһим Гашигуллович аксыл йөзенә бик килешеп торган зур пыялалы күзлек кигән Наилә Хатиповадан. Тегесе, баш врач ниндидер гаебебезне тапты, ахры, дигәнрәк тавыш белән:

— Юк... Ә нигә? — дип сорап куйды.

Баш врач көлемсерәде:

— Зарыгыз булмаса, бик яхшы!

Югары катта физиотерапия бүлмәләре тезелеп киткән: электрофоарез, гальваник яка, кварц, УВЧ, Бернард тогы, амплипплюс аппараты, ультратавыш белән дәвалау җайланмалары. Бу комплекста авырулар белән бик йомшак мөгамәлә итүче тәҗрибәле медсестра Рокыя Абдрахманова һәм яшь кыз Венера Абдрахманова эшли. Монда чисталык, тынлык хөкем сөрә. Медсестралар үзләре дә пышылдап кына сөйләшәләр.

Тынлыкны ятагында йокыга киткән авыруның гырылдавы боза. Рокыя аның янына ашыга.

— Электрофоарез кабул иткәндә, йокларга ярамый.

— Төнне йоклый алмадым,— ди әлеге авыру.— Бүлмәдәшем форточканы ачып йоклый, борын тыгылган.

Икенчесе сүзгә кушыла:

— Ә мин синең гырылдавыңнан йокыга китә алмый интегәм...

Барысын да игътибарга алырга кирәк. Монда эшләүчеләрнең төп сыйфаты бу. Кешеләрнең һәр үтенеченә үтә сизгер булу үрнәген Ибраһим Гашигуллович үзе күрсәтә.

Көндәлек эшләре муеннан булса да, Гашигуллин санаторий-профилакторийдагы дәвалау методикасы буенча эзләнүләр дә алып бара. Ул күп укый, үз тәҗрибәсен гомумиләштереп, фәнни нәтиҗәләр чыгара.

— Минем уйлавымча,— ди ул,— кеше үзенең төп җирлеге булган гадәтләнгән эшеннән аерылып дәваланганда, психологик киртә үтәргә мәҗбүр. Ә санаторий-профилакторийларда мондый хәл булмый: кеше дәва ала да, эшен дә дәвам итә. Шунлыктан санаторий-профилакторийларның киләчәге зур.

Ибраһим Гашигуллин үзенең ачышлары белән матбугатта да чыгышлар ясый, барлык эзләнү һәм табышларын туплап, китап бастырырга да әзерләнә.

Аның эш өстәлендә бер альбом саклана. Аңа илебезнең төрле почмакларыннан бу санаторий-профилакторийга алдынгы тәҗрибә өйрәнергә килгән белгечләрнең фикерләре теркәлгән.

«Ял һәм дәвалау өчен төзелгән бу сәламәтлек сараен зур канәгатьләнү белән карап чыктык. Чисталык, уңайлык, менә дигән медицина җиһазлары. Игътибарлы һәм кайгыртучан кешеләр...» (Владимир, Новокуйбышевск, Тула өлкәсенең санаторий-профилакторий врачлары.)

«Гаҗәпләндек», «Исебез китте» кебек сүзләрне Мәскәү, Ленинград, Ростов, Луганск, Омск, Тамбов, Чиләбе, Краснодар, Волгоград, Саратов, Оренбург, Ульяновск, Пенза, Пермь өлкәләреннән, Башкортстан, Якут, Удмурт, Мари, Мордва АССРлардан килүче врачлар язып калдырганнар.

Монда хәтта Румыния, Монголия, Марокко, Австралия кебек илләрнең профсоюз делегацияләре дә булып киткән. Врач Ибраһим Гашигуллин башлап җибәргән эшкә карап, алар да соклангач.

Үз эшенә биектән карап, алдагыга таба омтылу турында әйткән идек. Үр арты үр яулангач, син дә башкалар үрнәк алырлык биеклеккә әйләнәсең икән.

Ибраһим Гашигуллович кәгазьләрдән арынып тәрәзә аша яшәреп күренгән бакчага карады.

— Әнә анда,— ди ул үз алдына сөйләнгәндәй итеп,— фин тибындагы мунча салырга уйлыйбыз. Сауна диләр аны. Пар белән дәвалап карарга исәп...

Киләчәккә өметләр бихисап, һәм врачтагы тәвәккәллек аларның тормышка ашачагына ышандыра.

**Мирза Мәхмүтов,**

СССР Педагогия фәннәре академиясе академигы

# ТАРИХИ БУ БЕРГӘЛЕК

«Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез «халык шигырьләрен» туплар да ватмады, уклар да кадамады... Алар сәламәт әле; алар яңгырый әле»... Бөек шагыйребез Габдулла Тукай тарих катламнарыннан күтәрелгәндә, тормыш-көнитеш карурманнарын кичеп чыкканда сау, саф көе калган халык рухы турында менә шулай тыгыз, олы мәгънәле итеп әйткән. Шәһәрләрен яулар җимерсә дә, китапларын ут ялмаса да, уртак ватанда күршеләре белән «тел, логать, гадәт вә әхлак алмашып» яшәгән халкыбыз үз күңелендәге зур культура мирасын җуймыйча гасырлар тирәнлегеннән килә. Аның әкиятләрендә сакланган өмет-хыяллары чынга ашып бара, уллары-кызларының батырларча хезмәте риваять-эпос каһарманнарына тиң. Аның җыр-моңнарында — күңел яктысы, уйлар сафлыгы.

Бүген Бөек Союзның күпмилләтле гаиләсендә чәчәк атучы татар халкы үз шәҗәрәсен тарихның кайсы катламнарыннан башлый? Кемнәр соң алар — татарлар, кайдан килеп чыкканнар соң алар?..

«Татарлар килә!» Әледән-әле Европаны сискәндереп уяткан шушы аваз, Уралдан алып Вислага хәтле илләрне, халыкларны шомга салып, гасырлар күкрәгендә яңгыраган, үз юлындагы шәһәр һәм авылларны көл итеп, талау, көчләү һәм үтерүләр өермәсе булып узган.

«Татарлар килә!» Атылган ук кебек ашкын, кылыч йөзе кебек рәхимсез яуларның канлы юлын тарих әнә шундый яңгыравыклы исем белән теркәп калдырган. Күп кенә халыклар хәтеренә «татар» сүзе хәтәр булып, усал һәм вәхши көч мәгънәсендә уелып калган. Шул заманнардан башлап төрле телләрдә татарга каршы мәкаль-әйтемнәр, такмак-такмазалар иҗат ителгән, буыннан-буынга, «явыз татар» турында әкият һәм риваятьләр күчеп килгән.

Кызганычка каршы, аныклык урынына хата фикер тудыручан кайбер галимнәр, башка халыклар тарихына йөз чөеребрәк караучы, тарихи вакыйга һәм фактларны сыйнфый күзлектән чыгып бәяли белмәгән кайбер хезмәтләр әле дә үз эшен эшли: акны карадан аера алмаган, чикләнгән карашлы кайберәүләрнең хәтта бүгенге татар халкына да үпкәсе бар шикелле.

Куликово кырындагы тарихи сугышның 600 еллыгын бәйрәм иткән вакытта бер танышым, шаярган-көлгән булып кына миннән: «Безнекеләр анда сезне кыйнаганнармы соң?» дип сораган булды. «Юк шул, безне түгел!» — дидем мин. Шаярып кына әйтмәдем, йөзем җитди иде.

Әйе, безне түгел! Тарихны яхшы белгән, үз халкын һәм башка халыкларны хөрмәт иткән кеше болай шаярта алмас иде.

...«Һуннар килә!» Ачыргаланып кычкырган шул авазны басып, халыкларның тыныч тормышын сытып-изеп Европада тояк тавышлары яңгырый.

Диңгез булып кан ага, шәһәрләр җир белән тигезләнә. Татарлардан күп гасырлар элек (V гасыр урталарында ук) зур кабилә берләшмәсе төзеп, һуннар башка халыкларны буйсындыру юлы белән көн күрәләр.

Европада, гомумән, дәһшәтле еллар, гасырлар күп була. Килмешәкләрдән дә уздырып, бишенче йөздә вәхши герман кабиләләре Көнбатыш Рим империясен талыйлар, антик осталар тудырган гүзәллек дөньясын җимерәләр...

Ләкин халыклар тарихы — сугышлар тарихы гына түгел. Һуннар кузгаткан Бөек күчеш вакытында Идел-Чулман буйларына да үз җирләреннән аерылып киткән төрле кабиләләр килеп урнаша. III—IV йөзләрдә үк бу төбәктә яшәгән төркиләр нәкъ менә Идел — Урал җирләренә үтеп кергән һәм шунда төпләнеп калган һуннарның варислары булырга тиеш. Һуннар Җиһангире кыю Атилланың да исемендә «Идел» (Әтил-ле, Идел-ле) сүзенең ерак кайтавазы яңгырамый микән әле?

Гасырлар үткән, күп сулар аккан, дистәләгән халык һәм кабиләләр «бер дә булмаган төсле кырылганнар да беткәннәр»: берәүләрен көчлерәк йоткан, икенчеләре яшәү өчен тигезсез көрәштә һәлак булган. Өченчеләре, үзләре тарих комына күмелеп калмасалар да, исемнәрен җуйганнар, нәсел-нәсәпләре очын югалтканнар. Әйе, борынгылык эзе шәһәр казылмаларында һәм кабер ташларында гына түгел, исем-атамаларда да уелып калган. Мәсәлән, һуннардан соң күп заманнар алышынгач, кире үз яклары, Керулен ярларына кайтып китүче монгол яуларыннан аерылып, кайбер кабиләләр Иделнең уң як ярында калган. Төркичә «калу» — «калмак» сүзенең әлеге кабилә исеменә («калмык») күчүендә, әнә шулай итеп, тарих тамгасы ята.

Иделнең урта агымында исә, Идел белән Урал арасында IX гасырның соңгы чирегендә хәзерге венгрларның бабалары мадьярлар яшәп яткан. Төрки телле болгарлар, чувашлар, угрофин кабиләләре — мордва, мари, удмуртлар үзара тел-легать алмашып, яу килгәндә бер-берсенә калкан булып көн күргәннәр. Идел буе киңлекләреннән башка бик күп халыкларның да юллары, язмышлары үткән: баскынчылык итүчеләрнең дә, күчмә тормыш белән яшәүчеләрнең дә.

Болгарлар кайдан килеп чыккан соң бирегә? Аларның борынгы ватаны VII гасыр башында Кубань һәм Азов диңгезе буйларында төзелгән Бөек Болгар иле түгелме соң? Тарихтан мәгълүм: бу төрки телле илнең башкаласы Таман ярымутравы булган. Кубрат хан заманында Бөек Болгар чәчәк ату, көчәю чорын кичерә һәм Төрки каганлык йогынтысыннан котыла. Ләкин беркадәр вакыт үтү белән, аны Төньяк Кавказ итәкләренә ыргылучы гарәпләр һәм күрше хазарлар кысрыклый башлый. Шуның өстенә кабиләара тарткалашулар, феодал-тарханнарның этле-мәчеле яшәүләре бу дәүләтне шактый хәлсезләндерә. Кубрат ханның үлеме кабиләләр бердәмлеген тагын да йомшарта. Болгар иле, корт анасы үлгән күч сыман, таркала-туза башлый.

«Болгарлар килә!» Азов ярларында яшәп яткан «вәхшиләр», Византиялеләрне гаҗәпкә калдырып, бөтенләй көтелмәгән яктан Кара диңгезнең кояш баешы ягыннан пәйда булалар. VII йөз ахырында Кубратның улы Аспарух хан байрагы астында, болгар кабиләләренең бер өлеше күчмә халыкларга таныш юллар буйлап Көнбатышка таба кузгалып китә һәм, бара торгач, Дунайның түбәнге агымы белән юылучы җирләрдә туктап кала. Җирле славян кабиләләре белән иңгә-иң торып, болгарлар куәтле Византия империясенә каршы торалар, аның майлы калҗа эзләп сузылган кулларын «кыскарталар». Тора-бара, славян кабиләләре белән аралашып-кушылып, төрки телле болгарлар әлегәчә булмаган яңа халыкка әверелеп яши башлыйлар. Славян телен кабул итсәләр дә, исемнәре «болгар» булып кала, вакытлар узу белән мәҗүси аллаларын онытып, Византия православиесенә күчәләр... Дунай

буйларындагы Болгария дигән илнең яңа шәҗәрәсе әнә шул заманнардан килә.

Кубратның икенче улы Батбай, кабиләдәшләрен үз тирәсенә туплап, төп нигездә, ата-бабалары туфрагында торып кала. Ләкин хазарлар һәм гарәпләр басымы астында әлеге кабиләләр («кара болгарлар») шулай ук шәһәр һәм авылларны ташлап, Төньяк Кавказ таулары арасына көчеп китәргә мәҗбүр булалар. Шул төбәктә яшәүче төрки телле балкарларны, карачайларны галимнәр нәкъ менә шул кабиләләрнең варисы дип уйлыйлар.

Ниһаять, хазарларның эзәрлекләп торуына түзә алмыйча, болгарларның өченче төркеме, Кубрат ханның өченче улы Котраг җитәкчелегендә, Кубань һәм Дон буйларыннан кузгалып, озын юл үтеп, Идел һәм Чулман (Кама) буйларындагы урман-далалар куенына килеп сыена.

Төрки телле, мәҗүси динле болгарларны Идел белән Кама кушылган урында элек-электән яшәп яткан төрки кардәшләре каршы ала. «Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява» торган төбәкне, уңдырышлы кара туфракны болгарлар үз итәләр: иген игә, бакча утырта башлыйлар, авылларга нигез салалар. Күршедә генә яшәгән күчмә мадьярлар аларга иген игүдә комачауламыйлар: яңа хуҗалар үстергән икмәктән аларга да өлеш тия. Мадьяр кабиләләре бу төбәктә туктап кала алмыйлар, далалар буйлап сәфәрләрен дәвам итеп, Көнбатышка барып чыгалар, һәм, ниһаять, Европаның үзәгендә, Тисса һәм Дунай сулары арасындагы уңдырышлы туфраклы, чәчәккә күмелгән үзәнлектә торып калалар. IX гасыр ахырында анда артык зур булмаган мадьяр дәүләте (Венгрия) барлыкка килә.

IX гасыр азагында болгар, суар, берсула, эсегел кабиләләре үзара якыная башлап, кабилә берләшмәсе төзиләр, үз тирәләренә башка кабиләләрне дә туплыйлар. Төрле кабиләләрнең үзара дошманлашып алулары бөтенләй бетмәсә дә, көнчыгыш Европада Киев Русе шикелле беренче дәүләтләрдән булган Идел — Кама Болгар иле барлыкка килә. Тарихи язмаларда ул заманына күрә көчле, бай, мәдәниятле ил буларак билгеләп үтелә. Биләр, Суар, Болгар шәһәрләре гасырлар дәвамында чиратлашып Болгар иленең башкаласы булып торалар.

Шилке хан Болгар падишаһлары нәселенә нигез сала, бу династия аның варислары — Шилкенең улы Алмыш, Алмышның улы Әхмәт һәм башка ханнар тарафыннан ныгытыла килә. Көчле дәүләт белән ерак һәм якын күршеләре дә исәпләшергә мәҗбүр булалар. Марилар, башкортлар һәм чувашлар белән генә түгел, ерак Киев Русе белән дә дуслык элемтәләре җайга салына. Алмыш хан заманында ук куәтле Багдад хәлифәлеге белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаша һәм алга таба тагын да ныгый төшә. 920 елда Болгар рәсми рәвештә ислам динен кабул итә, Алмыш хан үзенә әмир Җәгъфәр бине Габдулла дигән гарәпчә исем ала.

Шул заманда Көнчыгыш Европада телгә алырлык ике генә дәүләт булган: Киев Русе һәм Идел — Кама Болгары.

Гасырлар үтә, Идел, Кама, Чирмешән буйларында туктап күчмә халыклар, дала сугышчылары атларын сугаралар, болгарлар тыныч уртак тормыш белән яшәүләрен дәвам итәләр, елъязмалар билгеләп үткәнчә, гадел сәүдә итәләр, хәрәмләшүне кичермиләр, үзләре тәпләнгән җирнең хәзинәсен арттыралар, яңа шәһәрләр салалар һәм авыллар төзиләр.

Болгарлар терлекчелек, җир һәм бакча эшләре белән генә шөгыльләнмичә, булдыклы аучылар һәм балыкчылар, оста һөнәрчеләр дә булалар. Гарәп тарихчылары болгар тимерчеләре, күнчеләре, көмешчеләре һәм тукучыларының зур осталыгын билгеләп үтәләр. Халыкның күпчелек өлеше кабилә башлыклары (биләр), тарханнар, ханнар өчен

бил бөгеп тамагын туйдыра. Фарсы иле һәм Һиндстан белән, кыпчаклар һәм руслар белән сәүдә итешүдән дә ханнар хәзинәсендә байлык ишәя бара. Безнең бабайлар ни белән генә сәүдә итмәгәннәр! Зур һәм кечкенә базарларда Болгар осталары иҗат иткән алтын-көмеш бизәнү әйберләре, кыйммәтле күн һәм мех әйберләр күз явын алган, болгар сәүдәгәрләре биредә югары сыйфатлы ашлык, бал, тукыма, чимал тәкъдим иткәннәр. Болгар маллары зур сәүдә үзәкләрендә хөрмәтле урыннарны биләп торганнар, ерак төбәкләргә барып ирешкәннәр. «Булгари» читекләрнең фарсылар һәм гарәпләр арасында даны таралган. Болгарның үзендә дә, хәзерге телдә әйткәндә, халыкара ярминкәләр оештырылган.

Шул ук базарларда, әлбәттә, әсирләр һәм коллар белән дә сәүдә иткәннәр. Байгуралар хәзинәсенә көмеш тәңкә булып ятимнәр һәм ярлы-ябагайның күз яше тамган, кол кызларның гүзәллеге салкын бизмәннәргә салынган...

Әнә шул ерак чорларда күршедәге рус җирләре белән Болгар арасында аеруча тыгыз, тотрыклы сәүдә-экономика мөнәсәбәтләре урнаша. Киев һәм Чернигов, Владимир һәм Суздаль, Новгород һәм Псков купецлары зур-зур сәүдә көймә һәм олау кәрваннары төзеп Идел һәм дала буйлап болгар шәһәрләренә киләләр. Аларның кайберләре болгар җирендә даими сәүдә йортлары тота. «Русларның товарлар төягән кораблары килеп болгар пристанена туктыйлар»,— дип X гасыр башында ук Ибн Фадлан язып калдырган. Рус сәүдәгәрләре алып килгән төп товарларын — урман бүләкләрен икмәккә, тукыма, корал, кыйммәтле савыт-саба һәм бизәнү әйберләренә алыштырып алалар. Мәскәүдәге Корал палатасында һәм Ленинградтагы Рус музеенда бизәкләп-сырлап эшләнгән сугышчан баш киемнәре, түгәрәк калканнар, алтын басма белән коръән аятләре төшергән кәкре кылычлар әнә шул ерак заманнар төсе булып саклана; алар арасында әле болгар осталары ясаган үрнәкләр дә юк түгелдер дип әйтергә мөмкин.

Хезмәтчел Болгар иле төрле диннәрнең бер төбәктә яшәвенә дә тыныч караган, аның күгенә мәчет манараларына ияреп, рус һәм әрмән чиркәүләре дә үрелгән. Аксөякләр башка милләтләрнең байбәтчеләре белән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырганда хәтта туганлашудан да тайчынмаганнар! Шул заманның көчле хакимнәреннән, мәсәлән, Владимир князе Андрей Боголюбский — төрки телле кыпчак хатынының улы — Болгар патшаның кияве дә була. Нәкъ шул заманда, 1170 нче елларда, Казан каласы да («Кальга» «крепость» мәгънәсендә кулланылган) салына.

Урта гасырларның борынгыдан килгән гадәтләре, «көчленеке — замана» принцибы күрше белән күрше, туган белән туган арасында низаглар кабынып тору, көч хакимияте рәвешендә чагылган. Ыруг, кабилә, халыклар бер-берсенә зур бүләкләр белән башкодалар, илчеләр генә түгел, баштан-аяк кораллы яу да җибәргәннәр. Ләкин, тарих сәхифәләрен актарып карасаң, тыныч көннәр барыбер күбрәк булыр иде.

985 елны беренче рус-болгар килешүе төзелә, егерме елдан соң ул янә яңартыла: болгар сәүдәгәрләре рус шәһәрләрендә, рус купецлары исә Болгар җирләрендә иркен алыш-биреш итү мөмкинлеге алалар. Рус елъязмасында бу хезмәттәшлекнең күркәм нәтиҗәләрен сурәтләгән сәхифәләр җуелмаган әле... Рус сәүдәгәрләренә төрки телне яхшы белүнең дә файдасы тими калмый. Бәлки нәкъ әнә шул заманнардан рус теле хәзинәсе товар («туар»дан), товарищ, кумач, аргамак, курган, сарай, башлык, башмак кебек төрки сүзләр белән баеп калгандыр...

«Тел,ләгать вә әхлак илә...» генә алмашып калмаганнар. Суздаль кнәзьлеге җирләрендә борынгы руслар арасында «хлебный ларь» дип аталган иген игелгән «Ополье» бар. Шул җирләрдә 1024 елны гомер булмаган корылык нәтиҗәсендә ачлык кешеләргә сөякчел кулларын

суза. Болгар икмәген — бодай, арпа, тары төягән сәүдә кораблары Идел буйлап Суздальгә күтәрелә. Бабаларыбыз күршеләргә килгән авырлыкны үз иңнәренә дә алалар, аларны ач үлемнән йолып калалар. 1228—1229 елларда бөтен Русьта, бигрәк тә Новгород һәм Белозерскийда, ике елга сузылган көчле ачлык вакытында болгарлар Идел һәм Ока сулары буйлап кәрван-кәрван ашлык озаталар, ә болгар ханы Новгород князенә утыз көймә икмәкне бүләк итеп җибәрә. Бу вакыйгалар Болгар иленең явыз дошманга каршы торган иң дәһшәтле чорга туры килә.

Болгар иленең, болгар халкының үсешенә Шәрык белән мөнәсәбәтләр ничек тәэсир иткән соң? Мәктәп дәреслекләреннән үк һәркемгә билгеле булганча, бу чорларда инде гарәп философлары, математиклары, астрономнары, тарихчылары, тел һәм география галимнәре ирешкән уңышлар, аларның хезмәтләре бөтен дөньяда танылырга өлгерә. Европалылар Платон һәм Аристотель хезмәтләрен гарәпләр тәрҗемәсендә укыйлар, гарәп фән-гыйлем үзәкләренә белем алырга баралар. Дөнья әдәбияты хәзинәсе Мөслехетдин Сәгъди поэмалары, Әбугалисина, Әбунаср Фараби, Әбурәйхан Бируниларның үлемсез хезмәтләре, Гомәр Хәйямның нәфис робагыйлары белән байый.

Болгарга сәүдә киңәю һәм ислам дине белән бергә гарәп язу системасы һәм шәрык культурасы үтеп керә. Экономик, политик ихтыяҗлардан чыгып һәм дин уртаклыгы нигезендә гарәп дөньясы һәм Урта Азия белән тыгыз экономик, культура бәйләнешләре урнаша. Болгар шәһәрләрендә һәм авылларында бер-бер артлы мәчетләр һәм мәхәллә мәдрәсәләре ачыла. Кулдан язган китаплар тарала башлый, фәлсәфи фикер уяна. Шәрык архитекторлары Идел буенда мәчетләр һәм сарайлар салырга булышалар. Болгарлар үзләре дә биек ташпулат торгыза, күпер суга, керамиксыман көпшәләр буйлап су куа, чуен коя белгәннәр, мәгърифәткә һәм фәнгә омтылганнар, шул заманча югары культурага ирешкәннәр. Аларның үз галимнәре һәм әдипләре булган. Бу хакта Багдад хәлифәсенең илчесе сыйфатында Болгарга килгән Әхмәт ибн Фадлан, аңа кадәр үк тарихчы һәм философ Фараби, ә соңыннан сәяхәтче ибн Батута язып калдырган. Кызганычка каршы, Болгар чоры әдәби ядкарьләреннән безнең көннәргә бер генә кульязма — XIII йөз шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре генә килеп җиткән.

...Әйе, безнең бабаларыбызның беренче ватаны — Дон һәм Кубань буйлары булса да, Урта Идел урман-далаларына алар монгол яуларына чаклы күп гасырлар элек килеп утырганнар. Төньяк Кавказдагы балкар, карачай кебек икенче тармак болгарлар тел ягыннан да, антропологик яктан (баш сөяге, йөз формасы һ. б. буенча) да Идел-Урал төркиләреннән аеруча бүгенге татарларга якынрак. Гасырлар буе күп үзгәрешләр, кушылулар булган — төп охшашлык, туганлыкны исбатлаучы билгеләр барыбер җуелмаган. Һәм мондый охшашлыкны очраклы хәл дип кем әйтә ала. Тарих катламнарында кеше гомереннең иң соңгы символы — кабер ташлары калган. Арада гомумтөрки (чөй) язулары да (болгарларның әле Идел буена килгәнче үк шундый язуга ия булуы бик ихтимал), Болгар ислам диненә күчкәч — гарәп хәрефләре белән эшләнгәннәре дә бар. X гасыр Болгар акчаларында (кабер ташлары гына түгел, фани дөнья малыннан алтын-көмеш тәңкәләр дә озын гомерле икән!) шундый ук гарәп язулары аермачык укыла. Кабер ташларындагы язулар теләсә кайсы төрки телгә караганда да татарга якынрак. Бу да очраклы хәл түгел.

«Яу килә!» Болгар иленең тыныч шәһәр һәм авылларын сискәндереп, коралга тотынырга чакырып, шушы аваз яңгырый. XIII йөз башында Идел буйларына көчле һәм шәфкатьсез илбасарлар монгол-татар яулары килеп җитә. Аларны инде күрше Кыпчак даласында ук кансызлыгы белән яманаты чыккан Сүбүдәй исемле яубашы җитәкли.

1223 елда бу гаскәр Калка елгасы буенда русларның кыпчаклар белән берләшкән көчләрен җиңүгә ирешә. Бу уңыштан рухланып киткән монголлар, кыпчак җирләрен талап аргач, Идел буйлап, кара болыт булып, Болгарга таба килә башлыйлар. Чыңгыз туруны (оныгы) Бату ханның яулап алу ниятләрен һәм «аппетитын» чамалап өлгергән болгарлар, әлбәттә, үз дәүләтләренең чиген ныгыталар, дошманга каршы тору өчен ашыгыч чаралар күреп өлгерәләр. Эреле-ваклы һөҗүмнәргә һәрвакыт әзер торырга мәҗбүр булган Болгар яхшы коралланган, өйрәтелгән гаскәр тоткан. Моның өстенә илнең көньяк һәм көнчыгышында биек балчык өемнәре, тирән урлар дошманны лаеклы каршы алырга әзерләнеп торган. 1223 елның көзендә болгар сугышчылары Җигули таулары тирәсендә монголларны урап алып тар-мар итәләр. Илбасарларның бик азы гына качып котыла. Хәйләкәр Сүбүдәй, Иран һәм Кавказ арты илләреннән, кыпчак җирләреннән талап алган малыннан колак какмас өчен, тәртәне тизрәк кире бору ягын карый. Бату хан урдасына монголларның беренче зур җиңелүе турында хәбәр кайтып җитә.

Болгарларның көче, күрәсең аз булмаган: алар унбиш ел буе дулкын-дулкын булып килгән монгол-татар яуларын зур югалтулар кичереп кире чигенергә мәҗбүр итәләр. Ләкин кояш баешына таба, «соңгы диңгез»гә ыргылучы вәхши илбасарлар, бәйләнчек усал эт кебек, Болгар эргәсеннән китмиләр. Кылыч һәм калкан тавышлары, уклар яңгыры көчәйгәннән-көчәя бара...

«Яу килә!» — чик буйларында кизү торучы җайдак угланнарның атлары күбеккә бата. Болгар өчен дә, руслар өчен дә кара кайгылы унөченче йөзнең утызынчы еллары килә.

Ике ел буена махсус әзерләнеп, үзләренә буйсындырган төрки халыклардан да бик күп сугышчы җыеп, күп яуларда остарган монголлар гаять зур атлы гаскәр белән яңадан Идел — Кама буйларына килеп чыгалар. Бу юлы көчләр тигез булмый, ике яктан да бик күп кан коелып, берничә көчле бәрелештән соң монголлар Суар, Җүкәтау, Кашан шәһәрләрен яулап алалар, Болгар дәүләтенең башкаласын талыйлар, яндыралар.

Ләкин болгар халкы дошманга баш ими, ата-бабалар туфрагын калдырып китәсе булса да, коллыкта яшәүдән баш тарта. Кайберәүләр төньякка — Кама аръягына качып китә, кайберәүләр «Руська киләләр һәм үзләренә урын бирүне сорыйлар»,—дип елъязмалар хәбәр итә.

Болгар иле ярты Азияне яулап алган рәхимсез һәм дәһшәтле дошман һөҗүмен үз күкрәге белән каршылап, монголларның Европадагы беренче корбаны булса да, аларның алга таба юлын күпмедер вакытка торкарлап, илбасарлык гайрәтен шиңдереп тора, ниһаять, ерткычларча өзгәләп ташланганнан соң да Бату ханның тылында баш күтәрә.

Искиткеч зур җирләр — Болгар иле, Киев Русе, Польша, Венгрия, Чехия, Адриатика...— монгол атларының тоягы астында кала. Иртыш елгасыннан Дунайга хәтле мәйданда яшәүче дистәләгән халыклар Батуга ясак түли. Коллыкка төшкән халыкларны буйсындырып тоту өчен төзелгән гаять зур Алтын Урда дәүләтенә бай, уңдырышлы болгар җирләре дә кертелә. Ярым мөстәкыйль рус җирләре авыр ясак түләп торырга мәҗбүр ителә. Хуҗалыгын, шәһәрләрен кабат торгызып, үз исемен саклап калса да, ике гасыр дәвамында баскыннарга үзе үстергән икмәкне, сугышчы ир-егетләрен, угланнарын, чибәр кызларын биреп яшәргә мәҗбүр булган борынгы Болгар.

Алтын Урдада хөкем сөргән монгол-татар гына түгел, халыкларның күбесе мәҗүси, динсез булган (1310 елларда гына Үзбәк хан ислам дине кабул итә). Күп гасырлар ислам дине тәэсирәтендә тәрбияләнгән болгарларны, руслар белән бер үк дәрәҗәдә ят күреп, рәхимсез изгән-

нәр: мәчетләрен җимереп, авылларын туздырып, китапларын утка ташлап, хатын-кызларын хур итеп, гореф-гадәтләрен кимсеткәннәр.

XIV гасыр урталарында ук буйсындырылган халыкларның көчле каршылык күрсәтүе, феодаль ызгышлар нәтиҗәсендә, Алтын Урда хәлсезләнә, әкренләп таркала башлый. Болгар җире, бигрәк тә аның хезмәт халкы еш кына феодаль тарткалашулар корбанына әверелә. Алтын Урта ханнары-тарханнары һәм рус князьләре бергә әледән-әле яу чабып, талап китәләр, Болгарны һәм аның тирә-ягындагы шәһәр-авылларны җимерәләр. Болгар җире соңрак Туктамыш хан белән Аксак Тимер гаскәрләренең дә яу кырына әверелеп ала. Монгол яуларыннан көл-кисәү хәлендә калдырылган Болгар шәһәре үз халкының уңганлыгы, тырышлыгы нәтиҗәсендә генә яңадан аякка басып житкәч, 1432 елда Федор Пестрый дигән Мәскәү князе шәһәрне талап, җимереп, яндырып китә. Бу вакыт болгар-татарларның Алтын Урда кул астыннан чыккан чоры була. Барыбер Болгар шуннан соң инде тернәкләнә алмый. Рус елъязмаларында Бөек шәһәр дип телгә алынган төбәктә хәрабәләр һәм кайбер ташлары гына җәйрәп кала. Хәер, хәтта XVIII гасыр ахырларында да әле биредә 44 яхшы ташпулат һәм ике биек мәчет манарасы сакланып калган була...

«Татарлар килә!» Рус шәһәрләре һәм авылларына зур бәла килгәнен аңлатып, чиркәү чаңнары кага-кага, шул яман хәбәр тарала. Урдада властьны үз кулына алган Мамай хан, ясак түләми торуларын сылтау итеп, рус җирләренә яу белән барырга ниятли. Төрле миллләт сугышчыларыннан тупланган чуар гаскәр Сарай шәһәреннән Идел буйлап өскә таба күтәрелә, Сары чин («сары ком») елгасы буенда көнбатышка таба борылып, Мәскәү ягына юл ала. Гасырлар үткәч бу урында Царицын дигән шәһәр үсеп чыгар, ул легендар Сталинград сугышлары белән тарихка керер һәм шунда кыю татар егетләре башка халыкларның вәкилләре белән бергә Мамай курганын штурмлауда, уртак Ватанны яңа чор илбасарларыннан саклауда катнашырлар...

Әлегә исә — тарихи 1380 ел бара. Мамай гаскәрен алуда Куликово кыры, күп заманнар бил бөгеп түзгән рус халкының көчле йодрыкка әверелгән нәфрәте көтеп тора...

Ике елдан соң Урданың яңа ханы Туктамыш Мәскәүне кабат яулап, яндырса да, беренче зур җиңүдән соң рус халкы инде үзенең көчен аңларга өлгерә. Алтын Урда әле бер яктан, әле икенче яктан югалтуларга дучар булып, көчсезләнә бара. Моны сизеп-күреп торган башка халыклар да баш күтәрә башлыйлар. Тарихтан билгеле ки, мондый очракларда иң алдан үз дәүләте, экономикасы, бердәм теле, дине һәм тарихы булган халыклар аерылып чыга.

Шул чорларда Алтын Урданың төньягында, элекке шәһри Болгардан да өстәрәк, борынгы кечкенә бер кала — «Яңа Болгар» көч ала башлый. XV гасырның беренче яртысында биредәге морзалар Сарай ханнарына ачыктан-ачык буйсынмауларын белдерәләр. Шулай итеп, үзенең яңа башкаласы исеме белән аталган Казан ханлыгына нигез салына. Биредә, рус елъязмачылары билгеләп үткәнчә, «казанлылар дип йөртелә торган болгарлар» яши. Ул вакытта, димәк, аларны Урда татарларыннан аерып караганнар, аерым халык итеп танығаннар. Шулай да еллар үтү белән Идел болгарлары әкренләп онытыла: ким дигәндә биш йөз еллап рус тарихчыларының игътибар үзәгендә торган болгарлар Алтын Урда чоры башлангач күз уңыннан төшә башлыйлар, елъязмаларда Алтын Урда халыклары, тел һәм кабилә аермалыкларына карамастан, уптым-илаһи «татарлар» дип кенә йөртелә. XV гасырда «казанлылар» атамасы әйләнешкә керсә дә, әзербәйҗан, нугай, балкар, кырымлылар, төрки телләрдә сөйләшүче башка халыклар белән беррәттән, Казан ханлыгы халкы да татар дигән гомуми исем астында йөртелә башлый. Тора-бара инде монгол яулары булып

килгән «татар» белән Казан татарларын да бер үк халык дип карауга да ерак калмый... Н. Г. Чернышевскийның түбәндәге сүзләрен кайбер тарихчыларның да исенә төшерү зарар итмәс иде: «Хәзерге татарлар— Батуга чаклы ул төбәкләрдә яшәгән һәм руслар кебек үк Бату тарафыннан буйсындырылган кабиләләрнең варислары»,— дип язган ул.

Билгеле булганча, Алтын Урдада монголлар азчылык булып, алар дәүләттәге төп халык — төрки телдә сөйләшүче кыпчаклар белән кушылып-аралашып китә. Монгол-татарлар кулындагы байлык, көч һәм властьтан өлеш чыкмасмы дип, буйсындырылган халыкларның аксөякләре дә Сарай тирәсенә ныграк елышалар, Урда ханнарыннан битек-ярлык эләктерә алганнары тәкәббер түшләрен тагын да киерә төшеп, үзләрен «татар» (власть иясе) дип хис итә, «татар» дигән исем ала башлый. Үзләренең татар шәҗәрәләре белән кайбер рус дворяннары да горурланалар, үз гербларына татар тарханнары — морзаларының нәсел тамгаларын төшерәләр. Князь Юсупов кебекләр хәтта хан нәселеннән чыгулары белән кәперәергә яраталар...

Казан ханлыгы чорында Касыйм ханлыгына һәм рус патшасына хезмәт итәргә китеп, кайберләре исемнәрен һәм диннәрен алыштырган морзалар да үзләренең нәсел-нәсәбен онытып бетермәгәннәр, әлбәттә. Еллар үтү белән, алардан рус казагы шикелле хәрби хезмәт итүче «служилый» татарлар» дигән тулы бер сословие барлыкка килгән. Аларның күбесе хәрби хезмәткә ялланып, Россиянең көнчыгыш чикләрен даладан килүче баскыннардан саклауда катнашкан. Граф Шереметьев (Ширәхмәт) кебек байгуралар гына түгел, тарихчы Карамзин, язучы Куприн, язучы Радищев һәм башка күпләрнең шәҗәрәсе әнә шулай ерактан — татар нәселеннән килә. Тәнендә Ибраһим Нурбәк морзалар каны йөгергән атаклы рус шагыйре Державин, төрле заманнарда Шәрык илләрендә Рус дәүләтенең мәнфәгатьләрен яклаган тәҗрибәле татар дипломатлар... Искә төшерсәң, безнең халыкларны бер җепкә теркәгән тарих сәхифәләре аз түгел...

Тарих кабатлана, диләр. Дон-Кубань буйларыннан Дунай үзәненә килеп утырган болгарлар исемнәрен җирле славяннарга биреп, үзләре шулар арасында комга төшкән су кебек эреп бетәләр. Көнчыгыштан Идел буена килеп чыккан татарлар җирле болгар халкына һәм күп кенә башка төрки телле халыкларга үз исемнәрен калдыралар.

Болгар иле Алтын Урда хакимлеге урнашкан җирләр арасында да үзенең дәрәҗәсен югалтмаган, һәрвакыт иң байлардан саналган. Бу байлык күршеләрне талау хисабына түгел, сабанчылар, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һәм сунарчыларның тырыш хезмәте белән тупланган. Тикмәгә генә мени Алтын Урдага килгән яулар көнчыгыштан килсәләр дә, көнбатыштан кузгалсалар да, «эшне» Болгар халкын талаудан башлаганнар...

Күршеләргә каршы талау сугышлары алып бару белән бергә, монгол-татарлар яулап алынган җирләрдәге халыкны да ерткычларча изеп яшәгәннәр. Елъязмаларда — балаларын ясак итеп түләргә мәҗбүр булган аналар күз яше, чит-ят җирләргә сатып җибәрелгән осталар сагышы. Италия, Франция, Мисырдагы коллар базарында — күндәм холыклы, алтын куллы, чибәр яшь болгар хатыннарының, ак тәнле сылу болгар кызларының бәясе зур булган...

Нинди генә авыр шартларда яшәсә дә, халыкның күңел күге аяз, табигате сабыр-йомшак булып калган. Ул иҗат иткән тарихи культура байлыклары, яхшы гореф-гадәтләр буыннан-буынга өзелми тапшырылган. Хезмәт сөючән болгарлар тирә-юньдә кунакчыллык белән аерылып торганнар. Тәмәке тартмаганнар, аракы эчмәгәннәр, сүгенү дә бик зур гаеп эш дип бәяләнгән. Хатын-кызлар пәрәнҗә астына качмасалар да, башларына яулык бәйләмәгән килеш кеше күзенә чалынмаганнар, хатын-кыз матурлыгын чит ирләргә күрсәтү әдәпсезлек саналган. Го-

мумән, гөнаһ, оят төшенчәләре хезмәт белән бергә халык педагогикасының төп чараларыннан булган. Әдәп-әхлак кануннарының үтәлүе өчен аксакаллар алдында бөтен ыруы, нәсел-нәсәбе, авылы белән җавап биргәннәр. Олысын-кечесен хөрмәтләү, арулык-пакьлек, тыйнаклык, көнкүреш культурасы бүген дә татар халкы арасында югары бәяләнә, яшәү кануны булудан туктамый...

«Яу килә!» Казан ханлыгы өчен хәлиткеч вакытлар — XVI гасыр урталары әнә шул аваз белән тулы.

VII гасырда гарәп-хазар яулары һәм кабиләара килешә алмау болгарларның Дон һәм Кубань буйларыннан таркалып-аерылып китүенә сәбәпче булса, мең елга якын вакыт узгач, татар ханнары һәм биләренең власть, байлык өчен үзара якалашулары хезмәт халкы язмышын яңадан зур сынау алдына куя. Иван Грозный, Казанны алу өчен берничә тапкыр талпынып та максатына ирешә алмагач, бик зур әзерлек җәелдереп җибәрә. Өч мәртәбә Казан тәхетендә утырган Шаһгали (русча Шигалей) бу әзерлек эшләрендә зур тырышлык күрсәтә — Казанны алуда җитди роль уйнаган Свияжск кальгасын төзүдә дәртләнеп катнаша. Аның бу хезмәте өчен Иван Грозный бәләкәй генә Касим шәһәрендә утырып калган «Экс-падишаһ»ка яңадан Казан тәхетен вәгъдә итә. Казанны өч ай блокадада тотып, ачлык һәм янгыннар белән халыкның түземлеген сынаган, соңыннан шушы ныклык, чыдамлыклары өчен рәхимсез кан кою юлы белән буйсындырган гаять зур гаскәрнең зур өлеше рус җирләренә электән үк күчеп утырган татарларның атаклы отрядларыннан, куштан князьләренә буйсынып ут эченә керергә мәҗбүр булган җәяүле башка миллә сугышчыларыннан гыйбарәт була...

Тарих тузаны сарыла башлаган вакыйгаларны бер сүз белән аңлату җиңел түгел. Казан алынудан алты ел узуга 30 мең татар «оланнары» (уланы) рус гаскәре белән бергә, уртак ил, яңа туган Россия (аңа чаклы «Русь» дип аталган) мәнфәгатьләрен яклап, Ливон сугышында катнаша. Тагын утыз елдан Тәтеш морзасы Сәлим татарларны «кяфергә каршы, дин өчен изге сугышка» күтәрелергә чакырып чыга. Ләкин гади халык кан коюлардан да, жылы туннарына төренгән байларның «дин-ислам өчен газаватка» өндәүләреннән дә туеп, әтәчләнгән морзаның башын кисеп (чынмы, риваять кенәме), Казанга рус воеводасына бүләк итеп җибәрә.

Болгар-татар һәм рус хезмәт ияләренең язмышы акренләп бер-берсенә үрелә башлый һәм Россия тарихының уртак үзәнендә аерылгысыз бер агымга әверелеп китә. Гасырлар буе бергә көн күрү дәверендә ут күрше булып яшәгән халыклар яңа мөнәсәбәтләргә керәләр, үзләрен талаучы байларга һәм илбасарларга каршы да бергәләп көрәшәләр. Уртак ватанга кулын сузган дошманнар — XVII гасырда «Ялган Дмитрий»ларны яклаган булып патша тәхетен, рус җирләрен яулап алырга кызыккан полякларны алар, XVIII йөздә Полтавага хәтле килеп кергән шведлар короле Карл гаскәрене, XIX гасыр башында Европаны буйсындырып килгән Наполеон яуларымы, Россия белән ничә ел сугышып һаман да сабак алып житкерә алмаган японнар яисә немецларны, — аларга рус халкы тирәсенә тупланган, төрле телдә сөйләшүче россияннар белән дә эш итәргә туры килгән.

Рус дәүләте бөтен көчен җигеп, поляк илбасарларына каршы торганда, боярлар һәм дьяклар татар морзаларына: «.. без сезне туганнарыбыздан якын күреп ышанабыз, бу авыр вакытта, «фетнәле чорда» сез баш күтәрмәссез, безгә каршы яу ачмассыз...» — дип язалар. Казан өчен барган канлы сугышлар тынып калганга әле күпме генә гомер узган, әмма «Рәсәй»не уртак ватан дип тану, аңа килгән авырлыкны бергә күтәрү билгесе булып, илне, Мәскәүне яулаучылар өчен Идел буеннан икмәк, атлар, корал килә. Тарих боларның барысын да яхшы

хәтерли. Православиегә күчкән ике татар морзасы — бертуган Урусовларның 1610 елның декабрендә ялган Дмитрийның башын кылыч белән чабып өзүен дә, яисә:

> Мәскәүгә дә кердек без, Наполеонны күрдек без,
> Французны җиңгәндә җир җимертеп йөрдек без,—

дигән татар бәетен дә хәтерли тарих...

Һәм менә гомере буе изелеп яшәгән халыкның хыял байрагы җилфердәп үз канаты астына, изге яуга чакыра — крестьян патшасы Емельян Пугачев гаскәренә полковник Бәхтияр Канкаев, меңбашы Муса Мостафин, полковник Мәсәгут Гомәров кебек кыю егетләре җитәкчелегендә 85 мең татар килеп кушыла:

> Пугачев патшаны күрсә иден,
> Алларыннан бил бөгеп узса иден,
> Аргамак менеп, дан тотып,
> Җаек яуларында йөрсә иден!

...Сал кебек, Идел суында канлы мәетләр ага. Рус, татар, чуваш крестьяннарыннан Әби патша үч ала, Үлем җәзасыннан котылу юлын эзләп, Урал ягына, казакъ даласына көтү-көтү татарлар качып бара.

Россиянең тышкы дошманнарына һәм үзендәге изүчеләргә каршы иңгә-иң торып көрәшү, урман кисүдә, рудникларда һәм шахталарда, шәһәрләр һәм юллар төзүдә бергәләп эшләү русларда да, татарларда да бер-берсенә якынлык, уртак уйлар, кичерешләр барлыкка килүенә сәбәпче була. Бергәләп гомер итү, тәҗрибә уртаклашу тормышның күп кенә мәсьәләләренә, күренешләренә бер төрлерәк караш тудыра. Шул нигездә зур һәм күп милләтле Россиягә эчкерсез мәхәббәт хисләре бөреләнә. Ватаныбызның яңа тарихы, аның безгә аеруча таныш сәхифәләре менә шул чорлардан башлана. Диңгезгә исәпсез елгалар суы тулган кебек, руслар белән бергә еллар, гасырлар буе бергә яшәгәндә татарларның күңеленә «без Рәсәй халкы» дигән уй-тойгы тула. Моны безнең замандашыбыз Әхмәт Ерикәй болай белдерә: «Рус булмасам да мин — Россиялы, рус шикелле аны яратам».

XIX гасыр — гаҗәеп бер чор. Әкияттәге каһармандай ул рус милли культурасын күккә чөеп бөтен дөнья рухи мәйданына чыгарып күрсәтә. Пушкин, Лермонтов, Лобачевский, Толстой, Бутлеровлар, Глинка, Чайковский, Айвазовский, Репиннар даһилыгы татарга да Европа мәдәниятенең якты нурын җиткерә. Шул нурлар иҗат дәртен уята, Мәрҗәниләр, Тукайлар, Ибраһимовлар чоры башлана. Руссо, Вольтер, декабристлардан кабынып киткән азатлык ялкыннары Чернышевский, Плехановлар хезмәтләре аркылы күпләрнең зиһененә бөек идеяләр булып сеңә. Данлы Казан шәһәрендә 1887 нче елда могҗиза булып тарихта (һәм татар тарихында!) Ульянов-Ленин балкып чыга... XX гасыр бусагасыннан атлап Россияга, марксизмга таянып, яңа заман кискен сыйнфый көрәш килеп керә.

...1905 ел революциясе дулкыннарының иң югары күтәрелгән бер мәлендә шовинистик матбугат, һәртөрле карагруһчылар: «Россия җирендәге сез килмешәкләр. «Төркиягә китегез» — дип, шау-шу күтәрәләр. Ни өчен? Төркиягә бернинди кагылышы булмаган Идел буе татарларын туган җирләреннән сөрергә азапланунын максаты ни? Революцион көчләрнең хәлиткеч бердәмлеген булдырмау, демократик һәм милли азатлык көчләрен таркату. 1905 нче елда татар эшчеләренең нинди көчкә ия булуы мәгълүм. Тикмәгә генәме Донбасста һәм Бакуда, Казан, Мәскәү, Пенза, Уфа һәм Самарада революцион хәрәкәттә катнашкан татар эшчеләрен җәзалыйлар! Демократик юнәлештә татар интеллигенциясе революциягә шулай ук зур өметләр баглый, аның җиңүенә өлеш кертергә омтыла. Менә, фоторәсемдә, Гафур Коләхметов үзенең якын кешеләре арасында, кулында Ленин «Искра»сы һәм бу — 1903 елда! Кара реакция тантана иткән 1907 елда да татар телендә

большевистик «Урал» газетасының ялкынлы авазы яңгырый. Шул ук 1907 елда татар халкының алдынгы карашлы уллары, карагруһ реакционерларның йөзенә бәреп, Тукай сүзләре белән әйтәләр:

Иң бөек максат безем:—хөр мәмләкәт — хөр Русия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе ру сияһ!
Ап-ачык бу бер җавап тыр, сүздә түгел, басмада:
Если лучше вам,
Туда сами пожалте, господа!

...1978—79 ел кышында зәмһәрир суыкларда алмагач кына түгел карт имән агачлары да чыдый алмады, өшеде, корыды. Әмма үз туфрагына тирән киткән тамырлардан ике-өч елдан соң зәгыйфь кенә үсентеләр күтәрелде. Еллар үткәч алар имән һәм алмагач булып үсәчәк әле...

Безнең тарихыбыз да шулай түгелме соң? Монголларның 200 ел хөкем сөрүе халкыбызның тәрҗемәи хәлен ике парәгә, ике өлешкә бүлде: беренчесе корыды, янды, кара төтен булып җилгә очты. Икенчесе Алтын Урдадан котылгач кына яшь үсенте булып күренде, ләкин «үләргә мәхрүм булган» культурабыз гасырлар буе күтәрелә алмады: беренче тарихыбызны Якуб Ибн-Ногман XI йөздә язган булса, икенчесен XIX йөзнең ахырларында гына Шиһаб Мәрҗани төзи башлый. Әмма халкыбызның чын тарихы беренче рус революциясеннән генә башлана...

Без Бөек Октябрь революциясе һәм Совет властен ныгыту елларында, Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт фронтларында бөтен совет халкы белән бергә татар уллары һәм кызларының да фидакарьлек, батырлык үрнәкләре күрсәтүен яхшы беләбез һәм моның белән горурланабыз.

Бөек Ленин кулы белән төзелгән Татарстан Совет Социалистик Автономияле Республикасы тугандаш халыкларның бердәм ганләсендә яңадан-яңа уңышларга ирешә, анда яшәүче төрле милләт кешеләрен бер уй, бер максат берләштерә: халыклар дуслыгы бакчасына әверелгән Ватаныбыз куәтен арттыру хакына, совет кешеләренең яңа буыннары тагын да матуррак тормышта яшәсен өчен, алар бөтен көчләрен, белем һәм тәҗрибәләрен салып хезмәт итәләр. Татар халкы үзенең бүгенге барлык казанышлары өчен кешелек тарихында яңа эра ачкан Бөек Октябрьга, социализм шартларында чәчәк аткан халыклар дуслыгына һәм, беренче нәүбәттә, талантлы дусты — рус халкына бурычлы.

Халыклар дуслыгы — тарихи төшенчә. Катлаулы һәм каршылыклы вакыйгалар, ачыктан-ачык дошманлык һәм бер-береңне аңларга теләмәү дәверләре аша, гасырлар дәвамында, бик зур авырлыклар белән, әкрен-әкрен генә тернәкләнеп килә ул нәфис дуслык чәчәге һәм уртак гамь белән яшәүче рус, татар халыклары күңелендә үзенең тамырларын тирән җәя.

Ерак тарихның кайбер сәхифәләрен генә актарып караганда да, без бик ачык күрдек: бу дуслык турында гасыр башында ук татар әдәбияты классигы Габдулла Тукай әйткән сүзләрдә гаҗәеп зур хаклык бар икән:

Рус җирендә без әсәрле, әзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без.
...Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

Халкыбызның Идел — Кама төбәгендә яшәп килгән «тузга язган» тарихы бер мең ике йөз елларга сузылган. Алты йөз «болгар», ике йөз ел — «болгар-казанлы», дүрт йөз елдан артык «татар» исеме белән тормыш Идел суы кебек агып бара. Шул исемнәр астында хасил булган тирән тамырлы тарих, иҗат ителгән матур гореф-гадәт, хәзинә кебек рухи мирас, казанган дан-шөһрәт — халкыбызның өне, күзгә күренерлек, һич тә бетмәс байлыгы... Берсеннән дә ваз кичәрлек сәбәп юк, барысы өчен дә без Олы елъязмаларда күрше халыкларның күңелендә мөхтәрәм...

## БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**Фәрваз Миңнуллин**

# РЕАЛЬ ХӘЛЛӘРГӘ КҮЗ САЛЫЙК

Прозабызның сыйфаты, әсәрләребезнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе әдәби җәмәгатьчелекне дә, укучыларны да инде байтактан борчый иде. Проза бер урында таптана, прозаиклар үсмиләр, эзләнмиләр, дип зарланулар бүген генә башланган нәрсә түгел. Кыскасы, сөйләшәсе сүзләр дә, бергәләп хәл итәсе мәсьәләләр дә күбәйгән иде.

Реаль хәлләргә күз салсак, бүгенге прозабыз турындагы байтак фикерләрнең берьяклырак булуын күрербез. Проза үсми, прозаиклар эзләнми, дип зарлануларны алыйк. Бу — уйлап җиткермичә әйтелгән фикер. Бәлки, без көткәнчә үсмидер, без теләгәнчә эзләнмиләрдер?.. Әмма әдәбият эзләнми яши алмый. Юкса, ул шунда ук заман барышыннан артта калачак. Ил күләмендә барган зур вакыйгалардан, ил күләмендә барган гомуми әдәби процесстан язучылар берничек тә читтә кала, фән-техника революциясе тудырган үзгәрешләр, ул үзгәрешләрнең кеше аңына, аның психикасына тәэсире хакында уйланмый булдыра алмыйлар. Югары белемле, күпне күргән, күпне белгән бүгенге укучының таләп һәм ихтыяҗлары белән дә санашмый булмый. Шуны аңлап, язучылар өзлексез төстә чорга ярашлы сәнгать чаралары, чорга ярашлы әдәби стиль эзлиләр. Әнә шулай, акрынлап, әмма туктаусыз төстә язучыларның тормыш материалына булган мөнәсәбәте, образ тудыру алымнары, сурәтләү чаралары үзгәрә — әдәбият үзгәрә. Әле кайчан гына без прозаикларыбызны артык озын итеп язуда, максатсыз тасвирлаулар белән мавыгуда гаепли идек. Тыгыз һәм кыска итеп язарга омтылу бүген гомум тенденциягә әйләнеп бара. Прозаның үсү-яңаруы аерым язучылар иҗатын тикшергәндә тагын да ныграк күзгә ташлана. Ә. Еники әсәрләре Фатих Әмирхан яки Шәриф Камал әсәрләреннән аерылган кебек, А. Гыйләҗев Әмирхан Еникичә, я булмаса, М. Мәһдиев Фатих Хөсничә язмый. Ә. Баянов, Ә. Гаффар кебек прозаиклар иҗатын безнең әдәбияттагы бер генә язучы иҗаты, бер генә әсәр белән дә янәшә куеп булмый. Шул ук сүзләрне Н. Фәттахка карата да кулланып була. Ул — чын мәгънәсендә тарихи романнар язучы бердәнбер кешебез.

Илебездә иҗат өчен бөтен шартлар, мөмкинлекләр туган бер дәвердә, башка халыкларда әдәбият, сәнгать гөрләп чәчәк атканда, нигә безнең проза гына артта бара, дип аптырыйлар кайбер иптәшләр. Әйе, социаль-экономик шартларыбыз охшаш булса да, әдәбиятларыбыз төрле-төрле. Чөнки төп, гомуми закончалыклардан тыш һәр милли әдәбиятның әле үз эчке хасияте, үз мөмкинлекләре һәм үз традицияләре бар. Татар әдәбияты кебек бай тарихы булган әдәбият хакында сүз барганда, моны истән чыгарып булмый, истән чыгарырга ярамый.

Татар совет әдәбияты узган зур юлга күз салсак, без төрле чорларда прозаның үсеш дәрәҗәсе төрлечәрәк булганын күрербез. Безнең прозаның үсеп-көчәеп китүе 30 елларга туры килә. Бөек Ватан сугышы елларында прозаның очерк, хикәя кебек кечерәк күләмле жанрлары аеруча активлаша, көндәлек матбугат битләрендә публицистика зур урын ала.

Сугыштан соң, бигрәк тә 50 еллар башында проза өлкәсендә яңа күтәрелеш полосасы башлана. Прозаиклар тагын әдәбиятның алгы сафына чыга һәм күп еллар буена әдәби хәрәкәткә юнәлеш, тон биреп бара. К. Нәҗми, Г. Бәширов, Г. Әпсәлә-

мовларның мәгълүм романнары безнең прозаны бөтенсоюз аренасына алып чыга. Партиянең XX съездыннан соң илебез тормышында булып узган тирән үзгәрешләр әдәбият, шул исәптән прозаның үсешенә дә уңай йогынты ясый. Прозаиклар ил күләмендәге проблемаларга багышланган, зур иҗтимагый конфликтларга корылган романнар язалар, чорның актуаль мәсьәләләрен яктырткан повестьлар нык активлаша. И. Гази, Ф. Хөсни, А. Расих, Г. Ахунов романнары, Ә. Еники, Р. Төхфәтуллин повестьлары 50 еллар ахыры һәм 60 еллар башындагы прозабызның колачы, характеры турында фикер йөртү өчен бай материал бирә.

Менә шул көчле һәм кызыклы прозабыз бер заман ничектер бер урында таптана башлады. Аз-азлап кына, сиздерми генә ул үзенең көчле сыйфатларын: карашлар киңлеген, олы характерларын, масштабларын һәм иҗтимагый яңгырашын югалта барды. Прозаиклар тавыш-тынсыз гына әдәби хәрәкәтнең артынарак чигенделәр.

Без байтак еллар моны күрмәмешкә салынып йөрдек. Бер күреп алгач, шауларга һәм зарланырга тотындык. Шул ук хәл бүген дә дәвам итә. Хәлбуки, соңгы 10 ел вакыт эчендә проза өлкәсендә кызыклы гына үзгәрешләр барлыкка килде.

Шулай да заманында безнең прозаның үсешен тоткарлаган нәрсәләр хакында берничә сүз әйтми узу ярамас. Алар күп булырга мөмкин. Мин шуларның икесенә тукталмакчы булам.

Билгеле булганча, татар әдәбияты элек-электән авыл әдәбияты булып килде. Аның бу теманы яктыртуда гасырлар буе туплап килгән бай тәҗрибәсе бар иде. Безнең прозаның алтын фондына кергән әсәрләрнең күбесе авыл темасына карый. Сугыштан соңгы чорда, бигрәк тә соңгы 20—25 ел вакыт эчендә республиканың икътисади йөзе нык үзгәрде. Элекке авыл хуҗалыгы республикасы булган Татарстан эре промышленность, зур төзелешләр үзәгенә әйләнде. Илебез һәм республикабыз тормышындагы үзгәрешләр әдәбиятны да читләтеп узмады. Элекке авыл әдәбияты йөз белән зур төзелешләргә, шәһәр тормышына борылды. Әйтик, соңгы елларда дөнья күргән романнарның иң зур күпчелеге шәһәр материалы җирлегендә язылган, эшчеләр тормышына багышланган. 70—80 елларда басылган 150 повестьның 100 дән артыгы шәһәр материалы җирлегендә язылган икән, бу да шул ук фикерне куәтли. Документаль һәм маҗаралы повестьларның һәммәсе диярлек шәһәр материалы җирлегендә язылган. Тарихи-революцион әсәрләргә мөрәҗәгать итсәк тә, шундыерак күренешкә тап булырбыз. Бүгенге яшь прозаикларның беренче повестьлары күпчелек очракта шәһәр җирлегендә язылган булып чыга. Элек алай түгел, урта буын әдәбият мәйданына авыл турындагы әсәрләр белән килгән иде. Сан ягыннан чыгып караганда, бүгенге татар прозасы йөз белән эшче темасына, шәһәр тормышына борылды, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Инде ул әсәрләргә сыйфат ягыннан карап якын килә башласаң, мәсьәлә башкарак төс ала. Нефтьчеләр тормышына багышланган әсәрләрне алсагыз да, КамАЗ темасына караганнарын күздән кичерсәгез дә, алар арасында прозабызның казанышы булып саналырлыклары күп очрамый. Дөрес, бүгенге прозаикларны яза торган өлкәләрен белмәүдә гаепләү читен. Шулай да әсәрләреннән еш кына тимер-бетон салкынлыгы бөркелеп тора, эшче темасына караган проза әсәрләрендә җан җылысы азрак була. Сәбәпләрен төрле кеше төрлечә аңлата. «Литературная газета»да басылган мәкаләләренең берсендә Р. Мостафин, мәсәлән, бу хәлне безнең язучыларның актуаль тема артыннан куулары һәм ашыгулары газета-журнал һәм нәшрият җитәкчеләренең белә торып яки ирексездән производство темасына ташлама ясаулары белән аңлата. Минемчә, төп сәбәп бүтәндә — төп сәбәп традицияләр аз булуда, тәҗрибә җитмәүдә. Билгеле булганча, КамАЗмы ул, космосмы ул, әдәбият тормышның һәр яңа өлкәсен акрынлык белән, дистә еллар дәвамында үзләштерә, сантиметрлап-миллиметрлап үзләштерә. Әнә шул тәҗрибә җитмәү, традицияләр азрак булу аркасында «Кама таңнары»нда М. Хәсәнов төп героеныңауга чыккан, балык тоткан, күңел ачкан чаклары белән мавыга, «Тау белән тау очрашмаса да» повестенда М. Хәбибуллин шофер егетләрен күбрәк тол хатыннар тирәсендә йөртә, «Урамнар киңәя» повестенда Б. Камалов геройларының КамАЗ белән бәйләнеше ял вакытларында, эштән бушаган арада, яңа шәһәр, андагы үзгәрешләр белән танышып, шуларга сокланып йөрүдән әллә ни ерак китми. Бүгенге проза турында сүз барганда, аның сыйфаты хакында, заманында безнең прозаның үсешен тоткарлаган нәрсәләр турында фикер йөрткәндә, моны искә алмый

булмый. Хәзергә хәлләр кыенрак булса да, мин прозабызның киләчәген шәһәр тормышы, эшче темасы белән бәйләп карау ягында. Прозаның үсеш тенденциясе шулай уйларга нигез бирә.

Сәбәпләрнең тагын берсе буыннар алмашыну белән бәйле дип уйлыйм. Безнең прозада байтак еллар буыннар алмашыну процессы барды. Һәм ул процесс шактый зур кыенлыклар белән барды. Өлкән буын ифрат көчле һәм талантлы иде. Әдәби эстафетаны кабул итәргә тиешле чираттагы буын шулар күләгәсенә ышыкланыбрак үсте. Аларга җил-яңгыр да тимәде, кояш та әллә ни күп әләкмәде. 60 еллар уртасыннан әдәби эстафета шул яңа буын кулына күчә башлады. Революцияне күргән, колхозлар төзүдә катнашкан, илне фашизм афәтеннән саклап калган, кыскасы, зур тарихи вакыйгаларның уртасында кайнап үскән өлкән буын белән чагыштырганда, яңа буын сыеграк, йомшаграк булып чыкты. Баштарак алар гомуми шаукымга ияреп йөрделәр, бер өлкәдән икенче өлкәгә, бер темадан икенче темага ташланып аптыраттылар.

Урта буын, ул буынның әдәби хәрәкәттәге роле хакында сөйләгәндә, аларның әдәби-эстетик карашлары формалашкан чорны да исәпкә алмый булмый. Партиянең XX съездыннан соң матур әдәбиятта гади кешегә, аның эчке дөньясына игътибар нык артты. Әдәбиятта психологик анализ көчәйде. Алгы планга «шәхси як» чыкты, иҗтимагый як икенче пландарак калды. Урта буын дип йөртелгән прозаикларның әдәби-эстетик карашы шул чорда формалашты, дөресрәге шул атмосферада калыплашты. Шуңа күрә булса кирәк, алар язган роман-повестьларда тормышчан һәм ышандырырлык гадәти геройлар, бер уку белән истә кала торган тормыш күренешләре күп. Әмма олы характерлар, эпик киңлек һәм масштаблылык җитеп бетми.

Бәхеткә каршы, урта буын үз өстенә төшкән миссиянең нихәтле җаваплы булуын тиз аңлады — төпкә җигелеп, безнең прозаны алга тарта башлады. Хәзер прозабызны шул буын җитәкли, әдәбиятка шул буын тон бирә.

Турысын әйтергә кирәк, урта буын хикәя жанрын үстерүгә сизелерлек өлеш кертә алмады. Ара-тирә шәп хикәяләр чыккалап торса да, хикәя жанры әле һаман бер урындарак таптана, бер югарылыктарак кала бирә. Гомуми шаукымга ияреп, без әле һаман әдәбиятның иң сугышчан һәм иң оператив жанры хикәя дип йөрибез. Башка халыкларда ничектер, әмма татар әдәбияты мисалында хикәя андый жанр булуын раслый алмады. Һәрхәлдә соңгы 25—30 ел эчендә. Кабатлау булса булыр ике генә мисал китерим. 50 еллар ахырында, илебез тормышында булып узган зур үзгәрешләр һәм яңарышлар нәтиҗәсендә, әдәбиятыбызның барлык тармакларында кискен җанлану башланды. Заман җилләре бер хикәя жанрын гына читләтеп уздылар. Кама буенда гигант автомобиль заводы һәм яңа кала салына башлагач, шул ук хәл кабатланды. Кыска гына вакыт эчендә КамАЗга багышланган шигырьләр, поэмалар басылды, пьесалар, романнар, повестьлар язылды. Юньле хикәя булмады шикелле.

Шул ук сүзләрне роман уңае белән дә кабатларга мөмкин. Соңгы 10—12 ел вакыт эчендә 30 га якын роман басылган. Шуларның кулга тотарлыгы, әдәбиятның уңышы дип санарлыгы берничә генә. Зур осталык һәм бай тәҗрибә, масштаблы фикер һәм колач киңлеге сорый торган роман жанрында безнең прозаның, шул исәптән урта буынның да уңышлары күп дип булмый. Алар арасында роман жанрын тәмам үзләштергән, шул эшнең остасы диярдәй кешеләр берничә генә.

Аның каруы, соңгы елларда повесть жанры нык активлашты. Әгәр 20—40 елларда һәр ун елда басылган повестьларның гомуми саны 10—15 тән артмаса, хәзер бездә шул хәтле үк повесть бер ел эчендә языла. Хикмәт санда гына түгел, билгеле. Заман ихтыяҗларына, чорның актуаль мәсьәләләренә аеруча сизгер һәм оператив бер жанр буларак та, замандаш образын тудыру, чорның уңай героен иҗат итү өчен уңай жанр буларак та, повесть бүгенге проза, аның гражданлык йөзе хакында фикер йөртү өчен бай материал бирә. Бүгенге прозаның иң характерлы яклары шушы жанрда тулырак чагыла, соңгы еллар татар прозасының үсеш тенденцияләрен асылда шушы жанр билгели. Шуңа күрә бу мәкаләдә сүз күбрәк повестьлар хакында барачак.

Оператив һәм сугышчан жанр булу өстенә, повесть әле иң демократик жанр да икән.

Тагын шунысы кызыклы: повестьны әдәбиятта чәч агарткан өлкән буын да үз итә, иҗат юлын яңа башлаган яшьләр дә ярата. Соңгы 10—12 ел вакыт эчендә безнең матбугатта 150 дән артык повесть басылган, диләк. Аларны 60 тан артык кеше язган. Шул 60 кеше арасында М. Әмир, Ә. Еники кебек өлкән буын вәкилләре очрый. Иң күбесе, билгеле, урта буын дип йөртелгән язучылар өлешенә туры килә. Повесть авторлары арасында Н. Гыйматдинова, М. Галиев, С. Хафизов, К. Кәримов, Ф. Бәйрәмова кебек яшьләр, С. Сөләйманова, Г. Рәхим кебек шагыйрьләр, Т. Миңнуллин кебек драматурглар бар. Әдәбиятның башка жанрларында мондый хәлне сирәк очратырсыз. Киң күңеллелекнең бер нәтиҗәсе буларак, соңгы елларда повесть — сан ягыннан бик күбәйде, сыйфаты белән шактый чуарланды.

Производство темасына караган проза әсәрләре, аларның сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе хакында алда беркадәр сүз булды. Өстәп шуны әйтергә мөмкин: шәһәр материалы җирлегендә язылган әсәрләрдә производство җитәкчеләренең, галимнәр һәм инженерларның кызыклы гына образлары очрый. Әмма бу өлкәнең йөзен билгеләүче кешеләр: завод-фабрика эшчеләренең, нефтьчеләр һәм төзүчеләрнең истә калырлык, калку образлары юк диярлек.

Тагын бер гыйбрәтле хәл. Кама буенда яңа шәһәр һәм автомобиль заводы салына башлауга, бирегә журналистлар кайтып кермәде, Чаллыдан язучы эзгы өзелмәде. Кыска гына вакыт эчендә үзебездә һәм үзәк нәшриятларда КамАЗга багышланган күп санлы җыентыклар басылып чыкты. Турыдан-туры матур әдәбиятка караганнары гына да егермедән артык. Күбесе, билгеле, очерк китаплары. Шуларны рәттән укырга тотындыңмы, бер закончалык күзгә ташлана. Никадәр генә гаҗәп тоелмасын, иң яхшы очерклар КамАЗга атна-ун көнгә командировкага килгән Мәскәү кешеләренеке булып чыга. Икенче урында Казан язучылары торса, иң йомшагы — шунда яшәп, шунда эшләгән иптәшләрнеке. Традиция һәм тәҗрибә җитмәү белән бергә, бу — прозаикларның карашлар киңлеге, белем һәм хәзерлек дәрәҗәсе турында да сөйли торган факт.

Хикәя һәм роман жанрлары пассивлаша төшкәнлектән, повесть алар тартырга тиешле йөкнең бер өлешен үз җилкәсенә алырга мәҗбүр булды. Нәтиҗәдә повестьның тематик колачы нык киңәйде, сюжет-композиция төзелеше төрләнде. Хикәягә яки романга тартым повестьлар күбәйде. Болар һәммәсе проза өлкәсендәге чуарлыкны тагын да көчәйтә төште. Бер караганда, повестьны тарихи һәм тарихи-революцион темаларны яктырту өчен иң уңай жанр дип булмый. Шулай да соңгы елларда язылган 150 повестьның уннан артыгы нәкъ менә тарихи һәм тарихи-революцион темага карый. Мин Г. Мөхәммәдованың «Яшьлек көннәре», Н. Ихсанов белән М. Скороходовның «Йөзгә-йөз», М. Маликованың «Язгы такыялар», А. Вергазовның «Ташу», Ә. Шәминнның «Янар таулар кичкәндә», С. Сабировның «Утлы фарватер», В. Нуруллинның «Яшьнәп үткән яшьлек», Х. Сарьянның «Егет язмышы» кебек әсәрләрен күздә тотам. М. Әмирнең «Үткән турында бүген», Ш. Маннурның «Агымсуларга карап» исемле автобиографик повестьлары да характерлары белән тарихи-революцион темага караган әсәрләргә якын торалар.

Безнең әдәбиятта маҗара жанры туып-формалашып килә. Эшләр хәзергечә барса, йөкнең авыр өлеше монда да повесть җилкәсенә төшәчәк. Бездә хәрби-патриотик теманы үзләштерүнең үз традицияләре бар. Прозабыз фронт тормышын яктыртуда төрле этаплар үтте. Беренче чор әсәрләрдә совет кешеләренең Ватан сугышы кырларында күрсәткән батырлыгына соклану өстенлек итсә, бераздан шул батырлыкның чыганакларын эзләү көчәйде. Соңгы елларда исә фронт тормышының прозасына, гади солдат язмышына игътибар арта төште. «Һәркемнең гомере бер генә» дигән романы белән бу юнәлешне Х. Камалов башлап җибәрде шикелле. Аннары «Без дә солдатлар идек», «Сусыз дәрья», «Яшьлек утравым», «Солдат тәймәсе» кебек повестьлары белән Ә. Еники, Г. Шәрәфи, Ә. Маликов, И. Беляевлар дәвам иттерде. Аларга «Кайдан син, Жан?», «Таңнар һаман матурмы?», «Кызлар-йолдызлар» һәм «Кипарислар җыры» дигән повестьлары белән Ш. Рәкыйпов килеп кушылды. Шулай автобиографик һәм биографик характерда язылган, истәлеккә тартым повестьлар барлыкка килде.

Соңгы елларда басылган повестьларның зур бер төркемен яшь прозаиклар тарафыннан язылган әсәрләр тәшкил итә. Әдәбият белемендә хәтта «яшьләр повесте» дигән махсус термин кереп килә. А. Ганиевнең «Сүзсез җыр», Ф. Яруллинның «Җилкәнне җилләр оккач», С. Хафизовның «Яшьтәшләр», Ф. Шәфигуллинның «Өй салуның нио бар», Ф. Гыйльметдиновның «Елганың борылган төшендә» һәм «Урсай тау итәгендә», М. Галиевнең «Ак абагалар» һәм «Ул чакта», Разил Вәлиевнең «Эт кояшы» һәм «Иске сәгать дөрес йөри», Г. Рәхимнең «Көннәр язга авышкач» һәм «Саргаймагыз, кашганнар» дигән повестьларын шул типтагы әсәрләр рәтенә кертергә мөмкин. Аларны гадәттә яшьләр яза, өлкәнрәк яшьтәге кешеләр дә язарга мөмкин. Хикмәт авторның картмы-яшьме булуында түгел, ә бәлки ул повестьларның нигезенә салынган тормыш материалының характерында, төп геройны ачу, иҗат итү принципларында. Кагыйдә буларак, мондый повестьларның үзәгендә яшь кеше образы куела. Төп игътибар аның кырыс чынбарлык белән очрашуын, тормышта үз урынын, үз юлын эзләвен сурәтләүгә юнәлтелә. Яшьләр повестенда тормышны, кешеләрне аңларга тырышу хисе көчле була. Гадәттә әсәр яшь геройның беренче сынауларны узуын, тормыш юлындагы беренче мөстәкыйль адымнарын күрсәтү белән тәмамлана. Мондый әсәрләр заманның яшь герое хакында фикер йөртү өчен бай материал бирә. Яшьләр повесте кыска һәм җыйнак була. Бу — аны озын хикәягә тартым итә. Аларның тагын бер үзенчәлекле сыйфаты — ихласлык, «исповедь» характерында булу. Югарыда исемнәре саналган повестьларның һәммәсенә хас сыйфатлар нигездә менә шулар.

Тагын шунысы игътибарга лаек: Ф. Гыйльметдинов, Ф. Шәфигуллин һәм С. Хафизов повестьларыннан кала, аларның һәммәсе дә иҗат кешеләре тормышына, сәнгать мәсьәләләренә багышланган. А. Ганиевнең Габделхагы, М. Галиевнең Данияр белән Сәйяры — булачак рәссамнар, Ф. Яруллинның Фәнияры — язучы, Г. Рәхимнең Тимере — архитектор, Р. Вәлиевнең Искәндәре — композитор.

Гомумән, татар прозасында иҗат мәсьәләләренә, интеллигенция вәкилләре — галимнәр, врачлар, укытучылар, артистлар, язучылар тормышына багышланган повестьлар елдан-ел күбәя бара. Язмышлары төрлесенеке төрлечәрәк. Бер ишеләре басылып чыгуга җитди тәнкыйтькә очрады. Икенчеләре ничектер күләгәдә калды. Арада әдәбиятка кызыклы образлар, проза өлкәсенә яңалык алып килгәннәре дә булмады түгел. Шундый әсәрләр рәтеннән иң элек А. Гыйләҗевның «Урталыкта» повестен телгә алася килә. Бүгенге чынбарлыкның, бүгенге яшәешнең актуаль мәсьәләләрен күтәргән һәм үзенең бөтен пафосы, яңгырашы белән рухи торгынлыкка каршы чыккан бу повестьны соңгы еллар прозасының бер казанышы дип санарга була.

Казанышлар турында сүз чыккан икән, аларны тудыручылар хакында да берничә сүз әйтү кирәктер. Чөнки сөйләшү барышында кылычлар шушы мәсьәлә тирәсендә аеруча нык чыңлады. А. Гыйләҗев аларның санын өч кеше белән чикләсә, икенче берәүләр исемлекне зурайту кирәк, дип чыктылар. Билгеле, һәр язучы көченнән килгәнчә әдәбиятны үстерү, аңа күпмедер өлеш кертү өчен тырыша. Ләкин көч, талант һәм сәләт дигән нәрсә һәркемгә дә бер дәрәҗәдә бирелмәгән. Шул яктан карагандa,казаныш тудыручылар 70 үк була алмый һәм 3 кенә дә түгел. Телисеңме-юкмы, чын казанышларны барлаганда, еш кына берүк исемнәргә мөрәҗәгать итәргә туры килә: безнең прозада үз мәктәбе һәм шәкертләре булган Әмирхан Еники; әдәбиятның үзәктәге, иң мөһим мәсьәләләрен вакытында күреп алып, шуларны калку образлар, публицистик пафос белән сурәтләп баручы Гариф Ахунов; безне тынгысыз булырга, һәрвакыт гамь белән, уйланып-борчылып яшәргә өндәүче Аяз Гыйләҗев; әзлексез яңа формалар эзләүче, прозаның кырыс реализмын поэзиянең шартлы алымнары белән үреп баручы Әхсән Баянов; әсәрләренең телен ювелирларча эшли торган, тәмам өлгереп, җитлегеп беткәч кенә безнең арадан китеп барган Хәсән Сарьян; язганнарында кырыслык юмор белән, лиризм сатира белән чиратлашып килә, һәр әсәрендә яшьлеген сагынып яши торган, кызыклы ситуацияләр һәм көлкеле эпизодлар остасы Мөхәммәт Мәһдиев; әдәбиятны яңа материал һәм яңа геройлар белән баеткан, прозага яңа сулыш алып килгән Миргазиян Юныс; повестьларын якын дустына иң яшерен серләрен сөйләгән кебек итеп яза торган Вакыйф Нуруллин...

Соңгы елларда повесть жанрының иң зур казанышлары, иң матур сәхифәләре шул исемнәр белән бәйләнгән. (Кабатлап әйтәм, сүз повесть жанры өлкәсендә эшләүчеләр хакында гына бара.)

Әдәбиятның мәңгелек темасына — мәхәббәткә багышланган повестьларга мөрәҗәгать итик. Нинди генә юк аларның! Ир-хатын һәм сөяркәләр мәхәббәтенә багышланганнары, беренче мәхәббәт, соңгы мәхәббәт турындагылары... Инде зур, олы мәхәббәт, кешене кеше, аны гражданин итә торган мәхәббәт турындагы, бу хисне туган илгә, туган җиргә мәхәббәт дәрәҗәсенә күтәргән, алай гына да түгел, безнең прозада мәхәббәт һәм нәфрәт темасын яңа биеклеккә күтәргән повестьларны санарга кушсалар, күбебез, беренче чиратта М. Юнысның «Биектә калу», А. Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар», Ә. Баяновның «Тау ягы повесте», Ә. Гаффарның «Язлар моңы» кебек әсәрләрен телгә алыр идек, дип уйлыйм.

Әгәр мәхәббәт повестьларының барысы да әлеге әсәрләр дәрәҗәсендә булса, прозаның хәленнән зарланырга урын калмас иде. Кызганычка каршы, алай ук түгел шул. Безнең повестьларның иң зур күпчелеге өлкәннәр мәхәббәтенә, ир-хатын, гаилә мөнәсәбәтләренә багышланган. Аларның саны арткан саен, охшаш ситуацияләр, штампланган алымнар да күбәя бара. Әйтик, булачак гаилә башлыклары очраклы төстә танышып китәләр, артык мәшәкать күрми генә өйләнешеп яши башлыйлар, тора башлагач, характерларының туры килмәве ачыклана, кагыйдә буларак, ир тыныч, сабыр холыклы, әмма рухи яктан ярлы кеше булып чыга, аерылышырга мәҗбүр булалар. Сөяркәләр мәхәббәтенең дә үз штамплары калыплашып килә. Мондый повестьларда, кагыйдә буларак, гаиләле карт ирләр кызлар яки яшь хатыннар белән типтерә. Сөлектәй яшь егетләр ирле яки ирдән кайткан тол хатыннар артыннан чаба. Мәхәббәт дигәннәре һәрвакыт ачы каргышлар һәм күз яшьләре, үпкәләшү-талашу, кыскасы, һәлакәт белән тәмамлана. Тормышчанлык җәһәтеннән караганда, аларның күбесенә тел-теш тидерерлек түгел. Нишлисең, заман үзгәрә, мәхәббәт үзгәрә, аңа булган мөнәсәбәт үзгәрә. Ләкин интим хисләр, җенси мөнәсәбәтләр артык иркенәеп барган бер чорда язучы тормышка ияреп кенә йөрмәскә тиеш. Л. Ихсанова хаклы, кайбер прозаиклар мәхәббәт кебек җитди мәсьәләгә шактый җиңел карый башладылар. Күңелне шул борчый.

Авыл җирлегендә язылган повестьларның саны күп түгел. Бик тырышып исәпләгәндә дә, утыздан артмый. Аның каруы, проза өлкәсендәге кызыклы эзләнүләрнең, ачыш һәм табышларның күпчелеге шулар өлешенә туры килә. Әдәби хәрәкәт үсешенә тирән эз салган, соңгы еллар прозасының казанышы булып саналырлык повестьларның күбесе шулар арасында.

Әйтик, без байтак еллар буе татар әдәбиятында массаларны үз артыннан ияртерлек, көчле рухлы, нык үзәкле коммунист образлары күбәеп бара, дип сөенеп йөрибез. Ун еллык прозаны алып, тикшереп карасак, аларның да байтагы авыл җирлегендә язылган повестьларга туры килүен күрербез. Ф. Хөснинең Сәлим Ахунҗановы («Мәйдан»), В. Нуруллинның Өлфәт Хәкимовы («Күпер чыкканда»), Г. Ахуновның Саматовы («Чикләвек төше»), Б. Камаловның Хафиз Кадергуловы («Ялыкмаслар»), Х. Хәйруллинның Рамай Вильдановы («Канатлар талмасын»). Болар бит барысы да нибары өч ел вакыт (1970—1973 еллар арасында) эчендә иҗат ителгән образлар. Бераз соңрак, 1979 елда, алар янына В. Нуруллинның Булат Вәлиеве («Аккан су юлын табар») килеп кушыла. Б. Камаловның Кадергуловыннан кала, барысы да колхоз председательләре. Х. Хәйруллинның Вильдановыннан кала, нигездә барысы да колхоз белән 50 елларда һәм 60 еллар башында җитәкчелек иткән председательләр. Соңгы еллар татар прозасының бер зур казанышы — әнә шул колхоз председательләре, көчле рухлы коммунист образлары. Безнең прозада беркайчан да аларның бу кадәр күп булганнары юк иде.

Аларның һәммәсе дә диярлек үзләрен тормышның чын хуҗалары, тормышның бөтен мәсьәләләре өчен җаваплы кешеләр итеп сизәләр. Алар кыю төстә авыр һәм катлаулы мәсьәләләрне хәл итәргә алыналар, читен эшләргә тотыналар.

Бүгенге коммунистлар М. Әмирнең Бикташовыннан да («Безнең авыл кешесе»), Ә. Еникинең Шакир Мостафиныннан да («Саз чәчәге») һәм Г. Әпсәләмовның Морта-

зиныннан да («Сүнмәс утлар») шактый аерылалар. Алардан аермалы буларак, бүгенге коммунистлар теләсә нинди мәсьәләне хәл иткәндә, беренче чиратта, халык массаларына, аларның ярдәменә таяналар. Әгәр шулай әйтергә яраса, бүгенге коммунистлар демократ җитәкчеләр, халык массаларына бик тә якын юлбашчылар. Аларның тарту көче шунда. Боларны — бүгенге коммунистларның һәммәсенә уртак сыйфатлар. Шуның белән бергә, алар һич тә бер-берләрен кабатламыйлар. Халикъ Сапатов Өлфәткә охшамаган кебек, Өлфәт тә Рамай Вильдановтан аерылып тора. Әсәрнең характерына, авторның индивидуаль үзенчәлегенә карап, һәр әсәрдә алар кабатланмас төс ала. Кыскасы, бүгенге коммунист образлары арасында бик тә кызыклы һәм оригиналь характерлар бар.

Сугыш чоры һәм сугыштан соңгы авыл безнең прозада әйбәт яктыртылды. Бу — безнең прозаның бер казанышы. Монда урта буын дип йөртелгән прозаикларның роле зур. Р. Төхфәтуллиннан башлап В. Нуруллинга хәтле булган прозаикларның 60—70 елларда язылган әсәрләрен күздән кичерсәк, алар арасында без берсеннән-берсе кызыклы дистәләрчә повестьлар очратырбыз. Әдәбият үсешендәге мөһим бер этап булып, алар тарихка кереп калачак.

Шуннан язучылар алдына бүгенге авылны сурәтләү, авылның бүгенге хәленә күчү мәсьәләсе килеп басты. Ул җиңел эш булмады. Бүгенге авылны сурәтләүгә килеп җиткәч, хәтта авылның үткәнен биш бармагыдай белгән Р. Төхфәтуллин кебек прозаиклар да бер мәлгә аптырап, югалып калдылар. Чөнки авыл кызу темплар белән кинәт үзгәрде. Авыл җирендә барган үзгәрешләр, бик күп шатлыклар белән бергә, яңа проблемалар тудырды, яңа каршылыклар китереп чыгарды. Авыл халкы күпләп шәһәргә күчә башлады. Яңа төзелешләргә китте, нефть эшенә керде. Авылда калганнарның материал хәле, көнкүреш дәрәҗәсе көннән-көн яхшыра барды. Авыл өйләренең түбәләрен телевизор антенналары сырып алды, авыл урамнарында мотоцикллар, җиңел машиналар күбәйде. Баштарак язучылар авылдагы үзгәрешләрнең өлегә күренеп торган, өстәрәк яткан якларын элэктереп алдылар. Халыкны шәһәргә китмәскә үгетләп карадылар. Аннан байтак вакытлар авыл халкының көнкүреше яхшыруга, авыл җирендәге муллыкка шатланып һәм куанып йөрделәр. Кыскасы, авыл җирендә барган үзгәрешләрнең асылына төшену җиңел булмады.

Әмма авыл белән кызыксыну, аны аңларга тырышу тукталмады. Авылның бүгенге хәлен, бүгенге авылга хас каршылыкларны башлап М. Хәбибуллин белән Х. Хәйруллин сурәтләп бирде. Мин аларның «Чоңгыллар» һәм «Канатлар талмасын» исемле әсәрләрен күздә тотам. Бераздан аларга башка прозаиклар кушылды. Торатора язучылар авыл җирендәге үзгәрешләрнең асылына ныграк төшенә бардылар. Ныграк төшенә барган саен, шатлану-соклану авазлары минор тоннар белән аралашты. Авыл җирендәге үзгәрешләрнең фәлсәфи-әхлакый аспекты белән кызыксыну көчәйде. Язучыларны шәхеснең җәмгыять һәм коллектив алдындагы җаваплылыгы, крестьянның җиргә, табигатькә мөнәсәбәте, материал һәм рухи байлыклар арасындагы бәйләнеш, гармония кебек мәсьәләләр ныграк борчый башлады. Бүгенге авылга, анда барган процессларга әхлак ноктасыннан карап бәя бирү көчәеп китте. Прозада әхлак мәсьәләләре алгы планга чыкты.

Шәхеснең җәмгыять, коллектив каршында җаваплылыгы арту әхлак традицияләренең чыганакларын эзләүне таләп итте. Язучылар, шуларны эзләп, Октябрь революциясен ясаган, совет властен урнаштырган, социализм төзегән, колхозлашу хәрәкәтендә катнашкан буынга — әти-әниләребез тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булдылар. Буыннар бәйләнеше мәсьәләсе яңа эчтәлек, яңа төс алды.

М. Мәһдиевнең барлык әсәрләрендә диярлек кайта-кайта сугышка хәтле һәм сугыш елларындагы колхоз тормышына, авыл кешеләренә мөрәҗәгать итүе турында күп язылды. Төптән уйлап баксаң, моның да нигезендә әхлак традицияләренең чыганакларын эзләү ята икән. Сугышка хәтле авыл кешеләрендә коллективизм хисе, ярдәмчеллек көчлерәк булган, алар җиргә, табигатькә якынрак булганнар, үзара мөнәсәбәтләрдә табигыйлек өстенлек иткән, алар матур итеп, күңелле итеп яши белгәннәр. Шатлык-сөенечләр, борчу-кайгылар уртак булган. Шул сыйфатлар аларга авыр сугыш елларын җиңеп чыгарга булышкан. М. Мәһдиев яшьлеген шуңа сагына икән. Ул элекке авыл кешеләреннән рухи матурлык эзли. Бүгенге авыл кешеләрендә

шул сыйфатларны күрәсе килгәнгә, өлкәннәр тәҗрибәсен яшьләргә тапшыру теләге белән, сугышка хәтле һәм сугыш елларындагы авылга кат-кат әйләнеп кайта. Һич тә искелекне яратканга, искелекне сагынганга түгел. Шул «иске чор» кешеләрендә бүгенге буын өчен кирәкле әдәп-әхлак нормалары сакланганга күрә. «Торналар төшкән җирдә» повесте тагын бер кат шундый фикергә этәрә.

Ахыр чиктә Х. Сарьян («Бер ананың биш улы») белән А. Гыйләҗевны («Җомга көн кич белән») да шул ук мәсьәләләр уйландыра. Соңгы еллар прозасының яңа бер уңышы дип бәяләнгән әлеге повестьларында алар, үз мәнфәгатьләреннән бигрәк, башкалар турында кайгыртучы, ил гаме белән яшәүче карчыкларны калку итеп сурәтлиләр.

Әхлак мәсьәләләрен кискен итеп кую, прозада сатирик башлангычны көчәйтеп җибәрде. Әсәр үзәгенә тискәре геройны алып, баштан-ахырга кадәр аны тәнкыйть итүгә, фашлауга багышланган әсәрләр күбәеп китте. Ә. Баяновның «Аязучан болытлы һава» повестенда без шундый геройларның бөтен бер галереясы белән танышабыз. Т. Миңнуллинның «Хәсән Вәгыйзович» повестенда тар күңелле бер вак бәндә, фәннәр кандидаты булып алгач, кайчандыр үзен кыерсыткан, үзе белән әчелешле булган кешеләрдән, махсус эзерләнеп, үч алып йөри. А. Гыйләҗевнең «Әтәч менгән читәнгә» повесте, байлык артыннан куып, рухи хәерчелеккә чыккан кешеләр турында.

Ә. Баянов, Х. Сарьян, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев һәм башка язучыларның повестьларын тикшергәндә, соңгы елларда язылган әсәрләрнең иң көчлеләре мораль, әхлак мәсьәләләренә багышланган булуы күренә. Бу — бер повестьларга гына карый торган күренеш түгел. Мораль, әхлак мәсьәләләре әдәбиятның барлык жанрларында көчәйде. Мисал тесендә А. Расихның «Сынау», Г. Бәшировның «Җидеген чишмә» романнарына, Ә. Еники хикәяләренә, И. Юзеев һәм Т. Миңнуллин, Р. Мингалимов һәм Р. Хәмид пьесаларына, шагыйрьләребезнең бик күп шигырь-поэмаларына мөрәҗәгать итәргә мөмкин булыр иде. Әдәбиятта әхлакый башлангычларның көчәюе заман, чор ихтыяҗларына бәйләнгән. Бу әлеге әсәрләрне КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик-тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карары яктылыгына куеп караганда аеруча ачык күренә. Шул чагында тагын бер кат без язучыларның ил, халык мәнфәгатьләре белән яшәвенә ышанабыз. Аннары, мораль-әхлак проблемаларының активлашуы тагын бер нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Күп гасырлык бай тарихы булган татар әдәбияты нәкъ шундый мәсьәләләрне хәл иткәндә көчләрәк булуын күрсәтте. Димәк, традицияләр безнең әдәбиятны шуңа — шул мәсьәләләрне ныграк сурәтләргә хәзерләгән булган.

Без әдәбиятны, шул исәптән андагы аерым жанрларны даими һәм өзлексез тесте үсә, камилләшә барырга тиеш дип күзалларга гадәтләнгәнбез. Ихтимал, шулай тиештер дә. Әмма әдәби хәрәкәт без уйлаганнан, без күз алдына китергәннән күп мәртәбә баерак, катлаулырак процесс. Аның шулай булуын бүгенге прозабыз да раслап тора. Безнең куанып сөйләрлек уңышларыбыз бар, шул ук вакытта безне борчый торган нәрсәләр дә юк түгел. Прозаның реаль хәле шул турыда сөйли.

# ӘСӘРНЕҢ ЫШАНДЫРУ КӨЧЕ КИРӘК!

Проза турында фикер алышу бездә, авыл укучыларында да зур кызыксыну уятты. Чыннан да, соңгы елларда бик күп повестьлар һәм романнар язылды. Ләкин шулар арасында күңелдә уелып калганнары, уйландырырга мәҗбүр иткәннәре артык күп түгел. Теге яки бу әсәргә бәя биргәндә безнең тәнкыйтьчеләр профессиональ югарылыктан торып фикер йөртәләр. Әсәрнең темасы, сюжеты, композициясе, теле турында әйбәт анализ ясала. Әйе, болар барысы да кирәк. Ләкин әсәрнең ышандыру көче турында ләм-мим.

Һәрбер әдәби әсәр киң катлау укучылар өчен языла. Хәзерге чорда әдәбият сөючеләрнең күбесе урта белемле, югары белемле. Колхозларны алып карасак та, аларның һәрберсендә югары белемле 10—12 авыл хуҗалыгы белгече һәм җитәкче эшли. Соңгы елларда сигезьеллык мәктәпләр урта мәктәп итеп үзгәртелделәр, һәм анда югары белемле укытучылар саны тагын да артты.

Менә укучыга «Казан утлары» журналының өр-яңа санын китерделәр. Укучы журналның эчтәлеге белән тиз генә танышып чыга да проза әсәрен укый башлый. Әсәр башыннан ук үзенә җәлеп итә, мавыктыра һәм андагы вакыйгаларга, әдәби геройларның үзара мөнәсәбәтләренә ышанып, бу сәгатьтә укучы шулар белән яши. 45—50 битле повесть булса, берничә сәгать эчендә укып чыга да, соңыннан «Их тагын моның дәвамы булса иде» диеп уйланып утыра. Ни өчен бу әсәр укучыны шул кадәр үзенә әсир итте соң?

Чөнки мондагы вакыйгалар тормышның үзеннән алынган, ясалмалык юк, бу әсәрдәге фикерләр укучының уйларына аһәңдәш дигән сүз. Әдәби әсәр укучыны беренче битләреннән үк ышандыра алмаса, «монысын соңрак укырмын» дип икенчесен укырга тотына ул.

Теге яки бу әсәрнең вакыт сынавын үтүе һәм укучылар соравы буенча кабат-кабат басылуы аның яшәү көченә ия булуын күрсәтә. Мондый әсәрләрнең тәрбияви әһәмияте зур һәм андагы әдәби геройларның образлары укучыны рухи һәм әхлак ягыннан үстерүдә уңай тәэсир итәләр.

Сугыш һәм сугыштан соңгы еллар авырлыкларын кичергән кешеләрдән «татар язучыларының әсәрләреннән сезгә кайсылары бик уңай тәэсир итте» дип сорагандс, алар һичшиксез Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар», Шәриф Камалның «Матур туганда» романнарын, Мирсәй Әмирнең «Агыйдел» повестен, Гомәр Бәшировның «Намус», Кави Нәҗминең «Язгы җилләр», Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», «Ак чәчәкләр» һәм Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» исемендәге әсәрләрен әйтәчәкләр. Бу әсәрләр һәм югарыда күрсәтелмәгән боларга тиң роман, повестьлар тормыштан алып язылулары, оптимистик рухта булулары белән бүгенге укучыны да уйланырга мәҗбүр итәләр, барыбыз өчен дә тәрбия мәктәбе булып торалар.

Татар әдәбиятында мондый роман, повестьлар артык күп түгел, әмма шуларга охшашлы әсәрләр әледән-әле язылып торалар. Укучы югары сәнгатьле әсәрләрне тиз таный һәм бу әсәр турында кыска гына вакыт эчендә җәмәгатьчелек фикере туплана башлый.

Шушы фикерләрне исбатлау өчен яңа гына дөнья күргән бер повестька тукталып үтәсе килә. «Казан утлары» журналының 1983 елгы өченче санында Газиз Кашаповның «Җир җылысы» повестен кызыксыну белән укып чыктык. Әсәрдә колхоз тормышы язылган, һәм бу әсәрнең авыл укучыларын кызыксындыруы табигый. Ләкин кайбер урыннарда күңел ышанмый, ясалмалык сизелә. Мәсәлән, көн-төн яңгыр явып,

игеннәр теземнәрдә үреп ятканда колхоз председателенең эшен шәхси тормышындагы кыенлыклар белән катлауландыру нигә кирәк булды икән?

Колхоз председателенең семьясы булып, тугрылыклы хатыны келәч йөзе белән ирен каршы алса, балалары «әти кайтты» диеп аның муенына сарылсалар да начар булмас иде бит. Колхоз председательләренең, совхоз директорларының бик күбесе яхшы җитәкче булырак, матур итеп семья коралар һәм күркәм итеп яши дә беләләр. Ни өчендер соңгы елларда авыл тормышыннан алып язылган проза әсәрләренең күбесендә җитәкчеләрнең хатыны белән мөнәсәбәтләре әйбәт итеп күрсәтелми.

Колхоз тормышын бик дөрес чагылдырган Хәниф Хәйруллинның «Канатлар талмасын» романында председатель малае Дамирның ата тәрбиясе күрмичә әнисе белән генә үсүе, җитәкче буларак Рамайны бизәми. Вакыйф Нуруллинның «Аккан су юлын табар» әсәрендә колхоз рәисе Булатның, завхоз булып эшләүче чибәр хатын Галия вәсвәсәсенә бирелеп, ихтыяр көчен югалтуы һәм көпә-көндез келәткә кереп бикләнүләре, уку өчен кызыклы булса да, сәеррәк тоела һәм бик үк ышандырмый да.

Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Чоңгыллар» романында колхоз председателе Талип семья мәсьәләсендә ихтыяр ягыннан көчсез итеп бирелә. Ул элекке танышы, соңгы вакытта авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы булып күтәрелгән Миңнисаны да онытып бетерми, бәргә яши торган хатыны Кәфиянең дә ташлап китүеннән курка. Автор сүзләре белән әйткәндә «Ул моңа — ике хатын белән, ике хис белән яшәүгә гадәтләнә башлаган иде, оялмады». Укырга дип киткән җиреннән хатыны Кәфия «Мин Казанда калырга булдым» диеп хат яза. Гаилә таркалу алдында кала.

Әдәби әсәрләрдә җитәкче кешенең шәхси тормышын сурәтләү, аның эчке дөньясына үтеп керү бик кирәк. Ләкин без, хәзерге чорның җитәкчеләрен әхлак ягыннан да югарырак, камилрәк итеп күрергә телибез. Колхоз председателе, совхоз директоры бүген авылда иң беренче җитәкче һәм тәрбияче булып тора. Җитәкче буларак ул үзенең абруен саклау өчен шәхси яктан да үрнәк булырга тиеш. Бүгенге көннең таләбе шундый.

Әдәби әсәрләрнең эчтәлеге тормыштагы, чынбарлыктагы вакыйгаларга нигезләнсен!

**СӘЛАХ ШӘРИПОВ,**
Азнакай районы Чаллы авылы.

# КАЙБЕР ТЕЛӘКЛӘР

Проза турында бик олы бәхәс кузгалып китте, ләкин бу бәхәснең соңы яхшылык белән, дуслык белән бетсен дә, ул яхшыдан-яхшы әсәрләр тууга ярдәм итсен иде.

Мин 28 елдан бирле журналны даими алам һәм җентекләп укып барам. Бу чорда күп язучыларның әсәрләре укучылар тарафыннан җылы каршыланды. Минемчә, А. Гыйләҗев, бәхәсне кискенләштерү максаты белән генә: «Бүгенге көн прозасыннан өч кенә кешенең әсәрләрен кайта-кайта укыйм...»,— дип әйтәдер. Ә без, сезнең китапларны укып баручылар, сез атаган өч кеше янына Г. Ахунованы, Х. Хәйруллин, М. Юныс, М. Хәбибуллин, Х. Сарьян, Б. Камалов, В. Нуруллин, М. Маликова, Ш. Рәкыйпов, Р. Төхфәтуллин, Э. Касыймов, Г. Галиев һ. б. язучыларның фамилияләрен дә ихтирам белән өстибез. Ә өлкән буын язучыларыбызның әсәрләре, уңай геройларының кыйммәте тагы да зуррак бит! Г. Әпсәләмов әсәрләре — уңай образ мәсьәләсендә, минемчә, бик югары әсәрләр. Алар тирә-юньне, тормышны дөрес тануда, идея-эстетик зәвык тәрбияләүдә искиткеч әһәмиятлеләр. Тормышчан образлар! «Алтын йолдыз» романы геройларының уйланма булуларына өлкән класс укучыларын ышандыру кыен. Бу образларны анализлаганда балаларда тирән уйлану, үз хорлык-фигыльләренә, эшләренә тәнкыйть аша карый белү кебек хисләр уяна. А. В. Луначарский да: «Характер меняется, когда человек увлекается, когда он разожжен,

когда он любит, когда затронуты струны его эмоционального, чувственного существа»,— дигән бит, әсәрләрнең эмоциональ көче, байлыгы турында уйланып. Г. Бәширов, Ә. Еники, Г. Гобәй, М. Әмир, И. Гази, А. Шамов, Ф. Хөсни, Г. Минский һ. б. өлкән буын әдипләребезнең әсәрләре бүгенге кайбер әсәрләргә караганда яратылыбрак укыла түгелме соң?

Берничә киңәш-фикер әйтәсе килә:

1. Мәктәп дәреслекләренә әсәрләр тәкъдим иткәндә, нык уйлап якын килергә кирәк. «Чыбыркы», «Кабак» кебек хикәяләр уйламыйча дәреслеккә бирелгән. Бу әсәрләр балаларда уңай тәэсир тудыра алмыйлар.

2. Балалар өчен яхшы проза әсәрләре аз. «Маякчы кызы» (Г. Гобәй), «Онытылмас еллар» (И. Гази), «Рөстәм маҗаралары» (Г. Кутуй) кебек мавыктыргыч, тәрбияви, бүгенге көн баласының күңелен җилкетерлек әсәрләр бармы?

3. Язучылар — әйдәп баручылар, бөтен яхшылык-изгелек орлыкларын сибүчеләр. Ә безнең язучыларда тормышка, аның кире күренешләренә ияру фактлары еш очрый. Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын» повестен яратып укыдык. Ләкин күңелдә канәгатьләнмәү хисе дә кала. Нигә кирәк булды икән Рамайны Сәкинәгә хыянәт иттерү, аннан килеп ике баласының мәхәббәте? Тормышта очраган мондый күренешләргә дә әрнеп карыйсың, язучы да шуны «пропагандалый» (чөнки Рамай — уңай герой, аны язучы гаепләми дә кебек, ул Мәрьямгә «ярдәм генә итә»). М. Мәһдиевнең дә чамадан уза төшкән вульгар урыннары бар. А. В. Луначарский басым ясап әйтә: «...Всемерно избегать всякой ругани и острословия, на том простом основании, что надо приучать публику уважать художественную работу». Бик матур фикер!

Ә. Баяновның «Таш китап» романында зур гына урын алган Сафа Байгуҗин — Гафур образы бирелгән. Бу образга кайсы яктан якын килергә дә белмисең. Әллә төзелеш тәрбияләгән образ димәкче буламы аны язучы, аңлашылмый. Фәез дә, эшчеләр белән кырыс кына, каты куллы җитәкче, Сафаның Гафур икәнлеген раслау өчен вакыт калдырып йөри. Бу Фәез характерына ябышып бетми. Кама образының да исеме җисеменә туры килми. Кама исеменә лаекмы соң бу хатын?

4. Бүгенге язучылар иҗатыннан, ни өчендер, мәктәп, укытучы темасы читтә кала. Булган әсәрләрдә дә (киноларда да) укытучы — көлке үзәге, чудак итеп бирелә. «Яшел яр» да (Г. Әпсәләмов) Гәүһәр, «Фронтовиклар» да (М. Мәһдиев) матур гына укытучы образлары бар. Ә бүгенге көн укытучысы? Нигә бераз уйланмаска? Нигә ата-аналарны балаларын тәрбияләүгә җаваплырак итмәскә? «Советская Россия» газетасында (1983, 10 апрель) «Достоинство учителя» мәкаләсе менә дигән тема ич. Әгәр мәктәпкә бурычлардан тыш, бераз хокуклар да бирелсә, бүгенге яшь белгечләрнең — студентларның, завод-фабрика эшчеләренең үз-үзләрен тотышында, хезмәткә карашларында да уңай үзгәрешләр булыр иде. Бик көтәбез сездән бу теманы ачуыгызны.

Без язучыларны иң гадел, иң объектив, гуманлы кешеләр итеп күз алдына китерәбез. Әнә шуңа күрә дә менә дигән образлар туар әле дигән өметтә калабыз!

**ФЛЕРА ӘХМӘТШИНА,**
укытучы.
*Брежнев шәһәре*

# ҮРДӘ ИМӘННӘР...

Тау битеннән сикереп аккан
Саф көмештәй чишмә бул син,
чишмә бул.
Нәфес, рыя ваклыгыннан
Өстә бул һәм чиста бул син,
чиста бул!

Шагыйрь Гамил Афзал менә утыз ел инде үзенең шигъри антына тугрылык саклый. Шагыйрьнең 1979 нчы елда дөнья күргән «Талларым, терәкләрем» һәм сүз алып бара торган «Үрләрдә имәннәр шаулый» (Татарстан китап нәшрияты, 1981.) китабы шуны раслый. Бу китаплар үзләренең эчтәлеге, әсәрләрнең тематикасы һәм, ниһаять, композициясе ягыннан бер бөтенне тәшкил итә. Әнә шуңа күрә аларны Г. Афзал иҗатында мөһим этап дип карарга нигез бар. Алар аша без шагыйрьнең 70 нче еллар азагы һәм 80 нче еллар башында нинди уй-проблемалар белән янып яшәвен, күңелендә нинди көенеч һәм сөенечләр барлыгын белә алабыз. Шул ук вакытта китапка тупланган шигырьләр аша без чорыбызның горурлыгы булган казанышларны да, җанны борчыган кимчелек һәм җитешсезлекләрне дә күзаллыйбыз.

Китап «Карап торганым бар», «Үрләрдә имәннәр шаулый», «Тойгылар тирән якта», «Елмаеп-көрсенеп» дип исемләнгән дүрт бүлектән тора. Беренчесендә — шагыйрьнең шигъри декларациясе итеп кабул ителерлек күләмле шигырьләр, икенчесендә — ике строфалы сигезъюллыклар, өченчесендә — дүртъюллык шигъри миниатюралар, соңгысында — сатирик һәм юмористик әсәрләр. Күренә ки, китапның дүрттән өч өлешен лирик әсәрләр тәшкил итә. «Талларым, терәкләрем» дә нәкъ шул принципта төзелгән иде. Әлегрәк үзен башлыча сатира һәм юмор остасы итеп таныткан шагыйрь өчен шактый мәгънәле факт бу. Ул шагыйрьнең иҗат эволюциясе кайсы якка авышканын сиземләргә мөмкинлек бирә.

Хәер, Г. Афзал беркайчан да «коеп куйган» сатира остасы гына булмады. Аның иң оста язылган сатирик һәм юмористик әсәрләрендә һәрвакыт лирик башлангыч үзен нык сиздерә, һәр шигырь артында шагыйрьнең я моңсу елмаюын, я усал көлүен төсмерләп була. Шуңа күрә аның сатирасын һәм юморын лирикадан аерып каравы да бик кыен, алар еш кына укмашкан хәлдә яшиләр. Бу ягы белән Г. Афзал шигырьләре Һ. Такташ әсәрләрен хәтерләтә. Ә сатирасының усаллыгы, компромиссызлыгы исә шагыйрь иҗатын Г. Тукайга якынайта. Г. Афзал иҗатының киң популярлыгы, халыкчанлыгы, китапларының тиз таралып бетүе дә әлеге факторлар белән аңлатыла, күрәсең.

Инде шагыйрьнең лирик иҗатына мөрәҗәгать итик. Шагыйрь гомумиләштерүләр ясар өчен фактларның күплегенә омтылмыйча, тормыштан бер, әмма иң характерлы фактны тотып алырга, шуннан чыгып гомумиләштерүләр ясарга омтыла. Шулай булмаса катлаулы тормыш юлы үткән шагыйрь шәхси биография, шәхси кичерешләр сферасына кереп чумган булыр иде. Әмма, Г. Ибсен әйтмешли, чын шагыйрь баштан узганнарны башы кичергәннән аера белергә тиеш. Чөнки соңгысы гына чын иҗат предметы, факты була ала. Г. Афзал да нәкъ шулай эшли. Ул да башы, йөрәге аша кичергән, җанын борчыган нәрсәләр турында язарга ярата. Г. Афзалның шигырьләре әйтеләсе фикернең саллы һәм туры бәреп әйтелүе, ихласлыгы аркасында тормышчан һәм актуаль яңгыраш таба, алар да шагыйрьнең изге принциплары, ышанулары ярылып ята, алар күңелне ярсыта, сафлыкка, рухи пакьлеккә әнди, икенче бер шагыйрь әйтмешли, «кулны вә җанны пешерә».

Шагыйрьнең «Рухым» шигыре әнә шундыйлардан берсе:

Иске бәет булып чормаларда яткан,
Сөреп, чәчеп, урып, кара тиргә баткан,
Тормыш арбасына нык җигелеп тарткан,
Йөк атыдай чыдам көчле рухым минем.

Менә шушы «елаган-көлгән, җиңгән-җиңелгән, якты өмет дигән» көчле рухы шагыйрьгә иҗат принципларыннан тайпылмыйча яңа үрләр яуларга җегәр, дәрт-дәрман бирә. «Иҗат» шигырендә ул бер генә мизгелгә дә тынып калмый торган шагыйрь күңеленең сихри табигатен ачып сала. Менә ул ат булып бүрәнә, кирпеч ташый, капитан булып, давылда диңгез кичә, я булмаса, төшендә Чапайны күрә, солы басуы өстендә җил булып исә, Уралга барып урала, сандугач килгән чагында гөлгә кунып сайрый... Шагыйрь, иҗатчы күңеле могҗиза белән тулы. Иҗатчы һәрвакыт көрәшче дә. Ул — якты идеаллар, изге ниятлар хакына башын, җанын салырга әзер.

Үлемгә бардым һөҗүмгә,
Җиңелде, үлде үлем.
Иске окоплар төбендә
Сөякләр ята минем.
Дөньядан киттем, котылдым
Соңгы кат һава сулап.
Алдадым, оттым, отылдым,
Һәм кабат тудым елап.

Иҗат эшен шулай тирән аңлаган Г. Афзал иҗатчының үлмәс, онытылмас сәхифә калдырачагына нык ышана. Кыскасы, китап — шагыйрь гомере, кайгы-шатлыгы, хыялы-өмете. Иҗатка шундый югары критерийлардан чыгып бәя бирүче шагыйрь күңелендә ирешелгәннәргә генә канәгать булмау хисе уянуы да табигый:

Бер адымлап һәр көн алга бардым,
Гомер буе җигелгән ат төсле.
Дәрәҗәдән, мактаулардан ардым;
Ә күңелдә канәгатьсезлек хисе.
Аз тырыштым, аз эшләдем төсле.

Г. Афзал лирик шигырьләрендә дә күпне күрә белүче, үткен күзле, усал телле сатирик булып кала бирә. Шагыйрь иҗаты тирән тарихчанлык белән сугарылган. Ул элекке һәм бүгенгене чагыштырып, сынап карарга күнеккән. Андый шигырьләрдә бөтен бер буынның, халыкның, илнең героик үткәне күз алдына бастырыла. Бу китаптагы «Дәртле агым», «Каерылып кайнады заманнар», «Беренче бишьеллык, унынчы бишьеллык» — шундый актуаль яңгырашлы шигырьләр. Г. Афзал ул елларның дәртле романтикасына мәдхия укып, дан җырлап кына калмый, уйлана, бүгенге көн белән чагыштыра. Аңа коры риторика, буш шапырыну — ят нәрсә. Автор ерак елларның кырыс матурлыгын, кешеләрнең хезмәттәге тыйнак батырлыгын күз алдына бастыра: алар «ат кебек» ял белмичә эшләгәндә дә күңел көрлеге, намус сафлыгын саклап яши белделәр, ди шагыйрь:

Мин күрдем ул чорның кепкалар
дулкынын,
Байраклар чайкалды дулкында:
«Бишьеллык — дүрт елда! Бишьеллык —
дүрт елда!»
Соклансын, тетрәнсен бар дөнья!

Җитлеккән социализм тудырган бүгенге шартларда экономия, хезмәт җитештерүчәнлеге, сыйфат, тәртип өчен көрәш барган көннәрдә 20—30 нчы еллар энтузиастларының берсе үзе булган шагыйрь яшьтәшләренең, чордашларының һәркайсы «оратор, үзара тәнкыйтьче» булулары, «прогулчы, ялкауларны» кызарта алуларына соклана. Бу күркәм сыйфатларны ул бүгенге яшьләрдә дә күрергә тели, «сәбәпсез моңсулык»ның тирән сәбәпләрен шагыйрь күңелендәге шул борчылуыннан эзләргә кирәктер.

Тирә-яктагы уңай күренешләр аны шатландыра, куандыра. «Без — егетләр», «Үзгәрергә кирәк», «Каршыга искән җилләр исертә» кебек шигырьләрендә көр күңелле, тырыш һәм уңган эшче егетләргә сүз бирелә:

Сафлык булсын кешеләрнең күзләрендә,
Шатлык булсын алма-алсу йөзләрендә...

Шагыйрьне глобаль проблемалар: яшәү-үлем, җир, ил язмышы, тынычлык һәм сугыш, мәрхәмәтлелек белән явызлык кебек мәңгелек проблемалар борчый. Ул үткәннәрдән гыйбрәт алырга өнди, кисәтә, ялвара.

Г. Афзалның «Йөз чәчәкле болын» шигыре (аны мин хәтта лирик поэма дип тә атар идем) — татар халкының катлаулы үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында. Шигырь тарихи дөреслеге, шигъри детальләрнең төгәллеге белән таң калдыра. Лашманчылар, Пугачев, камчылы казаклар, елан күзле патша, ак кокардалы жандарм, губернатор, «чагар күзле, тасма телле юха асыл сөяк» Лука Канашевич, поплар, алпавытлар, каторга, Себер, миссионер Ильминский, эмигрантлар, колчаклар, фашист-

лар... һәм, ниһаять, Октябрь, Ленин, Республика:

**Күктә кояш, җирдә тамырлар нык,**
**Шаулап үсә Ленин иманнәре.**

Күрәсез, Гамил Афзалның шигърият үрләрендә нинди иманнәр үсә, нинди иманнәр шаулый! Китапның беренче бүлеген шагыйрь тирән мәгънәле сүзләр белән тәмамлый:

**Ватаныбыз — йөз чәчәкле болын,**
**Йөз төрле җыр анда, йөз төрле моң.**
**Телләр бергә әйтә бер үк сүзне,**
**Ленин байрагына куеп йөзне.**

...Китабының соңгы бүлекчәсендә Г. Афзал сатирик һәм юмористик шигырьләрен урнаштырган. Анда, елмайткан, көрсендергән, һәм, хәтта, келә-көлә елаткан әсәрләр дә байтак. Бәлки кайберәүләр шагыйрьнең «көлке капчыгы» саегая башлаган, кояшлы, йомры юморы тоныклана төшкән диярләр. Без исә, 50—60 еллардагы Афзалның куәтле ташкын сыман ташып торган, елмаеп-көлеп, «шашып» аккан сатира-юмор елгасының тарая төшүен сизенсәк тә, аның үз агымын, кыйбласын үзгәртмәгәнлеген һәм һич тә саекмаганлыгын ассызыклап әйтеп үтәргә тиешбез.

Бу агым, бәлки, киң далага чыккан тау елгасы кебек, берәз салмаклана, җитдиләнә төшкәндер, тирә-якка артык җәелмичә, үзенә тиешле тирән фарватерын тапкандыр. Шагыйрь үз күңелен аеруча нык чокып торган җитешсезлекләргә кабат әйләнеп кайтканлыктан төпсез чоңгыллар да хасил булгандыр. Ләкин шунысы бәхәссез— шагыйрь һәм гражданин буларак, Г. Афзалның сатирик иҗаты туктаусыз үсештә һәм яңарышта.

Алдарак әйткәнебезчә, шагыйрьнең лирикасы сатирасыннан аерылгысыз яшь. Алар — бер атаның ике улы, икесе дә үз һәм кадерле. Шуңа күрә әлеге җыентыктагы бүленешләрнең шактый шартлы икәнлеген искәртеп үтәргә дә кирәктер. Мәсәлән, беренче бүлектәге «Күләгәле яклар» шигырен укымыйча, соңгы бүлекнең төп юнәлешен һәм пафосын аңлавы шактый читен булыр иде:

**Күләгәле якны күрә бу дип**
**Уйламагыз тагы.**
**Безнең генә түгел, Айның да бар**
**Күләгәле ягы.**
**Якты булыгыз дип кушып тора**
**Ямьле яшәр чаклар.**
**Ямьсез почмакларда посып тора**
**Күләгәле яклар.**

Шагыйрьнең бөтен иҗаты — лирикасы да, сатира-юморы да — шул күләгәләрне бетерүгә юнәлдерелгән. Иҗатын «Дөнья матур, дөнья киң!», «Кәефләр шәп, күңелләр шат!» дип, тормышка, кояшка, матурлыкка мәдхия җырлап башлаган Г. Афзал әле хәзер дә:

**Матурлыгын дөнья**
**Гел арттыра бара.**
**Көн яктыра бара,**
**Ил яктыга бара —**

дип җырлавын дәвам итә. Әмма утны-суны кичкән, күпне күргән һәм белгән иҗатчының үткен күзе, сизгер йөрәге кояшны вакыт-вакыт күләгәләп алган кара тапларны аермачык күрә һәм сизә. Монда ул художниктан бигрәк, оста табибны хәтерләтә. Ул авыруның исемен атап, сатира нурлары белән караганда, күләгәдә посып яткан чирнең бациллаларын көйдерергә, юк итәргә ниятләнә. Бу җитешсезлекләрне «елмаеп, көлеп» кенә бетереп булмый, көләргә дә, көрсенергә дә, дуларга да, көрәшергә дә кирәк! Гамил Афзал бу көрәшнең авыр һәм газаплы икәнлеген үз язмышында татып, кулыннан каләмен ычкындырмаган шагыйрь. Елмаю-көлүнең танылган остасы булуга карамастан, ул бу көрәшкә гаять җитди мөнәсәбәттә. Менә ни өчен аның шигърияте торган саен кырыслана, чыныга бара.

Бер шигырендә лирик герой исеменнән: «Әшәкелек, алдау булмый торган саф бәхетле тормыш корырбыз, туры юлдан гына барырбыз без, конфет ашап кына торырбыз» дип, беркатлы уйлап, «юеш борыннарны тарта-тарта, үткән заманнарны теткән» яшь шагыйрь инде дөньяга башкачарак карый:

**Гасырны минутлар ашый**
**Гамьсезлек белән,**
**Сүрәнлек белән.**
**Заманны кешеләр ясый,**
**Бөеклек белән,**
**Түбәнлек белән.**

Әйе, көрәш дәвам итә, «идеал өчен бәреп башны ташка» тарих мәйданына Некрасов, Тукай варислары килә. Алар белә: «Көрәш — газап, әмма җиңү якты!».

Шагыйрьнең борчулы уйланулары, рухи канәгатьсезлеге, җан пошынуы аны еш кына остазы Тукай янына алып килә. Мондый бәхетле минутларда чын, «туры Тукайча» яңгыраган шигырьләр туа:

**Берәү булса туры сүзле, кыю акыл,**
**җаны тапсыз,**
**Тиле, дибез, яши белми, фикер йөртә**
**масштабсыз.**

Г. Афзал тормышта очрап куйгалаган җитешсезлекләрне шигърияттнең бөек миссиясен аңлап фаш итә. Шагыйрь бик күп типлардан ачы көлә һәм аяусыз камчылый. Чыннан да, ялган, мәкер, ялагайлык, ике-йөзлелек, хөсет, яла, масаю, ришвәтчелек, бюрократизм кебек күренешләр — бүген генә туган яман шешләр түгел, ләкин аларның һәр чорда үзенчәлекле төсмерләре була. Г. Афзал әсәрләрендә дә андый персонажлар байтак. Сатирик, кайчандыр Акмулла тапкан, Тукай, Бабичлар үстергән алымны оста файдаланып, бу затларның үзләренә «трибуна бирә» — туйганчы эчләрен бушаттыра. Бу типлар ничаклы гына тискәре булмасыннар, алар бездә мыскыл катыш елмаю да уяталар. Һәм тагын шагыйрь аларны шундый сыгылмалы, үзенчәлекле тел белән сөйләтә ки, ирексездән, «шундый-шундый эшләр, тора-бара нишләр», «тәрәз аша карап торам, гайрәт белән мыек борам», «минем хәлне хатын ишеткән — пшол!— диде миңа ишеткән», «Әсмабикә җаным-ахирәт», дип, аларча сөйли башлыйсың. Бу әсәрләрдә сатирик Гамил Афзал юмор остасы Гамил Афзалдан аерылгысыз. Соңгы җыентыкларда исә сатира белән юмор арасындагы мөнәсәбәт шактый үзгәрә төште — сатираның чукмары саллыланды, юморның нәзакатлелеге артты.

Шагыйрьнең сатирик типлар галереясы бик бай: менә «Кояштай балкып, шат елмаеп», мөлаем елмаюыннан битлек ясап, төп «эшенә төкереп йөргән» җилкуар. Менә «үз данын саклап, көчлеләрне мактап», «капка саклап яткан эт кебек» көн күргән тип. Менә «хатынының адъютанты» булып, кибетләргә чабып йөрүче», шулай да үзен Наполеонга тиңләгән бер аумакай зат. Менә «кеше данын сөймичә, үт суын йотып ятучы хөсет җанлы ахмак», «күкрәк киереп алга да чыкмыйча, үт чәчрәтеп нотык та тотмыйча, анкетасы «курыкты, ашады, йоклады» дигән өч сүздән торган бәндә һ. б. һ. б.

Шагыйрьнең «Файдалы киңәшләр», «Фельетон геройларына сатирик теләкләр»е дә авторның яңа, кызыклы ачышларга юлыгуын күрсәтә. Шигырьләренең берсендә ул:

**Туры әйткән ярамый шул туганына,**
**Уйлый күңел ул ягын да, бу ягын да.**
**Урап-урап, кыек атып, туры тигән**
**Эзоп теле ярдәм итә шул чагында,—**

дип яза. Аның тагын «Патша белән табиб турында әкият», «Бер төркем иптәшләр», «Шабашниклар бәете» кебек әкият, мәсәл, бәет жанрыннан файдаланып язган әсәрләре дә бар. Автор аларда да сатира-юмор куәсенең бөтен куәтен кулланып яза.

«Прометейга үпкә» дигән озын шигырьдә махсус тукталасы килә, чөнки ул, бер яктан, Г. Афзалның туктаусыз эзләнү җимеше булып торса, икенче яктан бу тәҗрибәле останың да вакыт-вакыт чама чиген тоеп җиткермәвен күрсәтә. Биредә Прометейның үлемсез образы сугыш һәм тынычлык темасын ачуда уңышлы кулланыла. Шигырьнең беренче яртысы юмористик характерда, уен-көлке белән тутырылган. Ләкин шул рухта башланган шигырь:

**Прогрессмы бу,**
**Нагасаки көле,**
**Хиросима көле бизәкме!**
**Җанны үтерә торган агу җиле,**
**Прометей, сиңа кирәкме! —**

дигән юлларда җитди рух ала. Шулай итеп, олы тема, уңышлы образ аша бирелсә дә, Прометей бер үк вакытта сатирик һәм героик планда тасвирлану аркасында үзенең җитдилеген һәм тәэсир көчен югалта. Кыскасы, автор бу шигырендә сатира-юморның һәм лирик башлангычның уңышлы синтезына ирешә алмаган.

Гомумән алганда, шагыйрьнең бу җыентыгы Гамил Афзал иҗатының җитлегү чоры кичерүен күрсәтә. Шагыйрьнең тавышы татар поэзиясе хорында үзенчәлекле һәм матур яңгырый.

**РАФИС ӘХМӘТ.**

# ЯШЬ ЯЗУЧЫНЫҢ БЕР ХИКӘЯСЕ

«Татарстан яшьләре»нең быелгы 30 апрель санында яшь язучы Нәбирә Гыйматдинованың «Әтиле бала» исемле хикәясе басылды. Хикәянең кыскача эчтәлеге шуннан гыйбарәт. Авылда, Илбай өендә мәҗлес бара. Шул чакны күрше карчыгы: Фатыйма бала тапкан, дигән хәбәр китерә. Көтелмәгән хәбәр бөтен мәҗлеснең ямен җибәрә. Фатыйма баласының атасы Илбай икән. Колхоз бригадиры Илбайның үз семьясы бар. Илбай белән аның хатыны Нурбисәл арасында бозылышу булып ала. Бригадир яңа туган балага магазиннан кием-салым алып йөри. Бер-ике елдан соң Илбай үзенең Фатыймадан туган малае белән очраша, аны «кыр сыман иркен» кочагына ала. Шулай итеп, җилдән туган бала әтиле була.

Иң элек авторның уңай якларын күрсәтеп китәргә кирәк. Нәбирә кискен бәрелешләрдә кискен характерлар тудырырга тырыша. Тормышны ул үзенчә күрергә, үзенчә сурәтләргә омтыла һәм шул ук вакытта катлаулы проблемаларны да хәл итмәкче була.

Боларның барысы да яшь язучының кыюлыгы дип әйтергә мөмкин. Дөрес, яхшы хикәя иҗат итү өчен язучы кешегә кыюлыктан башка әле бик күп нәрсәләр кирәк. Кыюлык ул барыннан да элек белем, тәҗрибә һәм шигъри сиземләү белән беркетелергә тиеш. Авторда белем дә, тәҗрибә дә, сиземләү дә бар, әлбәттә. Ләкин җитәрлек дәрәҗәдә түгел, ягъни катлаулы тормыш күренешләрен, катлаулы характерларны дөрес итеп, чамасын белеп сурәтли алырлык дәрәҗәдә түгел.

Шулай итеп, Илбай дигән абзый кеше өендә мәҗлес бара. «Мәҗлес халкы туган-тумача, дус-ишләрдән җыелган, бу кичәгә барысы да, Илбай малае Арысланны кандидатлык диссертациясен уңышлы яклавы белән котлап, бушлай эчәргә килгән иде»,— ди автор.

Китерелгән өзек ике җөмлә рәвешендә язылырга тиеш иде. Беренче җөмлә «җыелган» дигән сүз белән тәмамлана, икенче җөмлә «бу кичәгә» дип башлана. Җөмләләрне дөрес аермау фикер буталчыклыгы китереп чыгара. Монысы — мәсьәләнең формаль ягы.

Эчтәлек ягына килгәндә, шул: кандидатлык диссертациясен уңышлы яклагач, беркем дә авылга, атай йортына кайтып, мәҗлес ясамый. Андый эш, әгәр дә ул эшләнә икән, якланган көнне үк шәһәрдә эшләнелә. Димәк, мәҗлеснең сәбәбе дөрес уйланылмаган. Арыслан шәһәрдән яшь килен белән кайткан. Мәҗлесне, дөресрәге, «аш-суны», «кунак җыюны», «кунак чакыруны» менә шул яшьләр кайтуы хөрмәтенә ясаган булсалар, отышлырак булган булыр иде. Шунда ук Арысланның кандидатлык диссертациясе яклавы турында да әйтеп китәргә булыр иде.

«Туган-тумача, дус-иш» турында авторның «бушлай эчәргә килгәннәр» дип әйтүе урынсыз. «Бушлай» сүзе укучыга күңелсез тәэсир ясый. Бит мәҗлесне хуҗа кеше үзе җыйган, аш-суны үзе пешергән, туган-тумачаны, дус-ишләрен дә, күрәсең, үзе чакыргандыр. Шулай булгач, аларның ашавы-эчүе тулысынча хуҗа исәбеннән булачагы алдан ук билгеле түгелмени? Гомумән, кунак чакыруда «бушлай» һәм «бушлай түгел» дигән нәрсә була алмый.

Шул рәвешчә, «Илбай малае Арысланның кандидатлык диссертациясен уңышлы яклавы белән котлап, «җыелган «мәҗлес» башланып китте. Беренче сүзне ата кеше әйтте. Автор бу хакта берни язмый, ләкин икенче абзац диалог белән башлана, һәм андагы сүзләрнең Илбайныкы икәнлеге аңлашылып тора.

— «Син кем дип, улымнан сорагач, тел белгече ди. Мин җир белгечен, ат белгечен беләм, мондыен юк. Ходайга шөкер, белгечләрсез дә эшлибез. Әнкәсе гаепле: алдына тау-тау китап өйде, кирәк-

лесен генә укытмаган, юкса, минем нәселдә сүздән өтер эзләүчеләр юк иде. Минем ата-бабам икмәк үстергән, ат караган».

Абзац шунда тәмам.

Бу сүзләрне ата кешенең кандидат улын котлап әйткән сүзләре дип әйтеп буламы? Юк, булмый. Теләсә нинди әти кеше туган-тумача, дус-иш алдында, табын янында, аек килеш үзенең улы белән мактанырга, ничек тә аның һәм шулай ук үзенең дәрәҗәсен күтәрергә тырышыр иде.

Автор Илбайны уңай герой итеп тасвирламакчы була. Аның бөтен уңайлыгы шунда: ул — җир кешесе, игенче, ат караучы. Ләкин игенчене данлау, аны яхшы яктан күрсәтү өчен яшь язучы дөрес булмаган алым куллана. Шәһәргә китеп укыган, галим булган Арыслан белән Илбайны ул конфликтта итеп күрсәтә. Уңай герой Илбай үзенең галим улы белән конфликтта булгач, Арыслан кире герой булырга тиеш. Ләкин Илбайның улына карата әйтелгән әлеге «котлау» сүзләрендә ата кешенең «уңайлыгы» тулысынча юкка чыга.

Шулай итеп, хикәя башында ук Илбай шактый аңсыз һәм надан бер кеше булып күз алдына килеп баса. Белемнең, китапның, тел белгече булуның хәзерге замандагы әһәмияте турында сөйләп тору кирәк микән? Шулай да әйтмичә булмый — киләчәк гомерен әдәби иҗатка багышларга, тел, белем һәм китап белән эш итәргә җыенган яшь язучының белемгә, галимлеккә каршы чыгуы һәм бөтен хикәя дәвамында диярлек тел белгеченә карата кирәкмәгән ирония, мыскыл сүзләре куллануы күңелне рәнҗетә.

Кунаклар алдында үзенең улына, хатынына шундый тупас сүзләр әйткән, һәм, күрәсең, башкаларның да кәефен бозган Илбай Арыслан белән генә, хатыны белән генә түгел, гомумән, бөтен авыл белән, үз халкының күптәнге традициясе белән конфликтка керә.

Әйтелгәнчә, тол хатын Фатыйма бала тапкан; баланың атасы — Илбай. Халыкта мондый нәрсәне килештереп бетермиләр. Купчелек моны гаеп эш дип, хурлыклы эш дип исәпли. Ни генә булмасын, бу — шактый катлаулы һәм четерекле мәсьәлә, һәм мондый нәрсәне һәр очракта да җиңел генә, акка-карага бүлеп кенә хәл итү мөмкин дә түгел.

Бүгенге көннең яшь прозаигы моңа ничек карый соң? Автор Фатыйманы бөтенләй диярлек тасвирламый. Шунлыктан без аның хәлен, эчке кичерешләрен белмибез. Илбай исә, бала тугач, чын мәгънәсендә батыр булып, тузынып, бөтен нәрсәгә «нипачум» дип йөри. Күрше карчыгы хәбәр китергәч, ул, кунакларын ташлап, «кулына ябышкан хатынын бер якка селтәп», «урындыкларны типкәли-аудара ишеккә» ташлана (автор «ишеккә капланды» ди). Фатыйма турында, яңа туган бала турында яратмыйча әйткән сүзләре өчен хатынына Илбай очып куна, колхоз конторасына дулап килеп кергән Әсләхне — Фатыйманың улын бик каты сүгеп чыгара.

Кыскасы, яшь язучы тулысынча Илбай яклы. Илбай нишләсә дә, нәрсә сөйләсә дә килешә кебек. Дөрес, автор монда бала хокукын, аның әтиле булырга хакы барлыгын яклый сыман. Мәсьәләгә бу яктан караганда, берни әйтеп булмый. Туган икән, теләсә нинди баланың яшәргә һәм бәхетле булырга хакы бар. Бу — мәңгелек проблема.

Бары психологик романнарда гына хәл ителергә мөмкин булган менә шушы мәңгелек проблеманы Нәбирә Гыйматдинова кыска хикәядә хәл итмәкче була. Шуңа күрә дә ул уңга-сулга тайпыла, күп нәрсәнең очын очка ялгый алмый, күп нәрсәнә уйлап-чамалап җиткерми.

Мәсәлән, дөньяда бит җилдән туган бер бала һәм Илбай гына яшәми. Дөньяда тормыш күптән дәвам итә. Кешеләрнең нык урнашкан үз карашлары, кагыйдәләре бар. Җитмәсә, Илбай дигән әлеге кешенең гомер иткән үз хатыны да исән. Хатын, билгеле, иренең кыек эшен хуплый алмый. Телисеңме-теләмисеңме, бу очракта ул хаклы. Хатынына Илбай: «Ярар, тарлыгыңны тый!» — ди, ныграк телләшә башлагач, «җиде бабаңны хәтерләрсең!» — дип янап та ала.

Яшь язучы бар нәрсәдә ирне акларга, хатынны яманларга тырыша. Илбай хатыны Нурбисәлнең исә яманлыгы башыннан ашкан. Улы Арысланның авылда калмыйча, шәһәргә китеп тел белгече булуында, баланы атадан аеруда тулысынча Нурбисәл гаепле имеш.

«Арысланга яшь тулар-тулмас көннәрдә малаеның барлыгы белән мактанып (?) кырлар-урманнар әйләнергә хыялланган Илбай баланы, һәйбәтләп төрдә дә үзе белән янәшә тарантас читенә (?) утыртты. Нурбисәл бакчада (?) кәрләр әлә иде, кузгалабыз дигәндә генә, ярканат сыман (?) чәчрәп, балага кунды (?).

— Алма! Жә ялгыш тегермәчкә кысарсың!» (?) дип яза автор.

Ана белән атаның конфликты хикәядә менә шушы вакыйгадан башлана. Әлеге ызгыш вакытында Нурбисәл тагын болай ди:

«— Баланы үзем тәрбиялим. Калада яшәүче ученый итәм. Тирес исеннән болай да гарык».

Автор дәвам итә:

«Төшкәме кайта Илбай, кичкәме, өйдә илереп бала елый, аны тыеп, әнисе акыра:

— Әтиеңнең аты тешләк! (?) Әтиеңнең аты пычрак! Бар, төсле рәсемнәр кара, телевизор кабыз!

— Ат, ат карыйм!..— дип үкергән бала телевизор каршында тынычланып кала».

Ана күшенең яше дә тулмаган баланы тарантаска утыртып каядыр кырлар-урманнар әйләнергә җибәрмәве бик табигый. Яше дә тулмаган бала ана янында, ана күзәтүендә булырга тиеш. Бу, беренчедән. Икенчедән шул: ата белән ананың сабый бала өчен, аның киләчәге өчен автор язган рәвештә тартышы, бәхәсе булу мөмкин түгел.

Бишектәге бала бишкә тәрләнә, ди халык. Менә шундый «бишектәге бала» турында ананың: үзем тәрбиялим, «ученый» итәм дип, «ярканат сыман» чәчрәп кунуы ышандырмый. Бит ананың баланы тәрбияләү хокукын беркем дә тартып алганы юк! Аннан соң, ата кешенең үз баласын үзе янына утыртып йөртүе ул әле «тәрбия» була алмый. Гомере буена авылда яшәгән, «утыз ел укыткан», димәк, укытучы хатынның тирес исе яратмавы, бала алдында әледән-әле ата кешене хурлавы, «атаңның аты пычрак» дип «акыруы», «ат, ат карыйм! дип үкергән» балага рәсемле китаплар да телевизор гына карарга кушуы шулай ук ышандырмый.

Чынлыкта хикәядә ир белән хатын арасында бернинди каршылык та юк. Ананың үз улын «ученый» итәргә чамалавы гына каршылык була алмый. Ир белән хатын арасындагы конфликтның төбендә башка төрлерәк, җитдирәк сәбәпләр ятарга тиеш иде сыман. Автор исә андый сәбәпләрне күрсәтә алмый һәм бөтен нәрсәне ананың «ялгыш тәрбиясенә» кайтарып калдырырга тырыша. Баланың галим булуы ана кеше өчен генә түгел, ата кеше өчен дә горурлык булырга тиешләгән Нәбирә исәпләп җиткерми. Арыслан һәм Арыслан кебек бик күпләрнең туган-үскән авылларын ташлап, шәһәргә китүләре бугенге көннең иң катлаулы проблемаларыннан берсе булып тора. Бу мәсьәләне шулай ук «аңсыз» ана тәрбиясенә генә кайтарып калдыру дөрес булмас иде.

Нурбисәлне бар нәрсәдә гаепле итеп күрсәтү авторга Илбай-Фатыйма мөнәсәбәтен аклау өчен кирәк. Әлеге мөнәсәбәтнең мораль ягына мин тукталып тормыйм. Монда мин автор тасвирлаган вакыйгаларның логик эзлеклеге, психологик яктан аклавы һ. б. шундый нәрсәләргә генә тукталмакчы булам.

Мәҗлес башында ук Илбай «чәй салынган (?) чәшкесен кулына тотып», «котлау» сүзе әйтә башлагач, Арыслан, янындагы хатынына пышылдап: «Әткәй картайды, тиз исерә»,— ди. Әтисе улының сүзләрен ишетеп кала да, әйтә: «Борчылма, улым, атаң инде ун ел чәй эчә. Тазалыгы да бар»,— ди.

Автор Илбай исеменнән тагын шундый сүзләр дә әйттерә: «Ферма тәзек, халык тук икән, атаң таза. Кырлар ялангач түгел, урманнар шәрә түгел икән, атаң нык» — ди. Яшь язучы, билгеле, Илбайны җиргә, урманга, халыкка якын кеше итеп тасвирламакчы була, ләкин чынлыкта, чагыштырып булмый торган нәрсәләрне чагыштырып, ул ялгыш юлга кереп китә. Мәсәлән, фермалар бик тәзек булырга, ләкин халык тук булмаска мөмкин. Кырлар, урманнар күзен шәрәләнеп кала, кышын кар белән капланa. Мондый табигый үзгәрешләрнең аерым кешенең сәламәтлегенә карата бернинди катнашы юк.

Икенче бер урында, айгыр җигеп, Фатыйманы больницага илтергә җыенганда, Илбай тагын мактанып ала: «Миндәге тазалык әле әдрит! Әйеме, кара айгыр? Сездән-бездән (?) ким түгел, әйеме, туган?» — ди. Автор, Илбайның тазалыгын күрсәтү өчен, айгыр белән аның арасында параллелизм үткәрә. Илбай, имеш, шундый шәп ир кеше, аңа хәтта яшь килене дә күз атып утыра. «Киленчәк баядан бирле каенатасының күзендәге ымсындыргыч очкыннарны аулап уфтана иде»,— дип яза автор. «Киленчәк уфтангагда», ата кеше үзенең улына: «Марш йокларга!» — ди. «Әти кеше өстәл сугып, тәл бәлгечәнең сүз запасын кыскартты»,— ди шунда ук автор. Каенатасының боерыгыннан соң яшь килен: «Печәнлеккә менеп яткач та, кара яндырып чәметәм әле боламыкны» — дип уйлый.

Әйтергә кирәк, нечкә, ышерен хис-тойгылар турында автор ничектер, чамасы

белмичәрәк яза. Хәер, психологик яктан акланган булса, андый «белмичәрәк»ләрне йотып та җибәргән булыр идең. Ләкин Нәбирә күп нәрсәне исәпләп җиткерми. Мәсәлән, янында «боламык» булса да яшь ире булган яшь хатынның тупас каенатасына карап уфтанып утыруын һәм гомумән шул дәрәҗәдәге талымсызлыгын һәм әдәпсезләгән күз алдына китерүе кыен.

Шулай да ниндирәк ир кеше соң ул Илбай-бригадир? «Мәҗлес» башланганда ук Илбай кулына «чәй салган чәшке» тотып, аягүрә басты. «Атаң инде үн ел чәй эчә»,— ди ул үзе турында. Димәк, ул ел элек ул аракы эчкән. Хәзер әнә эчми. Аракыны яратмаган өчен түгел, булдыра алмаган өчен эчми дип уйлыйбыз.

Илбайның Фатыйма белән очрашуын автор болайрак тасвирлый. Төнлә фермадан кайтып килгәндә, Илбай печән урлаган Фатыйманы очрата. Бригадир кеше буларак, каракны ул беркадәр шелтәләп ала. Шулчакны «тез башына суктыларммыни, Илбай урталай сынды»,— дип яза автор.— «Йөрәкмени, ходзем! Хәмитне дә шул каһәр гүргә тыкты»,— ди Фатыйма.

Яшь язучы тасвирлавын дәвам итә:

«Фатыйма, печән күтәргән сыман итеп кенә бригадирны кочаклап, өенә алып керде» — ди. Әле генә ниндидер баһадир булып тоелган ир кеше менә шушы җөмләдән соң бик нык кечерәеп, мәскенләнеп кала. Авыру Илбайны хатын караватка сала. «Фатыйма караватк кырыена тезләнде дә, эт баласына охшатып, башы белән мендәр читенә төртелде» ди автор. Шулай итеп, батыр Илбай яшь язучы тасвирлавында «эт баласы» кебек кенә булып калды.

Хикәя азагында Илбайның батырлыгын күрсәтүгә тагын урын бирелә. Тарантаска утырып барганда, Илбай «кара айгырның сыртына гомерендә беренче мәртәбә чыбыркы тидереп» ала. Айгыр, ачуланып, «үчләшүен (?) баса алмыйча, арбасы-ние белән хуҗасын коймага китереп сылады...» диелә хикәядә. Яшь киленчәкне ымсындыра торган, «күкрәгендә тыпыр-тыпыр яшь шайтаннар биешә торган», үзен «кара айгырдан» ким санамый торган бригадир Илбай, ниндидер җебегән малай-шалай кебек, рәтләп дилбегә дә тота алмый һәм үзен арбасы-ние белән коймага китереп сыларга» юл куя!

Фатыйма белән Илбай мөнәсәбәте дә бик сәер генә тасвирлана. Кем соң ул Фатыйма? Яшьмә, картмы, чибәрме, ямьсезме, дигәндәй? Мондый нәрсәләр турында без бер нәрсә белмибез. Шулай да автор кайбер детальләрнә теркәп уза. Фатыйма — әйтелгәнчә, тол хатын. Аның, башка чыгып, үз гаиләсе белән яшәүче Әсләх дигән улы бар. Фатыйма, күрәсең, таза, көчле, тупас хатындыр. Илбайны ул әнә җиңел генә күтәреп өенә алып керде. «Илбай таза, нык кулны сыйпап күкрәгенә салды» — дип яза хикәя авторы Фатыйманың кулларын күз алдында тотып. Хатын-кызның кулы ир кешегә, киресенчә, йомшак булып тоелырга тиеш иде югыйсә.

Шунысы кызык, әле җитмәсә Фатыйма— карак та. Караклык аларның нәселеннән килә икән. «Миңа, Патыйма килен, тәртипле шәһәр укымышлысына караганда шул каракларым якынрак бит. Алар ил-җирдән качмыйлар»,— ди Илбай. (Бу сөйләшү хикәядә тасвирланган вакыйгадан ике ел элек, ягъни Арыслан галим булып кайтканчы була.) Автор Илбай сүзләре белән турыдан-туры караклыкны, урлашуны аклау юлына баса. Мөнысы инде тагын да сәеррәк.

Сәер нәрсәләр хикәядә гомумән бик күп. Тел-стиль хаталарын, логик ялгышларны тавык чүпләп бетерерлек түгел. Мәсәлән, Илбай Фатыймадан туган баланың малай булуына бик нык шатлана һәм аны да үзе кебек үк авыл кешесе, җир хуҗасы булыр дип өметләнә ахрысы. Ләкин бөтенләй көтмәгәндә, яшь язучы: «Фатыйма ике ел буена аңар бала төсен күрсәтмәде» дигән хәбәр әйтә. Баласын күрергә теләгән атага нинди генә ана каршы килеп торыр икән дә, кем генә үз баласын ике ел буена кешедән яшереп-качырып асрар икән?! Бәлки монда эшләр башкачарак булгандыр? Әйтик, ата кеше, бәлки, үзе күрергә теләмәгәндер баланы? Алайса, нишләп автор аны шундый бала җанлы итеп тасвирларга тырышты соң?

Нәбирә Гыйматдинова ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләренең нечкәлекләрен һәм башка шундый гап-гади нәрсәләрне белеп җиткерми янсә, белсә дә, хикәя язганда, уйлап-чамалап җиткерми. Аның тасвирлавынча, бала тапкан Фатыйманы, айгыр җигеп, больницага илтеп куялар. Гадәттә авырлы хатынны бала табар алдыннан илтәләр «бүлнискә». Гыйльмия карчык Фатыйманың бала табуы турында авыл буенча сөйләп йөри. «Бригадир төнлә бәбәйләде. Патыймадан, ялганласам, чәчрәп таралыйм»,— ди Гыйльмия карчык. Ашыгу-

ыннан ул кешеләрне, исемнәрне буташтырырга да мөмкин. Ләкин хикәядә мондый буташтыру Гыйльмия карчык буташтыруы булып түгел, язучы буташтыруы булып аңлашыла. Айгыр турында яшь язучы: «хуҗасын күргә, ул тынычсызланып бии башлады»,— ди. Икенче бер урында шул ук айгыр турында: «койманы сөзеп кенә аударды да, канатланып, Сәмит болынына очты»,— диелә. «Бабаң җирдә караңгы булган», «Илбай тынга капты», «Үзәннән дә артмый, чамасы ишле бит» — диган җөмләләрдә сүзләрнең мәгънәләре аңлашылмый.

Әдәби әсәрдә кешеләргә (геройларга) исем кую шактый кыен нәрсә. Булачак геройның исеме дөрес табылса, аның характеры да, әсәрдәге «тормыш юлы» да дөрес билгеләнә. Кайбер яшь язучылар үз геройларын күз күрмәгән, колак ишетмәгән ят исемнәр белән атарга яраталар. Ят исемле кеше ныграк истә кала дип уйлыйлар, күрәсең. Нәбирә дә шундый алым кулланган. Укучы буларак миндә, мәсәлән, Илбай, Нурбисәл кебек исемнәр бары кире тойгы гына тудыра. Илбай саф төрки исем, шулай да ул хәзерге заман турындагы хикәядә ятышмый. Нурбисәл — ясалма һәм ят исем.

Кыскача нәтиҗә ясап, шуны әйтергә туры килә: Нәбирә Гыйматдинова, үзе нык-лап белмәгән, өйрәнмәгән психологик темага алынып, хата ясаган. Теләсә нинди язучы бары тик үзе белгән, үзе инанган нәрсә турында язганда гына яхшы әсәр иҗат итәргә мөмкин. Яшь язучы турында сүз барганда, бигрәк тә шулай.

**НУРИХАН ФӘТТАХ.**

## Мансур Шиһапов

# ТЕАТР—ЗАМАН КӨЗГЕСЕ

Татар дәүләт драма һәм комедия театры — республикабыз тамашачыларына, шулай ук башка автономияле республикалар, Урал, Оренбург, Астрахань өлкәләре, Казахстан, Әзербайҗан, Урта Азия союздаш республикалары хезмәт ияләренә яхшы таныш булган, совет театр сәнгатен үстерүгә үзеннән лаеклы өлеш кертүче, үз йөзен булдырган коллектив.

1933 елда Татар дәүләт академия театры каршында күчмә колхоз филиалы оештырыла. Академия театрының төп иҗат көчләре «авыл театры» тудыру инициативасын зур шатлык белән каршылыйлар һәм аның нигезен салуда катнашырга зур теләк белдерәләр. Мәсәлән, филиал дәверендә куелган спектакльләрдә татар сәхнәсенең якты йолдызлары булган Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская, шулай ук Колмәмәт, Мәҗит Илдар, Ибраһим Шәһдәлиев, Зариф Закиров актив катнашалар. Ә труппаның төп нигезен Мәскәү татар театрыннан кайткан артистлар тәшкил итә. Режиссер итеп Гали Ильясов билгеләнә. Мәскәү татар театрын оештыруда актив катнашкан, аның сәхнәсендә озак еллар режиссер һәм актер булып эшләгән, югары театр белеменә ия булган Г. Ильясов Казанда яңа иҗат коллективын туплый.

Театр филиалының ачылу көне Бөек Октябрьның 16 еллыгы бәйрәменә туры килә. Ул К. Тинчурин белән К. Нәҗминең колхоз төзелешенә багышланган «Булат бабай семьясы» спектакле белән ачыла. Спектакль беренче тапкыр 6—7 ноябрьда Питрәч районының Шәле авылы колхозчыларына күрсәтелә. Шул чакларда, Казанда әле филармония булмаган бер вакытта, театр каршында концерт-эстрада группасы оештырырга да мөмкинлек туа...

Коллектив үзенең иҗади йөзен билгеләп, киң катлам тамашачыларның ихтирамын казанып, яңадан-яңа уңышлар яуларга омтылганда, Бөек Ватан сугышы башланып китә. Артистларның бер өлеше автомат алып фронтка китә. Яшь артистка З. Хәлиуллина, мәсәлән, Кызыл Байраклы зенит артиллериясе полкында хезмәт итә, ирләр белән бер сафта торып сугыша. Талантлы артистлардан Г. Зәйнуллин, Г. Хисаметдинов, Ф. Камал сугыш кырында батырларча һәлак булалар.

Сугышның беренче елларында театрга кечерәк күләмле пьесалар, концертлар куярга туры килә. Тора-бара коллектив зур күләмле әсәрләргә дә мөрәҗәгать итә башлый. Дәһшәтле сугыш елларында Х. Садрыйның «Партизаннар», Р. Ишморатның «Гөлзадә», «Кайту», Ш. Мәҗитовның «Сөеклеләр» дигән пьесалары сәхнәгә менә.

Иҗат коллективының ялкынлы патриотик хисләре, фидакарь хезмәтләре сугышның иң авыр шартларында театрны таркалудан саклап кала. Әсгать Мәҗитов, Хан Исмәгыйлов, Газиз Гыйматов, Бибинур Галиуллина, Вера Минкина, Сәләх Сәгыйтов, Сафия Хөснетдинова, Асия Әхмәтҗанова һ. б. артистлар партиябезнең хак сүзен халыкка җиткерү, аны җиңүләргә рухландыру өчен бөтен көчләрен куялар. Аларга еш кына декорацияләрне тартып йөрергә, көненә 2—3 чыгыш ясарга, суык клубларда, кыр станнарында уйнарга туры килә.

Театрның шөһрәте республикабызның барлык районнарына тарала. Аның килүен һәр җирдә көтеп алалар. Нәтиҗәдә, 1944 елның октябрь аеннан ул Татар дәүләт республика күчмә театры дип йөртелә башлый.

Сугыштан соңгы еллар театрның чын мәгънәсендә профессиональ коллективка әверелү еллары булып исәпләнәләр. Бу елларда аның иҗат йөзе тагын да ачыклана, спектакльләрнең сыйфаты күтәрелә. Труппага Совет армиясеннән кайткан З. Хәлиуллина, З. Тунишева, М. Хәмзин, Ф. Юнысов, Т. Кичубаев, Ә. Әбдерәшитов кебек сәләтле артистлар кушыла. М. Шаһидуллина, З. Камалова кебек яңа көчләр килә. Театр үз репертуарын заманча проблемалар күтәргән әсәрләр белән баетырга тырыша. Мәсәлән, режиссер Г. Юсуповның «Тормыш җыры» (М. Әмир), «Украина далаларында» (А. Корнейчук) әсәрләре буенча куйган спектакльләре коллективның бу еллардагы зур иҗади уңышлары булып торалар. Шушы спектакльләр өчен театрга колхоз-совхоз театрлары смотрында беренче премия бирелә.

50 нче еллар башыннан алып Татар дәүләт республика күчмә театрының иҗаты белән республикадан читтә яшәүче татар тамашачылары да таныша башлый. Театрның гастроль маршрутлары Урал шәһәрләреннән алып, Казахстан далаларындагы чирәм җирләргә кадәр барып җитә.

1955 елны театрга баш режиссер булып Кәшифә Тумашева килә. Югары театр белемен ия булган, режиссура өлкәсендә бай тәҗрибә туплаган, татар театр сәхнәсенә кадрлар әзерләү буенча үзен танытып өлгергән К. Тумашева коллектив алдына зур иҗади бурычлар куеп эшкә керешә. Бу елларда авторлар белән эшләү системалы төскә керә. Драматурглар Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, Г. Насрый, Х. Захит, Ш. Зәйни, Г. Минский, художниклар Ә. Тумашев, Ә. Нагаев, аннары Җ. Фәйзи, Х. Вәлиуллин, С. Садыйкова кебек композиторлар театрның иҗади эшендә актив катнашалар.

50 нче еллар ахырына театр югары профессиональ әзерлекле иҗат көчләре туплаган коллектив буларак танылa. Шуннысы характерлы, труппадагы артистларның теоретик белемнәре һәм практик тәҗрибәләре бертигез булмауга карамастан, аларның барысын да актерлык осталыгын камиллаштерергә өйрәнү, эзләнү, Станиславский системасына таянып иҗат итү теләге берләштерә.

1962 елдан алып бүгенге көнгә кадәр театрның баш режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Равил Тумашев төрле милләт халыкларының алтмышка якын әсәрен сәхнәгә куйды. Ул күчмә театрның үзенчәлекле эш шартларыннан һәм аның иҗади состав мөмкинлекләреннән чыгып, һәрбер спектакльне профессиональ югарылыкта иҗат итәргә омтыла. Озак еллар дәвамында театрның директоры булган Мөхәммәт Хәмзин, 70 нче еллар уртасында аңа алмашка килгән Сәет Шакуров иптәшләр театрыбызның традицияләрен баетуда, коллективны иҗади үстерүдә уңышлы эшләделәр.

Театр соңгы 10—15 елда үз драматургларын тәрбияләп үстерде. Бүгенге көндә киң катлам тамашачыларга танылып өлгергән байтак драматургларның әсәрләре беренче тапкыр безнең театр сәхнәсендә куелды. Аның Т. Миңнуллин, И. Юзеев, А. Гыйләҗев, М. Маһдиев, Р. Хәмид, Ә. Гаффар кебек драматурглары бар. Аларның әсәрләре тормышның үзе кебек чын, геройлары тамашачыны ышандырырлык итеп сурәтләнә. И. Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» спектаклендәге урманчы Хәмзин образын, мәсәлән, һәр як тамашачысы: «Безнең авыл кешесе турындагы спектакль ич бу!» — дип кабул итте. Т. Миңнуллинның «Нигез ташлары»ндагы Гарифулла образы шулхәтле тормышчан иде ки, ул авторны соңрак Әлмәндәр кебек олы образ тудыруга этәрде.

Бу драматурглар белән театр үзенең иҗади планнарын бәйли. Ул алардан һәр сезонда яңа пьесалар көтеп алуы һәм аларны сәхнәләштерүе белән, бәлки, әлеге авторларны яңа әсәрләр иҗат итүгә рухландырыр. Театр өчен дә, авторлар өчен дә бу, һичшиксез, күңелле хәл. Чыннан да, бер-береңне тирәнтен аңлау, бер үк идеаллар белән рухлану һәркайсыбызның күңелендә зур канәгатьләнү тойгысы тудыра.

1979 елның апрель аеннан, ТАССР Министрлар Советы карары нигезендә, Татар дәүләт республика күчмә театры Татар дәүләт драма һәм комедия театры дип атала башлады. Театр коллективы бу вакыйганы партия һәм хөкүмәтебезнең иҗат кешеләре турында даими кайгыртучанлыгы итеп кабул итте. Бу, бер үк вакытта, катлаулы иҗат юлы үткән коллектив эшенә бирелгән зур бәя иде. Моңа бәйле рәвештә, коллектив алдына яңа бурычлар да килеп басты. Югары идеяле, яхшы сыйфатлы спек-

такльләр тудыру бурычы иде ул. һәм соңгы елларда мондый спектакльләрнең саны тагын да артты. Бүген репертуарыбызда заман проблемаларын күтәргән, төрле тема һәм жанрларда язылган егермедән артык әсәр даими уйнала. Алар арасында классика да, бүгенге тәҗрибәле драматургларның, шулай ук яшьләрнең яңа әсәрләре бар.

Театр авыл тамашачыларын идея һәм политик яктан тәрбияләүдә уңышлы эшләп килә. Ул ярты гасыр буе юлда. Елларның дәһшәтлесе дә, юлларның газаплысы да аны бу изге максатыннан аера алмады. Театр елына 500—550 спектакль күрсәтә икән, аның дүрт өлешеннән артыгы авыл тамашачылары алдында уза. Бу спектакльләрне 176 меңнән артык тамашачы карый. Үз нәүбәтендә авыл тамашачысы театрны, театр белән бергә артистларны үстерде, баетты. Коллективның авыл тамашачысы белән мөгамәләсе дусларча, һаман ныгый бара. Шуның нәтиҗәсендә коллектив республика, РСФСР, Союз театрлары арасында оештырылган социалистик ярышта һәрвакыт призлы урыннарны яулый. 1981 елның икенче яртыеллыгы, 1982 елның беренче яртыеллыгы нәтиҗәләре буенча Бөтенсоюз социалистик ярышында безнең театрга III урын бирелде. Коллективның күп кенә артистлары төрле медальләр, Почет грамоталары белән бүләкләнде.

Театр үзенең 50 еллык юбилеена әзерләнгән репертуар белән Ташкент, Бохара, Сәмәркәнд, Казан тамашачылары алдында иҗат отчетын уңышлы тапшырды. Алар тиздән илебез башкаласы Мәскәүдә уздырылачак гастрольләргә әзерлекнең җитди сынавы булдылар.

Драма һәм комедия театры үзенең илле еллыгына өлгергән, җитлеккән иҗат коллективы буларак килде. Алда аны шул ук җаваплы һәм мактаулы эш — авыл тамашачыларына культура хезмәте күрсәтү эше көтә.

**Гүзәл Вәлиева**

# ТАТАР КЕЛӘМЕ ҺӘМ ГОБЕЛЕНЫ

Бизәкле тукыма һәм келәмнәр эшләү халкыбызның борынгыдан килгән һөнәрләреннән санала. Пәрдә, җәймә, сөлге ясалган тукымаларның, келәм һәм киезләрнең халкыбыз көнкүрешендә тоткан урыны зур. Казан татарлары элек-электән туку станы ярдәмендә төрледән-төрле төсләрдәге геометрик сурәтләр белән бизәлгән келәмнәр сукканнар. Тарихчыларның әйтүенә караганда, безнең болгарларга кадәр күчмә тормыш алып барган бабаларыбызның көнкүрешендә дә келәм билгеле урын тоткан. Кызыл балчыктан ясалган күп төрле табылдыклар Идел буе болгарларында да тукучылык һөнәренең нык таралган булуы турында сөйлиләр.

Казан татарларында туку станы һәрбер өйдә диярлек булган. Хатын-кызлар күп вакытларын шул стан янында уздырганнар, тукымалар, келәмнәр сукканнар, аларның бу хезмәтләрендә халыкның дөнья матурлыгын күзаллавы чагылган. Хәзер ул туку станнарын авыл өйләренең чардакларында гына табып була. Республикабызның кайбер авылларында бу борынгы һөнәрчелекнең осталары да очраштыргалый. Һәм шунысы куанычлы: алар бу борынгы эшне чын күңелдән бирелеп дәвам итәләр. Әйтик, Балтач районы Шеңшеңәр авылында яшәүче М. Хәйруллина бик күп туку алымнарын, аның борынгы серләрен белә, шакмаклы һәм буй юлы ысулы белән бизәкләнгән берсеннән-берсе матуррак паласлар суга. Мондый паласларны идәнгә җәяргә дә, диварга эләргә дә мөмкин. Алабугада яшәүче А. Дәүләтшина, татар орнаментларын файдаланып, традицион йон келәмнәр тукый. Аның хезмәтләре югары профессиональ осталык һәм тирән милли үзенчәлекләре белән аерылып торалар. Традицион бизәкле тукымалар, келәмнәр шәһәрләрдәге заманча квартираларга да, зур биналарга да бик ятышлы була алалар. Бу өлкәдә бигрәк тә Латвия, Литва, Гру-

зия, Украина, Казахстан, Молдавия рәссамнары һәм халык мастерлары зур эш башкаралар.

Татарстан рәссамнарының бүгенге иҗади эшчәнлеге тукымалардан зур картиналар — гобеленнар булдыру, бу мәһабәт хезмәтләрнең иркен залларга куелуы белән билгеләнә. Тукымадан паннолар эшләү республикабызда 40—50 нче елларда башлана. Зур бәйрәмнәрдә Казанның Ирек мәйданындагы трибуналарның милли келәмнәр һәм гобеленнар белән бизәлүе дә мәгълүм. 1939 елда Мәскәүдә уздырылган Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә Татарстан павильонының үзәк залына ефәк панно эленә. 50 нче еллардагы тукыма панноларның сәнгатьчә чишелеш үзенчәлеге турында П. Сперанскийның «Казан татарлары орнаментлары» дигән альбомындагы энҗе белән чигелгән гобелен сурәте буенча фикер йөртеп була. Панно уртасында — татар чигүләрә рухында эшләнгән чәчәкле орнамент белән каймап алынган Җиңү ордены. Ул әнә шундый үзенчәлекле булуы белән үзенә тартып тора.

60—70 нче елларда Татарстанда декоратив сәнгать белән интерьерны берләштерергә омтылган бер төркем рәссамнар барлыкка килә. Тукыма, тире ябыштырып эшләнгән, республикабыз тарихында сирәк очрый торган картиналар иҗат ителә. Шулай итеп, «Түбән Кама» совхозы культура йорты залын — 2×5 метр зурлыкта булган тукымадагы композиция, Брежнев шәһәрендәге 5-09 һәм 26-07 нче балалар бакчаларын төрле тукымалар ябыштыру юлы белән эшләнгән картиналар бизәп тора. Казан Яшьләр үзәгендә, Тукай-Кырлай авылы культура йортында һәм башка урыннарда сурәтле ефәк пәрдәләр эленгән.

Аппликация һәм ефәк пәрдәләрне бизәү өлкәсендә художник С. Кузьминых нәтиҗәле эшләп килә. Аның М. Җәлил әсәрләре тәэсирендә иҗат ителгән композицияләре, «Болгар мотивлары» дигән декоратив триптихы аеруча игътибарга лаек. А. Егоров әсәрләре, Р. Кругляковның тукымаларны ябыштыру юлы белән ясалган, халык иҗаты традицияләренә якын булган хезмәтләре шулай ук тамашачылар күңеленә хуш килә. М. Кальюранд тукып ясалмаган гобеленнар буенча тәҗрибәләр үткәрә. Билгеле, болар әле килечәктә олы юлга алып чыгачак сукмаклар кебек кенә.

Илебездә 60 нчы елларда ныклап үсеп киткән гобелен сәнгатенең республикабызда хәзер үз урыны бар. Бу сүзләрне раслау өчен, 1980 елда уздырылган «Зур Идел» күргәзмәсендә гобеленнар экспозициясе булуын искә төшерү дә җитә. Гобелен тукымага ясалган картиналардагы төсләр стихиясен, орнаментларны, сынлы сәнгать күренешләрен, композиция төрләрен һәм алымнарын ачып җибәрә. Рәссамнарны сәнгатьнең бу төре кулдан эшләнүе, тирә-юньне җанландыруы һәм кабатланмас булуы белән җәлеп итә.

Бу жанрга безнең республикада беренчеләрдән булып М. Килдебәкова мөрәҗәгать итә. «Зур Идел» күргәзмәсенә куелган «Музыкантлар» дигән беренче гобеленын ул 1964 елда иҗат итә. Казанда гобеленның профессиональ остаханәсен булдыру өчен, оештыру, фикердәшләр табу ягыннан байтак иҗади кыенлыклар кичерергә туры килә. Тора-бара шушы эш буенча рәссамнар М. Килдебәкова, А. Егоров, Г. Маликова, бераз соңрак Г. Шәрипова берләшәләр. Гобелен сәнгатенә үзләренең иҗат юлында шулай ук Р. Килдебәкова, В. Губаль еш мөрәҗәгать итәләр. Татарстанда бу сәнгать орнаменталь-декоратив башлангычы өстенлек итү белән аерылып тора.

Гобеленның Казан көнкүреш хезмәте күрсәтү йортында киң җәмәгатьчелек игътибарын үзенә тарткан беренче уңышлы тәҗрибәсе 1976 елда художниклар Рөстәм һәм Мария Килдебәковалар, Г. Маликова, А. Егоров, Г. Шәрипова тарафыннан эшләнде. 36 квадрат метрлы бу паннога куе кызыл һәм алтын-сары төсләр кушылмасы үзгә бер ямь биреп тора. Орнаментлы келәм татар халык иҗатына хас тантаналы милли бәйрәм рухын бирә.

Казанның бу өлкәдәге остаханәсе рәссамнары баштан ук бергәләп эшлиләр, техника һәм материаллар белән төрле тәҗрибәләр үткәрәләр. Аларның профессиональ осталыгы, эрудицияләре үскәннән-үсә бара. Бу үсеш Казан сәүдә үзәге ресторанындагы гобеленнан да күренә. Ул алгы бүлмәнең һәм икенче каттагы залларның архитектура үзенчәлекләрен истә тотып эшләнгән. Бу хезмәт А. Башмаков белән Г. Богородская иҗат иткән «Сәгать» дигән декоратив композицияне дә үз эченә ала. Бер стенада аерым ритмик элементларны ...тә иҗат ителгән дүрт гобелен урын алган.

Табигать күренешләрен шигъри һәм сәнгатьчә итеп тасвирлаган бу панноларның исемнәрен искә төшереп узыйк: «Айлы юл» (художнигы М. Килдебәкова), «Ай яктысы» (М. Килдебәкова, А. Егоров), «Салават күпере» һәм «Шәфәкъ» (А. Егоров). Аларның кайбер үзенчәлекләренә игътибар итик. Мәсәлән, «Салават күпере» иректе рәвештә салынып торган җепләр ярдәмендә иҗат ителгән. Ул җепләр акрынлап кына озынайганнан-озыная баралар. Мондый иҗади алым сурәтне яңгыр юган дигән тәэсир калдыра. Гобелен зәңгәр, күк һәм алтын-сары төсләр белән ясалган. Биредәге һәрбер хезмәт әнә шундый аерым үзенчәлеккә ия. Бары тик «Шәфәкъ» дигән төсле композициядә генә чама дигән төшенчәне онытып җибәрү сизелә.

Бер уйласаң, тимер-бетон һәм пыяладан төзелгән бүгенге биналарның архитектурасы үзеннән-үзе гобелен сорап тора. Килдебәковлар иҗат иткән «Чәчәкләр» исемле хезмәтне күргәч, ирексездән менә шулай уйлап куясың. Төзелеше буенча орнаменталь композиция караңгы, бертөрле диярлек фонда якты төсләрнең ритмик кабатланып баруына нигезләнә. Художниклар татар халык иҗатына хас булган сәнгать үзенчәлекләрен файдаланалар, гобеленның милли сәнгать әсәрләренә охшаш булуына басым ясыйлар. Бу — образлылыкны һәм тамашачыга тәэсир итү көчен арттыра. Гобеленның ачык аңлаешлы булуы композиция төзелешенең гадилегенә, орнаменталь мотивларның һәм төсләрнең ритмик бүленешенә бәйле. Ләкин безнең карашча, «Чәчәкләр» әсәренең авторлары бу жанрның сәнгать үзенчәлекләрен тулысынча ачып бетермәгәннәр. Чыннан да, Татарстан сәнгатенең яңа бер төре булган гобеленның милли йөзен тудыру буенча көн үзәгенә баскан мәсьәлә зур иҗади эзләнүләр таләп итә.

Бу өлкәдә махсус белемле булган А. Егоров хезмәтләрендә чын профессиональ осталык ярылып ята. Шуңа күрә дә аның 1978 елда иҗат ителгән 170—137 сантиметр зурлыктагы «Казанны акгвардиячеләрдән азат итү» дип аталган гобеленын сәнгать сөючеләр шундук яратып каршыладылар һәм 1980 елда «Зур Идел», 1981 елда «Советская Россия» күргәзмәләрендә дә лаеклы урынын тапты. Бу әсәр әле кыюсыз хезмәтләренең берсе булса да, художникның иҗат алымы һәм сәләте үзенчәлекләрен ачып бирде. Башка осталар шикелле ул да бертөрле эрләнгән җепләр белән эш итә. Аның башкалардан аерылып торган ягы — төсләрне сайлый белүендә, аларны горизонталь рәвештә урнаштыруында һәм һәрбер деталь турында сәнгатьчә фикер йөртүендә. Югарыда телгә алынган хезмәт — Кремль территориясендәге күренекле биналардан торган ритмик эзлеклектәге күп планлы композиция. Биредәге биналарга атка атланган кызылармеецларның байраклар җилфердәтеп, дошманнарны куып баруы хәрәкәт өстәп тора. Рәссам, кызыл төс белән куе зәңгәр төснең кушылуын файдаланып, гобеленның драматик яңгырашын тапкан, әсәрнең идеясен, революция темасын актив рәвештә ачып бирүгә ирешкән. Сюжетны аңлатуның турыдан-туры сөйләп бирү сыйфаты авторга вакыт, вакыйгалар һәм архитектура үзенчәлекләрен ачып салырга ярдәм иткән.

А. Егоров иҗат иткән гобеленнарның гаять образлы һәм тәэсир итүчән булуларының нигезе, әлбәттә, авторның озаклап эзләнүләре нәтиҗәсе. Ул барысыннан да элек сынлы сәнгать нигезләренә һәм тукымаларны булдыру техникасы үзенчәлекләренә таяна. Шуңа күрә рәссамның «Казанда Ленин бакчасы» дигән күп бизәкле композициягә мөрәҗәгать итүе бер дә очраклы хәл түгел. Билгеле, булачак әсәрнең эскизы гына сызылган әле. Аның төп максаты — башкалабызның бу гүзәл почмагын бөтен матурлыгы, шигърилеге белән ачып бирергә омтылу. Мондагы кешеләр һәм, гомумән, сюжет бик тормышчан булулары белән сине ышандыра. Автор үзен дулкынландырган ике мәсьәләне алга куя. Беренчесе — гәүдә тотыш характерларын аңлату, икенчесе — әсәр яссылыгында дулкынланып торган һава киңлеген иҗат итү. Беренче мәсьәләне ул башка хезмәтләрендә хәл итә дә башлаган иде инде. Дөресен генә әйткәндә, бу яңа әсәргә без күбрәк өмет багларга да хаклыбыз.

Казанның яңа никахлар сараендагы шактый зур күләмле (200×634 см) гобеленының эчтәлеге дә тәэсир итү көче белән ачыла. Әсәрнең композициясе фанфара сурәтләре ритмикасы буенча югарыга таба омтыла. Формасының мәһабәт булуы, кызгылт төсләр балкышы аңа нәкъ бу очрактагы тантаналы җылылык рухы өсти.

1981 елда Казанның чит ил белгечләре йортында урын алган «Тау ташкыннары» исемле гобеленның орнаменталь-декоратив булуы аңа үзгә бер юнәлеш бирә. Автор бу очракта сурәтнең җәмелдәп торуына күбрәк игътибар итә һәм теләгенә ирешә дә ала. А. Егоровның зур масштаблы әсәрләргә мөрәҗәгать итүе аның яңа иҗади эзләнүләргә этәрде. Рәсем һәм фонның үзара бәйләнеше, әсәрнең иркен структурасын ачып бирү нигезләре, аның интерьер белән ярашу мәсьәләләре көннән-көн катлаулана бара. Авторның бу яңа әсәрләрендәге төсле таплар һәм вак сызыкларның талгын кучешләр ритмикасы, һәр детальнең чын сәнгатьчә булуы, гобеленның йомшак фактуралылыгы... Биредә хәрәкәтләргә гаҗәп бай композиция әнә шулар ярдәмендә төзелгән. Сары, кызыл, зәңгәрсу, шәмәхә төсләр белән бәркеп бөрчекләр ясалган көмеш сыман гамма шатлыклы лирика итеп кабул ителә. Гомумән алганда, ул бинаның беренче катындагы холл киңлегенә бик килешеп тора. Икенче һәм өченче катларны бизәүдә шулай ук дивар келәмнәре төп урынны алып торалар. Алар «Күбәләкләр» (художнигы Г. Маликова) һәм «Декоратив» (М. Килдебәкова) дип аталалар. «Күбәләкләр» гобелены ирекле асимметрик композициядә эшләнгән. Әмма аның төсләр капма-каршылыгына корылган булуы ансамбль белән ярашмый һәм аның гармония тигезлеген боза. Икенче әсәрдәге кызыл, сары, кызгылт-көрән төсләр исә тантаналы рух биреп торалар.

М. Килдебәкова белән Г. Маликова иҗатында гобеленның җитлеге килгән орнаменталь-декоратив төре өстенлек итә. Мәсәлән, Г. Маликованың «Җәй» дип исемләнгән хезмәтендә күтәренке рух бирә торган якты көн чәчәкләр белән бизәлгән. Тукыма үзе дә нәкъ шундый ук дәртле алым белән сугылган. Г. Маликованың бу хезмәте «Зур Идел» (1980 ел), «Советская Россия» (1981) күргәзмәләренә куелганнан соң, Әлмәт нефтьчеләр Культура йортына куелды.

М. Килдебәкова үзенең иҗатында орнаментлар белән бизәүгә сынлы сәнгать чараларын кушып алып бару эшенә тугры булып калды. Аның хезмәтләреннән лирика, наз һәм профессиональ осталык ташып тора. «Гөлчәчәк», «Сабан туе» (1969), «Алтынчәч», «Очыгыз, күгәрченнәр» (1970) исемле әсәрләре Татарстан гобелены тарихына классика булып керде. Иҗат юлы башындагы сюжетлы композицияләрдән соң ул әсәрләрен орнаментлар белән бизәү этабына күчте. «Казан» санаториесы өчен 1982 елда эшләнгән «Иртә» гобелены моңа матур бер мисал булып тора ала. Монда чәчәкләр, ямь-яшел үләннәр янында ритмик эзлеклелек белән зуррак орнаменталь мотивлар бирелгән. Брежнев шәһәрендәге «Татарстан» кунакханәсенә эленгән «Яз» исемле гобеленда да шушы ук нигез ята. Монда кош сурәтләре булу халык иҗатындагыча милли тәэсир уята. Төсләрнең талгын күчеше, сабыр моң М. Килдебәкова иҗатының төп төсмерләре булып торалар.

Йомгак ясар алдыннан яшь сәнгатьнең үсү юлында иңкәнлеген билгеләп үтик. Киләчәк гобеленының йөзе аерым иҗат әһелләренә, мәгълүм милли үзенчәлекләргә бәйле булуын, моңа өстәп, тагын гобелен эчтәлегенең образлылыгы төп мәсьәләләрнең берсе икәнлеген искә төшерик һәм татар каләменнән башланган югары сәнгатьбезгә зур киләчәк телик!

# АРХЕОГРАФ ВӘЛИ ЗӘБИРОВ



Татар халкының катлаулы тарихы, уй-хыяллары теркәлеп калган бай кульъязма мирасны җыю, өйрәнү, матбугатта чыгару эше, мәгълүм булганча, XIX гасырның беренче чирегендә үк башланып китә. Атаклы мәгърифәтчеләр, тарихчылар И. Хәлфин, Г. Утыз-Имәни, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Р. Фәхретдинов, рус галимнәреннән К. Фукс, И. Березин, В. Вельяминов-Зернов, Р. Игнатьев, Н. Катанов һ. б. ларның бу өлкәдәге эшчәнлеге махсус тәкъдир ителүгә лаек. Шулай да кульъязма мирасны өйрәнүнең күп кенә проблемалары хәзергә кадәр тиешенчә яктыртылмаган һәм үзенең тикшерүчесен көтеп ята.

Көн тәртибендә торган шундый бурычларның берсе — кульъязма ядкарьләрне җыю һәм өйрәнүгә гомерләрен багышлаган шәхесләрнең эшчәнлеген өйрәнү. Махсус мәкаләләрдә, монографияләрдә исемнәре телгә алынган, хезмәтләре билгеләп үтелгән галимнәрдән тыш, киң җәмәгатьчелеккә бөтенләй үк диярлек билгеле булмаган фидакарьләр дә бар. Вәли Зәбиров — әнә шундыйларның берсе.

Ул 1898 елда Уральск шәһәрендә халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның апасы Газизә белән җизнәсе Габдрахман гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. Вәли яшьтән үк китап яратучан, бик тырыш бала булып үсә. Мәдрәсә белеменнән тыш ул Г. Тукайны укыткан учитель Әхмәтшадан өч ел русча сабак ала, шулай ук бухгалтерия курсларында да укый. Әнисе Газизә апаның истәлекләреннән күренгәнчә, кечкенә Вәлигә Г. Тукайдан да дәресләр алырга туры килгән [1].

В. Зәбиров яшьтән үк җәмәгать эшләренә катнашып китә. Революциягә кадәр Уральскида һәвәскәр спектакльләр куюда катнаша. Октябрь революциясен шатланып каршылаган Вәли 1919 елда большевиклар партиясе сафларына керә, кулына корал тотып Уральскины ак гвардиячеләрдән саклауда катнаша. Гражданнар сугышы беткәч, ул Уральскида партия органнарында эшли, казах совет көндәлек матбугатының нигез ташларын салышуда да үзеннән өлеш кертә.

Егерменче елларның ахырында В. Зәбиров Ташкентта Урта Азия Коммунистик университетында укый. ВКП(б) Үзәк Комитетының Урта Азия бюросы карары буенча ул 1930—1934 елларда Ленинградта, СССР Фәннәр академиясе аспирантурасында укый, бер үк вакытта Ленинград Тарих-археография институтында фәнни хезмәткәр булып эшли. Бу елларда да В. Зәбиров җәмәгать эшләрендә актив катнаша: фәнни хезмәткәрләр секциясенең, Коммунистик академиянең Ленинград бүлеге каршындагы «Көнчыгышны өйрәнүче марксистлар җәмгыяте»нең члены булып тора, СССР Фәннәр академиясенең Иҗтимагый фәннәр бүлеге учреждениеләре ассоциациясенең гыйльми секретаре вазифаларын башкара.

[1] Зәбирова Г. Тукай турында хәтердә калганнар.— «Азат хатын», 1961, 4 сан, 8 бит.

Кыска гына иҗат чорында Вәли Зәбиров башлыча төрки халыклар тарихын, аерым алганда татар тарихын өйрәнә. Аспирантурада укыган елларында ул Урта Азия һәм Казакстанда революцион хәрәкәт һәм җәдитчелек тарихын тикшерү белән шөгыльләнә, шулай ук XVIII гасыр казах ханлыкларының Россия белән сәүдә һәм дипломатик мөнәсәбәтләрен чагылдырган документаль чыганаклар җыентыгын (1933) матбугатта чыгаруда катнаша. Фәнни әдәбиятта югары бәя алган бу тарихи истәлекләр җыентыгы[1], мәгълүм булганча, совет чорында казах тарихы буенча чыккан хезмәтләрнең тәүгеләреннән иде, һәм ул әле дә үзенең фәнни әһәмиятен югалтмаган. «Патша Россиясенең Казакстандагы милли-колониаль политикасы» дигән проблема белән шөгыльләнгән хуплап, гомумән фәнни хезмәткәр һәм көнчыгышны өйрәнүче тарихчы буларак В. Зәбировның эшчәнлеген фәнни җитәкчесе атаклы галим, академик А. Самойлович уңай бәяли[2].

Ул елларда әле, билгеле ки, СССРда тарих фәне катлаулы чорын кичерә: марксистик-ленинчыл методологияне үзләштергән тарихчылар аз, ә рус булмаган халыкларда — бармак белән санарлык дәрәҗәдә генә. Революциягә кадәр «киләчәге перспективасыз» дип мөһер сугылган халыкларның, шул исәптән татар халкының да тарихын язу эшен яшь совет тарих фәне үз алдында торган мөһим бурычларның берсе итеп саный.

Татар тарихи чыганакларының азлыгы, билгеле булганнарының да әле системага салып өйрәнелмәве (дөрес, моның беренче үрнәкләрен без Г. Гобәйдуллин, Г. Сәгъди хезмәтләрендә күрәбез) бу эштә зур тоткарлык булып тора. В. Зәбиров нәкъ менә шушы эшкә алына. Тарих фәненең нигезе булган тарихи документларны тикшерә башлый. Ул беренчеләрдән булып 1773—1775 елларда Е. И. Пугачев җитәкчелегендә булган Бөек крестьяннар сугышына караган татарча документаль истәлекләрне өйрәнә һәм аларга фәнни классификация ясап махсус мәкалә бастыра[3]. Шул ук мәкаләдә ул әлеге документлар белән бергә сакланып калган хосусый актларга да кызыклы гына күзәтүләр ясый. В. Зәбиров Е. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышына караган татарча документларны русчага тәрҗемә итеп матбугатта чыгарырга әзерли, әмма бу хезмәт төрле сәбәпләр аркасында ул вакытларда басылмый кала.

Мәгълүм булганча, 20—30 нчы елларда 1773—1775 елгы Крестьяннар сугышының 150 еллык юбилее уңаеннан, бу азатлык көрәшенә багышланган күп кенә хезмәтләр дөнья күрә: «Пугачевщина» исемендә, рус телендәге документаль чыганакларның өч томлы җыентыгы басылып чыга, фәнни киңәшмәләр үткәрелә. Ленинградта үткәрелгән шундый киңәшмәләрнең берсендә (1933 елның 9—11 декабрендә) ясаган чыгышында В. Зәбиров, татар телендәге документларга нигезләнеп, рус булмаган халыкларның Крестьяннар сугышына катнашуының сәбәпләрен ачыклауга үзеннән өлеш кертә.

1934 елда В. Зәбиров татар кулъязмалары җыю буенча Тарих комиссиясе, Тарих-археография институты һәм Көнчыгышны өйрәнү институты тарафыннан Татарстанга оештырылган археографик экспедициягә җитәкчелек итә. Документаль чыганакларны җыю белән генә чикләнмичә, ул татар әдипләре һәм галимнәре Хәлфиннар, Г. Утыз-Имәни, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, шулай ук рус галимнәреннән Н. И. Ашмарин, Н. Ф. Катановларның да кулъязма мирасларын җыюны бурыч итеп куя. Шундый чыганаклардан Г. Тукайның ике хатын һәм Г. Зәбированың бөек шагыйрь турындагы истәлекләрен В. Зәбиров соңыннан «Совет әдәбияты» журналында бастырып та чыгарды.

Бу экспедиция баштагы план буенча бөтен Татарстан территориясен җирләргә тиеш булса да, үзенең эшен хәзерге Арча, Биектау, Балтач районнарында һәм Казанда

---

[1] Материалы по истории Узбекской, Таджикской и Туркменской ССР. Т. 1. Торговля с московским государством и международное положение Средней Азии в XVI—XVII вв. Л., 1933.

[2] СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге Көнчыгышны өйрәнүчеләр архивы, 152 фонд, 3 тасвирлама, 236 эш, 3—4 битләр. (Алга таба: Көнчыгышны өйрәнүчеләр архивы).

[3] Забиров В. Новые источники об участии национлов в пугачевщине.— «Проблемы источниковедения», Сб, 1, М.-Л., 1933, 22—24 битләр.

алып бара. Төрле кыенлыкларга карамастан, ике ай эшләү дәверендә 1203 кульязма, бер мең данә чамасы документаль чыганаклар, 1859 басма китап җыела һәм Ленинградка, Көнчыгышны өйрәнү институтына тапшырыла[1].

Кульязма истәлекләрне, документларны җыю гына түгел, фәнни җәмәгатьчелекне шул кыйммәтле ядкарьләр белән таныштыруга да В. Зәбиров зур игътибар бирә. СССР Фәннәр академиясенең 1934 елгы декабрь сессиясендә, ул Татарстанга оештырылган археографик экспедициянең эше һәм җыелган материаллары турында, доклад белән чыгыш ясый. Доклад академиклар И. Ю. Крачковский, А. Н. Самойлович, Ф. И. Щербатской, Н. И. Конрадларның, профессор И. Н. Бороздинның уңай бәясен ала[2].

Шулай ук В. Зәбиров татар кульязмаларын җыю эшен тагын да дәвам иттерүне, Татарстанда гына түгел, татарлар яшәгән башка өлкәләргә чыгуны да алга куя. Җыелган язма истәлекләрне өйрәнү өчен Ленинградтагы Көнчыгышны өйрәнү институтында махсус кабинет оештыру мәсьәләсен дә күтәреп чыга. 1936 елда СССР Фәннәр академиясе президиумының карары буенча бу кабинет оештырыла башласа да, күп сәбәпләр аркасында әлеге ният тормышка ашмый кала.

Кульязмалар җыю эшен В. Зәбиров 1935 елда да дәвам иттерә. Бу юлы ул Әстерхан—Уральск—Оренбург—Троицк—Орск маршруты буйлап сәфәргә чыга. Археографик экспедиция Әстерханда, мәсәлән, кыска гына вакыт эчендә 200 гә якын кульязма, 700 гә якын иске басма китап җыя. Болардан тыш табылган меңнәрчә документ җирле архивка тапшырыла. Әстерханда җыелган китаплар арасыннан, тегәлрәге Габдрахман Ниязовның китаплары арасында, Г. Тукайның 1909 елның 11 декабрендә Пирмөхәммәт Ниязовка язган хаты табыла.

Бөтен эзләнү һәм табышларына йомгак ясый торган зур хезмәтләр язу эше белән мәшгуль булып, зур иҗат планнары белән яшәгән бер чорда галимнең тормышы фаҗигале рәвештә өзелә (1941 ел).

Җыеп әйткәндә, В. Зәбиров кульязма мирасыбызны җыюда, саклап калуда зур хезмәт куйган, яшь совет тарих фәненең нигез ташларын салуда катнашкан. Тарихчы галимнәребез яңа буыны (М. Госманов, С. Алишев, Ф. Фасеев һ. б.) аның гыйльми хезмәтләреннән иҗади файдаланып, аның эшен алга таба дәвам иттеләр.

В. Зәбировның гыйльми мирасы һәм ул җыйган кульязмалар фонды — фәнебез өчен гаять бай хәзинә булып тора һәм ул җентекләп өйрәнелергә лаеклы.

**Җәүдәт МИҢНУЛЛИН.**

# ХАЛЫККА АҢ-БЕЛЕМ БИРҮ ЮЛЫНДА

Казан университетында XIX гасырның икенче яртысында культура үсешенә зур өлеш керткән фәнни мәктәпләр һәм юнәлешләр барлыкка килә. Шул фәнни мәктәпләрнең берсе булган Казан лингвистика мәктәбе Идел буе халыкларының тел белеме, мәгариф һәм культура үсешенә зур йогынты ясый.

Казан лингвистика мәктәбе вәкилләре тел белеме белән генә чикләнеп калмыйлар, иҗтимагый-политик хәрәкәтнең актуаль проблемалары, рус булмаган халыклар, бигрәк тә татарлар арасында мәгариф һәм культура үсеше белән якыннан кызыксыналар. Фәнни мәктәп галимнәре педагогика һәм психология, әдәбият һәм әдәбият белеме, логика, эстетика, философия һ. б. мәсьәләләрне игътибар үзәгендә тоталар. Казан лингвистика мәктәбе вәкилләренең фәнни диапазоны шактый киң була. Бу мәктәп татар халкының мәгарифен һәм культурасын үстерүдә нинди роль уйнаган — бүген сүз менә шул хакта.

Казан лингвистика мәктәбе күренекле тел галиме һәм җәмәгать эшлеклесе И. А. Бодуэн де Куртенэ тирәсендә оешып китә. Анда В. В. Радлов, В. А. Богородицкий, танылган педагог А. И. Анастасиев, профессорлар Н. В. Крушевский, С. И. Булич, А. И. Александров, А. С. Архангельский һ. б. күп кенә галимнәр дә була.

---

[1] Көнчыгышны өйрәнүчеләр архивы, 111 фонд, 1 тасвирлама, 6 эш, 2—3 бит. Забиров В. А. Предварительное сообщение о работе Археографической экспедиции Академии наук.— «Исторический сборник», М.-Л., 1935, № 4, 269—282 битләр.

[2] СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, 53 фонд, 4 тасвирлама, 1 эш, 77 бит.

Шушы үзәкнең йогынтысы астында М. Мәхмүдов, Ш. Әхмеров, М. Иманаев, Ш. Таһиров, И. Терегулов кебек алдынгы татар галимнәре һәм педагоглары үсеп чыга. Соңрак, совет чорында эшләгән М. Корбангалиев, М. Фазлуллин, Г. Шәраф, Г. Сәгъди, Х. Бәдигый, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров кебек галимнәр иҗатында да әлеге мәктәпнең йогынтысы сизелә. Алар фәнни мәктәпнең тюркология тармагын күтәреп алалар һәм яңа якты сәхифәләр өстиләр.

Мәктәпнең иң күренекле вәкилләре рус булмаган халыкларны агарту идеясен яклап чыгалар, милли мәктәп проблемасына җитди игътибар биреп, анда укытуның үзенчәлекләрен басым ясап күрсәтәләр. Мәсәлән, «Татар мәгарифе мәсьәләсе» дигән махсус мәкаләсендә А. И. Анастасиев татарлар өчен дөньяви мәктәпләр булдыру мәсьәләсен күтәреп чыга. Шул ук вакытта мәдрәсәләрдә укыту-тәрбия процессының куелышын кискен тәнкыйть итә. Хәлбуки, һәр татар авылында мәдрәсә булуын һәм халыкның белемгә омтылуын ул уңай күренеш итеп карый.

1871 елда Казан уку округында татар, башкорт, кыргыз мәктәпләре инспекторы дигән яңа хезмәт урыны булдырыла. Татар халкының җанлы сөйләмнәрен өйрәнгән, гореф-гадәтләрен белгән кеше буларак ул урынга академик В. В. Радлов билгеләнә. Әлбәттә, рус булмаган халыкларны укытуның максаты аларга киң мәгънәдә аңбелем бирү түгел, ә бәлки аларны руслаштыру була.

Әмма үз чорының прогрессив кешесе булган В. В. Радлов үзенчә фикер йөртә, патша хөкүмәтенең установкаларына тәнкыйть күзлегеннән карый. Аерым алганда, ул рус булмаган халыкларга рус телен укытуда иреклелек принцибын яклый.

В. В. Радловка мәгърифәтчелек эшендә К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Ш. Әхмеров, М. Мәхмүдов кебек алдынгы татар педагоглары зур ярдәм күрсәтә. Радлов инспектор вазифаларын ун елдан артыграк башкара, бу елларга алдынгы фәнни-педагогик фикернең үтеп керүенә булышлык итә. 1872—1873 елларда алдынгы татар педагогларының ярдәме белән ул беренче рус-татар училищелары һәм мәдрәсәләрдә рус класслары ачылуына ирешә. Казанда рус-татар училищесының беренче укытучысы К. Насыйри, ә «Госмания» мәдрәсәсе каршында ачылган беренче рус классының укытучысы Ш. Әхмеров була.

В. В. Радловның актив катнашында (К. Насыйри белән бергә) 1870 елның 26 мартында чыгарылган хөкүмәт карары нигезендә төп предметы рус теле булган берничә татар мәктәбе ачыла.

Атаклы җәмәгать эшлеклесе һәм мәгърифәтче В. В. Радлов Казанда һәм Уфада укытучылар мәктәпләре (учительская школа) ачтыруда зур роль уйный. Татар һәм башкорт халыкларының культурасын үстерүдә, халык мәгарифе эшенә бирелгән яшь милли интеллигенция формалаштыруда бу мәктәпләрнең әһәмияте бик зур була. Татарлардан беренче революционерлар да шунда тәрбияләнеп чыга.

Казан лингвистика мәктәбе вәкилләре татар педагогларына кичектергесез педагогик проблемаларны хәл итүдә ярдәм күрсәтәләр. Казан мәктәбендә укытучы булып эшләгән Ш. Таһиров шушы лингвистик мәктәп вәкилләренең социаль-педагогик һәм методик йогынтысы астында була. 1881 елда Казан укытучылар мәктәбенә инспектор итеп университетта И. А. Бодуэн де Куртенэ янында зур әзерлек үткән Ш. Әхмеров билгеләнә. Соңрак ул уналты ел буена шушы мәктәпкә җитәкчелек итә, татар мәктәпләренә укытучылар әзерләү өчен вакытын да, көчен дә кызганмый. Рус-татар училищеларының һәм мәдрәсәләр каршындагы рус классларының татарлар өчен чын мәгариф һәм культура учагы икәнлеген ул яхшы аңлый. Ул мәктәптә укучылар өчен санитария-гигиена шартларын яхшырту буенча күп тырышлык куя, укытучылар мәктәбенең материаль хәлен яхшырту турында даими кайгыртып тора, аны гимназияләр кызыгып карарлык итә.

Татарлардан Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов, Г. Коләхметов кебек беренче профессиональ революционерлар әнә шуннан чыга, мәктәпнең Казан округында марксизм-ленинизм теориясен таратуда өлеше зур була. 1905—1907 еллар революциясе чорында мәктәпнең пропагандистик роле бигрәк тә арта.

Халкыбызның Ш. Әхмеров, М. Иманаев, Ш. Таһиров, И. Терегулов кебек алдынгы уллары Казан лингвистика мәктәбе вәкилләре белән кулга-кул тотынып эшләләр, бу галимнәрнең хезмәтләре һәм карашлары аларга күп нәрсә бирә. Мәсәлән, Ш. Әхмеров рус мәктәпләре өчен язылган дәреслекләрнең рус-татар мәктәбендә

куллану өчен эчтәлеге дә, башка яклары да ярамавын әйтә, татар укучылары өчен В. В. Радлов язган дәреслекләрне бердәнбер һәм алыштыргысыз итеп саный. Шуның белән бергә яңа, камилрәк дәреслекләр һәм кулланмалар да кирәклегенә игътибар юнәлдерә. Ш. Әхмеров Казан лингвистика мәктәбе белән иң тыгыз бәйләнештә тора, аның идеяләрен пропагандалый, файдалы киңәшләр, рекомендацияләр ала. И. А. Бодуэн де Куртенэ аны югары бәяли, университеттагы иң сәләтле шәкертләреннән берсе итеп саный.

Казан лингвистика мәктәбе вәкилләре татар журналистикасы үсешенә дә сизелерлек йогынты ясыйлар. Мәсәлән, Ш. Әхмеров, Ш. Иманаев һәм башкалар А. И. Анастасиев чыгара торган «Городской и сельский учитель» журналының актив корреспондентлары булалар. Пропаганда чыганагы буларак, бу журнал Казан ягы халкының киң катламнарына прогрессив иҗтимагый-педагогик идеяләр алып килә. Мәсәлән, Ш. Әхмеров шушы журналда басылган «Казан мөселманнары» дигән мәкаләсендә татарларның зур үсешкә сәләтле булуы турындагы идеяне яклап чыга, шуның белән рус булмаган халыкларның тулы бәяле булмавы турындагы великодержавный шовинистик карашларны фаш итә («Городской и сельский учитель», Казан, 1897, 72 бит).

Архив мәгълүматларыннан күренгәнчә, Казан лингвистика мәктәбе галимнәре белән Ибраһим Терегулов (1852—1921) һәм Шакирҗан Таһиров та (1858—1918) зур дуслык бәйләнешендә торалар. Алар да үз-үзләрен татар мәгърифәте эшенә, укытучылар әзерләүгә һәм яшь буынны тәрбияләүгә багышлыйлар. Казан университетында эшләгән алдынгы рус педагогларыннан алар күп нәрсәгә өйрәнәләр, иҗтимагый фикер, табигать фәннәре, сәнгать өлкәсендә дә фәнни белемнәр бирү өстендә эшлиләр. Алар дөньяны төрле яклап танып-белү юлы белән татар халкын милли чикләнгәнлектән алып чыгарга омтылалар.

И. А. Бодуэн де Куртенэ Терегуловны үз чорының белемле кешесе итеп саный, аны җәмәгать эшчәнлегенә тартырга тырыша. Мәсәлән, 1905 ел революциясе көннәрендә ул аны Петербургка аз санлы халыклар вәкилләренең съездына чакыра. Әмма Терегулов анда бара алмый кала. Моннан тыш Бодуэн де Куртенэ аңа киңәшләр, консультацияләр биреп, төрле ярдәмлекләр җибәреп тора.

В. В. Радлов та И. Терегулов белән Ш. Таһировка карата яхшы мөнәсәбәттә була, аларның педагогик карашларына югары бәя бирә. Мәсәлән, 1878 елда ул И. Терегуловны Казан укытучылар мәктәбендә табигать фәннәре укытучысы итеп раслату хәстәрен күрә. Аның ярдәме белән Ш. Таһиров 1884 елда шул ук мәктәптә рәсем һәм матур язу буенча укытучы булып эшли башлый. Нәкъ менә В. В. Радлов Таһировны осталыгын арттыру өчен реаль училищега, рәссам Х. Г. Пашковский янына индивидуаль дәресләр алырга җибәрә.

И. Терегулов һәм Ш. Таһиров марксист революционерлар түгел, әмма алар бөтен гомерләрен һәм энергияләрен татар яшьләренә алдынгы фәнни белемнәр бирүгә багышлыйлар, яшьләрне җәмгыять төзелеше турында уйлануга этәрәләр. Алар прогрессив рус педагогларының йогынтысын үзләре тою белән бергә, шәкертләрен дә демократик идеалларга тугрылык, кеше бәхете өчен көрәш рухында тәрбиялиләр. Аларның иҗтимагый-педагогик эшчәнлегенең зур пропагандистик һәм тәрбияви әһәмияте бар.

XIX гасырның 50 елларында Казан лингвистика мәктәбе формаль яктан караганда эшләүдән туктый. Бодуэн де Куртенэ Казаннан Петербургка киткәч, аның вәкилләре түгәрәк утырышларына йөрми башлыйлар. Әмма бу мәктәп үсеше белән хәзерге заман арасында бәйләүче буын булган принциплар, идеяләр һәм традицияләр кала. Алар совет галимнәре хезмәтләрендә яңа интерпретация ала һәм практикага үтә. 30—50 нче елларда шушы мәктәпнең прогрессив традицияләрендә Казанда М. Корбангалиев, Г. Шәрәф, М. Фазлуллин, Е. Бахмутова, Г. Алпаров, Р. Газизов кебек галим һәм педагоглар тәрбияләнә.

Казан галимнәренең яңа төркеме үз фәнни эшчәнлеген марксистик-ленинчыл методология нигезендә кора, лингвистика мәктәбенең уңай традицияләрен дәвам иттерә.

**ЗИННУР ШӘРӘФЕТДИНОВ.**

## Гамил Афзал

●

«Бездән булмас» диеп фараз кыла
Салам түбә, каен кыртәләр.
Ерактагы кояш җылы була,
Пигамбәрне читтән көтәләр.

●

Син гади Саттар,
Мин гади Җаббармын.
Син мине якла,
Мин сине яклармын.

Син мине макта,
Мин сине мактармын:
Син даһи Саттар,
Мин даһи Җаббармын.

●

Күрсәтмәләр көтеп торыйм микән,
Әллә рульне үзем борыйм микән?

Алай итсәм болай булыр микән,
Болай итсәм кулай булыр микән?

Шик-шөбһәләр тулы гомер итәм,
Җае чыгар диеп фикер йөртәм.

Пошмый гына симереп ятар өчен
...Күк капусы ачылганын көтәм.

●

Минем кулга кулай иде тимер көрәк.
«Юк, иптәшләр, миңа шагыйрь булу кирәк!»
Китап-фәлән караштырдым сирәк-мирәк.
Акыл да юк, белем дә юк, һөнәр дә юк,
Алтмыш ел алдашып йөрим көлемсерәп...

●

Ил эш көтте, хатын акча көтте,
Эш уңмады, план тулмады.
Буш докладлар сөйләп гомер үтте,
Рәтле кеше булып булмады.
Кулдан тотып хатын артка типте...
Мораль-фәлән укып тормады.

●

Дан аласың, Баш буласың килә,
Кыяфәт шәп синең.
Трибунага мен дә, доклад сөйлә:
«Мин һәм Дөнья...» диген.

## Бер ялагайга

Түрәләргә тәлинкә тот,
чәчең белән җир себер,
Әләкче бул, йомышка йөр —
файда итмәс берсе бер.

Шымчылык, ваклык, түбәнлек
карьераң тирәсендә,
Кол булып тугансың, энем,
кол булып үләрсең дә.

## ЯЗУЧЫЛАР — УРАК ӨСТЕНДӘ

Август аенда республикабыз әдипләренең күпчелеге иген язмышы хәл ителгән җирдә — республикабыз районнарында иҗади командировкаларда булып, игенчеләр алдында чыгышлар ясадылар, язылган әсәрләр геройларының тормыш-көнкүрешләре, фидакарь хезмәтләре белән таныштылар. Язучы Гариф Ахунов Арчада, шагыйрьләр Самат Шакир, Гөлшат Зәйнашева, Мөдәррис Әгъләмов Чүпрәле районында, Мәхмүт Хөсәен Актаныш, Рәшит Гәрәй Минзәлә, Рәфкать Кәрами Сарман, Барлас Камалов, Роза Хәлиуллина, Роберт Әхмәтҗановлар Мамадыш, Ринат Мөхәммәдиев Актаныш, Флүн Мусин Мөслим районнарында булдылар һәм республикабыз матбугатында бүгенге авылның актуаль проблемаларын яктырткан публицистик мәкаләләре белән чыгыш ясадылар.

## ИҖАТКА УҢАЙ БӘЯ

РСФСР Язучылар союзында язучы Шамил Рәкыйповның иҗаты тикшерелде.

РСФСР Язучылар союзының хәрби-художество әдәбияты Советы председателе урынбасары, философия фәннәре докторы Ю. Б. Лукин, язучы И. В. Черных, Советлар Союзы Герое язучы А. Л. Кожевников һәм тәнкыйтьче Ф. Мусин аның иҗатына уңай бәя бирделәр.

## Ш. БАБИЧКА МЕМОРИАЛЬ ТАКТА

Июнь азагында күренекле татар һәм башкорт шагыйре Шәехзадә Бабичның туган авылы Башкорт АССРның Дүртөйле районы Әсән авылында шагыйрь хөрмәтенә мемориаль такта ачу тантанасы булды. Аны кереш сүз белән «Әсән» колхозының партком секретаре Дамир Хәмзин ачты. Ул мемориаль тактаны ачу хокукын Ш. Бабичның яшьтәше һәм балалык дусты Шакир бабай Сабировка һәм шагыйрьнең бертуган сеңелесе Фәсәхәт Бабичевага тапшырды. Аннары Әсән урта мәктәбе укытучысы Ганс Хәкимов тантанада катнашучыларны шагыйрьнең кыскача тормыш һәм иҗат юлы белән таныштырды. Кунаклардан — башкорт шагыйрьләре Равил Бикбаев һәм Йосыф Гәрәй Ш. Бабичның татар һәм башкорт әдәбиятында Г. Тукай һәм М. Гафурилар кебек сүнмәс йолдыз булуын билгеләп үттеләр, үзләренең шигырьләрен укыдылар.

Тантанада шулай ук халык депутатларының Дүртөйле район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары Камил Гарипов, Әсән урта мәктәбе укучысы Зөлфия Исламова, шушы ук мәктәп укытучысы Фәнүз Фатыйхов, журналист Вил Казыйханов һәм Әсән колхозы председателе Наил Садыйковлар чыгыш ясады.

Соңыннан Дүртөйле район Культура сараеның үзешчән артистлары чыгышы булды.

Соңгы өч елда шушындый ук мемориаль такталар районның Чишмә авылында татар шагыйре Зыя Мансур һәм Дүртөйле поселогында башкорт шагыйре Бәдрүш Мокамай хөрмәтенә куелды.

## УКУЧЫЛАР ЯНЫНДА

Алабуга дәүләт педагогия институтында язучылар белән очрашу матур традициягә керде. Июнь башында институтка тагын бер кадерле кунак — язучы Әмирхан Еники килеп китте. Ул студентлар, укытучылар һәм галимнәр белән очрашты.

Язучы очрашуда катнашучыларны иҗат процессының үзенчәлекләре белән таныштырды, әсәр өстендә ничек эшләве турында сөйләде. Ул С. Сәйдәшев, Һ. Такташ кебек күренекле эшлекләребез турындагы истәлекләре белән уртаклашты.

Соңыннан Ә. Еники күп санлы сорауларга җавап бирде. Ул «Гөләндәм туташ хатирәсе» әсәрен язуы тарихына тукталып, матур әдәбиятта Салих Сәйдәшев образы турында кызыклы гына фикерләр әйтте, әсәрнең иҗат ителү процессына тукталды.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

1 августта Әлмәт язучылар оешмасының киңәйтелгән җыелышы булды. КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы карарлары яктылыгында Әлмәт язучылар оешмасының бурычлары турында оешманың җаваплы секретаре Әхәт Гаффар сөйләде.

Язучылар Шамил Бикчурин, Энҗе Мөэминова, Әдип Маликов, Роберт Рәкыйпов үз чыгышларында язучылар оешмасы һәм, аерым алганда, һәр язучы алдында торган конкрет бурычларга тукталдылар.

Заманның һәр проблемасы, киеренке сулышы, тыныч хезмәтнең һәм тынычлык өчен көрәшнең аерылгысыз бердәмлегә бөтен катлаулылыгы белән производство коллективлары тормышында чагыла. Шуңа күрә эшчеләр һәм авыл хезмәт ияләре белән аралашу язучының иҗатын тормыш дөреслеге, халыкчанлык рухы һәм публицистик кайнарлык белән сугара. Шуны истә тотып, Әлмәт язучылары колхоз-совхозлар белән элемтәне тагын да көчәйтергә кирәк дигән карарга килде.

Әлмәт язучылар оешмасы районның «Кичү» совхозы белән хезмәттәшлек килешүе төзегән иде. Иҗатчылар десантының иң беренчесе шушы совхоз хезмәтчәннәре янына оештырылды.

## РОМАНДА — ТАТАРСТАН НЕФТЬЧЕЛӘРЕ

Мәскәүнең «Современник» китап нәшриятында язучы Шамил Бикчуринның «Тирән катлам» романы басылып чыкты. Бу әсәрдә якташларыбызның Түбән өлкәсендә нефть һәм газ ятмаларын үзләштерүдәге фидакарь хезмәтләре истә калырлык катлаулы образлар аша сурәтләнә.

Романны русчага язучы Юрий Сбитнев тәрҗемә иткән. Ул үзе төп Себер кешесе, геолог буларак гомерен андагы җир асты байлыкларын ачуга багышлаган, күп кенә хикәяләр, повестьлар, романнар авторы. Китап 50 000 данәдә чыгарылган.

## КОЛ ГАЛИ УРАМЫ

ТАССР Министрлар Советының 8 сентябрь карары белән, Казандагы урамнарның берсенә болгар-татар поэзиясенә нигез салган шагыйрь Кол Гали исеме бирелде. Башкалабызның генераль планы буенча бу урам Горкидагы 11 нче микрорайонның көньяк-көнчыгыш читеннән алып 10—14 нче микрорайоннарның көньяк читенә кадәр сузылачак.

Кол Галинең исемен мәңгеләштерү бөек шагыйрьнең туына 800 ел һәм «Кыйссаи Йосыф» поэмасының язылуына 750 ел тулу белән бәйле.

Брежнев йортлар төзү комбинаты яшьләре һәм комсомоллары Татарстан атом электр станциясен төзүдә актив катнашалар. Автомобильчеләр шәһәрен салуда эшләүчеләр үзләренең ял көннәрендә Кама Аланына барып өмәләр уздыру гадәтен башлап җибәрделәр. Бу өмәләрдә көндәлек эш нормалары ике-өч мәртәбә арттырып үтәлә, шул ук вакытта яшь төзүчеләргә тәҗрибәле төзүчеләрнең осталыгы үрнәк итеп күрсәтелә. Өмәләр күп төрле милләт яшьләрен тагын да ныграк дуслаштыруга да ярдәм итә.

* * *

Брежнев язучылар оешмасы Татарстан атом электр станциясен һәм Кама Аланын төзүчеләр белән тыгыз элемтәдә яши. Мәсәлән, язучы Газиз Кашапов биредәге төзелеш мәйданында беренче көннәрдән үк еш була. Хәзер ул Кама Аланын төзүчеләрнең тормышыннан «Исәнме, Калатау!» дигән яңа әсәрен тәмамлап килә. Күптән түгел генә биредә Брежнев язучылары булып киттеләр. Алардан Альберт Сафин очерк язу өчен материал туплады, ә әдәбиятны пропагандалау бюросының Брежневтагы хезмәткәре, яшь шагыйрь һәм тәнкыйтьче Мансур Сафин беренче йортларны салучылар каршында үзенең шигырьләрен укыды.

* * *

«Камгэсэнергострой» берләшмәсенең Брежнев шәһәрендәге «Энергетик» Культура сарае каршындагы үзешчән сәнгать коллективлары Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр янында еш булалар. Төзүчеләр халык биюләре ансамбльләрен, халык уен кораллары оркестрын, «Ләйсән» вокаль ансамбле чыгышларын һәрвакыт яратып каршылыйлар, яшь композитор И. Закиров язган көйләрне, үзешчән җырчылар Г. Сабирова, С. Мәҗитова, Ф. Кадыйрова һәм рус халык җырларын Л. Дергачева башкаруында зур дулкынлану белән тыңлыйлар.

# «СТУДЕНТЛАР ҖЫРЫ»

70 нче елларда Татарстан сынлы сәнгате илебезнең төрле югары уку йортларын тәмамлаган иҗат кешеләре исәбенә тагын да баеп китте. Алар арасында Валерий Скобеев баштан ук үзенең талантлы рәссам икәнен исбат итте. Ә соләтен камилләштерүгә исә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Муса Җәлил исемендәге Татарстан комсомолы премиясе лауреаты рәссам В. Н. Скобеев югары профессиональ әзерлеге һәм даими киеренке иҗат эшчәнлеге нәтиҗәсендә иреште.

Рәссам нинди генә хезмәткә тотынса да, һәрвакыт илебезнең бүгенге көне, тарихны булдыручы кешеләр һәм киләчәк турында тирәнтен уйлана. Бигрәк тә хезмәт темасына мөрәҗәгать иткәндә, художникның иҗат мөмкинлекләре тагын да ачылып, яктырып китә. В. Скобеевны аеруча кеше, күңел түрендәге хис һәм фикерләр байлыгы кызыксындыра. Ул әнә шул халәт-күренешләрне шигъри итеп тасвирлап, романтик образлар тудыра, әйләнә-тирәгә җан өрә. Шундый рухтагы «Юл», «Кама өстендә акчарлаклар», «Комсомол-яшьләр» кебек картиналар авторны танылган рәссамнар белән бер рәткә куя.

«Зур Идел-80» дигән күргәзмәдә урын алган «Студентлар жыры» исемле әсәрендә рәссам заман ритмнарын, студент отрядларының хезмәт ялкынын тасвирлау эшенә алына. Һәм сынлы сәнгатьтә бөек төзелешләрне тудыруның яңа бер үрнәге — үзенең ихласлыгы, яңалыгы белән күңелләрне җәлеп итәрдәй әсәр күз алдына килеп баса.

...Студентларның дәртле җыры иртәнге авыл тынлыгын уята. Күтәренке рух, балкып торган яшь йөзләр, төз, көчле гәүдә төзелешләре... Аларның бердәм хәрәкәт итү омтылышыннан яшьлек ялкыны ташып тора. Бөтен дөнья шушы яшьләр кулында, һәм аларның хисаплап бетерә алмаслык мөмкинлекләре бар. Моң зәңгәр күк биеклегенә ашкына, офыкларны киңәйтеп, туган җирнең иксез-чиксез киңлекләренә тарала, бәхет, тынычлык, хезмәт җырына әйләнә.

Бу картинаны караганда, яңгыравык җырның үзен ишеткәндәй буласың. Рәссам моңа бигрәк тә әсәрнең ритмик төзелешенә дәртле аһәңлелек бирү юлы белән ирешә. Ул студентларны тыгыз бер төркемгә туплый, аларны бөтен буйлары белән гәүдәләндерми. Нәтиҗәдә моң киңлегенә урын мул кала. Очсыз-кырыйсыз күккә омтылган көрәкләр, төзелеш сызыклары, зәвык белән уйланылган төсләр байлыгы әсәргә канатлы җиңеллек, музыкаль рух өстиләр.

В. Скобеев хезмәтләренең һәрбер сызыгындагы фикер һәм хис тулылыгы, төсләр үзенчәлеге төрледән-төрле кешеләрне үзенә тартып тора. Аларда саф күңел һәм эчке киеренкелек ярылып ята.

**Д. САДЫЙКОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык артисткасы Зилә Сөнгатуллина.

**Рөстәм Мансуров слайдлары.**

# «Казан утлары» 1984 елда

Татар совет әдәбиятының иң күренекле әсәрләре укучыларыбызга иң элек «Казан утлары» аша барып ирешә. СССР һәм РСФСР Дәүләт премияләре лауреатлары да, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары да үзләренең әсәрләрен беренче булып журнал битләрендә бастырдылар. «Казан утлары»нда басылып чыкканнан соң ул әсәрләр әлеге югары бүләкләргә лаек булдылар. Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлилнең ерак Европа илләрен гизеп кайткан атаклы «Моабит дәфтәре» дә «Казан утлары» аша бөтен дөньяга танылды. Бу традиция дәвам итә.

«Почет билгесе» орденлы «Казан утлары» бүген дә чорыбыз белән бер сафта атлый. Ул халкыбыз тормышына торган саен ныграк якыная. Журнал битләрендә иң яхшы очеркларга «Авыл офыклары» конкурсы бара. «Бүгенге проза: геройлар, проблемалар» исемле дискуссия дәвам итә. Анда күренекле язучылар, тәнкыйтьчеләр генә түгел, журнал укучылар үзләре дә актив катнаша. Быел Татарстан атом электр станциясендә «Казан утлары»ның әдәби посты оештырылды.

1984 елда да «Казан утлары» үзенең укучыларын яңа романнар, мажаралы повестьлар, үзешчәннәр өчен яңа пьесалар, яңа җырлар, авыл кешеләренә багышланган очерклар, язучылар, артистлар, рәссамнар, композиторлар турында мәкаләләр, шигъри әсәрләр, укучыларның хатлары белән таныштырып барачак. Алар арасында, мәсәлән, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торгайлар кайтыр» романы, Чиләбедә яшәүче язучы Рөстәм Вәлиевнең Тукай турындагы яңа романы, Әмирхан Еникинең «Соңгы китабы» (өченче кисәк) бар. Г. Бәширов, С. Хәким, А. Шамов, Н. Дәүли, Г. Ахунов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Н. Фәттах һ. б. әдипләр журнал битләрендә үзләренең яңа әсәрләре белән катнашачаклар. Ел дәвамында татар халкының килеп чыгышы, гореф-гадәтләре, культурабыз тарихына кагылышлы материаллар да басылачак. Шулай ук күренекле әдипләрнең, галимнәрнең архивларыннан яңа публикацияләргә, М. Җәлил, Г. Ибраһимов, Х. Туфан турындагы истәлекләргә киң урын биреләчәк. «Бер сорауга — бер җавап» рубрикасында язучылар, композиторлар, рәссамнар, артистлар, фән эшлеклеләре редакциянең һәм укучыларның төрле сорауларына җавап бирәчәкләр.

Укучыларыбыз игътибар иткәндер инде: быелгы беренче саннан безнең журнал яңача бизәлештә чыга башлады. Алдагы елларда да тышлыкның беренче бите Татарстан рәссамнарының киң билгеле картиналарыннан фоторепродукцияләр белән бизәләчәк. Шуңа күрә журналның һәр саны сынлы сәнгать белән кызыксынучылар өчен дә көтеп алынган кунак булыр дип ышанабыз. Ә инде тышлыкның дүртенче бите театр һәм эстрада сәнгатенә багышлана. Анда укучыларыбыз яратып карый торган спектакльләрнең төсле фотолары, күренекле артистларның, җырчыларның, сәнгать эшлеклеләренең портретлары булачак. Журналның эчке битләрендә роман-повестьларга, шигъри әсәрләргә рәссамнар тарафыннан иллюстрацияләр дә ясалачак.

«Казан утлары» Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Аның индексы 73210. Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекчәләрендә язылырга мөмкин.

Язылу кампаниясенең 1983 елның 31 октябрендә тәмамлануын хәтерегезгә төшерәбез. 1 ноябрьдан соң язылганда журнал 1984 елның февраленнән башлап һәм аннан соңгы айларда гына киләчәк.

Язылу бәясе бер елга 10 сум 80 тиен, 6 айга — 5 сум 40 тиен, 3 айга — 2 сум 70 тиен.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)